**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман планын раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Урманга кагылышлы мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларга үзгәрешләр керү белән бәйле рәвештә, Урман хуҗалыгы федераль агентлыгының үзгәрешләр кертелгән Татарстан Республикасы урман планы проектына уңай бәяләмә бирүен исәпкә алып, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман планын раслау турында» 2009 елның 16 мартындагы ПУ-146 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектының урман планын әзерләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 24 апрелендәге 246 номерлы карары белән» сүзләрен «Урман хуҗалыгы федераль агентлыгының «Россия Федерациясе субъекты урман планының үрнәк формасын һәм составын, аны әзерләү тәртибен раслау турында» 2011 елның 5 октябрендәге 423 номерлы боерыгы белән» сүзләренә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасы Урман планын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ / ГОМУМИ БҮЛЕК / АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2015 ел, 23 октябрь
№ ПУ-1014

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның « 23 » октябрендәге
ПУ-1014 номерлы Указына
кушымта

Татарстан Республикасы

# УРМАН ПЛАНЫ

# ЭЧТӘЛЕК

**КЕРЕШ**........................................................................................ 3
**I БҮЛЕК. УРМАННАР ТОРЫШЫҺӘМ АЛАРДАН ФАЙДАЛАНУ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ**............................................. 7
1.1. Урманнарның торышы һәм урманнар торышы үзгәрү, урманчылыклар һәм урман-парклар буенча аларның максатчан билгеләнеше турында, шулай ук урман үсемлекләре зоналары һәм урман районнары хакында........................................................... 7
1.2. Татарстан Республикасы территориясендә урманнардан файдалануны, аларны саклауны, яклауны һәм торгызуны социаль-икътисадый бәяләү............................................................... 72
1.3. Татарстан Республикасының урманлы районнары буенча урман хасил итүче төп агач төрләрен кисү еллары..................................... 181
1.4. Урман чималлары потенциалына һәм аннан файдалануга характеристика, җәмгыятьнең урманнарга һәм урман ресурсларына ихтыяҗын билгеләү..................................................... 185
**II БҮЛЕК. УРМАННАРДАН ФАЙДАЛАНУНЫҢ, АЛАРНЫ САКЛАУНЫҢ ҺӘМ ТОРГЫЗУНЫҢ ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘРЕ**............ 228
2.1. Урманнар торышын яхшыртуның күләме һәм сыйфаты буенча максатчан күрсәткечләр....................................................................... 230
2.2. Урманнарны планлаштырылган үзләштерү зоналарына бүлү ( шул исәптән алардан файдалану төрләре һәм үзләштерү интенсивлыгы буенча)...................................................................... 236
2.3. Урманнардан файдалану күрсәткечләре(урманнардан файдалану төрләре буенча планлаштырылган күләмне дә кертеп) ................... 243
2.4. Урманнардан нәтиҗәле файдалануэшчәнлегенең төп юнәлешләре һәм аны гамәлгә ашыручаралары исемлеге................ 245
2.5. Урманнарны саклау, яклау, торгызу һәм урман үрчетү өлкәсендә эшчәнлекнең төп юнәлешләре һәм чаралар исемлеге............................... 263
2.6. Урман һәм урман эшкәртү инфраструктурасы үсеше күрсәткечләре............................................................................................ 275
2.7. Урманнарга антропоген, рекреакцион һәм техноген йөкләнешне киметүнең максатчан күрсәткечләре....................................................... 278
**IIIБҮЛЕК. УРМАННАРНЫ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН ҮЗЛӘШТЕРҮ ЧАРАЛАРЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУНЫҢ ИКЪТИСАДЫЙ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ**.................................. 284
3.1. Урманнарны үзләштерүне планлаштыру чараларын финанс-икътисадый нигезләү........................................................................ 284
3.2. Урманнарны планлаштырылган үзләштерү чараларын үтәү нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләре............................................... 291
**Татарстан Республикасы Урман планы буенча нәтиҗәләр**........................................................................................ 293

# КЕРЕШ

Татарстан Республикасы Урман планыРоссия Федерациясе Урман кодексының 86 статьясына таянып Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы белән «Рослесинфорг»ФДУП«Поволжский леспроект» арасында төзелгән 2008 елның 18 февралендәге 66 номерлы дәүләт контракты нигезендә (теркәлү номеры – 241002.08.001564-г) әзерләнде.

Урман планы Татарстан Республикасының урман планлаштыру документы булып тора һәм 2009 елдан 2018 елга кадәр урман тармагын үстерүне күздә тота.

Урман планында каралган чараларны үтәү республиканың урман ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануны яхшыртырга мөмкинлек бирәчәк.

Заказчының почта адресы:
420124, Казан ш., Ямашев пр., 37 А йорт,
ИНН/КПП 1660098481/166001001.

Эшләр башкаручы: «Рослесинфорг» ФГУП «Поволжский леспроект» филиалы Казан экспедициясе.

Юридик адрес:
«Рослесинфорг»ФДУП
113035, Мәскәү ш., Садовническая ур., 56/49 йорт, 1нче төзелеш,
ОГРН 1037739350835.

Почта адресы:
Филиал ФГУП «Рослесинфорг» «Поволжский леспроект»: Россия, 603024, Түбән Новгород ш., Полтавская ур., 22 нче йорт.
ИНН/КПП 7705028865/526202001.
Тел. (831) 218-92-73, факс (831) 218-97-61.
E-mail: pnv@lesproekt.nnov.ru, ofice_nnov@list.ru.
Филиал директоры Петухов Н. В.
Казан экспедициясе: 420087, Казан ш.,Гадел Кутуй ур., – 155 А йорт,
Тел. (843) 272-31-83, 272-17-81, 272-33-92.
Экспедиция директоры Юсыпов А.Я.

Урман планын әзерләүдә предприятиеләрне реформалаштыру үзәге катнашты(ОАНО «ЦПР»).

Почта адресы:
420111, Татарстан Республикасы, Казан, Островский ур., 23 нче йорт, лит. 1.
ОГРН 1031621001125.
Үзәк директоры Дрошнева В.Н.

Проектлауның норматив-техник базасы һәм мәгълүмати нигезен түбәндәге документлар тәшкил итте:

1. Россия Федерациясе закон актлары.
2. Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары.

3. Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгы актлары.

4. Урман хуҗалыгы федераль агентлыгы боерыклары һәм хатлары.

5. Татарстан Республикасы закон актлары.

6. Татарстан АССР урман хуҗалыгын оештыру һәм үстерүнең төп нигезләмәләре, 1980 ел.

7. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2001-2007 еллардагы еллык хисаплары.

8. Татарстан Республикасы урман хуҗалыклары буенча 2001-2006 елларда «Поволжский леспроект»ФДУП урман төзелеше материаллары буенча төзелгән урман хуҗалыгын оештыру һәм алып бару проектлары.

9. 2005 елның 27 декабрендәге 133-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2005 – 2010 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасы.

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәр чорга кластерлы алым нигезендә Татарстан Республикасы җитештерүче көчләрен үстерү һәм урнаштыру программасын раслау турында» 2008 елның 22 октябрендәге 763 номерлы карары.

Урман планы аны үтәүнең административ регламентациясен таләп иткәнгә күрә, һәр бүлектә куелган бурычларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм сроклары билгеләнде.

Татарстан Республикасы Урман планы 2009 елның 1 гыйнварыннан2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

2010 елның 29 октябрендәге 441 номерлы дәүләт контракты нигезендә әлеге Урман планына үзгәрешләр һәм өстәмәләр әзерләнде:

- «Россия Федерациясенең урман үсемлекләре зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урман районнары исемлеген раслау турында» 2011 елның 9 мартындагы 61 номерлы Россия Урман хуҗалыгы министрлыгы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы урман фонды җирләре территорияләрен бүлүгә (1 нче кушымта);

- «Россия Федерациясенең аерым закон актларына һәм Россия Федерациясе Урман кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 16 июнендәге 232 номерлы Россия урман хуҗалыгы министрлыгы боерыгы нигезендә һәм «Татарстан Республикасының Нурлат урманчылыгы территориясендә урманнарны кыйммәтле урманнарга, файдалану урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2010 елның 5 октябрендәге 372 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 14 мартындагы 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә урман фонды җирләре территорияләрен максатчан билгеләнеш һәм урманны яклау категорияләре буенча бүлүгә;

- «Россия Федерациясе Урман кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына һәм «Аучылык һәм аның ресурсларын саклау, Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»2009 елның 14 мартындагы 32-ФЗ номерлы Федераль закон

нигезендә урманнарның төрләре һәм алардан файдалану күләмнәре исемлегенә;

- «Россия урман хуҗалыгы министрлыгының 2008 елның 19 февралендәге 37 номерлы боерыгына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»Россия урман хуҗалыгы министрлыгының 2008 елның 6 октябрендәге 283 номерлы боерыгына;

- «Татарстан Республикасы территориясендә урманчылыклар санын билгеләү һәм аларның чикләрен күрсәтү турында»Федераль урман хуҗалыгы агентлыгының 2010 елның 17 октябрендәге 320 номерлыбоерыгына үзгәрешләр кертү турында»Россия урман хуҗалыгы министрлыгының 2010 елның 19 июлендәге 280 номерлы боерыгына;

- «Россия Федерациясенең аерым закон актларына һәм Россия Федерациясе Урман кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 16 июнендәге 232 номерлы урман хуҗалыгы федераль агентлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 16 маендагы 179 номерлы Россия урман хуҗалыгы министрлыгы боерыгына;

- урманнарны саклау, яклау, торгызу һәм алардан файдалану буенча планлаштырыла торган чараларга;

- хайваннар дөньясыннан аучылык максатларында файдалану өчен территорияләр һәм акваторияләр бирү турында;

- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджет системасына түләүләр җыю күләмнәренә;

- арендаторлар тарафыннан урманнардан файдалану һәм урман хуҗалыгы чараларын үткәрү, торглар буенча күрсәткеч күләмнәренә;

-гражданнарның үз ихтыяҗлары, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен «Урманчылык» ДБУ буенча арендаторларның еллар буенча агач әзерләү күләмнәрен бүлүгә;

- урман төзү эшләренең планлаштырыла торган күләмнәренә һәм аларны үткәрү чыгымнарына;

- картографик материалларга;

- закон чыгару актларындагы сылтамаларга;

- урман законнарының үтәлешенә контрольне тәэмин итү һәм урманнар белән идарә итү структурасына;

- Татарстан Республикасы урман сәнәгать комплексының планлы үсешенә;

- урманнарны планлы үзләштерү буенча финанс-икътисадый нигезләүгә һәм икътисадый нәтиҗәлелекне билгеләүгә;

- урман саклау һәм янгынга каршы чараларның планлаштырыла торган күләмнәренә.

Үзгәрешләрәзерләгән оешма турында белешмәләр.

Татарстан Республикасы Урман планына үзгәреш «Рослесинфорг» ФДУПның 2009 елның 10 ноябрендәге 103 номерлы боерыгы белән расланган Казан филиалы турындагы нигезләмәгә таянып эш итүче «Рослесинфорг» ФДУПның Казан филиалы тарафыннан әзерләнде.

Почта адресы:
420087, Казан шәһәре, Гадел Кутуй – 155 А йорт,
тел. (843) 272-31-83, 272-17-81, 272-33-92.
ИНН/КПП 7705028865/166032001.
E-mail: lesproekt@inbox.ru.

2013 елда әлеге Урман планына 2012 елның 25 декабрендәге 815 номерлы дәүләт контракты белән түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр әзерләнде:

- «Россия Федерациясе субъекты Урман планының үрнәк рәвешен һәм составын раслау турында» 2015 елның 5 октябрендәге Россия урман хуҗалыгы министрлыгы боерыгы нигезендә Урман планы структурасына;
- Татарстан Республикасы урман фонды җирләре территорияләрен урман үсемлекләре зоналарына һәм урман районнарына бүлүгә;
- урман законнары үтәлешенә контрольне тәэмин итү һәм урманнар белән идарә итү структурасына;
- урман фонды җирләре территорияләрен максатчан билгеләнеше һәм урманнарны яклау категорияләре буенча бүлүгә;
- урманнардан файдалану чараларының планлаштырыла торган күләмнәренә;
- урман торгызу чараларының планлаштырыла торган чараларына;
- урманнарны саклау һәм янгынга каршы чараларның планлаштырыла торган күләмнәренә;
- урман кисү исәп-хисабына;
- Урман планына үзгәрешләр әзерләнгәнгә кадәрге елларда Урман планы чараларын гамәлгә ашыру белешмәләренә;
- дәүләт урман реестры белешмәләре буенча 2013 елның 1 гыйнварына булган мәгълүматка;
- картографик материалларга;
- урман төзелеше эшләренең планлаштырыла торган күләмнәренә һәм аларны үткәрү чыгымнарына;
- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджет системасына түләүләр җыю күләмнәренә;
- закон чыгару актларына сылтамаларга һәм закон чыгару актлары исемлегенә.

Татарстан Республикасы Урман планына үзгәрешләр «Ульяновсклеспроект»җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан әзерләнде. Адресы: Ульяновск шәһәре, Орлов ур., 21 А йорт, тел. (8422) 72-79-29.

# IБҮЛЕК. УРМАННАРТОРЫШЫҺӘМ АЛАРДАНФАЙДАЛАНУ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ

## 1.1. Урманнарның торышы һәм урманнар торышы үзгәрү, урманчылыклар буенча аларның максатчан билгеләнеше турында, шулай ук урман үсемлекләре зоналары һәм урман районнары хакында

### 1.1.1. Урман планын әзерләү чорына кадәр 5 елда урманнар торышы үзгәрүне сан һәм сыйфат ягыннан бәяләү

Татарстан Республикасы (алга таба – ТР) Россия Европа өлешенең көнчыгышында ике зур елга Идел һәм Кама елгалары тоташкан жирдә 47° һәм 54°, көнчыгыш озынлыкның 54° һәм 57°күрсәткечләре арасында уңайлы географик урын билэп тора. (1.1.1.1 рәс.).

Республика төньякта Киров өлкәсе һәм Удмурт Республиксы, көнчыгышта Башкортостан Республикасы, көнбатышта Чувашия Республикасы, көньякта Ульяновск, Самара һәм Оренбург өлкәләре, төньяк-көнбатышта Марий Эл Республикасы белән чиктәш. Татарстан Республикасы территориясенең озынлыгы төньяктан көньякка кадәр – 265 -290 км, көнбатыштан көнчыгышка 425-460 км тәшкил итә. Татарстан Республикасы мәйданы 67,8 мең км$^2$ яисә Россия Федерациясе территориясенең 0,4 % ы һәм Идел буе федераль округы территориясенең 7% билэп тора. Республика 43 муниципаль районга бүленгән, республика әһәмиятендәге 14 шәһәрдән (Казан, Чаллы, Түбән Кама, Азнакай, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, БуаАлабуга, Зәй, Зеленодольск, Лениногорск, Нурлат, Чистай), 9район буйсынуындагы шәһәрдән (Әгерже, Арча, Иннополис, Лаеш, Мамадыш, Менделеевск, Минзәлә, Болгар, Тәтеш), 18шәһәр тибындагы поселоктан һәм район үзәге булып торган 12 авылдан тора. 2004 ел башына халык саны 3,8 млн. кеше, шул исәптән эшкә сәләтлеләр саны 2,4 млн. кеше тәшкил итте. Республиканың башкаласы – Казан шәһәре, Россия башкаласы Мәскәүдән 797 км көнчыгышта урнашкан.

Татарстан Республикасы территориясе диңгез өслегеннән 170-180 м биеклектәге калкулыклы тигезлектә урнашкан. Идел һәм Кама елгалары үзәннәре Татарстан жирләрен 3 төбәккә бүлә: Кама алды, Кама аръягы, Идел алды. Идел алды Идел буе калкулыгының төньяк-көнчыгыш өлешендә республиканың көньяк-көнбатышында урнашкан. Зөя елгасы Идел алдының уртасы буйлап көньяктан төньякка таба ага, аны ике өлешкә бүлә.




1.1.1.1. рәс. Татарстан Республикасының географик урнашуы

Кама алды Кама елгасыннан төньякта урнашкан һәм Казансу, Нократ, Мишә һәм Ык елгалары бассейннарын биләп тора. Кама аръягы Кама елгасыннан көньяк-көнчыгышта урнашкан һәм көньяк-көнчыгышка таба күтәрелеп бара торган сөзәк калкулыклы тигезлектән гыйбарәт. Кама аръягы уртасы буенча агучы Чишмә елгасы Кама аръягын ике өлешкә көнбатышка һәм көнчыгыш өлешләргә бүлә. Татарстан Республикасында иң биек калкулык (381 м) – Бөгелмә калкулыгы Кама аръягыныңкөнчыгышында урнашкан.Уйсулыклар урыны-урыны белән Идел һәм Кама елгасы үзәннәре Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычы сулары белән тулган. Татарстан өчен минималь биеклек (53 м) билгесе Куйбышев сусаклагычы биеклегеннән чыгып тасвирлана. Шулай итеп, рельефның бөтен өслеге биеклегенең гомуми амплитудасы 328 м. (381-53 м) тәшкил итә. Үзәннәр һәм калкулыклар рельефның эрозия, карст, яр ясалу һәм башка процесслар нәтиҗәсендә барлыкка килгән кечерәк формадагы комплекслар белән яргаланган. Территориянең төп өлеше югары Пермь системасына караган Казан һәм татар яруслары агач токымнары; көньяк-көнбатыш югары юра һәм акбур системалары утырмалары; елгаларның борынгы үзәннәре неоген һәм дүртенчел системалар утырмалары катламнарыннан гыйбарәт. Елга үзәннәре һәм су бүлемтекләре чокырлар һәм балкалар белән бүленгән.

Чокырлар эрозиясе барлыкка килүгә урманнарны бетерү һәм җирләрне сөрү аркасында антропоген эшчәнлек йогынты ясады. Чокырларның мәйданы 41,8 км$^2$, аларның озынлыгы 27,3 мең км тәшкил итә. Ел саен республикада чокырлар артканлыктан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге 1 мең гектар җир юкка чыга. Эрозия йогынтысындагы җирләр мәйданы артып тора.

Пермь карбонат-сульфат токымнарында карст процесслары арта. Карстлы чокырлар, казаннар һәм мәгарәләр Идел елгасы үзәненә таралган һәм, Тәтеш шәһәренең төньягы буйлап,аның уң як ярына сибелгән. Карстлы күренешләр Зәй һәм Ык елгалары бассейннарына да хас. Югары Пермь системасына караган акбур, юра һәм татар ярусы акбур һәм балчыклы елга үзәннәренең текә ярларына таралган. Идел, Кама, Нократ елгаларының комлы яр буйларында һәм башка елгаларда эол рельефы очрый, ул неоплейстоцен коры салкын климаты шартларында барлыкка килгән.

Республика туфрагы төрлелеге белән аерылып тора – көрән урманлы һәм көлсу туфрактан алып республиканың көньягында кара туфракның төрле төрләре очрый. Өч туфраклы район билгеләнә.

Төньяк туфрак районы (Кама алды). Төп туфрак фонды – ачык-соры урман туфрагы (29%) һәм кара- көлсу туфрак (21%).

Көнбатыш туфрак районы (Идел алды). Урман туфрагының соры һәм куе соры төсләре өстенлек итә.

Көньяк-көнчыгыш туфрак районы. (Кама аръягы). Кара туфрак, кара-көлсу һәм соры урман туфраклары өстенлек итә.

Татарстан Республикасы сулыкларының гомуми мәйданы барлык территориянең 5,2% ын тәшкил итә. Республика территориясе буйлап эре

елгалардан Идел (республика эчендә 177 км), Кама (380 км), Агыйдел (50 км), Нократ (60 км) аларның кушылдыклары Зөя, Ык, Иж, Мишә, Чишмә һәм башка кече һәм урта елгалар ага. Елгаларның һәм кече сулыкларның гомуми озынлыгы 19,6 мең км. Урта һәм кече елгалар 9965 берәмлек исәпләнелә. Иң эре сусаклагычлар – Куйбышев(республика чикләрендә – 3120 км$^{2)}$ һәм Түбән Кама сусаклагычлары (1084 км$^{2)}$.

Татарстан Республикасы территориясеҗәй көне җылы һәм кыш көне уртача салкын төрдәге урта киңлекләрдәге континенталь климат белән характерлана.

Республика чикләрендә климат аерымлыгы чагыштырмача зур түгел, җылы чорның озынлыгы ($0^0$ С югарырак температура белән) территория буенча 198-209 көн, салкын һава торышы белән 156-167 көн тәшкил итә. Республика территориясе диңгез һәм океан йогынтыларыннан ерак булганга күрә, республика территориясе һава массаларының көнбатыш юнәлешләренең йомшак булуы һәм климатның континентальлеге көчәюгә бәйле булуы белән характерлана, бу күчеш чорларының кыскарып, кыш вакытының озынлыгында чагыла. Җәй башында һәм ахырында уртача тәүлеклек температураның $+5^0$ тан артуы яз көне апрель урталарына, ә көз көне октябрьнең икенче яртысына туры килә. Беренче кырау 10-28 сентябрьгә, сонгы кырау 10-21 майларга туры килә. + $10^0$ тан арткан температура майның беренче декадасына, көз көне сентябрьнең икенче декадасына туры килә. Кырау төшми торган вакыт гадәттә 106-150 көнгә сузыла. Җилләр күбрәк көньяк-көнбатыштан, көньяк - көнчыгыштан исә. Уртача күрсәткечләрдән тайпылышлар 30-40 көнгә җитәргә мөмкин.

Тулаем алганда, табигать-климат шартлары урман үсемлекләре өчен унай, ләкин аерым елларда уртача күрсәткечләрдән шактый аермалар очрый – орлыкларның тишелеп чыгару һәм үсеше өчен тискәре шартлар – корылык чорлары, көзге һәм язгы кыраулар вегитация чорын шактый кыскарта.

Территория буенча явым-төшем чагыштырмача тигез бүленә, еллык сумма 460-540 мм тәшкил итә. Явым-төшемнең 65-75% җылы чорга туры килә. Явым-төшемнең максималь күләме июль аена (51-65 мм), минималь күләме февральгә (21-27 мм) туры килә. Тотрыклы кар катламы ноябрьнең икенче декадасында туплана һәм апрельнең беренче яртысында ул эри.

Урман фондының гомуми мәйданы һәм аңа керми торган башка категорияләрдәге җирләрдә урнашкан урманнарның гомуми мәйданы 2013 елның 1 гыйнварына 1271,1 мең га яисә Татарстан Республикасы территориясенең 17,5% тәшкил итте.

Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасындагы урман мөнәсәбәтләре өлкәсендәге органы – Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы. Аның карамагында урман фонды җирләрендә урнашкан 1236,4 мең га яисә республика урманнарының гомуми мәйданының 97,3% тора.

Башка категорияләрдәге җирләрдә урнашкан урманнарга Россия Федерациясе Оборона министрлыгы җирләрендәге урманнар (Суслонгер хәрби урманчылыгы) – 1,7 мен га яисә республикадагы барлык урманнарның

0,1%, торак пунктлардагы җирләрдә урнашкан урманнар («Аккош күле» урман паркы), Буа һәм Зеленодольск шәһәрләре урманнары) – 3,9 мең га (0,3%), башка категорияләрдәге җирләрдә урнашкан урманнар – 0,6 мең га (0,04%) һәм табигатьне саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт карамагындагы махсус сакланыла торган табигать территорияләре җирләрендә урнашкан урманнар («Түбән Кама» милли паркы, Идел-Кама дәүләт табигать тыюлыгы) – 28,6 мең га (яисә2,2%) урманнар керә. Бу Идел-Кама дәүләт табигать тыюлыгы 10,1 мең га һәм «Түбән Кама» милли паркы» 18,5 мең га мәйдан биләп тора.

Татарстан аз урманлы регионга керә. Урманнар беркайчан да Татарстан Республикасы территориясенең күп өлешен капламаган (50%ка кадәр).XIX гасырдан башлап XX гасыр уртасына кадәр урманнарның мәйданы кыскартылган, аннары аның үсеше тотрыкланган, ә соңгы елларда урманнарның арту тенденциясе күзәтелә.

Республиканың аерым районнары буенча урман күрсәткече төрлечә һәм ул физик-географик, климатик, туфрак шартларына, табигать күренешләренә һәм кешенең хуҗалык эшчәнлегенә бәйле. Территориянең урманлы булуы, ягъни гомуми территориянең урман үсемлекләре белән каплану мәйданы Татарстан Республикасы буенча уртача 17,5%, районнар буенча зур аерма белән 2,9% Чүпрәле районында– 41,3% Нурлат районында күзәтелә.

2007 елның 1 гыйнварына республикада 30 урман хуҗалыгы һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 1 техникумы, «Түбән Кама» Милли паркы, Идел-Камадәүләт табигать тыюлыгы, «Аккош күле» урман паркыһәм Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Суслонгерхәрбиурманчылыгы» эш итте.

Россия урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә урманчылыклар санын һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2008 елның 17 октябрендәге 320 номерлы боерыгы (2010 елның 19 июлендәге ред.) нигезендә элеккеге урман хуҗалыгы чикләрендә Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы урманнардан 30 урманчылык оешты (рәс. 1.1.1.2). Күрсәтелгән боерыкка кертелгән Россия урман хуҗалыгының 2013 елның 5 сентябрендәге 256 номерлы боерыгы нигезендә элеккеге Лубян урман-техник көллияте чикләрендә участок урманчылыкларына бүлмичә, Алабуга урманчылыгының Лубян участок урманчылыгы базасында яңа урманчылык төзү күздә тотыла («Лубян урманчылыгы»).




1.1.1.2. рәс. Урманчылыкларның урнашуы

1.1.1.1таблица

**Урманчылыкларның урнашкан урыны,**
**аларның мәйданы һәм территорияләрнең урман каплаганлыгы**

| № т/с | Муниципаль район яисә шәһәр | Мун.-аль район мәйд. мең га | Урманчы-лык | Урманнар урнашкан җирләр, га | | | | | | Ур-ман белән кап-лану, % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Барлы-гы | Урман фонды җирлә-рендәге урман-нар | ООПТ җир-ләрен-дәге урман нар | Обо-рона җир-ләрен-дәге урман-нар | Җир-лек-ләр җир-лә-рен-дәге ур-ман-нар | Башка кате-гория-ләрдә-ге җир-ләрдә-ге урман-нар | |
| 1 | Әгерҗе | 179,7 | Әгерҗе | 45346 | 45346 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 45346 | 45346 | | | | | 23,5 |
| 2 | Азнакай | 214,8 | Азнакай | 36743 | 35743 | | | | | |
| | | | Бөгелмә | 8157 | 8157 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 44900 | 44900 | | | | | 19,0 |
| 3. | Аксубай | 143,9 | Аксубай | 25837 | 25837 | | | | | |
| | | | Биләр | 5607 | 5607 | | | | | |
| | | | Нурлат | 954 | 954 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 32398 | 32398 | | | | | 21,9 |
| 4. | Актаныш | 203,4 | Минзәлә | 19528 | 19528 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 19528 | 19528 | | | | | 6,9 |
| 5. | Алексеевск | 207,4 | Биләр | 24782 | 24782 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 24782 | 24782 | | | | | 11,3 |
| 6. | Әлки | 172,7 | Әлки | 33392 | 33392 | | | | | |
| | | | Биләр | 847 | 847 | | | | | |
| | | | Болгар | 2839 | 2839 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 37078 | 37078 | | | | | 21,0 |
| 7. | Әлмәт | 242,8 | Әлмәт | 40177 | 40177 | | | | | |
| | | | Зәй | 4227 | 4227 | | | | | |
| | | | Кәләй | 32797 | 32797 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 77201 | 76527 | | | | | 28,2 |
| 8. | Апас | 104,8 | Буа | 4581 | 4581 | | | | | |
| | | | Кайбыч | 3371 | 3371 | | | | | |
| | | | Идел буе | 1085 | 1085 | | | | | |
| | | | Тәтеш | 51 | 51 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 9088 | 9088 | | | | | 8,5 |
| 9. | Арча | 184,4 | Ача | 20075 | 20075 | | | | | |
| | | | Саба | 3381 | 3381 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 23456 | 23456 | | | | | 11,9 |
| 10. | Әтнә | 68,1 | Арча | 912 | 912 | | | | | |
| | | | Ислейтар | 1897 | 1897 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 2809 | 2809 | | | | | 3,9 |
| 11. | Баулы | 121,4 | Баулы | 19821 | 19821 | | | | | |

| № т/с | Муниципаль район яисә шәһәр | Мун.-аль район мәйд. мең га | Урманчылык | Урманнар урнашкан жирләр, га | | | | | | Урман белән каплану, % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Барлыгы | Урман фонды жирләрендәге урманнар | ООПТ жирләрендәге урманнар | Оборона җирләрендәге урманнар | Җирлекләр җирләрендәге урманнар | Башка категорияләрдәге җирләрдәге урманнар | |
| | | | Бөгелмә | 3635 | 3616 | | | | 19 | |
| | | | Барлыгы | 23456 | 23437 | | | | 19 | 17,9 |
| 12. | Балтач | 109,5 | Арча | 11216 | 11216 | | | | | |
| | | | Саба | 1210 | 1210 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 12426 | 12426 | | | | | 10,6 |
| 13. | Бөгелмә | 140,5 | Әлмәт | 2717 | 2717 | | | | | |
| | | | Баулы | 3616 | 3616 | | | | | |
| | | | Бөгелмә | 23022 | 23022 | | | | | |
| | | | Ленино-горск | 960 | 960 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 30315 | 30315 | | | | | 19,7 |
| 14. | Буа | 153,0 | Буа | 10305 | 10305 | | | | | |
| | | | Тәтеш | 147 | 147 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 10452 | 9884 | | | | | 6,6 |
| 15. | Югары Ослан | 130,3 | Идел буе | 24879 | 24879 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 24879 | 24879 | | | | | 18,4 |
| 16. | Биектау | 166,7 | Исләйтар | 15285 | 15285 | | | | | |
| | | | Шәһәр яны | 14238 | 13838 | | | | 400 | |
| | | | Суслонгерхәрби урманчылыгы | 186 | | | 186 | | | |
| | | | Саба | 857 | 857 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 30566 | 30566 | | 186 | | 400 | 17,6 |
| 17. | Чүпрәле | 103,0 | Буа | 3051 | 3051 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 3051 | 3051 | | | | | 2,9 |
| 18. | Алабуга | 136,0 | Алабуга | 11474 | 11474 | | | | | |
| | | | «Түбән Кама»НП | 8999 | | 8999 | | | | |
| | | | Барлыгы | 20473 | 11474 | 8999 | | | | 13,4 |
| 19. | Зәй | 184,2 | Әлмәт | 7272 | 7272 | | | | | |
| | | | Зәй | 14300 | 14300 | | | | | |
| | | | Кәләй | 5515 | 5515 | | | | | |
| | | | Түбән Кама | 27895 | 27895 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 54982 | 54468 | | | | | 28,5 |
| 20. | Зеленодольск | 140,2 | Зеленодольск | 26418 | 26356 | | | | 62 | |
| | | | Кайбыч | 4827 | 4827 | | | | | |
| | | | Идел буе | 1397 | 1397 | | | | | |

| № т/с | Муниципаль район яисә шәһәр | Мун.-аль район мәйд. мең га | Урманчылык | Урманнар урнашкан җирләр, га | | | | | | Ур-ман белән кап-лану, % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Барлы-гы | Урман фонды җирлә-рендәге урман-нар | ООПТ җир-ләрен-дәге урман нар | Обо-рона җир-ләрен-дәге урман-нар | Җир-лек-ләр җир-лә-рен-дәге ур-ман-нар | Башка кате-гория-ләрдә-ге җир-ләрдә-ге урман-нар | |
| | | | Идел-Кама тыюлыгы | 5921 | | 5921 | | | | |
| | | | Барлыгы | 38563 | 32508 | 5921 | | | 62 | 25,8 |
| 21. | Кайбыч | 99,5 | Кайбыч | 17093 | 17093 | | | | | |
| | | | Идел буе | 680 | 680 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 17773 | 17773 | | | | | 17,2 |
| 22. | Кама Тамагы | 119,9 | Тәтеш | 10921 | 10921 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 10921 | 10921 | | | | | 8,3 |
| 23. | Кукмара | 149,2 | Лубян | 12966 | 12966 | | | | | |
| | | | Кызыл-Йолдыз | 17 | 17 | | | | | |
| | | | Мамадыш | 1496 | 1496 | | | | | |
| | | | Саба | 17972 | 17972 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 32451 | 32422 | | | | | 19,7 |
| 24. | Лаеш | 216,9 | Лаеш | 19732 | 19732 | | | | | |
| | | | Идел-Кама тыюлыгы | 4170 | | 4170 | | | | |
| | | | Шәһәр яны | 11043 | 10867 | | | 85 | 73 | |
| | | | Суслонгерхәрби урманчылы-гы | 545 | | | 545 | | | |
| | | | Барлыгы | 35490 | 30599 | 4170 | 545 | 85 | 73 | 15,3 |
| 25. | Лениногорск | 181,1 | Бөгелмә | 246 | 246 | | | | | |
| | | | Ленино-горск | 51877 | 51877 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 52123 | 52123 | | | | | 26,9 |
| 26. | Мамадыш | 260,1 | Кама | 18431 | 18431 | | | | | |
| | | | Кызыл-Йолдыз | 11996 | 11996 | | | | | |
| | | | Мамадыш | 46276 | 46276 | | | | | |
| | | | Саба | 576 | 576 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 77279 | 77279 | | | | | 28,2 |
| 27. | Менделеевск | 74,5 | Алабуга | 4658 | 4658 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 4658 | 4658 | | | | | 5,8 |
| 28. | Минзәлә | 192,0 | Минзәлә | 24464 | 24464 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 24464 | 24464 | | | | | 11,2 |
| 29. | Мөслим | 146,4 | Азнакай | 1547 | 1547 | | | | | |
| | | | Минзәлә | 26555 | 26555 | | | | | |

| № т/с | Муниципаль район яисә шәһәр | Мун.-аль район мәйд. мең га | Урманчылык | Урманнар урнашкан жирләр, га | | | | | | Урман беләнкаплану, % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Барлыгы | Урман фонды жирләрендәге урманнар | ООПТ жирләрендәге урманнар | Оборона жирләрендәге урманнар | Жирлекләр жирләрендәге урманнар | Башка категорияләрдәге жирләрдәге урманнар | |
| | | | Барлыгы | 28102 | 28102 | | | | | 18,5 |
| 30. | Түбән Кама | 167,2 | Зәй | 32536 | 32536 | | | | | |
| | | | Түбән Кама | 13639 | 13639 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 46175 | 46175 | | | | | 26,2 |
| 31. | Яңа Чишмә | 131,7 | Аксубай | 3254 | 3254 | | | | | |
| | | | Биләр | 24 | 24 | | | | | |
| | | | Зәй | 7834 | 7834 | | | | | |
| | | | Кәләй | 3368 | 3368 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 14480 | 14461 | | | | | 10,7 |
| 32. | Нурлат | 229,4 | Биләр | 11620 | 11620 | | | | | |
| | | | Нурлат | 87591 | 87591 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 99211 | 99211 | | | | | 41,3 |
| 33. | Питрәч | 136,0 | Лаеш | 13552 | 13552 | | | | | |
| | | | Шәһәр яны | 2174 | 2174 | | | | | |
| | | | Саба | 1478 | 1478 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 17204 | 17204 | | | | | 12,1 |
| 34. | Балык Бистәсе | 205,2 | Кама | 30442 | 30442 | | | | | |
| | | | Кызыл Йолдыз | 24020 | 24020 | | | | | |
| | | | Лаеш | 747 | 747 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 55209 | 55209 | | | | | 24,9 |
| 35. | Саба | 109,8 | Кызыл Йолдыз | 257 | 216 | | | | 41 | |
| | | | Саба | 28130 | 28130 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 28387 | 28346 | | | | 41 | 24,6 |
| 36. | Сарман | 138,6 | Азнакай | 7813 | 7813 | | | | | |
| | | | Түбән Кама | 1326 | 1326 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 9139 | 8798 | | | | | 6,0 |
| 37. | Спас | 202,2 | Әлки | 4070 | 4070 | | | | | |
| | | | Болгар | 16013 | 16013 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 20083 | 20050 | | | | 33 | 9,2 |
| 38. | Тәтеш | 163,8 | Буа | 630 | 630 | | | | | |
| | | | Тәтеш | 26513 | 26513 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 27143 | 27143 | | | | | 15,9 |
| 39. | Тукай | 174,4 | Алабуга | 12545 | 12545 | | | | | |
| | | | Минзәлә | 1371 | 1371 | | | | | |
| | | | Түбән Кама | 626 | 626 | | | | | |
| | | | «Түбән Кама» НП | 9539 | | 9539 | | | | |
| | | | Барлыгы | 24081 | 14542 | 9539 | | | | 12,9 |

| № т/с | Муниципаль район яисә шәһәр | Мун.-аль район мәйд. мең га | Урманчылык | Урманнар урнашкан җирләр, га | | | | | | Урман белән каплану, % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Барлыгы | Урман фонды җирләрендәге урманнар | ООПТ җирләрендәге урманнар | Оборона җирләрендәге урманнар | Җирлекләр җирләрендәге урманнар | Башка категорияләрдәге җирләрдәге урманнар | |
| 40. | Теләче | 84,4 | Кызыл Йолдыз | 6353 | 6353 | | | | | |
| | | | Саба | 6778 | 6778 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 13131 | 13131 | | | | | 14,9 |
| 41. | Чирмешән | 136,4 | Чирмешән | 36373 | 36373 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 36373 | 36373 | | | | | 25,3 |
| 42. | Чистай | 179,9 | Аксубай | 531 | 531 | | | | | |
| | | | Биләр | 7895 | 7895 | | | | | |
| | | | Кама | 5293 | 5293 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 13719 | 13719 | | | | | 7,2 |
| 43. | Ютазы | 76,1 | Бөгелмә | 9073 | 9073 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 9073 | 9073 | | | | | 11,0 |
| | Казан шәһәре җирләре | 42,5 | Шәһәр яны | 3522 | 3522 | | | | | |
| | | | Суслонгер хәрби урманчылыгы | 960 | | | 960 | | | |
| | | | Лесопарк «Аккош күле» урман паркы | 3547 | | | | 3547 | | |
| | | | Барлыгы | 8029 | 3522 | | 960 | 3547 | | 16,3 |
| | Алабуга шәһәре җирләре | 4,1 | Алабуга | 331 | 331 | | | | | 5,3 |
| | Чаллы шәһәре җирләре | 14,7 | Алабуга | 45 | 45 | | | | | 0,2 |
| | Буа шәһәре җирләре | 1,4 | | 39 | | | | 39 | | 2,8 |
| | Зеленодольск шәһәре җирләре | 3,8 | | 141 | | | | 141 | | 3,6 |
| | Республика буенча барлыгы | 6783,7 | | 1271129 | 1236402 | 28629 | 1691 | 3812 | 595 | 17,5 |

Россия Федерациясе Урман кодексының (алга таба РФ Ур.к)23 статьясы нигезендә урманчылык урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, торгызу өлкәсендә төп территориаль идарә берәмлеге булып тора. Урманчылык конкурсларда һәм аукционнарда сәүдәләр оештыра, урманнарда федераль дәүләт урман күзәтчелеген һәм федераль дәүләт янгын күзәтчелеген (урманны саклау) гамәлгә ашыра, урман участокларын төзүне оештыра, урман реестры өчен белешмәләр туплый, тармак буенча статистик хисаплылыкны алып бара һәм урман хуҗалыгы регламентын гамәлгә ашыруны тәэмин итә. Шуңа күрә Татарстан Республикасында урманнар белән идарә итү структурасын, территорияләрнең урман белән каплануыннан һәм транспорт инфраструктурасы булудан, идарә функцияләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең эш белән тәэмин ителеш санынннан, урман эшчәнлеге принципларыннан чыгып төзергә кирәк.

Урманчылыклар участок урманчылыкларына бүленә.

Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы участок урманчылыкларының гомуми саны 2013 елның 1 гыйнварына 124берәмлек тәшкил итте. Россия урман министрлыгының 2013 елның 5 сентябрендәге 256 номерлы боерыгы нигезендә аларның саны Лубян урманчылыгы оешуга бәйле рәвештә бергә кимеде.

Идел-Кама дәүләт тыюлыгы 1960 елда Лаеш урман хуҗалыгының Раифа һәм Саралан урманчылыклары базасында барлыкка килгән.

Раифа урман дачасы – берничә төр дала үсемлекләре үсә торган көньяк тайга участогы. Имәнлекләр, наратлыклар, катнаш урман, юкәлекләр, каенлыклар, усаклыклар, су баса торган зиреклекләр очрый. Тыюлык флорасында Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән 718 исемлекнең 77 се очрый, алар арасында йөзүче Сальвиния, төньяк Линнеясе, озын сабаклы борынгы үсемлекләрнең сирәк төрләре һәм башкалар бар. Монда имезүчеләрнең 50 төре, 180 төрдәге кош яши. Татарстан Республикасы Кызыл китабына имезүчеләрнең 18 төре, кошларның 41 төре, рептилияләрнең 3 төре, амфибиянең 2 төре, умырткасызларның 25 төре кертелгән. 20 га мәйданлы дендрология бакчасы эшләп килә, анда Европа, Азия һәм Төньяк Американың 500 төрдәге һәм сорттагы агач, куаклык токымнары үсә. Раифа урман дачасы фәнни һәм тарихи әһәмияткә ия. Саралан урман дачасы – Идел һәм Кама елгалары кушылдыгында төзелгән, нарат һәм юкә агачларыннан торган табигый урман массивы. Флора 502 төрдәге югары тармаклы үсемлекне берләштерә. Аларның 51е Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән. Фауна 300 төрдән тора, шулардан умырткасызларның 24 төре, амфибиянең 2 төре, рептилиянең 3 төре, 35 төрдәге кош һәм 10 төрдәге имезүче Кызыл китапка кертелгән.

«Түбән Кама» милли паркы 1991 елда Алабуга һәм Тукай муниципаль районнары территориясендә нарат урманнарын һәм чыршы-ак чыршы агачларын саклап калу максатында Алабуга урманы һәм Кызыл Тау урман массивлары базасында төзелде. Алабуга урман территориясендә нарат агачларыннан торган урман яисә тиз үрчи торган каенлы наратлыклар бар. Кызыл Тау – Урта Идел буенда куе ылыслы тайга вәкилләре булган чыршы

һәм ак чыршы үсә торган бердәнбер участок. Алар Урта Идел буеның көньяк читендә үсә һәм Кама елгасының сул ягына күчә.

Суслонгер хәрби урманчылыгы оборона җирләрендә урнашкан урманнарда урман хуҗалыгы алып бару максатында Казан шәһәре җирләре территориясендә 960 га, шулай ук республика административ районнарының Биектау (186 га) һәм Лаеш (545 га) территориясендә оештырылды.

Казан шәһәрне яшелләндерү хуҗалыгының «Аккош күле» урман паркы МУП трестының су һәм яшеллек хуҗалыгы Казан шәһәрендә урнашкан һәм 3547 га мәйданны били.

1.1.1.2 нче таблицадаурманчылыклар буенча урман төзелеше эшләре турында белешмәләр бирелә.

1.1.1.2нче таблица

**Татарстан Республикасы урманнарының өйрәнелгәнлеге**

| № т/с | Урманчылык | Урманчылык төзелү елы | Мәйдан, га | шул исәптән ысуллар буенча | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | натур таксация | фотостат ысулы |
| **1. Урман фонды җирләрендәге урманнар:** | | | | | |
| 1. | Әгерҗе | 2002 | 45346 | 45346 | - |
| 2. | Азнакай | 2004<br>1989 | 44401<br>1702 | 44401<br>1702 | -<br>- |
| 3. | Аксубай | 2004<br>1989 | 29375<br>247 | 29375<br>247 | -<br>- |
| 4. | Әлки | 2005<br>1989 | 37179<br>283 | 37179<br>283 | -<br>- |
| 5. | Әлмәт | 2004 | 50166 | 50166 | - |
| 6. | Арча | 2001 | 30802 | 30802 | - |
| 7. | Баулы | 2005<br>1989 | 22741<br>696 | 22741<br>696 | -<br>- |
| 8. | Биләр | 2005<br>1989 | 50648<br>127 | 50648<br>127 | -<br>- |
| 9. | Болгар | 2005<br>1989 | 18740<br>112 | 18740<br>112 | -<br>- |
| 10. | Бөгелмә | 2004<br>1989 | 43814<br>319 | 43814<br>319 | -<br>- |
| 11. | Буа | 2002<br>1989 | 17640<br>927 | 17640<br>927 | -<br>- |
| 12. | Алабуга | 2012<br>2003<br>1989 | 12966<br>28898<br>155 | 12966<br>28898<br>155 | -<br>-<br>- |
| 13. | Зәй | 2004<br>1989 | 58594<br>303 | 58594<br>303 | -<br>- |
| 14. | Зеленодольск | 2011 | 26356 | 26356 | - |
| 15. | Ислейтар | 2004<br>1989 | 17104<br>78 | 17104<br>78 | -<br>- |
| 16. | Кайбыч | 2011 | 25291 | 25291 | - |

| № т/с | Урманчылык | Урманчылык төзелү елы | Мәйдан, га | шул исәптән ысуллар буенча | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | натур таксация | фотостат ысулы |
| 17. | Калейкинское | 2004<br>1989 | 40949<br>731 | 40949<br>731 | -<br>- |
| 18. | Кама | 2002<br>2012 | 44227<br>9939 | 44227<br>9939 | -<br>- |
| 19. | Кызыл Йолдыз | 2003<br>1989 | 42345<br>257 | 42345<br>257 | -<br>- |
| 20. | Лаеш | 2001<br>1989 | 33692<br>339 | 33692<br>339 | -<br>- |
| 21. | Лениногорск | 2003 | 52837 | 52837 | - |
| 22. | Мамадыш | 2001<br>1989 | 47754<br>18 | 47754<br>18 | -<br>- |
| 23. | Минзәлә | 2005<br>1989 | 70941<br>977 | 70941<br>977 | -<br>- |
| 24. | Түбән Кама | 2005<br>1989 | 43126<br>360 | 43126<br>360 | - |
| 25. | Нурлат | 2002 | 88545 | 88545 | - |
| 26. | Идел буе | 2003<br>1989 | 27608<br>558 | 27608<br>558 | -<br>- |
| 27. | Шәһәр яны | 2011 | 30401 | 30401 | - |
| 28. | Саба | 2011 | 60292 | 60292 | - |
| 29. | Тәтеш | 2003 | 37632 | 37632 | - |
| 30. | Чирмешән | 2003 | 36373 | 36373 | - |
| | **Урманчылык буенчабарлыгы** | | 1226353 | 1226353 | - |
| | **2. Оборона министрлыгы җирләрендәге урманнар:** | | 1691 | 1691 | - |
| 1. | Суслонгер хәрби урманчылыгы | 1998 | 1691 | 1691 | - |
| | **3. Шәһәр урманнары:** | | 3812 | 3632 | - |
| 1. | шул исәптән:<br>«Аккош күле» урман паркы | 2002 | 3547 | 3547 | - |
| 2 | Буа, Зеленодольск һәм Лаеш т.п. | -<br>2001<br>2011 | 180<br>82<br>3 | -<br>82<br>3 | -<br>-<br>- |
| | **4. Махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләрендәге урманнар:** | | 28629 | 28629 | |
| 1. | шул исәптән:<br>«Түбән Кама»Милли паркы | 1993 | 18538 | 18538 | - |
| 2. | Идел-Кама тыюлыгы | 1993 | 10091 | 10091 | - |
| | **5. Башка категорияләрдәге җирләр** | 1989 | 595 | 595 | - |
| | **Республика буенча барлыгы** | | 1271156 | 1270976 | - |

Татарстан Республикасы урман хуҗалыкларында урман төзелеше эшләре 2001 елдан 2006 елларга кадәр «Идел буе урман проекты» ФДУП Казан экспедициясе тарафыннан Россия урман фондында урман

төзелешләрен үткәрү инструкциясе» таләпләре (1995 ел, 1 һәм 2 өлешләр) һәм урман төзелеше буенча үткәрелгән киңәшмәләр карарлары нигезендә 1 разрядлы яшьтәге агачларны класслау ысулы белән үткәрелде. 1998 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Элек авыл хуҗалыгы оешмаларына караган урман фонды турында» 1998 елның 26 маендагы 280 номерлы карарын үтәү йөзеннән авыл хуҗалыгы формированиеләреннән 106,8 мең га җир урман фонды составына алынды, 2001-2005 елларда урнаштырылды.

Элек авыл хуҗалыгы оешмалары карамагында булган урман участокларын дәүләт исәбенә урман фонды җирләре буларак куелуга бәйле рәвештә аларга Россия Федерациясе милке хокукы турында таныклык бирелде, 10,1 мең га авыл хуҗалыгы җирләрендәге урманнар Россия урман хуҗалыгы министрлыгының 2008 елның 17 октябрендәге 320 номерлы боерыгы нигезендәурман фонды составына кертелде һәм кадастр исәбенә куелды.

Авыл хуҗалыгы җирләренең калган 595 га мәйданы урман фонды составына киләсе елда кертеләчәк, аларда урман төзү эшләре 1988-1989 елларда башкарылган иде.

Территорияне оештыру урман хуҗалыклары тарафыннан әзерлек эшләре үткәрү чорында ук башкарылды. Урман фонды чикләре һәм мәйданы районнарда җир төзелеше органнары белән килештерелде. 1:10000 масштаблы планшетлар һәм 1:25000 масштаблы урман утыртмалары планнары төзү өчен алдагы урман төзелеше планшетлары, электрон карталар картографик нигез булды, алар «Җир» РКЦ» ААҖ тарафыннан тәкъдим ителде.

Урман фонды таксациясе барлык мәйданда да җир өстендә күз белән үлчәү таксациясе ысулы белән башкарылды.

Агачлар запасын корректировкалау өчен 1 га җирдә кисү һәм саклау запаслары мәйданнарының «Татарстан АССР урман хуҗалыгын оештыру һәм үстерүнең төп нигезләмәләре» (1980 ел) белән тәкъдим ителгән суммалар таблицасы кулланылды.

Урманны таксацияләгәндә техник нигез буларак аэрофото сурәтләрдән торган материаллар файдаланылды, алар урманнарны таксацияләү һәм урман карталарын төзү буенча төрле бурычларны хәл итәргә мөмкинлек бирә. Урман фондының бөтен мәйданында 30х30 һәм 50х50 см 1:15000 масштабындагы 2000-2004 еллардагы төсле аэрофото сурәтләр кулланылды.

2011-2012 елларда Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Зеленодольск, Кайбыч, Шәһәр яны һәм Саба урманчылыкларында, шулай ук Кама урманчылыгының Шомбыт участогында һәм Алабуга урманчылыгының Лубян участогында 165,4 меңга гомуми мәйданда урман төзелеше эшләре башкарылды.

1.1.1.3 таблицадаүзгәрешләр кертелгән вакытка урман планының элекке вариантында урман фонды җирләрендә (Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрлыгы буйсынуындагы) урнашкан урманнар торышына үзгәрешләрне сан һәм сыйфат ягыннан бәяләү китерелде.

Урман үсемлекләре белән капланган җирләрнең гомуми мәйданыннан 2013 елның 1 гыйнварына ылыслы агачларның өлеше 24,3%, каты яфраклылар -16,7%, йомшак яфраклылар - 59,0% тәшкил итте. 2008 елдан 2013 елга кадәр (шул елны да кертеп) ылыслы агачлар үсә торган мәйдан 9 мең га (3,1%) артты.

Урман культуралары мәйданы 13,4 меңгектарга (4,1%) артты. Тотылмаган урман культуралары мәйданы 3,3 меңга (21,2% кимеде. Бу күрсәткечләр урман торгызу өлешендә урманчылыкларның эшчәнлеген уңай яктан күрсәтә.

Соңгы биш ел эчендә (урман планына соңгы үзгәрешләрне керткәнчегә кадәр) урман үсемлекләре үскән җирләр 16,2 мең гектарга артты.

1.1.1.3нче таблица

**2003-2008 елларда биш ел эчендә һәм 2013 елның 1 гыйнварына урман фонды җирләренең мәйданнары һәм агач запасы үзгәреше**

мәйдан. мең га; запас – млн. кбм

| Күрсәткечләр | 2003елның 1 гыйнварына | | | 2008елның 1 гыйнварына | | | Алдагы исәп белән чагыштырганда аерма | | | 2003елның 1 гыйнварына (урман реестры буенча) | | | Алдагы исәп белән чагыштырганда аерма | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Саклау | Эксплуата-ция | Бар-лыгы | Саклау | Эксплуата-ция | Барлы-гы | Саклау | Эксплуата-ция | Бар-лыгы | Саклау | Эксплуата-ция | Барлы-гы | Саклау | Эксплуата-ция | Барлы-гы |
| **Урман фонды җирләренең барлык мәйданы** | 536.6 | 688,4 | 1225 | 538 | 688.4 | 1226,4 | +1.4 | - | +1.4 | 553.6 | 682.8 | 1236.4 | +15,6 | -5,6 | +10 |
| Җирнең урман үсемлекләре белән капланувы | 484,3 | 639,5 | 1123,8 | 489,5 | 650,3 | 1139,8 | +5,2 | +10,8 | +16 | 509,2 | 646,8 | 1156 | +19,7 | -3,5 | +16,2 |
| шул исәптән түбәндәгеләр өстенлек итә: | | | | | | | | | | | | | | | |
| ***Ылыслы токымнар*** | 130.4 | 127,7 | 258,1 | 136.8 | 132.9 | 269.7 | +6.4 | +5.2 | +11,6 | 144,5 | 134,2 | 278,7 | +7,7 | +1,3 | +9 |
| шулардан: нарат | 105,4 | 76,6 | 182 | 109 | 76,7 | 185,7 | +3,6 | +0,1 | +3,7 | 114 | 76,3 | 190,3 | +5 | -0,4 | +4,6 |
| чыршы, ак чыршы | 22,9 | 48,3 | 71,2 | 25,3 | 53,3 | 78,6 | +2,4 | +5 | +7,4 | 27,9 | 54,5 | 82,9 | +2,6 | +1,2 | +4,3 |
| кедр, карагай | 2,1 | 2,8 | 4.9 | 2.5 | 2.9 | 5.4 | +0,4 | +0,1 | +0,5 | 2,6 | 2,9 | 5,5 | +0,1 | - | +0,1 |
| 20 елга кадәр яшьтәге агачлар | 33,5 | 53,8 | 87,3 | 27,5 | 44,2 | 71,7 | +6 | -9,6 | -15,6 | 32,5 | 46 | 78,5 | +5 | +1,8 | +6,8 |
| ***Каты яфраклы токымнар*** | 110,4 | 99,3 | 209,7 | 99,1 | 91,7 | 190,8 | -11,3 | -7,6 | -18,9 | 101,2 | 91,3 | 192,5 | +2,1 | -0,4 | +1,7 |
| шулардан: биек кәүсәле имән | 43,3 | 64.7 | 108 | 43 | 59,4 | 102.4 | -0,3 | -5,3 | -5.6 | 43,9 | 58,9 | 102,8 | +0.9 | -0,5 | +0,4 |
| тәбәнәк кәүсәле имән | 60 | 20,7 | 80,7 | 47,1 | 17,8 | 64,9 | -12,9 | -2,9 | -15,8 | 48 | 17,8 | 65,8 | +0,9 | - | +0,9 |
| башкалар (өрәнге,карама) | 7,1 | 13.9 | 21 | 9 | 14,5 | 23,5 | +1,9 | +0,6 | +2,5 | 9,3 | 14 | 23,9 | +0,3 | -0,5 | +0,4 |
| 20 елга кадәр яшьтәге агачлар | 11,8 | 30.4 | 42,2 | 6.2 | 15,7 | 21,9 | -5,6 | -14,7 | -20,3 | 5,2 | 12,3 | 17,5 | -1 | -3,4 | -4,4 |
| ***Йомшак яфраклы токымнар*** | 234 | 412,4 | 646,4 | 246,7 | 425,6 | 672,3 | +12,7 | +13,2 | +25,9 | 256,1 | 421,2 | 677,3 | +9,4 | -4,4 | +5 |
| шулардан: каен | 86,8 | 104,4 | 191,2 | 89,2 | 112,2 | 201,4 | +2,4 | +7,8 | +10,2 | 90,5 | 110,4 | 200,9 | +1,3 | -1,8 | -0.5 |
| усак | 61,6 | 176 | 237,6 | 61,2 | 177,3 | 238,5 | -0,4 | +1,3 | +0,9 | 65,5 | 174,9 | 240,4 | +4,3 | -2,4 | +1,9 |
| вак яфраклы юкә | 68,2 | 123,4 | 191,6 | 77,3 | 127,6 | 204,9 | +9,1 | +4,2 | +13,3 | 78,4 | 127,6 | 206 | +1,1 | - | +1,1 |
| башкалар | 17,4 | 8,6 | 26 | 19 | 8,5 | 27,5 | +1,6 | -0,1 | +1,5 | 21,7 | 8,3 | 30 | +2,7 | -0,2 | +2,5 |
| 20 елга кадәр | 40,2 | 103 | 143,2 | 28,5 | 66,6 | 95,1 | -11,7 | -36,4 | -48,1 | 31 | 70,4 | 101,4 | +2,5 | +3.8 | +6,3 |

| Күрсәткечләр | 2003елның 1 гыйнварына | | | 2008елның 1 гыйнварына | | | Алдагы исәп белән чагыштырганда аерма | | | 2003елның 1 гыйнварына (урман реестры буенча) | | | Алдагы исәп белән чагыштырганда аерма | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Саклау | Эксплуатация | Барлыгы | Саклау | Эксплуатация | Барлыгы | Саклау | Эксплуатация | Барлыгы | Саклау | Эксплуатация | Барлыгы | Саклау | Эксплуатация | Барлыгы |
| яшьтәгеагачлар | | | | | | | | | | | | | | | |
| **Гомуми агач запасы** | 73,61 | 86,54 | 160,15 | 85,12 | 104,67 | 189,79 | +11,51 | +18,13 | +29,64 | 86,87 | 103,4 | 190,27 | +1,75 | -1,27 | +0,48 |
| шул исәптән өлгергән һәм карт агачлар | 14.31 | 17.7 | 32,01 | 21.84 | 33.89 | 55.73 | +7,53 | +16.19 | +23,72 | 22,03 | 33.16 | 55,19 | +0,19 | -0,73 | -0,54 |
| гомуми запастан түбәндәгеләр өстенлек итә | | | | | | | | | | | | | | | |
| ***Ылыслы токымнар*** | 23,74 | 16,74 | 40,48 | 28 | 21 | 49 | +4,26 | +4,26 | +8,52 | 28,67 | 20,98 | 49,65 | +0,67 | -0,02 | +0,65 |
| шулардан: нарат. | 20.83 | 12,86 | 33,69 | 24.36 | 15.51 | 39.87 | +3,53 | +2,65 | +6,18 | 24.76 | 15.27 | 40,03 | +0.4 | -0.24 | +0.16 |
| чыршы, ак чыршы | 2,59 | 3,45 | 6,04 | 3,23 | 4,94 | 8,17 | +0,64 | +1,49 | +2,13 | 3,48 | 5,15 | 8,63 | +0,25 | +0,21 | +0,46 |
| шулардан: өлгергән һәм карт агачлар | 1,74 | 0,69 | 2,43 | 2,19 | 1,17 | 3,36 | +0,45 | +0,48 | +0,93 | 2,18 | 1,11 | 3,29 | -0,01 | -0,06 | -0,07 |
| ***Каты яфраклы токымнар*** | 12.25 | 9,18 | 21,43 | 12.58 | 10.26 | 22.84 | +0,33 | +1,08 | +1,41 | 12.82 | 10.36 | 23,18 | +0,24 | +0,1 | +0,34 |
| шулардан: биек күәсәле имән. | 5,06 | 6,14 | 11,2 | 5,48 | 6,67 | 12,15 | +0,42 | +0,53 | +0,95 | 5,67 | 6,79 | 12,46 | +0,19 | +0,12 | +0,31 |
| тәбәнәк кәүсәле имән | 6,76 | 2,43 | 9,19 | 6,34 | 2,43 | 8,77 | -0,42 | - | -0,42 | 6,35 | 2,39 | 8,74 | +0,01 | -0,04 | -0,03 |
| ***Йомшак яфраклы токымнар*** | 37,43 | 60,62 | 98,05 | 44.42 | 73.41 | 117,83 | +6,99 | +12.79 | +19,78 | 45,28 | 72,06 | 117,34 | +0,86 | -1,35 | -0,49 |
| шулардан: каен | 13,38 | 14,43 | 27,81 | 15,07 | 17,78 | 32,85 | +1,69 | +3,35 | +5,04 | 15,06 | 17,43 | 32,49 | -0,01 | -0,35 | -0,36 |
| усак | 8,4 | 25,33 | 33,73 | 9,75 | 30.11 | 39.86 | +1,35 | +4,78 | +6,13 | 10.06 | 29.15 | 39,21 | +0,31 | -0.96 | -0,65 |
| вак яфраклы юкә | 14,12 | 20,07 | 34,19 | 17.55 | 24.49 | 42.04 | +3,43 | +4,42 | +7,85 | 17,83 | 24,49 | 42,32 | +0,28 | - | 0,28 |
| башкалар | 1,53 | 0,79 | 2,32 | 2,05 | 1,03 | 3,08 | +0,52 | +0,24 | +0,76 | 2,33 | 0,99 | 3,32 | +0,28 | -0,04 | 0,24 |
| гомуми уртача артым | 1,68 | 2,45 | 4,13 | 1,75 | 2,55 | 4.3 | +0,07 | +0,1 | +0,17 | 1.79 | 2,51 | 4,3 | +0,04 | -0.04 | - |
| урман үсемлекләре белән капланган җирләргә әверелгән урман культуралары | 112,4 | 168,7 | 281,1 | 132.2 | 180.8 | 281.1 | +19,8 | +12,1 | +31,9 | 140,8 | 185,6 | 326,4 | +8,6 | +4.8 | +13,4 |
| тотылмаган урман культуралары, мең га | 11 | 15,1 | 26,1 | 10 | 8,9 | 18,9 | -1 | -6,2 | -7,2 | 8,2 | 7,4 | 15,6 | -1,8 | -1,5 | -3,3 |

| Күрсәткечләр | 2003елның 1 гыйнварына | | | 2008елның 1 гыйнварына | | | Алдагы исәп белән чагыштырганда аерма | | | 2003елның 1 гыйнварына (урман реестры буенча) | | | Алдагы исәп белән чагыштырганда аерма | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Саклау | Эксплуатация | Барлыгы | Саклау | Эксплуатация | Барлыгы | Саклау | Эксплуатация | Барлыгы | Саклау | Эксплуатация | Барлыгы | Саклау | Эксплуатация | Барлыгы |
| урман торгызу фонды | 6,5 | 5,7 | 12,2 | 5,2 | 3,6 | 8,8 | -1,3 | -2,1 | -3,4 | 3,4 | 4,6 | 8 | -1,8 | 1 | -0,8 |

### 1.1.2. Башка категориялəрдəге җирлəрнең урман фонды җирлəрендə урнашкан урман күрсəткечлəре, аларның мəйданнарын урман районнары буенча бүлү

Урман үсемлеклəрен районлаштыру – урманнарны, урман барлыкка китерүче токымнарга, урманнарның типларына, урманнарның җитештерүчəнлегенə һəм урман торгызу эшлəренə бəйле табигать шартлары буенча аерылып торган өлешлəргə территориаль бүлү. Урман үсемлеклəрен районлаштыру, урман үсемлеклəренең географик төрлелеген һəм аны гамəлгə ашыру өчен зональ типологик нигездə урман хуҗалыгы җитештерү һəм оештыру буенча махсуслаштыру буларак гамəлдə булуын күрсəтə. Ул түбəндəге территориянең буйсынулы бүленешен үз эченə ала. Аның максаты – урманнарны урнаштырганда һəм урман хуҗалыгын билгелəгəндə зональ үзенчəлеклəрне исəпкə алу.

«Россия Федерациясе урман зоналары исемлеген һəм Россия Федерациясе урман районнары исемлеген раслау турында» 2011 елның 9 мартындагы 61 номерлы боерык нигезендə Татарстан Республикасы ике урман зонасына керə: 1) ылыслы- киңьяфраклы урманнар һəм 2) урман-дала зонасы (1.1.2.1нче табл.).

Татарстан Республикасының төньяк өлеше ылыслы- киңьяфраклы урманнар зонасына керə. Көнбатыш, көнчыгыш һəм көньяк өлешлəр урман-дала зонасына карый.

1.1.2.1нче таблица

**Урман үсемлеклəре зоналары**

| № т/с | Урман зоналары | Урман районнарына керү зоналары буенча аларның составы |
|---|---|---|
| 1. | Ылыслы-киңьяфраклы урман зоналары (төньяк территория) | Россия Федерациясенең Европа өлешенең ылыслы- киңьяфраклы районы (катнаш урманнар) |
| 2. | Урман дала зонасы (территориянен көнбатыш, көнчыгыш һəм көньяк территория өлешлəре) | Россия Федерациясе Европа өлешененурман дала районы |

Республика территориясе ике урман районын үз эченə ала: Россия Федерациясенең Европа өлешенең ылыслы-киңьяфраклы урман районы (катнаш урманнар), һəм Россия Федерациясе Европа өлешенең урман-дала районы.

РоссияУрман хуҗалыгы министрлыгының республика муниципаль районнарының урман районнары буенча бүленеше «Россия Федерациясе урман зоналары исемлеген һəм Россия Федерациясе урман районнары исемлеген раслау турында» 2014 елның 18 августындагы367 номерлы боерык нигезендə 1.1.2.2 нче таблицада бирелде.

1.1.2.2нче таблица

## Урман районнары

| Урман районнары | Россия Федерациясе субъектларысоставына керүче урман районнары, муниципаль районнар һәм башка административ муниципаль берәмлекләр | гомум урман. терр. мәйданы.,% |
|---|---|---|
| Россия Федерациясенең Европаөлеше | | |
| Россия Федерациясе нең Европа өлешендәге ылыслы-киңьяфраклы (катнаш) урманлы районнар | Әгерже, Арча,Әтнә, Балтач, Биектау, Алабуга, Зеленодольск (Иделнең сул як яры), Кукмара, Лаеш, Мамадыш, Менделеевск, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Тукай (Шилнә елгасыннан төнъяктарак), Теләче, Казан шәһәребуйсынуындагы территорияләр | 32,3<br>34,6 |
| Россия Федерациясенең Европа өлешендәге урманлы-далалы районнар | Азнакай, Аксубай, Актаныш, Алексеевск, Әлки, Әлмәт, Апас, Баулы, Бөгелмә, Буа, Югары Ослан, Чүпрәле, Зәй, Зеленодольск (Иделнең уңяк яры), Кайбыч, Кама Тамагы, Лениногорск, Минзәлә, Мөслим, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Нурлат, Сарман, Спас, Тәтеш, Тукай (Шилнә елгасыннан көньяктарак), Чирмешән, Чистай, Ютазы | 67,7<br>65,4 |

Республиканың көнбатыштан көнчыгышка һәм төньяктан көньякка озынлыгы табигать шартларының төрлелегенә бәйле (җирлекнең геологик корылышы, рельеф, климат, туфрак һ.б). Республика районнарының төньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш үсемлекләр дөньясында шактый аерма күзәтелә. Республиканың көнбатыш һәм төньяк-көнбатышта ылыслы һәм каты яфраклы үсемлекләр, ә көньяк-көнчыгыш өлешендә йомшак яфраклы агачлар үсә. Төньяк районнарда Себердән чыккан агач токымнары: чыршылар һәм ак чыршылар очрый.

Татарстан Республикасы урман утыртмаларының токымлы составы төрле һәм түбәндәгечә: усак –20,8%, вак яфраклы юкә –17,8%, каен – 17,4%, нарат – 16,5%, имән (биек һәм тәбәнәк кәүсәле) – 14,6%, чыршы – 7,1%.

Республика территориясендә ике урман районының булуы Татарстан Республикасы урманнарының зона үзенчәлекләренә бәйле. Беренче урман зонасында табигый ылыслы һәм каты яфраклы биек кәүсәле үсемлекләр булса һәм максатчан токымнарны кисә торган мәйданнарда ясалма һәм табигый урман үстерү өчен уңай шартлар булса, икенче урман утыртмалары зонасында киңьяфраклы үсемлекләр һәм аларга алмашка килгән йомшак яфраклы агачлар үсә.

Урман үсемлекләрен районлаштыру нигезендә махсуслаштырылган районнарның башка төрләре башкарыла: агач орлыклары әзерләү, янгынга каршы агач утырту, мелиоратив һәм таксация максатындаагач утыртуһ.б.

Урман таксациясе чикләрендә агач утыртканда бердәм белешмә-норматив материаллардан файдалану күздә тотыла, бу урман төзелеше объектында урман инвентаризациясенең сыйфатын һәм төгәллеген шактый арттыра.

Татарстан Республикасы урманнары агачлар үсешенең бердәмлегеннән чыгып, төп токымнарны бер төрле җитештерү билгесе буенча Үзәк урман таксациясе районына кертелә.

Татарстан Республикасы урманнарының типологик характеристикасы академик В.Н. Сукачев исемендәге урман типларын биогеоценотик классификацияләүгә нигезләнә. Ул П.С.Погребняк тарафыннан эшләнгән урман үстерү шартларының өстәмә схемасын исәпкә алып төзелгән. Бу классификациядә карт агачлар биләп торган территориядә үсемлекләрнең төрле төрләре исәпкә алынган. Монда урман төренең исеме өстенлек иткән агач токымы исеменнән (төп эдификатор)һәм туфрак өсте катламыннан чыгып төзелә (агач үсә торган урында шартларның индикаторы): ылыслык – караҗиләклек, чыршылык - әче туфрак, мүкле наратлык, юкәле чыршылык һ.б.

Бу классификация нигезендә «Татарстан АССР урман хуҗалыгын оештыруның һәм үстерүнең төп нигезләмәләре»ндә (1980 ел) чагылыш тапкан урманнарның Тамырдан һәм ботактан үскән төрләре схемасы төзелде.

Урман фонды җирләрендә һәм башка категориядәге җирләрдә урнашкан урман күрсәткечләре, урман районнары буенча урманчылыклар санынча аларның мәйданнары 1 нче кушымтада китерелде.

Махсус саклanaлучы табигать территорияләре җирләрендә урнашкан урманнарның 67% Россия Федерациясе Европа өлешенең ылыслы-киңьяфраклы урман районына, 33% - урман-дала районына керә.

### 1.1.3. Урманнар составын аларның максатчан билгеләнеше буенча гамәлдәге бүлүне анализлау

Урман фонды җирләрендә урнашкан республика урманнары Россия Федерациясе Урман кодексы нигезендә (10 ст.) максатчан билгеләнеше буенча саклау һәм эксплуатация урманнарына бүленә.

Саклау урманнарына мохит барлыкка китерүне, су саклау, санитар-гигиена, савыктыру һәм башка файдалы функцияләрне саклау максатында, әгәр урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бергә файдалану һәм шулар нигезендә файдалы функцияләр башкару шарты белән бергә үзләштерелергә тиеш урманнар керсә, саклау урманнары республика урманнарының гомуми мәйданыннан 45% биләп тора.

Эксплуатация урманнарына урманнарның файдалы функцияләрен саклаган килеш аларны тотрыклы, максималь нәтиҗәле, югары сыйфатлы агач һәм башка урман ресурслары, аларны эшкәртү продуктлары алу максатында үзләштерелергә тиешле урманнар керә, эксплуатация урманнары республика урманнарының 52% биләп тора.

Татарстан Республикасы территориясендә резерв урманнар юк.

Урманнарны максатчан билгеләнеш буенча бүлү1.1.3.1 нче рәсемдә китерелде.

Татарстан Республикасының схематик картасы




1.1.3.1.рәс. Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча һәм урман категорияләре буенча бүлү

Урман мәйданнарын максатчан билгеләнеше, саклау урманнарының категорияләре һәм җирләрнең категорияләре буенча 2013 елның 1 гыйнварына торышы 31 нче кушымтада китерелде.

Саклау урманнарының хокукый режимы үзенчәлекләрен исәпкә алып, күрсәтелгән урманнарның түбәндәге категорияләре билгеләнде:

1) махсус сакланылучы табигать территорияләрендә урнашкан урманнар.

Махсус сакланылучы табигать территорияләрендә урнашкан урманнарга Идел-Кама дәүләт табигать тыюлыгы һәм «Түбән Кама» милли паркы урманнары керә, алар Идел елгасының сул як яры террасасында урнашкан, аңа көньяк чиктә киң таралган тайга урманнарының фрагментын саклау һәм үзән-кыр үсемлекләренең төрләре комплексын һәм мөһим ылыслы һәм яфраклы урманнарның классик төрләрен чагылдырган урманнар керә. Күрсәтелгән объектлар федераль дәүләт учреждениесе статусын алдылар һәм Россия табигать күзәтчелеге карамагында тора. Әлеге категориянең бүленеше урманнарның файдалы функцияләрен саклау максатларына туры килә;

2) су саклау зоналарында урнашкан урманнар.

Су саклау зоналары елгалар, инешләр, күлләр буйлап 50, 100, 200 м киңлектә (елгаларның, инешләрнең озынлыгыннан, күлләрнең мәйданыннан чыгып) Россия Федерациясе Су кодексы нигезендә бүленде (2013 елның 21 октябрендәге 282-ФЗ номерлы закон редакциясендә). Су саклау зоналарында урнашкан урманнар су объектларын пычратуны, чүпләндерүне, ләм каплауны булдырмау һәм сулыкларны зәгыйфьләндермәү, шулай ук су биологик ресурслар тирәлеген һәм хайваннар, үсемлекләр дөньясының башка объектлары мохитен саклау функцияләрен үтиләр.

Әлеге категорияне шул рәвешчә бүлү урманнарның файдалы функцияләрен саклау максатларына туры килә.

Су саклау зоналары бүленгән елгалар исемлеге 24 нче кушымтада бирелде;

3) табигать һәм башка объектларны саклау функцияләрен башкаручы урманнар:

а) гомуми файдаланудагы тимер юллар буенда, гомуми файдаланудагы федераль автомобиль юлларында, Россия Федерациясе субъектлары милкендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буенда урнашкан урманнарны саклау полосалары.

Күрсәтелгән саклау полосалары юлларны кар көртләреннән һәм суның, җилнең эрозияле йогынтысыннан саклый. Федераль һәм өлкә әһәмиятендәге урманнарның саклау полосалары буйлап урнашкан тимер юллар һәм автомобиль юллары исемлеге 28 нче кушымтада бирелде.

Россия Федерациясе субъекты милкендәге гомуми файдалану автомобиль юллары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 сентябрендәге797 номерлы карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 17 сентябрендәге 468 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр) һәм 29 нчы кушымтада бирелде. Күрсәтелгән категориядәге сакланулы урманнар киңлеге «Табигатьне саклау. Җирләр. Дәүләт урман фонды җирләрендә тимер юллар һәм автомобиль юллары буйлап саклау полосалары бүлеп бирү нормалары»17.5.3.02-90 ГОСТына туры килә. Бу категорияне күрсәтелгәнчә бүлү урманнарның файдалы функцияләрен саклау максатларына хезмәт итә.

б) яшеллек зоналары.

Яшеллек зоналары халыкны тискәре табигый һәм техноген йогынтылардан саклауны тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм савыктыру максатларына билгеләнә;

в) урман-парк зоналары

Урман-парк зоналары халыкның ялын оештыру, табигать ландшафтларының санитария һәм гигиена, савыктыру һәм эстетик кыйммәтләрен саклау максатларында билгеләнә.

Урман-парк зоналары һәм яшеллек зоналары чикләрен һәм мәйданнарын билгеләгәндә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 14 декабрендәге 1007 номерлы карары белән расланган «Урман-парк зоналарында, урман-парк зоналары, яшеллек зоналары мәйданнарында һәм чикләрендә функциональ зоналар билгеләү турында нигезләмә»гә таянырга кирәк.

Россия Федерациясе Урман кодексы гамәлгә кергән көнгә кадәр урман фонды җирләрендә төзелгән яшел зоналарның урман-парклары һәм урман хуҗалыгы өлешләре чикләре тиешенчә урман-парк зоналарының һәм яшеллек зоналарының чикләре булып тора. Урман-парк зоналары һәм яшеллек зоналары бүлеп бирелгән республика торак пунктлары исемлеге 30 нчы кушымтада китерелде.

Урман-парк зоналары мәйданы тиешле җирлек халкы саныннан чыгып билгеләнә. Яшел зона мәйданы урман үсемлеге зоналарыннан чыгып, урманнар белән капланган мәйданнарның муниципаль район яисә әлеге яшеллек зонасы

билгеләнә торган чикләрдәге Россия Федерациясе субъекты территориясенең гомуми мәйданына карата тиешле җирлекнең халык санынннан чыгып билгеләнә. Урман-парк зонасының һәм яшеллек зонасының мәйданын билгеләү өчен нормативлар Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгы тарафыннан ачыклана. (Урман планына үзгәрешләр керткән вакытка нормативлар билгеләнмәгән);

г) дәвалау, савыктыру җирлекләренең һәм курортларның санитария саклау (тау-санитария) округларының беренче, икенче һәм өченче зоналарында урнашкан урманнар.

Саклаучы урманнарның күрсәтелгән категорияләренә «Табигать дәвалау ресурслары, дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлар турында» 1995 елның 23 февралендәге 26-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, «Бәкер» дәвалау-савыктыру шифаханәсе тирәсендәге урманнар керә. Күрсәтелгән урманнар табигый дәвалау чараларын пычранудан һәм зарарланудан саклау, халыкка дәвалану һәм ял итү өчен уңай шартлар тудыру функциясен үтиләр. Күрсәтелгән урманнар турында тулырак белешмәләр 27 нче кушымтада китерелде.

Әлеге категорияне шул рәвешчә бүлү урманнарның файдалы функцияләрен саклау максатларына туры килә;

4) кыйммәтле урманнар:

а) эрозиягә каршы урманнар эрозия процессларын туктату өчен һәм туфракның агып китүен, юылуын һәм таралуын булдырмау өчен бүлеп бирелде.Әлеге категорияне шул рәвешчә бүлү урманнарның файдалы функцияләрен саклау максатларына туры килә;

б) чүлләрдә, ярымчүлләрдә, урманлы далаларда, урман-тундра зоналарында, далаларда, тауларда урнашкан урманнар. Бу категория урманнарның максатчан билгеләнеше – кырларны һәм башка авыл хуҗалыгы җирләрен җил һәм су эрозиясеннән саклау, алар янәшәсендәге авыл хуҗалыгы җирләре микроклиматын яхшырту һәм табигатьне саклау һәм табигать барлыкка китерүнеңбашка функцияләре. Бу категориядәге урманнарны бүлеп күрсәтү мохит барлыкка китерүче су саклау, санитария-гигиена, савыктыру һәм урманнарның башка файдалы функцияләрен саклау максатларына туры килә;

в) фәнни һәм тарихи әһәмияткә ия урманнар. (25 нче һәм 26 нчы кушымталарда тулы характеристика). Бу категориядәге урманнарны яклау категориясенә Россия Федерациясе Урман кодексы нигезендә элеккеге беренче төркем урманнары саклау керә: «табигать ядкарьләре». Әлеге категорияне шул рәвешчә бүлү урманнарның файдалы функцияләрен саклау максатларына туры килә;

г) су объектлары буйлап урнашкан урманнарның тыелган полосалары Россия Федерациясе Урман кодексы нигезендә элеккеге «Елга, күл сусаклагыч һәм башка су объектлары ярлары буенча урманнарның тыелган полосалары» категориясеннән бүлеп бирелде. Әлеге категориядәге урманнарның максатчан билгеләнеше яңгыр һәм кар сулары агымы күләмен җайга салу, елга кушылдыкларында туфрак эрозиясен булдырмау, су объектларының гидрологик режимын җайга салу.Әлеге категорияне шул рәвешчә бүлү урманнарның файдалы функцияләрен саклау максатларына туры килә;

д) Россия Федерациясе Урман кодексы нигезендә урманнарның махсус полосалары «кыйммәтле сәнәгать балыкларының уылдык чәчү вакытларын саклый торган тыелган урман полосалары» яклау категориясе урманнарыннан бүлеп бирелде. Бу категориядәге урманнарның максатчан билгеләнеше – уылдык чәчү өчен сулыкларның тулылыгын саклау һәм тәэмин итү, чисталыгы өчен уңай шартлар булдыру. Әлеге категорияне шул рәвешчә бүлү урманнарның файдалы функцияләрен саклау максатларына туры килә;

Урман дала районында саклау урманнары ылыслы-киңъяфраклы (катнаш) урман районында мәйданның 40% биләп тора, саклау урманнары районның 58% биләп тора.

Рекреацион урманнарның ландшафт характеристикасына ландшафт типлары, агачларның ныклык дәрәҗәсе, территорияләрнең рекреацион дигрессия стадиясе, участокларның ачыклыгы һәм күренүчәнлеге, ландшафтларның санитар-гигиена һәм эстетик кыйммәте турында белешмәләр була.

Географиядә ландшафт – тышкы күренешнең барлыкка килү һәм бердәйлеген тасвирлый торган конкрет территория, ул бердәй геологик фундамент, бер төрдәге рельеф, уртак климат, бер рәвештәге гидротермик шартлар берлеге, туфрак һәм биоценоз уртаклыгына бәйле.

Урман-парк ландшафты дигәндә участокның төрле, структур формасы, аның агачлар белән билгеле бер дәрәҗәдә тулылануы, пространство характеры куе агачлык белән билгеләнә.

Республиканың рекрацион урманнарында ябык ландшафтлар өстенлек итә - мәйданның 76%ы.

Агачларның ныклыгы – аларның үсеше өчен уңайсыз шартларга каршы тоту сәләте. Бу күрсәткеч агачларның гомуми халәтен, үсү сыйфатын табигый артуның дәрәҗәсен тасвирлый.

Республиканың рекреацион урманнарында сәламәт, яхшы үсә торган агачлардан торган 1 классны ныклыктагы агачлар өстенлек итә (84%).

Рекреацион дигрессия стадияләрен бәяләү объект территориясенә элеккеге һәм хәзерге рекреацион йөкләнешне тасвирлый. Рекреацион файдалану йогынтысында урман мохитенең характеры үзгәреше буенча рекреацион урманнар (урман-парк зоналары) шундый дигрессиянең биш этабын үтә: абсолют бозылмаган агачлардан алып бозылган һәм кору стадиясенә кадәр булганнарын.

Республиканың рекреацион урманнары рекреация дигрессиясе стадияләре буенча түбәндәгечә бүленде: 1 стадия – 21%, 2 стадия – 30%, 3 стадия – 28%, 4 стадия – 14% и 5 стадия – 7%.

Дигрессиянең беренче стадиясендә урман түшәге бозылмаган барлык үләннәрнең тулы җыелмасы шушы урманга хас үсемлекләр, төрле яшьтәге үсемлекләрнең күп төрлелеге белән характерлана, агачларның һәм җирдә үлән түшәгенең зарарлануы гомуми санның 5%ын, туфракның минераль катламына кадәр тапталган өлеше барлык участокның 1% ка якынын тәшкил итә.

Икенче стадия сукмакларның булуы, үсемлекләр түшәген таптауның башлангыч стадиясе, куе агачлыкка төрле үсемлекләрнең үтеп керүе, туфракның минераль катламын 1,1-5,0% на кадәр зарарланган булуы белән характерлана.

Дигрессиянең өченче стадиясендә туфракның минераль горизонтына кадәр тапталган мәйданы өлеше 5,1-10,0% тәшкил итә, агач сирәкләнә (10% кадәр), яшь агачлар һәм үлән түшәге зарарлану 50-90% ка кадәр җитә. Яктылыкның төшүе куе агачлар арасына кыр үләннәре, хәтта чүп үләннәре үтеп керүгә китерә.

Дүртенче стадия өчен агачның алга таба сирәкләнүе яшь агачларның һәм үлән түшәгенең алан һәм сукмакларда булуы хас, аланнарда үлән түшәге тулысынча бозылган, кыр үләннәре үсә, туфракның минераль катламына кадәр тапталган мәйданы өлеше 10,1-25,0% тәшкил итә.

Бишенче стадия өчен агач үсемлекләренең зәгыйфьләнүе хас – күпчелек агачларның тамыры күренеп тора, ә агачлар үзләре авыру һәм механик зарарлануга дучар ителгән. Үсемлексез җирләр мәйданы участокның 25%тан артыгын тәшкил итә.

Эстетик бәяләү белән беренче класслы рекреацион урманнар мәйданының 50%ын тәшкил итә. Бу ылыслы һәм яфраклы агачлар, киң һәм озын ябалдашлар, уртача үлән түшәге, яхшы узып була торган, чүп-чар белән капланмаган, ачык рельефлы декоратив аланнардан торган кишәрлекләр.

Эстетик бәяләүнең икенче классы мәйданның 43% тәшкил итә. Бу очракта агачның ябалдашлары һәм кәүсәсе уртача урманның чүп-чар белән пычрануы бер гектарга 5 $м^3$ га кадәр тәшкил итә.

Эстетик бәяләүнең өченче классына (7%) усак һәм зирек өстенлек иткән урманнар, шулай ук бонитетның 4-5 класслы агачлары булган урманнар керә. Монда агачларның ябалдашы купшы түгел.Чүпле урыннар һәм тамырында корыганагачлар бер гектарга 5 $м^3$ тәшкил итә. Монда киселгән урман, сөрүлекләр, линиядәге объектлар, сазлыклар һәм артык ямьле булмаган башка ачык мәйданнар керә.

Югары санитария-гигиена бәяләмәсе бирелгән урманнар рекреацион урманнарның 63%ын тәшкил итә. Бу яхшы санитария халәтендәге, һавасы чиста, яхшы аэрация, тавышсыз, куе куаклар белән капланмаган урманнар, урманга хуш исләр, кош-корт тавышлары, ачык төсләр хас.

Санитария-гигиена ягыннан уртача бәя 35% урманнарга бирелгән. Бу кишәрлекләр чагыштырмача яхшы санитар халәттә, чүп-чар белән каплануы зур түгел, аерым корган агачлар бар, һава бераз пычранган, тавыш даими яисә юк.

Урманнарның 2%ын санитария-гигиена ягыннантүбән бәя бирелгән кишәрлекләр тәшкил итә, монда агачлар начар санитар халәттә, урман чүп-чар белән капланган, чүп-чар өемнәре очрый, карьер һәм чокырлар бар, һава пычранган, көчле җил, караңгылык, тавыш дәрәҗәсе югары, артык дымлы һәм куе чатырманлы кишәрлекләр тәшкил итә.

Уртача дәрәҗәгә ия рекреацион урманнар 73%, начар урманнар 9%, яхшы урманнар – 17% тәшкил итә.

Участокларның уртача узучанлыгы мәйданның 56%ына, яхшы узучанлык - 35% урманга хас.

Тулаем алганда, республиканың урман-парккы һәм яшел зоналарында урнашкан урманнар югары санитар-гигиена, эстетик рекреацион кыйммәтләр һәм ныклык белән характерлана.

Урманчылыклар территориясендә функциональ зоналарны билгеләгәндә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 14 декабрендәге 1007 номерлы карары белән расланган «Урман-парк зоналарында, урман-парк зоналары мәйданнарында һәм чикләрендә, яшел зоналарда функциональ зоналарны билгеләү турында нигезләмә»гә таянып эш итәргә кирәк.

Урман-парк зонасында функциональ зоналар, урман-парк зоналарының төрле өлешләрендә урманнарны файдалану, саклау, яклау һәм торгызу режимын дифференциацияләү максатларында бүлеп бирелә торган җирләрдән гыйбарәт.

Яхшы оештырылган, тотрыклы табигать ландшафтлары һәм рекреацион инфраструктура булган йә урманнардан файдалану, саклау, яклау һәм торгызу режимын дефференцацияләү таләп ителми торган очракларда функциональ зоналар бүленмәскә мөмкин.

Урман-парк зонасында актив ял итү һәм прогулка зонасы билгеләнә. Аерым очракларда фауна тирәлеген саклау һәм бозылган табигый ландшафтларны торгызу өчен функциональ зоналар – фауна һәм торгызу зонасы бүлеп бирелергә мөмкин.

Актив ял зонасы аларны төзекләндерү максатларында аеруча рекреация йөкләнеше булган урман паркы зоналары урыннарында һәм тотрыклы табигый ландшафтлар төзү урыннарында бүленә. Актив ял итү зонасы мәйданы урман паркы зонасы мәйданының 30% кадәрен биләп торырга мөмкин.

Прогулка зонасы халык аз йөри торган урман паркы зоналарында прогулкалар һәм туристлык маршрутлары, билгеләнгән тәртиптә азык-төлек һәм агачка карамаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю өчен бүлеп бирелә. Прогулка зонасы мәйданы урман паркы зонасының 70%тан артыгын тәшкил итә.

Фауна зонасы кошлар һәм хайваннарның яшәү тирәлеген һәм аларның үрчүе өчен оптималь шартлар тәэмин итү максатларында бүлеп бирелә.

Торгызу зонасы агачлар корыган йә аларның тотрыклылыгы кимегән һәм урманнарны торгызу буенча озак вакыт (кимендә 10 ел) таләп ителә торган комплекслы чаралар эшләүне таләп итә.

Урман паркы зонасында функциональ зоналар, ул зоналарның мәйданы һәм чикләре, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органы карары белән расланган проект документациясе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урман планына үзгәрешләр кертелгән вакытка урман паркы зоналарында функциональ зоналар, урман-парк зоналарының чикләрен проектлау, яшел зоналарның чикләрен билгеләү буенча эш башкарылмаган.

Татарстан Республикасы урман-парк зоналарында югарыда аталган барлык функциональ зоналар да бар.

**Татарстан Республикасыныңландшафт районнарына бүленүе**

Татарстан Республикасы территория ике ландшафт зонасына, дүрт ярдәмче зонага һәм 34 ландшафт районына бүленә. Бүленгән районнар нигезендә һәр районны түбәндәге биек яруслы класска һәм зональ сектор тибындагыландшафтларга кертергә мөмкин: бореаль салмак-континенталь (көньяк

тайга); бореаль салмак континенталь (тайга); суббореаль төньяк семигумид (киңьяфраклы); суббореаль төньяк семигумид (типик һәм көньяк урман даласы).

Татарстан Республикасы ландшафт структурасын типиклаштыру Ф.Н. Мильков алымнарын кулланып башкарылды, алар 1:200 000 масштабында Воронеж өлкәсендә ландшафтларның морфологик структурасы картасын төзегәндә тәкъдим ителде, анда геокомплекслар җирлек рангларында чагылыш тапты. Барлык җирлек тибындагы рангта таксономик берәмлекләр безнең тарафтан типлар һәм ярдәмче типлар классларына бүленде.

Рельеф буенча тиешенчә урнашкан һәм морфогенетик рельеф төркемнәреннән гыйбарәт булган 11 җирлек тибы билгеләнде. Җирлек түбәндәге типларга бүленә: 1) су бүленеше; 2) су янындагы бүлемтекләр һәм тау битенең биек өлешләре; 3) тау битенең уртача; 4) түбән өлешләре; 5) кече елгаларның биек террасалары (3 һәм 4); 6) кече елгаларның түбән террасалары (1 һәм 2); 7) зур елгаларның дүртенче террасасы; 8) зур елгаларның өченче террасасы; 9) зур елгаларның беренче һәм икенче террассалары; 10) зур елгаларның яр террассалары; 11) су баса торган болыннар.

Җирлекләрне ярдәмче типларга бүлү ярдәмче типлар дәрәҗәсендә туфрак катламы характеры буенча башкарылды, ә җирлекләрне классларга берләштерү дүрттән бер өлештәге катламның генетик типлары буенча билгеләнде.

Мондый классификация Ф.Н. Мильков алымнарыннан бераз аерыла. Аларга тугайлар да дә һәм шулай ук тугай өстендәге терраса урыннары да кертелгән. Без тәкъдим итә торган морфологик ландшафт структурасы вак өлешләргә бүленә, төрле дәрәҗәдәге террассаларны күрсәтә, елга тугайларының катлаулылыгын чагылдыра; яр буйлары шулай ук өч төргә бүленгән, шуна өстәп су буендагы бүлемтекләр мөстәкыйль төр итеп күрсәтелә.

Өйрәнелә торган территориядә җиде класс, унбер тип һәм егерме ярдәмче тип билгеләнә. Республикада 238 бер типтагы җирлек күзәтелә. Тәкъдим ителә торган белешмәдә җирлек төре аеруча әһәмияткә ия, чөнки рельеф– төрле җирлекләрне дифференцияләүнең әйдәүче факторы. Туфракның ярдәмче төрләре җирлекләрне ярдәмче төрләргә бүлүгә китерә.

Татарстанда җирлекнең төп төре тау битләренең урта өлешенә карый – 36,8%. Тау битләренең түбән өлешләрдәге ландшафтлары 24,4%, су буендагы бүлемтекләр 15%, терраса комплекслары 10,7%, тугайлар 8,6% (2 нче таблица).Иң аз биләнә торган мәйдан су бүлемтекләренә туры килә – 4,2%. Җирлек типлары структурасында ландшафт зоналары буенча кайбер аерымлыклар бар.

1.1.3.1нче таблица

**Татарстан Республикасында җирлек типлары нисбәте**

| Җирлек | Мәйдан,% |
|---|---|
| Су бүләр урыннар | 4,2 |
| Тау битләренен су бүләр урыннары өлешләре | 15,2 |
| Тау битләренең урта өлеше | 36,8 |
| Тау битенен түбән өлеше | 24,4 |

| Җирлек | Мәйдан,% |
|---|---|
| Кече елгаларның өченче һәм дүртенче югары террасалары | 0,6 |
| Кече елгаларның беренче һәм икенче түбән террасалары | 3,3 |
| Зур елгаларның дүртенче террасасы | 2,4 |
| Зур елгаларның өченче террасасы | 1,3 |
| Зур елгаларның беренче һәм икенче террасалары | 2,5 |
| Зур елгаларның тау бите террасалары | 0,6 |
| Тугайлар | 8,7 |

1.1.3.2нче таблица

**Татарстан Республикасы ландшафтларының ландшафт зоналары буенча морфологик структурасы**

| Җирлекләрнең типлары | Ландшафт зонасы (мәйдан,%) | |
|---|---|---|
| | Бореаль | Суббореаль |
| **Субүлгеч** | **6,5** | **3,5** |
| Сөзәклекләрнең субүлгеч өлешләре | 15,2 | 15,1 |
| **Сөзәклек** | **73,7%** | **77,1** |
| Сөзәклекләрнең урта өлешләре | 35,5 | 37,2 |
| **Дала** | **9,6** | **11,2** |
| Сөзәклекләрнең түбән өлешләре | 23,0 | 24,8 |
| Кече елгаларның биек террасалары (3, 4) | 0,2 | 0,8 |
| Кече елгаларның тәбәнәк террасалары(1, 2) | 2,5 | 3,6 |
| Зур елгаларның 4 нче террасасы | 2,6 | 2,4 |
| Зур елгаларның 3 нче террасасы | 2,5 | 0,9 |
| Зур елгаларның 1, 2 нче террасалары | 1,4 | 2,8 |
| Зур елгалар террасаларының сөзәклекләре | 0,4 | 0,7 |
| **Тугай тибы** | **10,1** | **8,2** |

Бореаль субүләр урыннар биләп торган ландшафт зонасында суббореаль зона җирендәге су Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиләр мәйданнар ике тапкыр артык. Мондый аерымлыкның иң ачык сәбәбе горизонталь бүленеш Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгының субүләр урыннары рәвеше һәм баскычлы рельеф булуга бәйле. Димәк, су бүлү урыннары контурларының рәвеше түгәрәк-дискрет яисә буйга сузылган була. Бореаль ландшафт зонасында рельефның төрле булуы гомумән алганда азрак, төп һәм иярчен дала зоналарының елга арасындагы киңлекләре кинрәк, ә рельефның ярусллы булуы Татарстан Республикасының көньяк-көнчыгышындагы кебек ачык түгел. Шуңа күрә суббореаль зонада субүләр урыннарның контуры дендрит рәвешендәге сурәткә охшаш.

Бореаль ландшафт зонасында ачык соры (43%), кара-көлсу (29%) һәм соры урман туфрагы (10%) өстенлек итә. Кара җирләр һәм аеруча дымлы шартларда барлыкка килгән туфраклар киң таралмаган. Татарстан Республикасы чикләрендәге

бореаль ландшафт зонасы кысаларында табигый үсемлекләр киң таралыш тапмый. Бу зонаның яфраклы агачлар белән гомуми каплануы 17,4% тәшкил итә. Ландшафтларның морфологик структурасында тау битләренең урта өлешләре өстенлек итә – 35%, тау битләренең түбән өлешләренә 22,9%, субүләр тибындагыларга – 6,5%, су баса торганнарга – 10% керә. Чирек катламнар тибындагы генетик җирләр арасында аллювиаль – (19%), элювиало-делювиаль (23%) һәм делювиаль-солифлюкцион (55%), сирәгрәк эол катламнар очрый. Бореаль ландшафт зонасы көньяк тайга – 2,4% һәм тайгага охшаш - 97,5% ландшафт зонасына бүленә.

Суббореаль төньяк семигумид ландшафт зонасы киңьяфраклыларга (24%) һәм урман-дала (75,8%) зоналарына бүленә. Суббореаль төньяк семигумид ландшафт зонасында селтеле кара туфрак (28%) һәм соры урман туфрагы (10%) өстенлек итә. Морфологик структурада шулай ук тау битләренең урта өлеше (37,1%) һәм түбән өлеше (24%) тәшкил итә; иң азы субүләр урыннарга туры килә (3,54%).Чирек катламнар төре арасында аллювиаль, элювиаль-делювиаль, делювиаль-солифлюкцион – 17%, 39% һәм 40% туры килә.

Урман формацияләре структурасында көньяк тайга зонасында наратлыклар (нарат культуралары белән бергә) – 57,5%; чыршылыклар – 10%, каенлыклар һәм усаклыклар 19,7 юкәлекләр 12,8% туры килә. Тайгага охшаш зонада наратлыклар (культуралары белән бергә) һәм чыршылыклар 43,2%, юкәлек һәм имәнлекләр(культуралары белән) – 25,3%, каенлыклар һәм усаклыклар – 31,0%, таллык һәм зиреклекләр 0,5% тәшкил итә. Киңьяфраклылар һәм урман-дала зонасында үсемлек формацияләренең составы түбәндәгечә: имәнлекләр (имән культуралары белән)65,2% һәм юкәлекләр 34%, усаклыклар һәм каенлыклар – 16,1% һәм 50,7%;наратлыклар һәм чыршылыклар (культуралары белән бергә)18,5% һәм 14,6%, таллыклар – 0,2% һәм 0,7% тәшкил итә.

Югарыда үсемлекләрне ландшафт зоналары буенча бүлү турында китерелгән белешмәләр ландшафт шартларының яхшы интеграль индикаторы булып тора (ләкин аеруча антропоген бозылу шартларындаабсолют төгәл түгел), бу без бүлгән ландшафт чикләренең җитәрлек дәрәҗәдә ышанычлы нигезләнгәнлеген дәлилли.

Шулай итеп, кояш радиациясенең үтеп керүе һәм дымлылык кебек зональ климатик шартлардагы үзгәрешләрнең гомуми фонында бореаль ландшафт зонасы законлы нигездә суббореаль зонасына алмаша. Геопространствода шулай ук кайбер зонага карамаган факторлар да үзгәрә: чирек катламнарның генетик типлары һәм рельеф. Зона һәм аңа карамаган факторларның катлаулы үрелеше ПТКның төрлелеген раслый һәм ландшафт структурасын катлауландыра, Россия тигезлегендә махсус территориаль берәмлек – бореаль экотон барлыкка китерә. Ландшафтлы районлаштыру 1.1.3.3 нче рәсемдә күрсәтелде.




**1.1.3.3. Ландшафт буенча районлаштыру**

1.1.3.3 нче таблица

**Ландшафтлы ярдәмче зоналарда бореаль бердәй үсемлек тупланмаларының нисбәте**

| Ярдәмче зоналар | Бореальурыннар | Мәйдан | % |
|---|---|---|---|
| Көньяк тайга | 2 – юкәлек | 9,61 | 12,67 |
| | 3 – усаклык | 8,23 | 10,84 |
| | 4 – каенлык | 7,50 | 9,89 |
| | 5 – наратлык | 5,38 | 7,11 |
| | 6 – чыршылык | 2,76 | 3,63 |
| | 8 – чыршы культуралары | 4,59 | 6,05 |
| | 9 – нарат культуралары | 37,79 | 49,81 |
| Тайгага охшаш | 1 – имәнлек | 309,73 | 10,74 |
| | 2 – юкәлек | 333,58 | 11,57 |
| | 3 – усаклык | 313,97 | 10,89 |
| | 4 – каенлык | 579,71 | 20,11 |
| | 5 – наратлык | 256,59 | 8,9 |
| | 6 – чыршылык | 145,85 | 5,06 |
| | 7 – имән культуралары | 87,29 | 3,03 |
| | 8 – чыршы культуралары | 282,36 | 9,79 |
| | 9 – нарат культуралары | 560,69 | 19,45 |

| Ярдәмче зоналар | Бореальурыннар | Мәйдан | % |
|---|---|---|---|
| | 10 – таллык | 13,05 | 0,45 |
| | 11 – зиреклек | 0,42 | 0,01 |
| Киңьяфраклы | 1 – имәнлек | 723,71 | 32,95 |
| | 2 – юкәлек | 465,82 | 21,21 |
| | 3 – усаклык | 169,77 | 7,73 |
| | 4 – каенлык | 185,28 | 8,44 |
| | 5 – наратлык | 146,43 | 6,67 |
| | 6 – чыршылык | 2,83 | 0,13 |
| | 7 – имән культуралары | 239,11 | 10,89 |
| | 8 – чыршы культуралары | 42,32 | 1,93 |
| | 9 – нарат культуралары | 216,35 | 9,85 |
| | 10 – таллык | 4,45 | 0,20 |
| Типик көньяк һәм урман-дала | 1 – имәнлек | 877,40 | 11,98 |
| | 2 – юкәлек | 1445,51 | 19,74 |
| | 3 – усаклык | 2251,97 | 30,75 |
| | 4 – каенлык | 1456,04 | 19,88 |
| | 5 – наратлык | 83,64 | 1,14 |
| | 6 – чыршылык | 1,92 | 0,03 |
| | 7 – имән культуралары | 174,84 | 2,39 |
| | 8 – чыршы культуралары | 205,21 | 2,80 |
| | 9 – нарат культуралары | 772,36 | 10,55 |
| | 10 – таллык | 54,18 | 0,74 |

188Бореаль ландшафт зонасы

*Көньяк тайга ландшафт ярдәмче зонасы*

***Илет – Ашыт*** (28) Урал алдында кара-көлсу һәм ачык соры урман туфрагында борынгы үләнле киңьяфраклылар ак чыршы-чыршы агачлыклары һәм нарат-чыршы урманнары (нарат, чыршы культуралары өстенлек иткән) үсә торган калку район.

*Тайгасыман ландшафт ярдәмче зонасы*

***Шушма – Ашыт***(27) Урал алдында ачык соры һәм кара-көлсу урман туфрагында борынгы үләнле нарат-чыршы һәм киңьяфраклылар агачлыклар һәм киңьяфраклылар урман фрагментлары (хәзерге вакытта наратлык һәм каенлык өстенлек иткән) үсә торган калку район.

***Көнбатыш – Казан*** (26) кара-көлсу һәм ачык соры урман туфрагындакөнчыгыш-Европа нарат һәм киңьяфраклылар-нарат урманнары үсә торган уйсу район.

***Казан*** (25) Урал алдында ачык соры һәм кара-көлсу урман туфрагында борынгы үләннәр, нарат-чыршы (наратлык һәм чыршылык өстенлек иткән) һәм киңьяфраклылар-чыршы агачлыклары һәм киңьяфраклылар үсә торган урман фрагментлары (имән-юкә өстенлек иткән) булган калку район.

***Кукмара*** (24) Урал алдында ачык соры һәм кара-көлсу туфракта борынгы үләнле киңьяфраклылар-ак чыршы-чыршы агачлыклары (имән-юкә өстенлек иткән) һәм нарат урманнары (нарат культуралары өстенлек иткән) үсә торган калку район.

***Мамадыш – Соколки*** (21) Урал алдында ачык соры, соры һәм кара-көлсу туфракта борынгы үләнле киңьяфраклылар-ак чыршы-чыршы агачлыклары һәм нарат урманнары (нарат культуралары өстенлек иткән) үсә торган калку район.

***Алабуга – Кама алды*** (20) Урал алдында ачык соры һәм кара-көлсу урман туфрагында киңьяфраклылар-ак чыршы-чыршы агачлыклары, нарат-киңьяфраклылар һәм наратлы-борынгы үләнле урманнар (хәзерге вакытта каенлыклар, усаклыклар һәм нарат, чыршы культуралары өстенлек иткән) үсә торган калку район.

***Әгерҗе*** (19) Урал алдында кара-көлсу, куе соры урман туфрагында һәм аллювиаль чирәмгә бай туфракта борынгы үләнле киңьяфраклылар-ак чыршы-чыршы, үләнле нарат урманнары (хәзерге вакытта каенлыклар, усаклыклар һәм нарат культуралары өстенлек иткән) үсә торган калку район.

Суббореаль төньяк семигумид ландшафт зонасы

*Киңьяфраклылар кече ландшафт зонасы*

***Идел – Мишә*** (5) кара-көлсу, куе соры урман туфрагында көнчыгыш Европа нарат-киңьяфраклылар (хәзерге вакытта усаклыклар һәм каенлыклар өстенлек иткән) һәм нарат агачлыклары булган өлешчә дала төсмере кергән урманнар үсә торган калку район.

***Түбән Мишә***(23) ачык соры, кара-көлсу, соры урман туфрагында урта Россия – Идел борынгы үләнле киңьяфраклылар (юкә-имән) һәм чыршы урманнары үсә торган калку район.

***Көньяк Мишә*** (22) ачык соры, кара-көлсу, соры урман туфрагында урта Россия – Идел борынгы үләнле киңьяфраклылар (юкә-имән һәм нарат культуралары белән) урманнары үсә торган калку район.

***Кама алды***(30) ачык соры, соры урман туфрагында урта Россия – Идел борынгы үләнле киңьяфраклылар (усаклыклар күбрәк булган юкә-имән агачлыклары) урманнары үсә торган калку район.

***Идел – Зөя***(4) соры, ачык соры урман туфрагында урта Россия – Идел борынгы үләнле киңьяфраклылар (юкә-имән) урманнары үсә торган калку район.

***Идел – Гөбенә*** (3) соры, куе соры һәм ачык соры урман туфрагында урта Россия – Идел борынгы үләнле киңьяфраклылар (юкә-имән), борынгы-дала үләне каплаган нарат-киңьяфраклылар урманнары, көньякта Идел буе – Идел аръягы киңьяфраклылар (корычагач белән юкә-имән) урманнары үсә торган калку район.

*Типик һәм көньяк урман-дала кече ландшафтзонасы*

***Зөя аръягы*** (1) селтеле һәм типик кара туфракта урта Россия – Идел буе болын-далалары булган һәм киңьяфраклылар-имән агачлыклары (хәзерге вакытта усаклыклар һәм нарат культуралары күбрәк үскән) дала үләнле урманнар үсә торган калку район.

***Урта Зөя*** (2) селтеле һәм типик кара туфракта урта Россия – Идел буе болын-далалары булган һәм киңьяфраклылар-имән агачлыклары (хәзерге вакытта нарат культуралары күбрәк үскән) дала үләнле урманнар үсә торган калку район.

***Болгар*** (6) типик кара һәм селтеле туфракта семигумид көнчыгыш Европа нарат-киңьяфраклылар (юкә) агачлыклары һәм өлешчә дала үләннәре каплаган урманнар үсә торган уйсу район.

***Актай – Шентала*** (7) көлсыман, селтеле һәм типик кара туфракта Кама аръягы – Идел аръягы болын-далалары булган, киңьяфраклылар имән-юкә агачлыклары һәм үләнле юкә (усак күбрәк үскән) урманнары үсә торган уйсу район.

***Чистай*** (9) селтеле, көлсыман кара туфракта һәм аллювиаль кара бай туфракта Кама аръягы – Идел аръягы болын-далалары булган, киңьяфраклылар имән-юкә агачлыклары һәм үләнле юкә (усак күбрәк булган) урманнары үсә торган калку район.

***Чишмә – Сулчә*** (10) селтеле кара туфракта, куе соры урман туфрагында һәм көлсыман кара туфракта Идел буе юкә-имәнлекләре, Кама аръягы – Идел аръягының юкә-имән һәм юкә урманнары үсә торган калку район.

***Сулчә*** (31) селтеле кара туфракта, куе соры урман туфрагында Идел буеның юкә-имәнлекләре үсә торган калку район.

***Түбән Зәй***(11) соры, ачык һәм куе соры урман туфрагында Идел буеның юкә-имән урманнары үсә торган калку район.

***Түбән Кама*** (12) ачык соры, соры урман туфрагында һәм аллювиаль кара бай туфракта Идел буе – Идел – Каманың имән, карама агачлыклары һәм Идел буеның юкә-имән урманнары (көньякта) үсә торган калку район.

***Минзәлә*** (13) соры урман туфрагында һәм селтеле соры туфракта Идел буеның юкә-имән урманнары белән Кама аръягы – Идел аръягы юкә-имән һәм юкә урманнары үсә торган калку район.

***Актаныш*** (14)селтеле соры туфракта һәм соры урман туфрагында Идел буеның юкә-имән урманнары белән Кама аръягы – Идел аръягының юкә-имән һәм юкә урманнары, шулай ук Идел буе – Идел – Каманың юкә-имән, карама урманнары үсә торган уйсу тигез район.

***Бахта – Биләр*** (29) селтеле соры туфракта һәм соры урман туфрагында Идел буеның юкә-имән урманнары белән Кама аръягы – Идел аръягының юкә-имән һәм юкә урманнары үсә торган уйсу район.

***Кече Чирмешән*** (8) куе соры урман туфрагында, көлсыман кара туфракта һәм соры урман туфрагында Идел буеның юкә-имән урманнары белән Кама аръягы – Идел аръягының юкә-имән һәм юкә урманнары үсә торган уйсу район.

***Чирмешән – Ык***(16) селтеле, көлсыман кара туфракта һәм соры урман туфрагында Идел буеның юкә-имән урманнары белән Кама аръягы – Идел аръягының юкә-имән һәм юкә урманнары үсә торган калку район.

***Зәй*** (15) соры урман туфрагында һәм селтеле кара туфракта Идел буеның юкә-имән урманнары белән Идел аръягының карама-имән, юкә-имән урманнары үсә торган һәм тыпчак далалары булган калку район.

***Әлмәт*** (17) селтеле һәм типик кара туфракта Идел буеның юкә-имән урманнары һәм Кама аръягы – Идел аръягының юкә-имән һәм юкә урманнары үсә торган калку район.

***Бөгелмә*** (18) селтеле һәм типик кара туфракта Идел буеның юкә-имән урманнары һәм Кама аръягы – Идел аръягының юкә-имән һәм юкә урманнары,

көнчыгышта Идел аръягының карама-имән, юкә-имән урманнары үсә торган һәм тыпчак далалары кишәрлекләре булган калку район.

### 1.1.4. Агач токымнары һәм яшь төркемнәре буенча урман утыртмалары бүленеше

Агач токымнары һәм яшь төркемнәре буенча урман утыртмаларын бүлү 2 нче кушымтада китерелде.

Урман утыртмалары белән капланган мәйданның 25% нарат утыртмаларына, 16% каты яфраклыларга, 58 % йомшак яфраклылар һәм куаклыклар өлешенә туры килә (1.1.4.1нче рәс.).




1.1.4.1 нче рәсем.Агач токымнары һәм яшь төркемнәре буенча урман утыртмалары бүленеше, мең га

Республика урманчылыкларының күпчелек урманнарында йомшак яфраклы урман утыртмалары өстенлек итә. Әгерже урманчылыгы, Арча, Зеленодольск, Исләйтар, Шәһәр яны урманчылыкларында агачларның 48%, 59%, 55%, 45%, 43%ын нарат агачлары тәшкил иткән урманчылыклар искәрмә булып тора. Мәйданның күпчелеген (70%) һәм ылыслы урман үсентеләренең запасын (83%) күбесенчә нарат агачлары биләп тора. Нарат республиканың бөтен территориясе буенча очрый, ләкин республиканың төньяк һәм үзәк районнарында (ылыслы-киңьяфраклы урман районында) алар күбрәк очрый. Көньяк районнарда төп утыртмалар бары тик ясалма барлыкка килгән. Тулаем алганда, нарат агачлары урман каплаган мәйданың 24%ын биләп тора. Ясалма утыртылган нарат агачлары гомуми наратлыкларның 79%ын били.

Ылыслы токым урман утыртмалары арасында икенче урынны чыршы агачы алып тора – 27%. Тулаем алганда, чыршы утыртмалары күп түгел – урман мәйданының 6,6%ын тәшкил итә. Табигый чыршылар чыршы утыртмалары мәйданының 20%ын тәшкил итә һәм республиканың төньяк районнарында очрый. Соңгы вакытта чыршы культуралары республиканың төньяк көнчыгышында да

таралыш тапты, ягъни табигый ареалдан читтә дә чыршы үсә, бу урман белгечләреннән аеруча зур игътибар таләп итә.

Карагай агачы барлык урманнарның 5,5 мең гектарын алып тора. Алар наратка караганда яхшырак үсәләр, югары җитештерүчән агачлар булып торалар. Республикада карагай агачлары аерым саклау участоклары итеп бүлеп бирелгән һәм ул эндемик һәм реликт токымнарга карый.

Каты яфраклы агачлар 53% мәйданда орлыктан үстерелгән имән үсентеләрен биләп тора. 34%ын түбән кәүсәле имәннәр тәшкил итә. Имән утыртмалары мәйданы 1978-1979 еллардагы салкыннар аркасында зыян килүгә бәйле рәвештә елдан-ел кими. Имән корып юкка чыкканга күрә каен, усак, өрәңге һәм юкә агачлары арта.

Республикада урман каплаган мәйданнарның 17% каен өлешенә туры килә.

Усак агачлары биләгән мәйданы һәм запасы буенча, урман барлыкка китерә торган төп токымнар арасында барлык мәйданның 20%ын биләп, беренче урында тора. Барлык усаклыклар да икенчел урманга карый. Урманнарны тоташ кисү аркасында зур гына мәйданнарда каен һәм усак утыртмалары барлыкка килде. Каен агачы ел саен үрчи, аның орлыгы үрчү өчен уңайлы вакытта җиңел тарала. Ул салкыннарга чыдам, урын шартларына артык таләпчән түгел, шуңа күрә киселгән кишәрлекләрдә тиз үсеп чыга. Республикада төрле шартларда: елга тугайларында, ком террасаларында, тау итәкләрендә һәм сазлыклы елга араларында табигый рәвештә каен урманнары калкып чыга. Усак каен белән чагыштырганда туфрак-климат шартларына таләпчәнрәк, шулай да сазлыклы һәм комлы урыннардан тыш, барлык туфракта да үсә.

Юкә агачы урман каплаган җирнең 17% ын биләп тора.

Республика урманнарында башка йомшак яфраклы урманнардан соры зирек, кара зирек, агачсыман тал һәм тирәк агачлары очрый, алар барлык мәйданның 2,5% ын тәшкил итә. Соры зирек, климатка һәм туфракка аз таләпчән агач токымы буларак, республиканың барлык районнарында да очрый. Кара зирек үсү шартларына шактый таләпчән. Бу токым дымлы һәм юеш урыннарда үсә (черемәле яисә сазлыклы тугайларда).

Тал башлыча елга тугайларында үсә, шулай да коры үзәнле туфракларда да очрый.

### 1.1.5. Урманчылыклар буенча урман үсемлекләренең токым һәм яшь структурасы

Агачларның яшь структурасы урман фондының иң мөһим күрсәткече булып тора. Ул аерым токымнар буенча да, урманнарга кагылышлы тулаем да яшь класслары буенча агачларның бертигез бүленмәве белән характерлана.

Агачларның уртача гомер озынлыгы – 46 яшь.

2 нче кушымтадан күренгәнчә, урманнарда яшь агачлар 26% биләп тора, уртача яшьтәге агачлар 35%, өлгереп килүче агачлар – 15%, өлгергән һәм карт агачлар – 24% тәшкил итә. Тулаем алганда яшь һәм уртача яшьтәге агачлар мәйданның 61% ын биләп тора. Бу күрсәткеч элек агачларның артык күп киселүен дәлилли.

Ылыслы токымнар буенча өлгергән һәм карт агачларга урман утыртмаларынын 4,3%, карт агачларга 8,4%, ә яшь һәм уртача яшьтәге агачларга 87,3% туры килә.

Бу күрсәткеч шулай ук ылыслы токымнарның яшь структурасы канәгатьләнерлек булмауны дәлилли.

Каты яфраклы агачларга чагыштырмача яхшырак яшь структурасы хас. Ләкин бу токым агачларның товар сыйфаты түбән булу, аларның тиз коруы хәзерге вакытта аларны яшьрәк һәм тазарак агачларга алмаштыру проблемасын китереп чыгара. Каты яфраклы токымнар арасында өлгергән һәм озак утырган агачлар өлешенә 12,5%, карт агачлар өлешенә 11,5% туры килә.

Кыйммәтле агачларның барлык урман мәйданының 58,1% ын биләп торуы ылыслы, каты яфраклы токымнар һәм каен утыртмалары булуга бәйле.

Йомшак яфраклы хуҗалыкта түбән сыйфатлы агачка ихтыяҗ булмаганлыктан, өлгергән һәм карт агачларның күп булуы күзәтелә (34%). Яшь агачлар өлешенә 14% туры килә. Хуҗалыкта йомшак яфраклы яшь агачларның аз булуы шулай ук каен һәм усак агачларын кискәннән соң ылыслы һәм каты яфраклы токымнар утыртылуга бәйле.

2013 елның 1 гыйнварына республика урманнарында агачның гомуми запасы 198,1 млн.м$^3$, шул исәптән ылыслы – 54,6 млн.м$^3$ (27,6%), каты яфраклы – 23,3 млн.м$^3$ (11,8%), йомшак ярфаклы – 120,1 млн.м$^3$ (60,6%) тәшкил итә.

Урманны төп барлыкка китерүче токымнарның уртача яше, нарат белән чыршыдан кала, оптималь зурлыктан артыграк – киселә торган агачларның яртысын тәшкил итә. Түбән кәүсәле имән агачлары (63 яшь), каен (50 яшь), юкә (66 яшь), усак (37 яшь) уртача яшьтәге агачлар булып санала.

Республика буенча агачлар бонитетының уртача классы 1,6 га тигез. Аеруча югары уртача класс – нарат агачларында (1а,8), усак агачларында (1,1), каен (1,2), ә иң түбәне түбән кәүсәле имәннәрдә (3,1).

Урман барлыкка китерүче төп агач токымнары арасында иң югары уртача тулылыкны усак алып тора, әлегә алар хуҗалыкта житәрлек үзләштерелмәгән.

Агач кәүсәсенең еллык уртача үсеше ( агач запасының уртача гомуми үзгәрүе) 4,3 млн.м$^3$,урман каплаган мәйданның 1 гектарга уртача үсеше – 3,8 м$^3$, агымдагы 1 гектарга – 3,7 м$^3$ туры килә.Барлык урманнарның гомуми үсешендә ылыслы агачларның артымы 25,6%, йомшак яфраклылар – 63,7% тәшкил итә.

Төп урман барлыкка китерүче агач токымнары арасында 1 гектарга иң зур запасны нарат агачлары (328 м$^3$), иң азы түбән кәүсәле имән агачлары (150 м$^3$), барлык урманнар өчен уртача – 210 м$^3$ тәшкил итә.

1.1.5.1 нче таблица

**Урман хуҗалыклары белешмәләре буенча урман барлыкка китерүче төп агач токымнары утыртмаларының уртача таксацион күрсәткечләре динамикасы**

| Күпчелекне тәшкил итүче токымнар | Урман утыртылган еллар | Уртача таксационкүрсәткечләр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | яшь, ел | бонитет | тулылык | 1 га запас, м$^3$ | | Урман каплаган җирләрнең 1 гектарыназапасның үзгәрүе, м$^3$ |
| | | | | | Урман каплаган җирләр | өлгергән һәм үсми торган карт агачлар | |
| Нарат | 1991-1994 | 43 | 1а,7 | 0,74 | 209 | 304 | 4,8 |
| | 2001-2005 | 47 | 1а,8 | 0,74 | 220 | 328 | 4,6 |

| Күпчелекне тәшкил итүче токымнар | Урман утыртылган еллар | Уртача таксационкүрсәткечләр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | яшь, ел | бонитет | тулылык | 1 га запас, м³ | | Урман каплаган җирләрнең 1 гектарыназапасның үзгәрүе, м³ |
| | | | | | Урман каплаган җирләр | өлгергән һәм үсми торган карт агачлар | |
| | Үзгәреш± | +4 | +0,1 | – | +11 | 24 | –0,2 |
| Чыршы | 1991-1994 | 24 | 1,1 | 0,71 | 71 | 257 | 2,7 |
| | 2001-2005 | 29 | 1,4 | 0,74 | 108 | 269 | 3,2 |
| | Үзгәреш± | +5 | +0,3 | +0,03 | +37 | +12 | +0,5 |
| Ак чыршы | 1991-1994 | 74 | 1,2 | 0,63 | 234 | 245 | 3,5 |
| | 2001-2005 | 70 | 1,2 | 0,62 | 229 | 239 | 3,0 |
| | Үзгәреш± | +4 | – | –0,01 | –5 | –6 | –0,5 |
| Карагай | 1991-1994 | 31 | 1а,7 | 0,76 | 167 | 309 | 5,4 |
| | 2001-2005 | 36 | 1а,7 | 0,76 | 199 | 348 | 4,9 |
| | Үзгәреш± | +5 | – | – | +32 | +39 | –0,5 |
| Кедр | 1991-1994 | 19 | 1,7 | 0,78 | 18 | - | 4,1 |
| | 2001-2005 | 13 | 1,0 | 0,72 | 38 | - | 4,1 |
| | Үзгәреш± | –6 | –0,7 | –0,06 | +20 | – | – |
| **Барлыгы ылыслы** | 1991-1994 | 39 | 1а,9 | 0,74 | 169 | 302 | 4,1 |
| | 2001-2005 | 42 | 1,0 | 0,74 | 189 | 320 | 4,2 |
| | Үзгәреш± | +3 | +0,1 | – | +20 | +18 | +0,1 |
| Имән биек кәүсәле | 1991-1994 | 42 | 2,4 | 0,65 | 89 | 144 | 2,1 |
| | 2001-2005 | 52 | 2,2 | 0,66 | 121 | 147 | 2,2 |
| | Үзгәреш± | +10 | –0,2 | +0,01 | +32 | +3 | +0,1 |
| Имән тәбәнәк кәүсәле | 1991-1994 | 57 | 3,1 | 0,60 | 120 | 141 | 2,2 |
| | 2001-2005 | 63 | 3,1 | 0,61 | 135 | 150 | 2,0 |
| | Үзгәреш± | +6 | – | +0,01 | +15 | +9 | –0,2 |
| Корычагач | 1991-1994 | 26 | 2,0 | 0,60 | 56 | - | 2,2 |
| | 2001-2005 | 35 | 1,3 | 0,75 | 124 | - | 3,4 |
| | Үзгәреш± | +9 | –0,7 | +0,15 | +68 | – | +1,2 |
| Өрәңге | 1991-1994 | 21 | 3,0 | 0,62 | 47 | 83 | 2,3 |
| | 2001-2005 | 30 | 3,0 | 0,65 | 79 | 122 | 2,2 |
| | Үзгәреш± | +9 | – | +0,03 | +32 | +39 | –0,1 |
| Карама | 1991-1994 | 41 | 3,2 | 0,51 | 72 | 101 | 1,9 |
| | 2001-2005 | 43 | 3,0 | 0,55 | 87 | 121 | 1,9 |
| | Үзгәреш± | +2 | –0,2 | +0,04 | +15 | +20 | – |
| **Барлыгы каты яфраклы** | 1991-1994 | 44 | 2,7 | 0,63 | 94 | 140 | 2,0 |
| | 2001-2005 | 53 | 2,6 | 0,64 | 121 | 150 | 2,1 |
| | Үзгәреш± | +9 | –0,1 | +0,01 | +27 | +10 | +0,1 |
| Каен | 1991-1994 | 44 | 1,0 | 0,72 | 155 | 188 | 3,7 |
| | 2001-2005 | 50 | 1,2 | 0,69 | 165 | 189 | 3,2 |
| | Үзгәреш± | +6 | +0,2 | –0,03 | +10 | +1 | –0,5 |
| Усак | 1991-1994 | 35 | 1,1 | 0,79 | 167 | 228 | 5,0 |
| | 2001-2005 | 37 | 1,1 | 0,77 | 170 | 231 | 4,5 |
| | Үзгәреш± | +2 | – | –0,02 | +3 | +3 | –0,5 |
| Соры | 1991-1994 | 40 | 2,5 | 0,56 | 86 | 107 | 2,2 |

| Күпчелекне тәшкил итүче токымнар | Урман утыртылган еллар | Уртача таксационкүрсәткечләр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | яшь, ел | бонитет | тулылык | 1 га запас, м³ | | Урман каплаган җирләрнең 1 гектарыназапасның үзгәрүе, м³ |
| | | | | | Урман каплаган җирләр | өлгергән һәм үсми торган карт агачлар | |
| зирек | 2001-2005 | 38 | 2,4 | 0,60 | 106 | 137 | 2,5 |
| | Үзгәреш± | –2 | –0,1 | +0,04 | +20 | +20 | +0,3 |
| Кара зирек | 1991-1994 | 47 | 2,4 | 0,56 | 96 | 125 | 2,2 |
| | 2001-2005 | 45 | 2,4 | 0,60 | 104 | 138 | 2,1 |
| | Үзгәреш± | –2 | – | +0,04 | +8 | +13 | –0,1 |
| Юкәй. | 1991-1994 | 60 | 2,6 | 0,63 | 186 | 223 | 3,2 |
| | 2001-2005 | 66 | 2,6 | 0,64 | 205 | 231 | 3,1 |
| | Үзгәреш± | +6 | – | +0,01 | +19 | +8 | –0,1 |
| Тирәк | 1991-1994 | 29 | 2,0 | 0,67 | 182 | 253 | 6,3 |
| | 2001-2005 | 34 | 2,4 | 0,54 | 175 | 206 | 5,2 |
| | Үзгәреш± | +5 | +0,4 | –0,13 | –7 | –47 | –1,1 |
| Тирәк культуралары | 1991-1994 | | | | | | |
| | 2001-2005 | 23 | 2,0 | 0,71 | 177 | 297 | 6,7 |
| | Үзгәреш± | | | | | | |
| Тал агачы | 1991-1994 | | | | | | |
| | 2001-2005 | 23 | 2,6 | 0,58 | 108 | 201 | 5,1 |
| | Үзгәреш± | | | | | | |
| **Барлыгы йомшак яфраклы** | 1991-1994 | 47 | 1,5 | 0,70 | 172 | 218 | 3,7 |
| | 2001-2005 | 50 | 1,6 | 0,70 | 177 | 216 | 3,6 |
| | Үзгәреш± | +3 | +0,1 | – | +5 | –2 | –0,1 |
| Куаклыклар (таллык) | 1991-1994 | 8 | 2,9 | 0,63 | 20 | 20 | 2,0 |
| | 2001-2005 | 7 | 3,0 | 0,61 | 15 | 16 | 2,0 |
| | Үзгәреш± | –1 | +0,1 | –0,02 | –5 | –4 | – |
| **Барлыгы рес-публика буенча** | 1991-1994 | 47 | 1,6 | 0,70 | 163 | 209 | 3,9 |
| | 2001-2005 | 48 | 1,6 | 0,70 | 169 | 210 | 3,8 |
| | Үзгәреш± | +1 | – | – | +6 | +1 | –0,1 |

Өлгергән һәм карт урман запаслары 2013 елның 1 гыйнварына 57,12 млн.м$^3$яисәгомуми урман запасының 28%ын тәшкил итә.

Республиканың табигать комплексларына антропоген йогынтыга бәйле үзгәрешләр дәүләт хакимияте органнары тарафыннан экологик хәлне оптимальләштерү буенча чаралар күрү өчен нигез булды. Соңгы 15 елда Татарстан Республикасы дәүләт органнары тарафыннан табигатьне саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалануның төрле юнәлешләре буенча 28 закон һәм йөздән артык законлы акт кабул ителде. 1993 елдан башлап, Татарстан Республикасы Экология һәм табигатьне саклау министрлыгы тарафыннан ел саен «Татарстан Республикасы табигать ресурслары торышы һәм әйләнә-тирә мохитне саклау турында» дәүләт докладлары басылып чыга, аларда экологик мониторингның нәтиҗәләре чагылыш таба.

Урман фонды торышын анализлау шуны күрсәтә: урман утыртмалары аларның продуктивлыгын арттыруга һәм савыктыру, саклау функцияләрен яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыруны дәвам итүгә һәм урман җирләрен нәтиҗәле файдалануга мохтаҗ.

Әйләнә-тирә мохитне һәм биотөрлелекне саклау проблемалары саклау түбәндәге ысуллар белән хәл ителде:

урманнарны янгыннан саклау;

урманнарның санитар хәлен яхшырту;

агачларның тазалыгына бәя бирү;

урманнарны торгызу һәм үрчетү;

хайваннар дөньясын саклау.

Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгып баручы төрләрне саклау.

Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм биомониторинг системасында Татарстан Республикасы Кызыл китабы зур әһәмияткә ия. Ул – юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар, үсемлекләр һәм гөмбәләр төрләренең сирәк очрый торган башка шундый объектларның таралуы, саны, торышы һәм саклау чаралары турындагы мәгълүматны үз эченә алган рәсми документ. Татарстан Республикасы Кызыл китабы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Кызыл китабы турында» 1993 елның 25 октябрендәге 615 номерлы карары белән гамәлгә куелды. Беренче Кызыл китап 1995 елда басылып чыкты. 2006 елда Татарстан Республикасы Кызыл китабының икенче басмасы чыкты.

Татарстан Республикасы Кызыл китабындагы Татарстан Республикасы территориясендә сакланырга тиешле, юкка чыгу куркынычы янаган һәм сирәк очрый торган агачлар һәм куаклар исемлеге бирелде 1.1.8.3 нче таблицада бирелде.

1.1.8.3нче таблица

**Сирәк очрый торган агач һәм куак төрләре исемлеге**

| Кызыл китапка кертелгән токымнар | Сирәк очрый торган категорияләр |
|---|---|
| Куаклар | |
| Башаксыман карлыган | 2 |
| Лапландия талы | 3 |
| Тәбәнәк тал | 2 |
| Филик яфраклы тал | 2 |
| Гади бүре җиләге | 3 |
| Ике башаклы эфедра | 3 |

Гади артыш, себер ак чыршысы, кан-кызыл дүләнә, кыргый алмагач, розмарин яфраклы тал Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелмәгән сирәк һәм четрекле, ләкин республика территориясендә даими контрольдә һәм күзәтүдә тотылырга тиешле таксоннар исемлегенә кертелде.

Район һәм республика газеталарында Кызыл китапка кертелгән сирәк һәм юкка чыгып баручы төрләргә багышланган статьялар бастыру зарур. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән аучылык объекты булырга мөмкин булган хайваннары төрләре турында плакатлар яисә буклетлар булдырырга кирәк. Бу плакатлар җыелышларда (администрация, клуб, мәктәп биналарында) даими эленеп торырга тиеш.

Нинди дә булса хуҗалык эшчәнлеге чикләнгән яисә тыелган Татарстан Республикасы урманнары мәйданы республикада 614,5 мең га (урман фонды җирләренең (49,7%) яисә Татарстан Республикасы мәйданнарының 9,1% мәйданнарын тәшкил итә, бу биотөрлелекне һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләрне саклап калыр өчен җитәрлек мәйдан.

Саклanулы урманнарда һәм хуҗалык эшчәнлеге чикләнгән яисә тыелган аеруча сакланулы урманнарда урнашкан урман кишәрлекләре челтәре барлык урманчылыклар буенча бүленгән. Ул мәйданнарның үзенчәлекле каркасын булдыра, бары тик әйләнә-тирә мохитне Кызыл китапка кертелгән биотөрлелекне саклап калу өчен генә түгел, интенсив антропоген (беренче чиратта техноген) йогынтыга дучар ителгән район территорияләре буенча аларны тарату өчен дә кирәк.

Моннан тыш, урманчылыклар территориясендә махсус сакланылучы урман кишәрлекләре (917,9 мең га) һәм өлгергән, артык утырган агачлы кишәрлекләр – 1 гектарга 50 $м^3$ запас белән һәм кимендә хуҗалык эшчәнлеге алып барылмый торган (9,9 мең га) кишәрлек бар. Мондый кишәрлекләр шулай ук Кызыл китапка кертелгән биотөрлелекне һәм төрләрне саклап калу урыннары да булып тора.

Хайваннарның, үсемлекләрнең, гөмбәләрнең төрле төрләре урын шартларына яшь структурасына һәм токым составына тыгыз бәйле.

Хуҗалык эшчәнлеге чикләнгән яисә тыелган урыннар буенча өлгергән һәм артык утырган агач токымнары буенча бүлү 1.1.7.2 таблицада китерелде.

Әйләнә-тирә мохитка зарарлы йогынтыны киметү һәм агач әзерләгәндә табигый компонентларны торгызуны тәэмин итү өчен түбәндәге чаралар каралган:

1. Урман кисү һәм урманны тазарту эшләренең технологияләрен нигезләү (урманны аралап кисү – үсемлекләрнең үсү шартларын, агачларның таксацион үзенчәлекләрен, агач әзерләү сезонын исәпкә алып, агач әзерләү машиналарыннан дефференцациялэнгән файдалану мөмкинлеге).

2. Туфракта эрозияне булдырмау максатында сезонлы әзерләүне һәм грунтларның үзенчәлеген исәпкә алып мәйдан буенча агач кисү алымнарын бүлү.

3. Агач кисү һәм агач утырту арасында балансны саклау.

4. Урманны тазарту максатында кисү.

5. Урманны торгызу.

6. Урманны саклау чаралар кўрү.

7. Янгынга каршы чаралар.

8. Россия Федерациясе Су кодексы нигезендә су саклау зонасында хуҗалык итү режимын катгый саклау.

Үзагач әзерләү нормалары һәм кагыйдәләре үсемлекләрнең биотөрлелеген һәм хайваннар дөньясын саклауга ярдәм итә, аларның түбәндәгеләре нигез булып тора:

– ел саен киселә торган үзагачның күләме урманнан файдалануның өзлексезлек һәм тулылык принцибы буенча исәпләнә торган урман кисү күләме белән чикләнә;

– киселә торган урман кишәрлекләренең күләмнәре һәм мәйданнары нормадан артык булмый;

– киселә торган урман кишәрлекләренең янәшәсендәге урман кишәрлекләрендә алып барыла торган эшләр исәпкә алына;

– елга ярлары буенча сусаклагыч һәм яр саклагыч утыртмалар, юл буйларындагы яр саклау полосалары, авыл хуҗалыгы җирләренең һәм торак пунктларның саклау полосалары сакланып кала;

– кыр тавыклары оялары тирәсендә, кондыз яши торган яр буйларында махсус сакланулы кишәрлекләр бүленә;

– киселә торган урман кишәрлекләрегн әзерләү урманнарны тиз арада яңарту, яшь үсентеләрне саклауга ярдәм итүче кагыйдәләр буенча, орлыклы агачлар, агач клумбалары калдырыла, урман үсентеләре шартларына җавап бирә торган урыннарда сайлап алып кисү алымнары, аеруча экологик алым буларак билгеләнә;

– бозылган җирләр (агач ташу юллары, төяү-бушату мәйданнары һәм башкалар) эш тәмамлангач торгызыла (техник, биологик яктан, ягъни урман культуралары утыртыла).

Республика территориясендә аучылык ресурсларын саклау зоналары бүленмәгән.

### 1.1.9. Урманнарның торышы һәм аларның хәле үзгәрү, урманчылыклар буенча аларның максатчан билгеләнеше турында, шулай ук урман үсемлекләре зоналарында һәм урман районнары турында башка белешмәләр

Россия Федерациясе Урман кодексы нигезендә үзләренең максатчан билгеләнеше буенча республика урманнары сакланулы һәм эксплуатацияләнә торганнарга бүленә.

«Россия Федерациясе Урман кодексын гамәлгә кертү турында» 2006 елның 4 декабрендәге 201-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясы нигезендә «Урман фонды җирләрендә Россия Федерациясе Урман кодексы гамәлгә кергәнгә кадәр төзелгән яшел зоналарның урман парк өлешләре һәм урман хуҗалыгы өлешләре Россия Федерациясе Урман кодексының 102 статьясында каралган урман парк зоналары һәм яшел зоналар итеп үзгәртелергә тиеш.

Урман парк зоналарының һәм яшел зоналарның мәйданнарын билгеләү нормативлары Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм Экология министрлыгы тарафыннан билгеләнә (урман планына үзгәрешләр кертелгән вакытка нормативлар билгеләнмәде).

Максатчан билгеләнеше һәм сакланулы урман категорияләре буенча урман мәйданнарын бүлү турында белешмәләр 31 нче кушымтада китерелә.

Россия Федерациясе Урман кодексы гамәлгә кергәннән соң сакланулы урманнарның түбәндәге категорияләре өстәмә рәвештә бүленде:

– су саклау зоналарында урнашкан урманнар;

– Татарстан Республикасы милкендәге гомуми файдалану автомобиль юллары буйлап урнашкан сакланулы урман полосалары.

Нәтиҗәдә, сакланулы урманнарның мәйданы Татарстан Республикасы урманчылыклары буенча 31,8 мең гектарга артты (5,9%).

## 1.2. Урман планын әзерләү алдыннан килә торган елда Татарстан Республикасы территориясендә урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызуга социаль-икътисадый бәяләмә

### 1.2.1. Россия Федерациясе бюджет системасы дәрәҗәләре буенча урманнардан файдаланудан алынган керемнәр

Урманнардан файдаланган өчен түләүләр Татарстан Республикасында урман хуҗалыгы чараларын финанслауның төп чыганагы булып тора. 2012 елда урман кеременең гомуми суммасы 120285,6мең сум тәшкил итте, шунын 115738,9 мең сумы федераль бюджетка һәм 4546,7мең сумы Татарстан Республикасы бюджетына керде.

2012 елда урманнардан файдаланган өчен федераль бюджетка суммалар 111481,2 мең сум (гомуми түләүләр суммасының 96%ы), аренда түләве – 102171,4мең сум (гомуми аренда түләве суммасының 88% ) тәшкил итте.

Татарстан Республикасында федераль бюджетка акча кеременең төп чыганагы төрле файдаланулардан аренда шартнамәләре буенча аренда түләвеннән гыйбарәт:рекреацион эшчәнлек башкару(45%), җир асты байлыкларын геологик өйрәнү файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү (34%). Факттагы түләүләр суммасы буенча белешмәләр 1.2.1.1нче таблицада китерелде.

1.2.1.1 нче таблица

**2012 елда файдалану төрләре буенча Татарстан Республикасы урманнарыннан файдаланган өчен түләүләр**

| Куллану төре | Бюджет дәрәҗәләре буенча аренда шартнамәләре һәм сату-алу шартнамәләре буенча түләүләрдән факттагы керем | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | шул исәтән: урманнардан файдалану нигезләре төрләре буенча | | | федераль бюджет | Татарстан Республикасы бюджеты |
| | | аренда шартнамәләре буенча | сату-алу шартнамәләре буенча | үз ихтыяҗлары өчен сату-алу шартнамәләре буенча | | |
| Урманнардан файдаланудан алынган керем | 120285.6 | 102171,4 | 9281,3 | 4575.2 | 115738.9 | 4546,7 |
| шул исәптән урманнардан файдаланган өчен түләү | 116027,9 | 102171,4 | 9281,3 | 4575,2 | 111481,2 | 4546,7 |
| Үзагач әзерләү | 16521,2 | 2664,7 | 9281,3 | 4575.2 | 11946,0 | 4575,2 |
| шул исәптән тоташ кисүләр | 7278,3 | 1893,1 | 810,0 | 4575,2 | 2703,1 | 4575,2 |
| сайлап кисү | 9242,9 | 771.6 | 8471,3 | 0 | 9242,9 | 0 |
| Үзагач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю | 150.8 | 150,8 | | | 150.8 | |
| Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру | 23,8 | 23,8 | | | 23,8 | |

| Куллану төре | Бюджет дәрәҗәләре буенча аренда шартнамәләре һәм сату-алу шартнамәләре буенча түләүләрдән фактагы керем | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | шул исәптән: урманнардан файдалану нигезләре төрләре буенча | | | федераль бюджет | Татарстан Республикасы бюджеты |
| | | аренда шартнамәләре буенча | сату-алу шартнамәләре буенча | үз ихтыяжлары өчен сату-алу шартнамәләре буенча | | |
| Авыл хуҗалыгын алып бару | 88,9 | 88,9 | | | 88,9 | |
| Рекреацион эшчәнлек башкару | 52338,4 | 52338,4 | | | 52366,9 | -28,5 |
| Урман җиләкләре, декоратив үсемлекләр, дару үләннәре үстерү | 0,4 | 0,4 | | | 0,4 | |
| Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар ятмаларын табу буенча эшләр башкару | 39782,7 | 39782,7 | | | 39782,7 | |
| Сусаклагычларны һәм башка ясалма су объектларын, шулай ук гидротехник корылмаларны һәм махсуслашкан портларны төзү һәм эксплуатацияләү | 1393,7 | 1393,7 | | | 1393,7 | |
| Линия объектларын төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү | 5727,7 | 5727,7 | | | 5727,7 | |
| Россия Федерациясе Урман кодексының 6 статьясы 2 өлеше нигезендә билгеләнгән башка төрләр | 0,3 | 0,3 | | | 0,3 | |
| Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән федераль бюджетка башка керемнәр (дәүләт урман реестрыннан өземтәләр биргән өчен) | 91,7 | 91,7 | | | 91,7 | |
| Акчалата түләүләрдән (штрафлардан) һәм башка суммалардан бүтән керемнәр | 2372,7 | | | | 2372,7 | |
| Урман турындагы законнарны бозган өчен федераль | 1529,0 | | | | 1529,0 | |

| Куллану төре | Бюджет дәрәҗәләре буенча аренда шартнамәләре һәм сату-алу шартнамәләре буенча түләүләрдән фактгагы керем | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | шул исәптән: урманнардан файдалану нигезләре төрләре буенча | | | федераль бюджет | Татарстан Республикасы бюджеты |
| | | аренда шартнамәләре буенча | сату-алу шартнамәләре буенча | үз ихтыяҗлары өчен сату-алу шартнамәләре буенча | | |
| милектәге урман кишәрлекләрендә билгеләнгән акчалата түләүләр (штрафлар) | | | | | | |
| Урман җирләрен урманга карамаган җирләргә күчергән һәм урман фонды җирләрен башка категорияләрдәге җирләргә күчергән өчен түләү | 104,9 | | | | 104,9 | |
| Федераль бюджетка салым булмаган башка керемнәр | 159,4 | | | | 159,4 | |

### 1.2.2. Урман сәнәгате производствосы һәм агач эшкәртү продуктларын, башка урман ресурсларын экспортка чыгару күләмнәре

Татарстан Республикасы куәтле чимал базасы булмаган аз урманлы регионнарга карый. 2013 елның 1 гыйнварына республиканың урман каплаган мәйданы 1187,4 мең га (урманлылык проценты – 17,5) тәшкил итә. Тамыр запасы 198,1 млн. $м^3$ итеп бәяләнә, шул исәптән йомшак яфраклылар токымы – 120,1 млн. $м^3$, шуның 41%ы – өлгергән һәм артык утырган агачлар.

Барлык урманчылыкларда да яфраклы токымнар өстенлек итә, алар урманнарның 72% биләп тора. Усаклык республика буенча барлык мәйданның 20% тәшкил итә. Яфраклы агачлар токымына ихтыяҗ юк, чөнки чимал файдаланылмый. Киселә торган урман кишәрлекләреннән файдалану дәрәҗәсе 2012 елда тулаем республика буенча 34%тан артмады.

2012 елда продукциянең төп төрләрен житештерү күләмнәре һәм аларның экспорт өлеше 1.2.2.1нче таблицада китерелде.

1.2.2 нчетаблица

**2012 елда урман сәнәгате, экспортка эшкәртелгән үзагач продуктлары һәм башка урман ресурслары күләменең натураль чагылышы**

| Продукция төре | исәпләү берәмлеге | производство күләме | экспорт күләме | житештерү күләмендә экспорт өлеше ,% |
|---|---|---|---|---|
| Түгәрәк урман материаллары | мең куб. м | 147,3 | – | 0 |
| шул исәптәнэшкә яраклы үзагач | мең куб. м | 75,8 | – | 0 |
| Пиломатериаллар, барлыгы | мең куб. м | 7,06 | – | 0 |
| шул исәптән ылыслы | мең куб. м | 2,9 | | |
| Ябыштырылган фанера | мең куб. м | 107,5 | 51,5 | 48 |
| Әзер целлюлоза | мең т | – | – | – |
| Кәгазь | мең т | 54,848 | – | – |
| Картон | мең т | 158,718 | – | – |
| Агач-йомычка плиталар | куб. м | – | – | – |
| Агач-җепсел плиталар | мең кв. м | – | – | – |
| Башкалар: | | | | |
| Ишек блоклары | мең кв. м | 97,7 | – | – |
| Тәрәзә блоклары | мең кв. м | 206,5 | – | – |
| Аркылыга киселгән шпон | мең кв. м | 398,0 | – | – |
| Урындыклар | шт. | 11558 | – | – |
| Диван-кроватьлар | шт. | 748 | – | – |
| Шкафлар | шт. | 3635 | – | – |
| Өстәлләр | шт. | 5115 | – | – |
| Агач кроватьлар | шт. | 1699 | – | – |

Эчке һәм тышкы базарларда сатыла торган продукциядән бары тик фанераны гына атарга мөмкин. Эчке базарда сатыла торган продукциянең төп төрләре – түгәрәк үзагач материаллары, пиломатериаллар, шпон, фанера, картон.

1.2.2.2 нче таблица

**Татарстан Республикасы сәнәгать продукциясендә сәнәгать тармакларының чагыштырма өлеше үзгәрү динамикасы, %**

| Сәнәгать өлкәләре | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Ягулык | 37,7 | 38,1 | 38,9 | 40,5 | 35,7 | 33,1 | 31, 1 | 28,9 | 26,8 | 17,3 |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | |
| нефть чыгару | 36,5 | 36,8 | 37,6 | 39,1 | 34,2 | 31,1 | 28,4 | 26,3 | 24,1 | 15,0 |
| нефть эшкәртү | 1,1 | 1,3 | 1,4 | 1,4 | 1,5 | 2,0 | 2,7 | 2,6 | 2,6 | 2,4 |
| Электрэнергетикасы | 6,9 | 6,7 | 6,7 | 6,5 | 6,8 | 6,7 | 6,4 | 6,1 | 6,1 | 5,0 |
| Химия һәм нефть химиясе | 17,1 | 17,3 | 17,1 | 16,6 | 18,8 | 19,9 | 21,2 | 24,2 | 24,4 | 30,1 |
| Машина төзелеше | 23,0 | 23,3 | 23,5 | 23,7 | 26,8 | 28,7 | 30,1 | 29,3 | 31,8 | 38,2 |
| Азык-төлек | 9,1 | 8,6 | 7,2 | 6,6 | 6,7 | 6,4 | 6,2 | 6,2 | 5,8 | 4,7 |
| Җинел | 0,9 | 0,7 | 0,7 | 0,7 | 1,0 | 1,2 | 1,2 | 1,3 | 1,3 | 1,5 |
| Фармацевтика | | | | 0,2 | 0,2 | 0,3 | 0,4 | 0,3 | 0,3 | 0,2 |
| Урман һәм агач эшкәртү | 1,5 | 1,4 | 1,4 | 1,2 | 1,2 | 1, 2 | 1,1 | 1,1 | 1,2 | 2,0 |
| Төзелеш материаллары | 1,7 | 1,7 | 2,5 | 2,3 | 2,3 | 2,3 | 2,4 | 2,5 | 2,3 | 1,4 |

Татарстан Республикасы урманнары өчен иң зур проблемаларның берсе – усакка ихтыяҗның булмавы. Шул ук вакытта ылыслы агачларга һәм каенга ихтыяҗ зур. Түбән сыйфатлы, ихтыяҗ булмаган агачлар диләнкәләрдә кала, чөнки аларны чыгару бу эшнең үзкыйммәтен капламый.

Шуңа бәйле рәвештә, шулай ук традицион энергетика ресурсларына (электр энергиясе, нефть продуктлары һәм башкаларга) тарифлар югары булганлыктан барлыкка килгән калдыкларны һәм түбән сыйфатлы агачны, аерым алганда, биоягулык буларак файдалану өчен каралган агачларныүтилләштерү актуаль мәсьәләләрнең берсенә әверелә бара.

Урман продукциясенең җитештерү технологияләрен куллану нигезендә, продукция күләменең 20% – агач әзерләү калдыклары, 35-55%, – пычкы чүбе тәшкил итә, китерелгән чимал күләменең 60% –фанера җитештергәндәге калдыклар, 20% – ЦБП агач калдыклары тәшкил итә. Агач әйберләре, мебель һәм башкаларны җитештергәндә калдыклар продукция күләменең 50%ын тәшкил итә. Калдыкларның бер өлеше технологик материал рәвешендә целлюлоза – кәгазь сәнәгатендә кулланыла, бер өлеше плиталар җитештерүгә китә. Ләкин агач калдыкларының күпчелеге ташлана яисә диләнкәләрдә кала.

Бу биоэнергетика куәте урман сәнәгате комплексы өчен яңа потенциал базарлар ача, дөрес файдаланган очракта җылылык электр энергиясе алу хисабына

социаль, экологик һәм икътисадый проблемаларның шактыен хәл итәргә мөмкин булыр иде.

Биоэнергетика үсеше шулай ук урман хуҗалыгы проблемасын хәл итәргә - усак һәм башка артык утырган агачларны (кагыйдә буларак, яфраклы), сәнәгать өчен яраксыз урман утыртмаларын үзләштерү һәм эшкәртүгә ярдәм итәчәк.

Кәгазь продукциясен җитештерү, куллану һәм дөнья буенча, урман сәнәгате алга киткән илләр буенча сату тенденциясен түбәндәгеләр гомумиләштерә[1]:

Чит илләрнең абсолют күпчелегендә урман сәнәгате комплексы даими үсә. Агачны читкә чыгару, пиломатериаллар җитештерү күләмнәре арта.

Чит илләрнең күпчелеге урман сәнәгатенең җитештерү структурасын камилләштерүгә, барыннан да элек әзерләнгән үзагачны һәм агач калдыкларын тирән эшкәртү, җитештерүләрен даими арттыруга йөз тота.

Хәзерге урман сәнәгате җитештерүенең төп асылы – җитештерүнең югары техник дәрәҗәдә булуы, югары житештерүчән машиналар һәм җиһазлар куллану.Конкурентлыкка сәләтле продукция җитештерүне һәм продукция ассортиментын киңәйтүне тәэмин итә торган прогрессив технологик процесслардан файдалану шуның ачык чагылышы.

Агач материалларының төп төрләрен житештерү күләмнәрен һәм урман сәнәгате производствосының югары техник дәрәҗәсен арттыру эчке һәм тышкы базарларда кәгазь продукциясенә булган тотрыклы ихтыяҗга бәйле.

Чит илләрнең күбесендә урман товарлары белән сәүдә итү көннән-көн арта. Алга киткән илләрдә валюта кеременең якынча өчтән икесе целлюлоза, кәгазь һәм картон сатудан керә, бу урман сәнәгате производство структурасын агачны тирән эшкәртүне үстерү юнәлешендә камилләштерүнең нәтиҗәлелеген раслый.

Урман бизнесын трансмилли интеграцияләнгән структуралар юнәлешендә төзү югары өстәлгән бәяле продукциягә бәяләрнең тирбәлешен туктата һәм агач чималына бәянең кимүенә китерә.

Урман сәнәгате комплексын үстерүдә чит илләрдәге прогрессив тенденцияләр соңгы елларда алга киткән илләрдә тулаем эчке продуктның үсешен тәэмин итүче уңай факторларның берсе булып тора.

Югарыда әйтелгәннәр нигезендә агач һәм аның продуктларын җитештерү һәм куллану озак сроклы һәм урта сроклы перспективада үсеш тенденциясенә ия. Барлыкка килгән тенденция Россия урман сәнәгате комплексы өчен зур мөмкинлекләр ача. Россия урман белән тәэмин ителеш буенча дөнья буенча беренче урында тора (81 млрд. куб метрдан артык), дөньяви агач запасының дүрттән бер өлешен били, бу АКШка караганда 3,5 тапкырга, Канадага караганда 3 тапкырга артык. Урманны исәпле кисү 500 млн. куб метрдан артык. Россия агачы физик-механик, табигый һәм урман күрсәткечләре параметрлары буенча бик югары сыйфатлы булып тора.

Россия экспортының бәя структурасында урман һәм целлюлоза-кәгазь индустриясенең төп биш товары арасында 2012 ел йомгаклары буенча пиломатериаллар һәм түгәрәк агач алдынгы позициядә тора, 45% һәм 20% тәшкил

---

[1] Электрон ресурс www.fao.org. www.government.ru

итә. Башка экспорт позицияләре арасында экспорт бәясе өлешендә фанера сату 12%, целлюлоза 14% һәм читкә газета кәгазе чыгарудан валюта табышы9%тәшкил итә.

Фанера һәм целлюлоза экспортының физик күләмнәре 2012 елда үсештә булды, алай гына да түгел, хисап елында фанера бушату шактый артты, ә агач целлюлозасын ташу бер елга 12% артты. Газета кәгазен читкә чыгару күләмнәре генә бер елда 1,4%ка кимеде. Барлык өч позиция буенча да экспорт бәяләре кимеде. Газета кәгазе бер ел эчендә уртача 9%ка кимеде. Фанера һәм целлюлоза буенча тышкы сәүдә бәяләренең кимүе 2011 ел белән чагыштырганда сизелерлек булды – фанера узган елга караганда 14% кимрәк бәядән сатылды, ә целлюлоза бер елда уртача 21% бәясен югалтты. Барлык экспорт товар позицияләре буенча 2012 хисап елында ерак чит илләргә экспорт күләмнәренең кимү тенденциясе билгеләп үтелде. Целлюлозаны һәм аз дәрәҗәдә фанераны читкә чыгару гына искәрмә булып торды. Якын чит илләр киресенчә соңгы ике елда, аеруча хисап елында агач- кәгазь продукциясе экспортын арттырдылар. Бу тенденция беренче чиратта фанерага кагылды. Газета кәгазен һәм целлюлозаны читкә чыгару аерым алганда, БДБ илләренә натураль күрсәткечләр буенча бер елда 64% ка һәм 35% ка артты. Шулай ук БДБ илләренә 2012 елда түгәрәк агач һәм пиломатериаллар сату да шактый артты, 45% түгәрәк агачка һәм 13% пиломатериалга.

2012 елда Татарстан Республикасы урман сәнәгате комплексында җитештерү күләме – 14,67 млрд. сум,шул исәптән, агач эшкәртү һәм агачтан әйберләр җитештерү 2,75 млрд. сум (ИПП – 1-2,1%) тәшкил итте.

Тулаем алганда, үткәрелгән анализ гофрокартон базарында конкуренция артуга бәйле рәвештә картон җитештерү шактый кимүгә карамастан, агач эшкәртү сәнәгате предприятиеләренең җитештерүчәнлеген уңай яктан дәлилли.

Агач эшкәртү сәнәгатендә 2012 елда җитештерүне түбәндәге предприятиеләр арттырды:

«Идел буе фанера-мебель комбинаты» ҖЧҖ - 107,9%;

«С.П.Титов исемендәге Чаллы кәгазь-картон комбинаты»МП ЯАҖ ИПП - 104,1%;

«Зеленодольск фанера заводы» ААҖтөп җиһазларга плансыз ремонтка һәм кадрлар җитмәүгә бәйле рәвештә җитештерү күләмнәрен 6% ка киметте, сәнәгать җитештерүе индикаторы - 94% тәшкил итте.

Тармакта төп проблемалар җайланмаларның искерүенә һәм квалификацияле кадрларның җитмәвенә бәйле.

Бу проблемаларны хәл итү өчен 2012 елда предприятиеләр тарафыннан «Сакчыл җитештерү» принциплары эшләнде һәм гамәлгә кертелде, җитештерүне модернизацияләү проектлары эшләнде. Мәсәлән,«С.П.Титов исемендәге Чаллы кәгазь-картон комбинаты»нда «Бобст» (Швейцария) фирмасының заманча җайланмасы урнаштырылды, ул яссы сетка технологиясе буенча гофроупаковка җитештерүгә мөмкинлек бирәчәк.

Агач эшкәртү тармагы инвестиция җәлеп итүчән булып кала, бу турыда 2012 елда булган чит ил инвестицияләре күләмнәре буенча фикер йөртергә мөмкин, алар 82,4 млн. АКШ долларын тәшкил итте. Инвестицияләрнең күп өлеше инвестиция проектларына туры килә.

«Кастамону Энтегре»компаниясе тарафыннан агач плитәләр җитештерү проектын гамәлгә ашыруга 3,4 млрд.сум планлаштырылган акчаның 2,4 млрд. сумы үзләштерелде. 2013 елда МДФ плиталар җитештерүнең беренче линиясе сафка бастырылды.

2012 елда санитар-гигиена кәгазен җитештерү буенча бер елга 60 мең тонна егәрлектә эшли торган «ХаятКимья» заводы төзелә башлады, планлаштырылган инвестицияләр күләме 2 млрд. сум тәшкил итә, файдалануга тапшыру елы – 2016.

«Кастамону Энтегре» ҖЧҖ (Төркия) проектын гамәлгә ашыру белән плитәләрне алга таба эшкәртү тармакның өстенлекле бурычларыннан берсе булачак. Бу завод продукциясе мебель сәнәгать үсеше һәм республикада мебель һәм комплектлау детальләрен җитештерү кластеры төзү өчен нигез булырга тиеш.

### 1.2.3. Татарстан Республикасы икътисадының урман секторында халыкның эш белән тәэмин ителеше, эшләүчеләр санын кертеп, характеристикасы, хезмәт хакының уртача дәрәҗәсе, социаль тәэминат

Республика урман сәнәгате комплексында сәнәгать үсеше темпларын арттыру тиешле хезмәт ресурслары һәм җитештерү базасы белән тәэмин ителә. Татарстан Республикасы урман сәнәгать комплексында эшләүчеләр саны 2013 елда 6428кеше тәшкил итте. Республика буенча эш белән тәэмин ителгән гомуми санның УСК да эшләүчеләр саны 5% тәшкил итә (1.2.3.1нче табл.).

1.2.3.1нче таблица

**2008 - 2018 еллардаТатарстан Республикасы урман сәнәгате комплексында эшләүчеләрнең исемлек буенча уртача саны**

| Күрсәткеч | Халык саны | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 |
| Татарстан Республикасы икътисадында эшләүчеләр | 1 381 300 | 1 346 300 | 1 349 600 | 1 344 700 | 1 363 800 | 1 353 800 | 1 350 400 | 1 350 400 | 1 350 400 | 1 350 400 | 1 350 400 |
| Урман комплексында эшләүчеләр-нең исемлек буенча уртача саны, барлыгы | 6712 | 5989 | 5863 | 5871 | 6524 | 6428 | 6704 | 6739 | 6739 | 6739 | 6739 |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | | |
| Урман сәнәгате комплексы, шул исәптән: | 2941 | 2866 | 2874 | 2863 | 3637 | 3851 | 3944 | 3980 | 3980 | 3980 | 3980 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| - агач эзерлэү | 756 | 737 | 739 | 735 | 747 | 741 | 739 | 739 | 739 | 739 | 739 |
| - агач эшкәртү һәм агач әйберләре житештерү | 2185 | 2129 | 2135 | 2128 | 2890 | 3110 | 3205 | 3241 | 3241 | 3241 | 3241 |
| Кечс предприятие-ләр, шул исэптэн: | 553 | 538 | 540 | 538 | 546 | 542 | 541 | 540 | 540 | 540 | 540 |
| - урман хужалыгы һәм шул өлкәдә хезмәт күрсәтү | 187 | 181 | 182 | 181 | 184 | 182 | 183 | 182 | 182 | 182 | 182 |
| - агач эшкәртү һәм агач әйберләре житештерү | 366 | 357 | 358 | 357 | 362 | 360 | 358 | 358 | 358 | 358 | 358 |
| Урман хужалыгы | 3218 | 2585 | 2449 | 2470 | 2341 | 2035 | 2219 | 2219 | 2219 | 2219 | 2219 |
| Республика икътисадында эшләүчеләрнең гомуми саныннан урман комплексында эшләүчеләр өлеше,% | 0,5 | 0,4 | 0,4 | 0,4 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 |

Эшнең юнәлеше хезмәт хакы үсеше белән билгеләнә (1.2.3.2нче табл.). УТК хезмәткәрләренең уртача хезмәт хакы 2013 елда 14587 сум тәшкил итте. Бу мәсьәләдә дәүләт идарәсе индикаторларының берсе 2010 елга уртача айлык хезмәт хакы дәрәҗәсе Россия Федерациясе буенча уртача тармак дәрәҗәсеннән кимрәк булмаска, 2015 елга урман сәнәгате кластеры буенча агач әзерләүдән башлап әзер продукт чыкканчыга кадәр уртача тармак дәрәҗәсенә ирешү, 2020-2030 елларга Татарстан Республикасы сәнәгатендә уртача хезмәт хакына ирешү индикаторы булырга тиеш.

1.2.3.2нче таблица

**2008-2018елларгаТатарстан Республикасы урман хуҗалыгы хезмәткәрләренең саны һәм хезмәт хакы фонды турында белешмәләр**

| Исеме / ел | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | факт | факт | факт | факт | факт | факт | көтелгән | план | план | план | план |
| «Урманчылык» ДКУ исемлек буенча уртача сан , кеше. | 1 546 | 1 234 | 1 242 | 1 240 | 1 218 | 892 | 929 | 929 | 929 | 929 | 929 |
| «Урманчылык» ДКУ хезмәт хакы фонды, меңсум | 130 105 | 140 242 | 144 079 | 145 465 | 152 545 | 155 475 | 161 000 | 161 000 | 161 000 | 161 000 | 161 000 |
| «Урманчылык» ДКУ уртача хезмәт хакы, меңсум | 7,0 | 9,5 | 9,7 | 9,8 | 10,4 | 14,5 | 14,4 | 14,4 | 14,4 | 14,4 | 14,4 |
| «Урман» ДКУ исемлек буенча уртача сан , кеше. | 1 616 | 1 297 | 1 132 | 1 100 | 980 | 977 | 1 098 | 1 098 | 1 098 | 1 098 | 1 098 |
| «Урман» ДКУ хезмәт хакы фонды, меңсум | 139 913 | 116 213 | 116 089 | 119 669 | 124 397 | 142 801 | 152 600 | 160 893 | 169 636 | 178 796 | 188 451 |
| «Урман» ДКУ уртача хезмәт хакы, меңсум | 7,2 | 7,5 | 8,5 | 9,1 | 10,6 | 12,2 | 11,6 | 12,2 | 12,9 | 13,6 | 14,3 |
| «Урман янгыннарына каршы үзәк» ДБУ исемлек буенча уртача сан , кеше. | | | | | 84 | 106 | 131 | 131 | 131 | 131 | 131 |
| «Урман янгыннарына каршы үзәк» ДБУхезмәт хакы фонды, меңсум | | | | | 9 591 | 14 704 | 14 747 | 15 492 | 16 274 | 17 169 | 18 113 |
| «Урман янгыннарына каршы үзәк» ДБУ уртача хезмәт хакы, меңсум | | | | | 9,5 | 11,6 | 9,4 | 9,9 | 10,4 | 10,9 | 11,5 |

| исеме / ел | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | факт | факт | факт | факт | факт | факт | көтелгән | план | план | план | план |
| Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органының исемлек буенча уртача хезмәткәрләре саны , кеше. | 56 | 54 | 75 | 130 | 59 | 60 | 61 | 61 | 61 | 61 | 61 |
| Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органының хезмәт хакы фонды, меңсум | 22 340 | 21 237 | 21 798 | 32 095 | 28 870 | 28 868 | 24 000 | 24 000 | 24 000 | 24 000 | 24 000 |
| Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органынынңуртача хезмәт хакы, меңсум | 33,2 | 32,8 | 24,2 | 20,6 | 40,8 | 40,1 | 32,8 | 32,8 | 32,8 | 32,8 | 32,8 |
| Урман хуҗалыгы хезмәткәрләренең исемлек буенча барлыгы уртача саны, кеше. | **3 218** | **2 585** | **2 449** | **2 470** | **2 341** | **2 035** | **2 219** | **2 219** | **2 219** | **2 219** | **2 219** |
| Урман хуҗалыгы хезмәткәрләренең хезмәт хакы фондыбарлыгы, меңсум | **292 358** | **277 692** | **281 966** | **297 229** | **315 403** | **341 848** | **352 347** | **361 384** | **370 910** | **380 965** | **391 564** |
| Урман хуҗалыгы хезмәткәрләренең уртача хезмәт хакыбарлыгы,меңсум. | **7,6** | **9,0** | **9,6** | **10,0** | **11,2** | **14,0** | **13,2** | **13,6** | **13,9** | **14,3** | **14,7** |

### 1.2.4. Урманнарны саклау, яклау, торгызу буенча үткәргән чараларны урманчылыклар буенча анализлау

#### 1.2.4.1. Урманнарны янгыннардан саклау

Татарстан Республикасы урманнары Россия Федерациясе Урман кодексы һәм башка норматив актлар нигезендә янгыннардан сакланырга тиеш. Урманнарны саклау аларның биологик һәм оештыру, хокукый һәм башка чаралар комплексын үз эченә алган региональ үзенчәлекләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Урманнарда янгын чыгу куркынычы һәм урманнарның фактта януы күп факторларга бәйле: агачларның токым составы һәм торышы, үсү шартлары, транспорт челтәре үсеше, урманнарда халыкның булуы, территорияләрнең янгынга каршы җайланмалар белән тәэмин ителеше һ.б.

Академик И. С. Мелехов тарафыннан эзерләнгән агачларның табигый янгын куркынычы шкаласы нигезендә республика урман фонды янгын куркынычсызлыгының биш классына бүленгән (1.2.4.1.1нче таблица).

1.2.4.1.1 нче таблица

| Янгын куркынычсызлыгы классы | Урман фонды мәйданының гомуми өлеше (%) |
|---|---|
| I | 9,2 |
| II | 11,8 |
| III | 41,4 |
| IV | 35,7 |
| V | 1,9 |

Табигый янгын куркынычының уртача классы 2.7гә тиң, бу республиканың урманнарына уртача янгын куркынычы янауны дәлилли.

Урман кишәрлекләренең янгынга каршы иң куркынычлылары (I һәм II класслар) мәйданның 20,9% биләп тора.

Урман янгыннары урман фонды торышына һәм динамикасына шактый йогынты ясыйлар.

Татарстан Республикасында булган урман янгыннары санына һәм мәйданнарына карата узган чорда урманчылыклар буенча белешмәләр 1.2.4.1.2 – 1.2.4.1.4 нче таблицаларда китерелде.

1.2.4.1.2нче таблица

**Республика буенча узган чорда (1998-2007 елларга) урман янгыннары турында белешмә**

| Еллар | Янгыннар саны, барлыгы | Янгын мәйданы, (га) |
|---|---|---|
| 1998 | 162 | 69 |
| 1999 | 47 | 13 |
| 2000 | 14 | 3 |
| 2001 | 38 | 8 |
| 2002 | 65 | 27 |
| 2003 | 41 | 17 |
| 2004 | 32 | 35 |
| 2005 | 16 | 10 |
| 2006 | 104 | 110 |
| 2007 | 24 | 8 |
| Барлыгы | 543 | 300 |

1.2.4.1.3 нче таблица

**Республика буенча узган чорда (2008 - 2012 елларга) урман янгыннары турында белешмә**

| Еллар | Янгыннар күләме, барлыгы | Янгын мәйданы, (га) |
|---|---|---|
| 2008 | 53 | 61,6 |
| 2009 | 48 | 83,8 |
| 2010 | 99 | 167,9 |
| 2011 | 0 | 0 |
| 2012 | 0 | 0 |
| Барлыгы: | 200 | 313,3 |

Биш елда (2008-2012 елларда) республика урманнарында гомуми мәйданы 313,3 га 200 урман янгыны булды. Узган чор белән чагыштырганда янгыннарның уртача еллык күрсәткече 1,8%ка кимеде, уртача еллык мәйданы 1,7 тапкырга артты, ә бер янгынның уртача мәйданы 0 ,83 гектардан 1,57 гектарга кадәр 1,89 артты.

1.2.4.1.4 нчетаблица

**Узган ревизия чорында Татарстан Республикасы урман янгыннары һәм янган урманнарга кагылышлы урманчылыклар буенча белешмәләр (2008-2012 елларда)**

| Урманчылыклар исемлеге | Янгыннар саны | | Янгын мәйданы, га | | 1 мең гаурман мәйданына чагыштырмача янган урман |
|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | уртача еллык | барлыгы | уртача еллык | |
| Әгерже | 16 | 3,2 | 17,5 | 3,5 | 0,39 |
| Азнакай | 3 | 0,6 | 18,8 | 3,8 | 0,42 |
| Аксубай | | | | | |
| Әлки | 3 | 0,6 | 16,7 | 3,3 | 0,45 |
| Әлмәт | 5 | 1,0 | 5,0 | 1,0 | 0,10 |
| Арча | 1 | 0,2 | 0,3 | 0,1 | 0,01 |
| Баулы | 3 | 0,6 | 2,7 | 0,5 | 0,12 |
| Биләр | 1 | 0,2 | 1 | 0,2 | 0,02 |
| Болгар | 8 | 1,6 | 32,9 | 6,6 | 1,76 |
| Бөгелмә | 7 | 1,4 | 5,0 | 1,0 | 0,11 |
| Буа | | | | | |
| Алабуга | 15 | 3,0 | 32,0 | 6,4 | 0,76 |
| Зәй | 3 | 0,6 | 3,8 | 0,8 | 0,06 |
| Зеленодольск | 19 | 3,8 | 3,4 | 0,7 | 0,13 |
| Исләйтар | 3 | 0,6 | 1,9 | 0,4 | 0,11 |
| Кайбыч | | | | | |
| Кәләй | 2 | 0,4 | 1,6 | 0,3 | 0,04 |
| Кама | 14 | 2,8 | 18,7 | 3,7 | 0,34 |
| Кызыл Йолдыз | 4 | 0,8 | 5,7 | 1,1 | 0,13 |
| Лаеш | 12 | 2,4 | 61,8 | 12,4 | 1,83 |
| Лениногорск | 7 | 1,4 | 15,5 | 3,1 | 0,29 |
| Мамадыш | 28 | 5,6 | 23,1 | 4,6 | 0,48 |
| Минзәлә | 9 | 1,8 | 11,3 | 2,3 | 0,16 |
| Түбән Кама | 1 | 0,2 | 4,0 | 0,8 | 0,09 |
| Нурлат | | | | | |

| Урманчылыклар исемлеге | Янгыннар саны | | Янгын мәйданы, га | | 1 мең гаурман мәйданына чагыштырмача янган урман |
|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | уртача еллык | барлыгы | уртача еллык | |
| Идел буе | 1 | 0,2 | 6,5 | 1,3 | 0,23 |
| Шәһәр яны | 33 | 6,6 | 22,8 | 4,6 | 0,75 |
| Саба | 1 | 0,2 | 1,2 | 0,2 | 0,02 |
| Тәтеш | | | | | |
| Чирмешән | 1 | 0,2 | 0,1 | 0,02 | 0,01 |
| Барлыгыурманчылыклар буенча | 200 | 40,0 | 313,3 | 62,7 | 0,25 |
| шул исәптән: Суслонгер хәрби урманчылыгы | 1 | 0.2 | 0.05 | 0.01 | 0.03 |
| «Түбән Кама» милли паркы | 25 | 5.0 | 17.38 | 3.48 | 0,94 |
| Идел-Камадәүләт тыюлыгы | 4 | 0,8 | 4,02 | 0,80 | 0,40 |
| Барлыгы | 230 | 46 | 334,75 | 66,95 | 0,26 |

Уртача статистика белешмәләре буенча республика урманнарында уйсулыкта янгыннар 96%, калкулыкта – 3%, җир асты (торф) янгыннары – 1% тәшкил итә.

Янгын килеп чыгуның төп сәбәпләре: авыл хуҗалыгы кырларында яндыру –96%, агач әзерләүчеләр гаебе белән (эш урыннарында) – 1%, җирле халык гаебе белән –2%, яшен аркасында –1% тәшкил итә.

Янгыннар килеп чыгуның төп сәбәбе (99%) – ут белән саксыз эш итү.

Урманнарда һава торышына бәйле янгыннар куркынычсызлыгы җирле шкала белән билгеләнә. Янгын куркынычсызлыгы шкалаларын әзерләү һәм раслау тәртибе Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы тарафыннан билгеләнә(Рослесхоз).Янгын куркынычсызлыгы биш класска бүленә.

1.2.4.1.5нче таблица

| № т/с | Янгын куркынычсызлыгы классы (якк) | Тасвирлама |
|---|---|---|
| 1 | I –300дән кимрәк булмау | 1 классслы янгын куркынычсызлыгы вакытында авиапатрульлек итү, кагыйдә буларак, башкарылмый. Гамәлдәге янгыннарның торышын контрольдә тоту һәм янгын сүндерүдә эшләүче командаларга ярдәм күрсәтү өчен эпизодик очышлар билгеләнергә мөмкин. Һава шартлары буенча урманда янгын куркынычсызлыгы барлыкка килүгә ул кечәйгән саен авиапатрульлек итү арта. |

| № т/с | Янгын куркынычсызлыгы классы (якк) | Тасвирлама |
|---|---|---|
| 2 | II – 301-1000 аз | Янгын куркынычсызлыгы (II класс) аз булганда янгыннар башлаганчы партульлек итү 1-2 көн аша үткәрелә. |
| 3 | III – 1001-4000 урта | Көн сан бер тапкыр патрульлек билгеләү урта дәрәҗәдәге янгын куркынычсызлыгы чорында (III класс) яисә  аз янгын куркынычсызлыгы (II класс) булган көннәрдә башкарыла. |
| 4 | IV – 4001-10000 югары | Ике тапкыр патрульлек билгеләү янгын куркынычсызлыгы югары булган  (IV класс) чорга кергәндә яисә янгыннар булукуркынычсызлыгы уртача көннәрдә (III класс)башкарыла. |
| 5 | V – 10001-12000 гадәттән тыш | Өч тапкыр патрульлек итүне билгеләү өченгадәттән тыш янгын куркынычсызлыгы чоры (V класс) яисә янгын куркынычсызлыгы югары булган көннәрдә янгын булу (IVкласс) нигез булып тора. |

1.2.4.1.6 нче таблица

**Урман янгыннары санын һәм мәйданын айлап бүлү**

| ел/ай | апрель | май | июнь | июль | август | сентябрь | октябрь |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| а) урман янгыннарының күләме% | | | | | | | |
| 2002 | 9 | 72 | 5 | 5 | 6 | 3 | - |
| 2003 | 2 | 27 | 5 | - | - | - | 66 |
| 2004 | 7 | 76 | 10 | - | 7 | - | - |
| 2005 | - | 56 | - | - | 25 | 13 | 6 |
| 2006 | 18 | 68 | 9 | 3 | - | 2 | - |
| 2007 | - | 33 | 42 | 8 | 4 | - | 13 |
| 2008 | 51 | 36 | - | - | 13 | - | - |
| 2009 | 23 | 40 | 29 | - | 2 | 2 | 4 |
| 2010 | 8 | 21 | 19 | 29 | 20 | 3 | - |
| 2011 | - | - | - | - | - | - | - |
| 2012 | - | - | - | - | - | - | - |
| б) янган мәйданнар% | | | | | | | |
| 2002 | 10 | 74 | 3 | 4 | 2 | 7 | - |
| 2003 | - | 18 | - | - | - | - | 82 |
| 2004 | 3 | 88 | 3 | - | 6 | - | - |
| 2005 | - | 89 | - | - | 6 | 4 | 1 |
| 2006 | 8 | 88 | 3 | 1 | - | - | - |
| 2007 | - | 27 | 31 | - | - | - | 42 |
| 2008 | 54 | 35 | - | - | 11 | - | - |
| 2009 | 15 | 75 | 3 | - | - | - | 7 |
| 2010 | 20 | 15 | 19 | 32 | 11 | 3 | - |
| 2011 | - | - | - | - | - | - | - |
| 2012 | - | - | - | - | - | - | - |

1.2.4.1.7 нче таблица

**Янгыннар куркынычы классын (ЯКК) янгын куркынычы булган сезоннарга айлап бүлү**

| № т/с | Айлар | 2011 ел | | | | | | 2012 ел | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | I | II | III | IV | V | Барлыгы | I | II | III | IV | V | Барлыгы |
| 1 | Апрель | 5 | 3 | 3 | - | - | 11 | 1 | 6 | 9 | - | - | 16 |
| 2 | Май | 4 | 3 | 16 | 8 | - | 31 | 3 | 6 | 15 | 7 | - | 31 |
| 3 | Июнь | 13 | 11 | 6 | - | - | 30 | 6 | 8 | 16 | - | - | 30 |
| 4 | Июль | 2 | 2 | 19 | 8 | - | 31 | 2 | 11 | 12 | 6 | - | 31 |
| 5 | Август | 1 | 4 | 6 | 9 | 11 | 31 | 9 | 6 | 7 | 9 | - | 31 |
| 6 | Сентябрь | 21 | 3 | 4 | 2 | - | 30 | 17 | 11 | 2 | - | - | 30 |
| 7 | Октябрь | 28 | 3 | - | - | - | 31 | 22 | 9 | - | - | - | 31 |
| 8 | Ноябрь | 23 | - | - | - | - | 23 | - | - | - | - | - | - |
| Барлыгы | | 97 | 29 | 54 | 27 | 11 | 218 | 60 | 57 | 61 | 22 | - | 200 |

1.2.4.1.8нче таблица

**Урман янгыннары санын янгын куркынычсызлыгы класслары буенча һәм айлап бүлү**

| № т/с | Айлар | 2011ел | | | | | | 2012 ел | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | I | II | III | IV | V | Барлыгы | I | II | III | IV | V | Барлыгы |
| 1 | Апрель | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 2 | Май | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 3 | Июнь | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 4 | Июль | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 5 | Август | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 6 | Сентябрь | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 7 | Октябрь | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Барлыгы | | 2 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

Беренче янгыннар, кагыйдә буларак, апрельнең беренче декадасында урманда кипкән үлән һәм туфракның өске катламы кибүгә бәйле кар киткәннән соң барлыкка килә. Урман янгыннарының язгы иң югары ноктасы май аеның беренче яртысыннан яшь үлән тишелеп чыкканчыга кадәр дәвам итә. Урманнар өчен җәйге коры һава куркыныч, монда үлән катламы һәм туфракның өсте нык

кибә һәм тиз янып китүчән була, шулай ук көз көне, иске яфраклар коелгач та, янгын куркынычы барлыкка килә.

Аеруча куркыныч һәм коры еллар 1994-1996 һәм 1998 елларга туры килде, бу елларда 761 урман янгыны чыкты. Мондый янгыннарны сүндерүдә кыенлыклар күп: беръюлы күп кешенең һәм янгын сүндерү чараларының кирәк булуы, авиаягулык кытлыгы, вертолетлар булмау, уңайсыз һава шартлары һәм башкалар.

Соңгы биш ел эчендә янгыннардан уртача еллык зыян 21,4 млн. сум тәшкил итте: шул исәптән 0,8 млн. сум. 2008 елда; 7,9 млн. сум. 2009 елда; 12, 7 млн. сум2010 елда; 2011 - 2012 елларда янгыннар булмады(0,8 млн. сум 2008 елда 21,7 млн. сумгакадәр2010 елда).

1971–2008 елларда Татарстан Республикасы урманнарында 3261 янгын булды (бер елга уртача 86), ул 6,9 мең га урман мәйданын биләде.

2011–2012 елларда Татарстан Республикасы урман янгыннары теркәлмәде.

Татарстан Республикасы урманнарының фактта янмавы урман янгыннарына каршы җир өсте алымнары, шулай ук авиация чаралары куллану ярдәмендә актив көрәш нәтиҗәсе булды.

1.2.4.1.9 нчетаблица

**Авиация ярдәмендә табылган урман янгыннары турында белешмә**

| Ел | Очу сәгате | Сезонда чыккан янгыннар | | Бер янгынның уртача мәйданы (га) | Авиация ярдәмендә табылган | | | Бер янгынның уртача мәйданы, га |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Саны. шт. | Мәйдан., га | | Саны., шт. | Мәйдан., га | % | |
| 2002 | 385 | 65 | 27,87 | 0,42 | 32 | 14,09 | 49,2 | 0,44 |
| 2003 | 277 | 41 | 17,22 | 0,42 | 22 | 7,51 | 53,5 | 0,34 |
| 2004 | 167 | 32 | 34,9 | 1,09 | 14 | 2,59 | 43,7 | 0,18 |
| 2005 | 120 | 16 | 10.12 | 0,63 | 5 | 0,05 | 31,2 | 0,01 |
| 2006 | 150 | 104 | 110,14 | 1,06 | 29 | 6,38 | 27,9 | 0,22 |
| 2007 | 50 | 24 | 8,43 | 0,35 | 1 | 0,01 | 4,2 | 0,01 |
| 2008 | 25 | 53 | 61,65 | 1,16 | - | - | - | - |
| 2009 | 29 | 48 | 83 | 1,73 | - | - | - | - |
| 2010 | 125 | 99 | 167,91 | 1,7 | 1 | 0,3 | 0,01 | 0,3 |
| 2011 | 85 | 0 | 0 | 0 | - | - | - | - |
| 2012 | 103 | 0 | 0 | 0 | - | - | - | - |
| Барлыгы: | 1516 | 482 | 521,24 | 0,65 | 104 | 30,93 | 21,6 | 0,30 |

2002 – 2012 елларда сезонда булган янгыннар вакытында урманнарга авиапатрульлек итү өчен түбәндәге һава судноларыкулланылды: АН-3самолёты, Ми-8 МТВ АНСАТ һәм R-44 вертолетлары.

2012 елда авиапатрульлек кысаларында фактта урманнарга 103 сәгать дәвамында 25 очыш ясалды. Бер очышның уртача дәвамлылыгы 4 сәгать 12 минут тәшкил итте.

Тулаем алганда, урманнарны янгыннан саклауның нәтиҗәлелеге канәгатьләнерлек дип бәяләнә.

«Чаралар планын» финанслау урман хуҗалыгының планлы йөкләмәләрен федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан, шулай ук арендаторлар акчалары исәбеннән финанслау нигезендә гамәлгә ашырылды.

2012 елда Татарстан Республикасында территориядә янгынга каршы түбәндәге эшләр башкарылды, алар 1.2.4.1.10нче таблицада китерелә.

1.2.4.1.10нче таблица

**2012 елда Татарстан Республикасы«Урман» ДБУ һәм арендаторлар территориясендә янгынга каршы җайланмалар белән эш башкару**

| № т/с | Чаралар исемлеге | Исәпләү берәмлеге | План | Факт | Планныңүтәлеше% |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Сукмак салу, янгынга каршы өзеклекләр, янгынга каршы минеральләштерелгән полосалар урнаштыру | км | 3816 | 3816 | 100 |
| 2. | Урманнарны янгыннан саклау өчен урман юллары салу | км | 28 | 28 | 100 |
| 3. | Урманнарны янгыннан саклау өчен урман юлларын эксплуатацияләү | км | 200 | 200 | 100 |
| 4. | Кипкән үләнне, урман үсентеләрен, корыган ботакларны янгынга каршы профилактик яндыру | га | 400 | 400 | 100 |
| 5 | Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан күреләә торган башка чаралар | | | | |
| | Сукмак салу, янгынга каршы өзеклекләр, янгынга каршы минеральләштерелгән полосалар урнаштыру | км | 6700 | 6700 | 100 |
| | Янгынга каршы корал һәм инвентарь сатып алу, янгын сүндерү техникасын һәм җайланмасын тоту, элемтә һәм хәбәр системаларын тәэмин итү, янгын сүндерү техникасы һәм җайланмасы, шулай ук ягулык запасы булдыру | мең сум | 1579,4 | 1579,4 | 100 |
| | Урманнарга килүче гражданнарга ял зоналарын төзекләндерү | мең сум | 121,5 | 121,5 | 100 |
| | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүматлы стендлар һәм башка билгеләр, күрсәткечләр урнаштыру | мең сум | 121,5 | 121,5 | 100 |

| № т/с | Чаралар исемлеге | Исәпләү берәмлеге | План | Факт | Планныңүтәлеше% |
|---|---|---|---|---|---|
| | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы мониторингы үткәрү, барлыгы | мең сум | 966,8 | 966,8 | 100 |
| | шул исәптән: җир өсте саклау зонасы | мең сум | 1,2 | 1,2 | 100 |
| | авиационсаклау зонасы | мең сум | 965,6 | 965,6 | 100 |

Урман янгыннарын профилактикалау һәм сүндерүгә әзерлек чаралары планы күпчелек күрсәткечләр буенча 100% үтәлде.

Муниципаль берәмлекләр администрацияләре тарафыннан мобилизацион чараларның оператив планнары ел саен раслана, аларда янгыннарны сүндерүгә башка предприятиеләрдә, районнарда урнашкан техника, транспорт һәм эшче көчләрдән файдалану күздә тотыла. Кирәк очракта, граждан законнары нигезендә «Урман» ДБУ белән предприятиеләр арасында шартнамәләр төзелде.

Янгын куркынычы сезонында урманны саклауга өстәп «Урман» ДБУ тарафыннан вакытлыча каравылчылар яллана, алар башлыча урманчылык конторaларында һәм урманчылык кишәрлекләрендә, янгын күзәтү вышкаларында һәм пунктларында кичке вакытта һәм ял көннәрендә кизү торалар. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында ял һәм бәйрәм көннәрендә генә түгел, 20 апрельдән октябрьгә кадәр көн саен да тәүлек буе кизү оештырыла.

Урман янгыннарын сүндерү хезмәтләре турында белешмәләр 1.2.4.1.11нче таблицада китерелде.

1.2.4.1.11нче таблица

**2014 елның 1 октябренә«Урман»ДБУ һәм «Урман янгыннарына каршы үзәк»ДБУ янгынга каршы хезмәтләре турындабелешмәләр**

| № т/с | Исемлек | Янгынга каршы химик станцияләр, типлар буенча | | | | Янгынга каршы инвентарь тупланган пунктлар | Янгын күзәтү вышкалары, телевизион җайланмалар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | I | II | III | Барлыгы | | |
| 1 | Әгерҗе урманы | | 1 | | 1 | | 2 |
| 2 | Азнакай урманы | | | | | 1 | |
| 3 | Аксубай урманы | | | | | 1 | |
| 4 | Алабуга урманы | | 1 | | 1 | | |
| 5 | Әлки урманы | | | | | 1 | |
| 6 | Әлмәт урманы | | 1 | | 1 | | |
| 7 | Арча урманы | | 1 | | 1 | | |
| 8 | Баулы урманы | | | | | 1 | |

| № т/с | Исемлек | Янгынга каршы химик станцияләр, типлар буенча | | | | Янгынга каршы инвентарь тупланган пунктлар | Янгын күзәтү вышкалары, телевизион җайланмалар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | I | II | III | Барлыгы | | |
| 9 | Биләр урманы | | | | | 1 | |
| 10 | Болгар урманы | | 1 | | 1 | | |
| 11 | Бөгелмә урманы | | 1 | | 1 | | |
| 12 | Буа урманы | | | | | 1 | |
| 13 | Зәй урманы | | 1 | | 1 | | 1 |
| 14 | Зеленодольск тәҗрибә урман хуҗалыгы | | 1 | | 1 | | 4 |
| 15 | Исләйтар урманы | | 1 | | 1 | | 1 |
| 16 | Кайбычмахсус орлыкчылык урман хуҗалыгы | | | | | 1 | |
| 17 | Кәләй урманы | | | | | 1 | |
| 18 | Кама урманы | | 2 | | 2 | | |
| 19 | КызылЙолдыз урманы | | | | | 1 | |
| 20 | Лаеш урманы | | 1 | | 1 | | 1 |
| 24 | Лениногорск урманы | | | | | 1 | |
| 22 | Мамадыш урманы | | 1 | | 1 | | 1 |
| 23 | Минзәлә урманы | | 1 | | 1 | | 2 |
| 24 | Түбән Кама урманы | | | | | 1 | 1 |
| 25 | Нурлат урманы | | 1 | | 1 | | 1 |
| 26 | Идел буе урманы | | | | | 1 | |
| 27 | Шәһәр яны укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы | | 2 | | 2 | | 3 |
| 28 | Укыту-тәҗрибә Саба урман хуҗалыгы | | 1 | | 1 | | 1 |
| 29 | Тәтеш урманы | | | | | 1 | |
| 30 | Чирмешән урманы | | | | | 1 | |
| 31 | Урман янгын үзәге | | | 5 | 5 | | |
| Барлыгы | | | 18 | 5 | 23 | 14 | 16 |

Җир өсте көчләре«Урман янгыннарына каршы үзәк»ДБУIII типтагы 5 янгынга каршы химик станциядән, «Урман» ДБУ IIтиптагы 18 янгынга каршы химик станциядән һәм янгынга каршы инвентарьлар тупланган 14 пункттан, шулай ук агач әзерләүче предприятиеләрнең – урман фонды арендаторларының янгынга каршы формированиеләреннән тора.

1.2.4.1.12 нче таблица

**IIтиптагы ПХСбелән тәэмин ителеш**

| № т/с | Җиһазлар һәм инвентарьлар исемлеге | Үлчәү берәм. | II типтагы ПХС турында нигезләмә буенча барлыгы таләп ителә | Барлыгы таләп ителә | Барлыгы фактта | Өстәмә таләп ителә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Төп җиһазлар | | | | | | |
| 1. | Урман автоцистернасы | шт. | 2 | 36 | 42 | |
| 2. | 6 т йөккүтәргеч, узучанлыгы югары булган бортлы автомобиль | шт. | 2 | 36 | 36 | |
| 3. | 1 тоннага кадәр йөккүтәргеч, узучанлыгы югары булган бортлы автомобиль | шт. | 1 | 18 | 18 | |
| 4. | 4-5 кешелек моторлы көймә | шт. | 1 | 10 | 5 | 5 |
| 5. | 600-800 л/мин җитештерүчәнлекле күчмә мотор помпа | шт. | 2 | 36 | 36 | |
| 6. | 60-120 л/мин җитештерүчәнлекле күчмә кече габаритлы мотопомпа | шт. | 2 | 36 | 30 | 6 |
| 7. | Аерым цистерна яисә су өчен резинамичкә | шт. | 2 | 36 | 36 | |
| 8. | Бульдозер | шт. | 1 | 18 | 15 | 3 |
| 9. | Урман сукасы | шт. | 2 | 36 | 36 | |
| 10. | Радиостанцияләр: | | | | | |
| | стационар | шт. | 1 | 18 | - | - |
| | күчмә | шт. | 3 | 54 | 30 | 24 |
| | күтәреп йөрешле | шт. | 4 | 72 | 35 | 37 |
| 11. | Тавыш җайланмасы | шт. | 2 | 36 | 17 | 19 |
| 12. | Янгын җибәрү аппараты | шт. | 4 | 72 | 65 | 7 |
| 13. | Кул урман янгыны сүндергече | шт. | 20 | 360 | 331 | 29 |
| 14. | «Дружба» моторлы бензин пычкычы | шт. | 2 | 36 | 36 | |

| № т/с | Җиһазлар һәм инвентарьлар исемлеге | Үлчәү берәм. | II типтагы ПХС турында нигезләмә буенча барлыгы таләп ителә | Барлыгы таләп ителә | Барлыгы фактта | Өстәмә таләп ителә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| II. Технологик җиһаз | | | | | | |
| 1. | 26 һәм 51 ммдиаметрлы, басымлы янгын шлангасы тоткычы | пог.м | 5000 | 90000 | 25420 | 64580 |
| 2. | Янгын сүндерү өчен озын кәүсә | шт. | 8 | 144 | 143 | 1 |
| 3. | Басым тоташтыру головкасы | шт. | 60 | 1080 | 521 | 559 |
| 4. | Утсүндергеч сыеклыкны саклау савыты беләнболгату агрегаты | шт. | 1 | 18 | 18 | |
| 5. | Тоткычларны күчереп йөртү жайланмасы | шт. | 2 | 36 | 27 | 9 |
| 6. | Универсаль корсет кыскычы | шт. | 50 | 900 | 184 | 716 |
| 7. | Янгы сүндерү көрәкләре | шт. | 100 | 1800 | 1800 | |
| 8. | Янгын сүндерү тырмалары | шт. | 20 | 360 | 311 | 49 |
| 9. | Янгын сүндерү чиләкләре | шт. | 20 | 360 | 360 | |
| 10. | Аркылы пычкы | шт. | 10 | 180 | 156 | 24 |
| 11. | Ягулык-майлау материаллары өчен 10-20 л сыешлы савыт | шт. | 10 | 180 | 180 | |
| 12. | Балта | шт. | 20 | 360 | 360 | |
| 13. | Психрометр | шт. | 2 | 36 | 10 | 26 |
| 14. | Инструментлар ташу өчен күчмә контейнер | шт. | 2 | 36 | 36 | |
| III. Оештыру-техниктәэмин ителеш | | | | | | |
| 1. | Дарулар (аптечка) | шт. | 6 | 108 | 100 | 8 |
| 2. | Шәхси яра бәйләү пакеты | шт. | 10 | 180 | 140 | 40 |
| 3. | Эчәр су өчен 20 л сыешлы канистра яисә бидон | шт. | 6 | 108 | 108 | |
| 4. | Махсус кием һәм махсус аяк киеме | шт. | 10 | 180 | 180 | |
| 5. | Респиратор | шт. | 10 | 180 | 180 | |
| 6. | Саклагыч күзлек | шт. | 10 | 180 | 180 | |
| 7. | Саклагыч каска | шт. | 10 | 180 | 180 | |
Яфракашар корткычларның, ылысашарлар белән чагыштырып караганда, хуҗалыкка кагылышлы әһәмияте, яфраклы агач төрләре өчен ассимиляцион аппаратның бер өлеше югалу бик үк куркыныч булмаганга күрә, әллә ни зур түгел. Бөҗәкләр белән зарарлану аркасында утыртмаларның коруы сирәк күзәтелде, булган очракта да аларның мәйданнары зур булмады. Ләкин әлеге төркемгә керә торган фитофаглар үсемлекләрнең торышына нык тәэсир итә: алар агачлыкларның авыруларга каршы торучанлыгы, агачларның радиаль үрчүе, урман кишәрлекләренең рекреация өчен кызыктырырлык булуы кимүгә, шулай ук урманның суны көйләү һәм су саклау функцияләре бозылуга сәбәпче булырга мөмкин.

Әлеге төркемгә керә торган бөҗәкләр урман авырулары куркынычы көчле булган зонаны тәшкил итүче Әлмәт һәм Идел буе урман саклау районнарында зур мәйданнарда киң таралган.

1.2.4.2.13 нче таблица

**Соңгы 10 елга яфракашар корткычлар чыганакларының мәйданнары**

| Корткычның төре | Чыганакларның мәйданы, га | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2003 | 2004 | 2005 | 2006 | 2007 | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 |
| Яшел имән яфрактөргече | 77 | 15744 | 48303 | 113 | 0 | 1758,4 | 25225,7 | 25225,7 | 28464,6 | 31273,6 |
| Ефәкче | 188 | 1094 | 1140.2 | 0 | 297 | 688,8 | 7146,3 | 34556,8 | 30457,1 | 29572,6 |
| Барлыгы | 265 | 16838 | 49443,2 | 113 | 297 | 2447,2 | 32372 | 59782,5 | 58921,7 | 60846,2 |

1.2.4.2.14нче таблица

**2012 ел ахырына төрләр буенча яфракашар корткычлар чыганакларының мәйданнары**

| Урманчылык | Корткычларның төрләре буенча чыганакларның мәйданнары, га | |
|---|---|---|
| | Яшел имән яфрактөргече | Ефәкче |
| Азнакай | | 6696,4 |
| Әлмәт | | 392,4 |
| Баулы | | 6323,7 |
| Биләр | 150,0 | |
| Болгар | 1405,1 | |
| Бөгелмә | | 10141,0 |
| Буа | 44,0 | |
| Зәй | 14,4 | 2,8 |
| Кайбыч | 9432,7 | |
| Лаеш | 6431,5 | |
| Лениногорск | 54,1 | 1254,8 |
| Минзәлә | | 2072,1 |
| Түбән Кама | | 2689,4 |
| Идел буе | 282,4 | |
| Тәтеш | 13459,4 | |
| Барлыгы | 31273,6 | 29572,6 |

2012 ел ахырына (1.2.4.2.14 нче таблица) әлеге төркемдә 51,4% мәйданны яшел имән яфрактөргече чыганаклары алып тора, ә 48,6% мәйдан ефәкчегә туры килә.

2012 елда яфракашар корткычлар төркемендә чыганакларның мәйданнары нисбәте яшел имән яфрактөргече чыганакларының кушма мәйданының ефәкче чыганакларының барлык мәйданыннан 1,06 тапкырга

күбрәк булуын күрсәтә. Яфракашар корткыч бөҗәкләр төркемендә 2012 елда чыганакларның мәйданнары нисбәте, 2011 ел белән чагыштырганда, яшел имән яфрактөргече ягына таба авышты, әлеге корткыч чыккан мәйданнар 9,9% ка артты.

1.2.4.2.15 нче таблица

**2012 елда яфракашар корткычлар чыганакларының мәйданнары динамикасы**

| Урманчылык | Чыганакларның мәйданы, га | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хисап елы башына | хисап елында ачыкланды | локальләштерү һәм юкка чыгару буенча чаралар үткәрелде | күрелгән чаралар нәтиҗәсендә юкка чыгарылды | табигый факторлар йогынтысында үзеннән-үзе бетте | хисап елы ахырына | шул исәптән локальләштерү һәм юкка чыгару буенча чаралар үткәрүне таләп итә |
| Азнакай | 5173,4 | 1523,0 | | | | 6696,4 | 1012,8 |
| Әлмәт | | 392,4 | | | | 392,4 | 87,8 |
| Баулы | 6363,7 | | 40,0 | 40,0 | | 6323,7 | |
| Биләр | 212,5 | 142,5 | | | 205,0 | 150,0 | 150,0 |
| Болгар | | 1405,1 | | | | 1405,1 | 1300,3 |
| Бөгелмә | 13601 | | 3460,0 | 3460,0 | | 10141,0 | 1935,6 |
| Буа | 197,7 | 44,0 | 197,7 | 197,7 | | 44,0 | 44,0 |
| Зәй | 17,2 | | | | | 17,2 | |
| Кайбыч | 11748 | 3175,7 | 6040 | 5491,0 | | 9432,7 | 7900 |
| Лаеш | | 6431,5 | | | | 6431,5 | 6431,5 |
| Лениногорск | 361,7 | 947,2 | | | | 1308,9 | |
| Минзәлә | 2072,1 | | | | | 2072,1 | 170,7 |
| Түбән Кама | 2677,4 | 12,0 | | | | 2689,4 | |
| Идел буе | | 282,4 | | | | 282,4 | 282,4 |
| Тәтеш | 16497 | | 3037,6 | 3037,6 | | 13459,4 | 4579,6 |
| Барлыгы | 58921,7 | 14355,8 | 12775,3 | 12226,3 | 205,0 | 60846,2 | 23894,7 |

2012 ел башына Татарстан Республикасы урманнарында яфракашар бөҗәкләр таралган мәйдан 58921,7 га тәшкил итте. «Урманчылык» ДКУендә урман авыруларына тикшерүләр үткәрү һәм модель тармаклар буенча исәпкә алу нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Үзәк завод лабораториясе хезмәткәрләре берничә «Урманчылык» ДКУендә 4897,2 га гомуми мәйданда яфракашар бөҗәкләрнең элек булган чыганаклары мәйданнары артуны, шулай ук 9458,6 га мәйданда әлеге төркемгә кергән бөҗәкләрнең яңа чыганаклары барлыкка килүне ачыклады. Яфракашар корткычларны локальләштерү һәм юкка чыгару буенча 12775,3 га гомуми мәйданда күрелгән чараларның нәтиҗәлелеге уртача 93% тәшкил итте. Шуның нәтиҗәсендә чыганаклар 12226,3 га мәйданга кимеде.

«Биләр урманчылыгы» ДКУ территориясендә урман авыруларын тикшерү буенча үткәрелгән өстәмә тикшерүләр барышында 205 га мәйданда ефәкче чыганакларының табигый факторлар йогынтысында үзеннән-үзе кимүе билгеле булды.

Шулай итеп, әлеге төркем корткыч бөҗәкләренең узган елгы күрсәткечләре 1924,5 га артты (2011 ел чыганакларының гомуми мәйданыннан 3,3% ка), һәм 2012 ел ахырына чыганакларның кушма мәйданы 60846,2 га тәшкил итте (1.2.4.2.15таблица).

1.2.4.2.16 нче таблица

**Соңгы 10 елга башка төркем корткычлар таралган урыннармәйданы**

| Урманчылык | Чыганакларның мәйданы, га | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2003 | 2004 | 2005 | 2006 | 2007 | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 |
| Әгерже | 132 | 132 | 56 | | | | | 262,6 | 602,3 | 516,6 |
| Азнакай | | | | | | | | | | |
| Әлки | | | | | | | | | 12 | 9,8 |
| Аксубай | | | | | | | | | | |
| Әлмәт | | | | 5 | | 3,5 | 3,5 | 20,2 | 20,2 | 32,8 |
| Арча | | | | | | | | | | 112,7 |
| Баулы | | | | | | 16 | 16 | 16 | 16 | |
| Биләр | | | | | | | | | | |
| Болгар | | | | | | | | | | |
| Бөгелмә | | | | | | | | 16,2 | 16,2 | 17,7 |
| Буа | | | | | | | | | | |
| Алабуга | | | | | | | | 140,8 | 782,0 | 723,8 |
| Зәй | | | | | | | | | | |
| Зеленодольск | 600 | 600 | 600 | 305 | 300 | 300 | 300,0 | 270,9 | 170,9 | 172,5 |
| Ары | | | | | | | | | | |
| Кайбыч | | | | | | | | | | |
| Кәләй | | | | | | | | | 37,6 | 36,8 |
| Кама | 7 | | 7 | 32 | 32 | 42,6 | 42,6 | 42,6 | 42,6 | 47,1 |
| Кызыл Йолдыз | | | | 26 | 26 | 26 | 26,0 | 26 | 26 | 26 |
| Лаеш | | | 10 | | | 2 | 2 | 2 | | |
| Лениногорск | | | | | | | | 17,8 | 17,8 | 12,8 |
| Мамадыш | 25 | 25 | 82 | 25 | 45 | 15 | 33,7 | 63,7 | 63,7 | 170,1 |
| Минзәлә | | | | | | | | | | 5,6 |
| Түбән Кама | | | | | | | | | | |
| Нурлат | | | | | | | | | | |
| Идел буе | | | | | | | | | | |
| Шәһәр яны | 70 | 70 | 70 | 30 | 24 | 15 | 15 | 15 | 15 | 15,0 |
| Саба | | | | | | | | | | 284,3 |
| Тәтеш | | | | | | | | | | |
| Чирмешән | | | | | | | | 12,6 | | |
| Барлыгы | 834 | 827 | 825 | 423 | 427 | 420 | 439 | 906,4 | 1822,3 | 2183,6 |

Татарстан Республикасында башка корткычлар төркеменә кәүсә корткычлары (зур нарат җепсел тукымаашары, зур чыршы җепсел

тукымаашары, кайрыашар-типограф һәм алты тешле кайрыашар), тамырны зарарлаучылар (май коңгызлары), бөреләрне һәм үрентеләрне зарарлаучылар (имән бәбәге көясе) һәм суыргыч бөҗәкләр (нарат кабыгасты кандаласы) кебек урман корткычлары керә.

2003 – 2012 еллар чорында башка төркем корткычлар чыганакларының уртача мәйданы 820,1 га тәшкил итте (1.2.4.2.16 нчытаблица), еллар буенча әлеге күрсәткеч 420 га (2008 ел) алып 2183,6 га (2012 ел) кадәр үзгәреп торды. 2010 елдан башлап чыганакларның мәйданнары арта бару күзәтелә.




1.2.4.2.1 нче рәсем.Соңгы 10 елга башка төркем корткычлар чыганакларының мәйданнары

2012 ел ахырына башка төркем корткычлар таралган урыннар мәйданы бүленеше 1.2.4.2.17 нче таблицада китерелде.

1.2.4.2.17 нче таблица

**2012 ел ахырына төрләр буенча башка төркем корткычлар таралган урыннар мәйданы**

| Урманчылык | Чыганакларның мәйданнары, га | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Май коңгыз-лары | Нарат кабыгасты кандаласы | Зур чыршы жепсел тукымаашары | Зур нарат жепсел тукымаашары | Кайрыашар-типограф | Алты тешле кайрыашар |
| Әгерҗе | | | 8,3 | | 508,3 | |
| Әлки | | | | | 9,8 | |
| Арча | | | | | 112,7 | |
| Бөгелмә | | | | 16,2 | 1,5 | |
| Алабуга | | | 23,2 | | 700,6 | |
| Зеленодольск | 170,9 | | | | 1,6 | |
| Кәләй | | | | 4,9 | 31,9 | |
| Кама | | 42,6 | | | 4,5 | |
| Кызыл Йолдыз | | 26 | | | | |
| Лениногорск | | | | 12,8 | | |
| Мамадыш | 15 | 20,2 | 26,5 | | 108,4 | |
| Минзәлә | | | 5,6 | | | |
| Шәһәр яны | 15 | | | | | |
| Саба | | | | | 284,3 | |
| Барлыгы | 200,9 | 88,8 | 66,1 | 57,4 | 1763,6 | 6,8 |

Әлеге төркемдә кайрыашар-типограф чыганаклары иң зур мәйданны алып тора: барлык башка төр корткычлар чыганакларының гомуми мәйданының 80,8% ын тәшкил итә.

1.2.4.2.18 нче таблица

**2012 елга башка төркем корткычлар таралган урыннар мәйданы динамикасы**

| Урманчылык | Чыганакларның мәйданы, га | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хисап елы башына | хисап елында ачыкланды | чаралар үткәрелде* | күрелгән чаралар нәтиҗәсендә юкка | табигый факторлар йогынтысында үзеннән-үзе бетте | хисап елы ахырына | шул исәптән чаралар үткәрүне таләп итә** |
| Әгерҗе | 602,3 | 7,6 | 93,3 | 93,3 | | 516,6 | 516,6 |
| Әлки | 12 | | 2,2 | 2,2 | | 9,8 | 9,8 |
| Әлмәт | 20,2 | 15,2 | 2,6 | 2,6 | | 32,8 | 32,8 |
| Арча | | 135 | 22,3 | 22,3 | | 112,7 | 112,7 |
| Баулы | 16 | | | | 16 | 0 | |
| Бөгелмә | 16,2 | 1,5 | | | | 17,7 | 17,7 |
| Алабуга | 782 | 44,5 | 102,7 | 102,7 | | 723,8 | 723,8 |
| Зеленодольск | 170,9 | 1,6 | | | | 172,5 | 1,6 |
| Кәләй | 37,6 | 7,7 | 8,5 | 8,5 | | 36,8 | 36,8 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Кама | 42,6 | 4,5 | | | | 47,1 | 47,1 |
| Кызыл Йолдыз | 26 | | | | | 26 | 26 |
| Лениногорск | 17,8 | | 5,0 | 5,0 | | 12,8 | 12,8 |
| Мамадыш | 63,7 | 109,9 | 3,5 | 3,5 | | 170,1 | 151,4 |
| Минзәлә | | 5,6 | | | | 5,6 | 5,6 |
| Түбән Кама | | 4,0 | 4,0 | 4,0 | | | |
| Шәһәр яны | 15 | | | | | 15 | 10 |
| Саба | | 287,6 | 3,3 | 3,3 | | 284,3 | 284,3 |
| Барлыгы | 1822,3 | 624,7 | 247,4 | 247,4 | 16,0 | 2183,6 | 1611,7 |

Башка төркем корткычларның чыганаклары хисап елы ахырына 361,3 га мәйданга артты. Кәүсә корткычларының 433,8 га мәйданда яңа чыганаклары табылды, шулай ук элек булган чыганакларның да мәйданнары артты. 247,4 га җирдә санитария-чистарту эшләре башкарылды, нәтиҗәдә кәүсә корткычлары чыганакларының бер өлеше бетерелде. Табигый факторлар йогынтысында 16 га мәйданда имән бәбәге көясе чыганагы юкка чыкты. Урманның башка төркем корткычлары чыганакларында 1611,7 га тигез гомуми мәйданда локальләштерү һәм юкка чыгару гамәлләрен, шулай ук санитария-чистарту гамәлләрен башкару таләп ителә.

2012 елда башка төркем корткычлар чыганаклары мәйданнары нисбәте үзгәрде. 2012 елда кайрыашар-типограф чыганакларының мәйданы узган елгыга караганда 26,2% ка артты. «Урманчылык» ДКУ мәгълүматлары һәм урман авыруларына мониторинг нәтиҗәләре күрсәткәнчә, беррәттән барлык башка кәүсә корткычларының чыганаклары да арткан, гәрчә санитария-чистарту чаралары күрелсә дә. Моннан тыш, алты тешле кайрыашарның яңа чыганагы табылган.

Көнчыгыш май коңгызы чыганаклары мәйданы 2011 елдагы кебек калды. Имән бәбәге көясе чыганагы табигый факторлар йогынтысында бетте. Әлеге төр корткычларның чыганаклары торышын тәгаенләү максатында урман авыруларына өстәмә тикшерүләр уздырырга кирәк.



1.2.4.2.2 нче рәсем. 2011 елда башка төр корткычлар таралганурыннар мәйданының аларның төрләре буенча нисбәте, га




1.2.4.2.3нче рәсем. 2012 елда башка төр корткычлар таралган урыннар мәйданының аларның төрләре буенча нисбәте, га

Татарстан Республикасында кәүсә корткычлары төркеменә зур нарат җепсел тукымаашары, зур чыршы җепсел тукымаашары, кайрыашар-типограф, алты тешле кайрыашар, кара нарат һәм чыршы мыеклачлары кебек урман корткычлары керә.

1.2.4.2.19 нче таблица

**10 елда кәүсә корткычлары таралган урыннар мәйданы, га**

| Урманчылык | Чыганаклар мәйданы, га | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2003 | 2004 | 2005 | 2006 | 2007 | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 |
| Кайрыашар-типограф | | | | | | | | 406,6 | 1397,5 | 1763,6 |
| Зур нарат җепсел тукымаашары | | | | | | | | 54,2 | 59,1 | 57,4 |
| Зур чыршы җепсел тукымаашары | | | | | | | | 39,4 | 61,5 | 66,1 |
| Алты тешле кайрыашар | | | | | | | | | | 6,8 |
| Барлыгы | | | | | | | | 500,2 | 1518,1 | 1893,9 |

2003 – 2012 еллар чорында кәүсә корткычлары тәүге тапкыр 2010 елда 500,2 га мәйданда табылды. Кәүсә корткычлары чыганакларының гомуми мәйданы соңгы 2 елда 3,8 тапкырга артты.

1.2.4.2.20 нчы таблица

**2012 ел ахырына кәүсә корткычлары таралган урыннар мәйданы, га**

| Урманчылык | Корткычларның төрләре буенча чыганакларның мәйданнары, га |
|---|---|

| | Кайрыашар-типограф | Зур нарат җепсел тукымаашары | Зур чыршы җепсел тукымаашары | Алты тешле кайрыашар |
|---|---|---|---|---|
| Әгерҗе | 508,3 | | 8,3 | |
| Әлки | 9,8 | | | |
| Әлмәт | | 23,5 | 2,5 | 6,8 |
| Арча | 112,7 | | | |
| Бөгелмә | 1,5 | 16,2 | | |
| Алабуга | 700,6 | | 23,2 | |
| Зеленодольск | 1,6 | | | |
| Кәләй | 31,9 | 4,9 | | |
| Кама | 4,5 | | | |
| Лениногорск | | 12,8 | | |
| Мамадыш | 108,4 | | 26,5 | |
| Минзәлә | | | 5,6 | |
| Саба | 284,3 | | | |
| Барлыгы | 1763,6 | 57,4 | 66,1 | 6,8 |

Әлеге корткыч бөҗәкләр төркемендә мәйдан ягыннан кайрыашар-типограф чыганаклары беренче урында тора, алар урман кәүсә корткычлары чыганакларының кушма мәйданыннан 93,1% тәшкил итә.



1.2.4.2.4 нче рәсем. Соңгы 10 елда кәүсә корткычлары тарлаган урыннар мәйданы динамикасы

1.2.4.2.21 нче таблица

**2012 елда кәүсә корткычлары чыганаклары мәйданнары динамикасы**

| Урманчылык | Чыганакларның мәйданы, га | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хисап елы башына | хисап елында ачыкланды | санитария-чистарту чаралары үткәрелде | курелгән чаралар нәтиҗәсендә юкка чыгарылды | табигый факторлар йогынтысында үзеннән-үзе бетте | хисап елы ахырына | шул исәптән санитария-чистарту чаралары үткәрүне таләп итә |
| Әгерже | 602,3 | 7,6 | 93,3 | 93,3 | | 516,6 | 516,6 |
| Әлки | 12 | | 2,2 | 2,2 | | 9,8 | 9,8 |
| Әлмәт | 20,2 | 15,2 | 2,6 | 2,6 | | 32,8 | 32,8 |
| Арча | | 135 | 22,3 | 22,3 | | 112,7 | 112,7 |
| Бөгелмә | 16,2 | 1,5 | | | | 17,7 | 17,7 |
| Алабуга | 782 | 44,5 | 102,7 | 102,7 | | 723,8 | 723,8 |
| Зеленодольск | | 1,6 | | | | 1,6 | 1,6 |
| Кәләй | 37,6 | 7,7 | 8,5 | 8,5 | | 36,8 | 36,8 |
| Кама | | 4,5 | | | | 4,5 | 4,5 |
| Лениногорск | 17,8 | | 5,0 | 5,0 | | 12,8 | 12,8 |
| Мамадыш | 30 | 108,4 | 3,5 | 3,5 | | 134,9 | 134,9 |
| Минзәлә | | 5,6 | | | | 5,6 | 5,6 |
| Түбән Кама | | 4,0 | 4,0 | 4,0 | | | |
| Саба | | 287,6 | 3,3 | 3,3 | | 284,3 | 284,3 |
| Барлыгы | 1518,1 | 623,2 | 247,4 | 247,4 | | 1893,9 | 1893,9 |

Хисап елы ахырына кәүсә корткычлары чыганаклары 24,8% ка артты, аларның кушма мәйданы 1893,9 га тәшкил итте. Кәүсә корткычларының 432,2 га мәйданда яңа чыганаклары табылды, шулай ук элек булган чыганакларның мәйданнары киңәйде. Моннан тыш, 6,8 га мәйданда алты тешле кайрыашарның яңа чыганагы ачылды. 247,4 га мәйданда санитария-чистарту гамәлләре башкарылды, нәтиҗәдә кайрыашар-типограф чыганакларының бер өлеше тулысынча юкка чыгарылды.




1.2.4.2.5 нче рәсем. 2011 елда урман корткычларының кәүсә төркемнәре чыганаклары мәйданнарының аларның төрләре буенча нисбәте, га

Кәүсә корткычлары төркемендә 2012 елда чыганаклар мәйданнары нисбәтендәге үзгәрешләр зур булмады, ул аеруча кайрыашар-типограф чыганакларында, узган елгы белән чагыштырганда, 26,2% ка артуда күренде. Моннан тыш алты тешле кайрыашарның яңа чыганагы табылды (6,8 га).




1.2.4.2.6 нчы рәсем. 2012 елда урман корткычларының кәүсә төркемнәре чыганаклары мәйданнарының аларның төрләре буенча нисбәте, га

Питомниклардагы һәм плантацияләрдәге, урман культураларындагы, басу саклау полосаларындагы һәм диләнкеләрдәге яшь үсемлекләр агач токымнарының тамыр, кәүсә һәм яфрак корткычлары белән зарарланалар. Күп кенә бөҗәкләр, гәрчә яфракларны, яшь ботакларны һәм ботакларны зарарласалар да, бары тик яшь үсемлекләргә зур зыян салалар. Әлеге төркемгә керә торган барлык төрләр ачык ландшафтны ярата. Аларның күбесе ел саен шактый санда очрап тора һәм аларның исәбендә кискен сикерешләр булмый.

1.2.4.2.22 нче таблица

**Соңгы 10 елда урман корткычларының башка төркемнәре чыганаклары мәйданнары**

| Урманчылык | Чыганакларның мәйданы, га | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2003 | 2004 | 2005 | 2006 | 2007 | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 |
| Әгерҗе | 132 | 132 | 56 | | | | | | | |
| Азнакай | | | | | | | | | | |
| Әлки | | | | | | | | | | |
| Аксубай | | | | | | | | | | |
| Әлмәт | | | | 5 | | 3,5 | 3,5 | | | |
| Арча | | | | | | | | | | |
| Баулы | | | | | | 16 | 16,0 | 16 | 16 | |
| Биләр | | | | | | | | | | |
| Болгар | | | | | | | | | | |
| Бөгелмә | | | | | | | | | | |
| Буа | | | | | | | | | | |
| Алабуга | | | | | | | | | | |
| Зәй | | | | | | | | | | |
| Зеленодольск | 600 | 600 | 600 | 305 | 300 | 300 | 300,0 | 270,9 | 170,9 | 170,9 |
| Ары | | | | | | | | | | |
| Кайбыч | | | | | | | | | | |
| Кәләй | | | | | | | | | | |
| Кама | 7 | | 7 | 32 | 32 | 42,6 | 42,6 | 42,6 | 42,6 | 42,6 |
| Кызыл Йолдыз | | | | 26 | 26 | 26 | 26,0 | 26 | 26 | 26 |
| Лаеш | | | 10 | | | 2 | 2,0 | 2,0 | | |
| Лениногорск | | | | | | | | | | |
| Мамадыш | 25 | 25 | 82 | 25 | 45 | 15 | 33,7 | 33,7 | 33,7 | 35,2 |
| Минзәлә | | | | | | | | | | |
| Түбән Кама | | | | | | | | | | |
| Нурлат | | | | | | | | | | |
| Идел буе | | | | | | | | | | |
| Шәһәр яны | 70 | 70 | 70 | 30 | 24 | 15 | 15,0 | 15 | 15 | 15,0 |
| Саба | | | | | | | | | | |
| Тәтеш | | | | | | | | | | |
| Чирмешән | | | | | | | | | | |
| Барлыгы | 834 | 827 | 825 | 423 | 427 | 420 | 439 | 406,2 | 304,2 | 289,7 |

Татарстан Республикасында башка корткычлар төркеменә тамыр корткычлары (май коңгызлары), бөре һәм яшь ботаклар корткычлары (имән бәбәге көясе) һәм суыргыч бөҗәкләр (нарат кабыгасты кандаласы) керә.

1.2.4.2.23 нче таблица

**10 елга урман корткычларының башка төркемнәренә керә торган бүтән төрләрнең чыганаклары мәйданнары**

| Корткычның төре | Чыганакларның мәйданы, га | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2003 | 2004 | 2005 | 2006 | 2007 | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 |
| Көнчыгыш май коңгызы | 571 | 571 | 495 | 255 | 260 | 230 | 230 | 200,9 | 200,9 | 200,9 |
| Нарат кабыгасты кандаласы | 263 | 256 | 320 | 158 | 167 | 177,6 | 187,3 | 187,3 | 87,3 | 88,8 |
| Имән бәбәге көясе | | | 70 | 20 | 20 | 21,5 | 21,5 | 16 | 16 | 0 |
| Барлыгы | 834 | 827 | 885 | 433 | 447 | 429,1 | 438,8 | 404,2 | 304,2 | 289,7 |

2003 – 2012 еллар чорында башка төркем корткычлар чыганакларының уртача мәйданы 519,5 га тәшкил итте, еллар буенча әлеге күрсәткеч 420 га алып (2008 ел) 834 га кадәр (2003 ел) үзгәреп торды. 2010 елдан башлап чыганакларның мәйданнары кими бару күзәтелә. 2012 ел ахырына башка төркем урман корткычлары чыганаклары мәйданнары үзара түбәндәгечә бүленә.

1.2.4.2.24 нче таблица

**2012 ел ахырына башка төркем урман корткычларының төрләре буенча күпләп таралган урыннары мәйданы**

| Урманчылык | Чыганакларның мәйданы, га | | |
|---|---|---|---|
| | Имән бәбәге көясе | Май коңгызлары | Нарат кабыгасты кандаласы |
| Зеленодольск | | 170,9 | |
| Кама | | | 42,6 |
| Кызыл Йолдыз | | | 26 |
| Мамадыш | | 15 | 20,2 |
| Шәһәр яны | | 15 | |
| Барлыгы | | 200,9 | 88,8 |

Әлеге төркемдә май коңгызларының чыганаклары төп урынны алып тора, алар башка корткычлар чыганаклары гомуми мәйданының 69,3% ын тәшкил итә.

1.2.4.2.25 нче таблица

**2012 елда башка төркем урман корткычларыныңкүпләп таралган урыннары мәйданы динамикасы**

| Урманчылык | Чыганакларның мәйданы, га | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хисап елы башына | хисап елында ачыкланды | чаралар үткәрелде* | күрелгән чаралар нәтиҗәсендә юкка чыгарылды | табигый факторлар йогынтысында үзеннән-үзе бетте | хисап елы ахырына | шул исәптән чаралар үткәрүне таләп итә** |
| Баулы | 16,0 | | | | 16 | 0 | |
| Зеленодольск | 170,9 | | | | | 170,9 | |
| Кама | 42,6 | | | | | 42,6 | 42,6 |
| Кызыл Йолдыз | 26,0 | | | | | 26 | 26 |
| Мамадыш | 33,7 | 1,5 | | | | 35,2 | 16,5 |
| Шәһәр яны | 15,0 | | | | | 15 | 10 |
| Барлыгы | 304,2 | 1,5 | | | 16,0 | 289,7 | 95,1 |

Хисап елы ахырына башка төркем корткычлар чыганакларында әллә ни үзгәреш булмады. «Мамадыш урманчылыгы» ДКУдә нарат кабыгасты кандаласының элек булган чыганагы мәйданы 1,5 га артты. «Баулы урманчылыгы» ДКУдә табигый факторлар йогынтысында имән бәбәге көясе чыганагы 16,0 га мәйданда үзеннән-үзе бетте. Шулай итеп, башка урман корткычлары төркемендә чыганакларның гомуми мәйданы 289,7 га тәшкил итә, шуларның 32,8% ы юкка чыгару һәм локальләштерү буенча чаралар үткәрүне таләп итә.

Татарстан Республикасында үсеп җиткән утыртмалар авыруларыннан тамыр губкасы, нарат губкасы, кәүсә күгәреге, сумала рагы, чын һәм ялган ку гөмбәсе, яфраклы токымнарның бактериаль һәм рак авырулары чыганаклары табылды.

1.2.4.2.26 нче таблица

**10 елга урман авырулары күпләп таралган урыннары мәйданы**

| Авыру төре | Чыганакларның мәйданы, га | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2003 | 2004 | 2005 | 2006 | 2007 | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 |
| Тамыр губкасы | 1951 | 2683 | 2785 | 4672 | 3150 | 2647,7 | 2512,6 | 2414,1 | 2465,3 | 2159,8 |
| Ялган ку гөмбәсе | | 68 | 62 | 15925 | 16941 | 16509,5 | 16404 | 16444,8 | 16750,4 | 16618,2 |
| Кәүсә күгәреге | | | | | | 2738,9 | 5401,3 | 5430,2 | 5767,3 | 5370,6 |
| Чын ку | | | | | | 1057,4 | 1056,4 | 1629,5 | 1629,5 | 1627,5 |
| Нарат губкасы | | | | | | | | 108,1 | 108,1 | 132,1 |
| Сумала рагы | | | | | | | 136,7 | 97,6 | 111,1 | 48,3 |
| Бактериаль авырулар | | | | | | | | | 3949,4 | 4018,7 |

| Авыру төре | Чыганакларның мәйданы, га | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2003 | 2004 | 2005 | 2006 | 2007 | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 |
| Тирәк һәм усак кара рагы | | | | | | | | | | 93,0 |
| Барлыгы | 1951 | 2751 | 2847 | 21174 | 20091 | 22953,5 | 25511 | 26124,3 | 30781,1 | 30068,2 |

2003–2012 еллардаурман авырулары чыганакларының уртача мәйданы18425,2 гатәшкил итте (табл. 1.2.4.2.26). Чыганакларның мәйданнары күрсәтелгән чорның 2006 елында кинәт артып китте. 2012 ел ахырына Татарстан Республикасы урманнарында урман авырулары чыганакларының мәйданнары 30068,2 га тәшкил итте, бу күп еллар буенча алып исәпләнгән күрсәткечтән 1,6 тапкырга артып китте.

1.2.4.2.27нче таблица

**2012 ел ахырына урман авыруларының төркемнәр буенча күпләп таралган урыннары мәйданы**

| Урманчылык | Чыганакларның мәйданы, га | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | авырулар төркеме | | | | | | | | |
| | кәүсә һәм кәүсәнең юан башы күгәреге | | некроз-рак авырулары | | тамыр күп авырулары | бактериаль авырулар | башка авырулар | | Барысы |
| | барлыгы | шул исәптән тамыр губкасы | барлыгы | шул исәптән соры рак | | | барлыгы | шул исәптән өнчыл чык | |
| Әгерҗе | 282,8 | | 1,2 | 1,2 | | | | | 284 |
| Азнакай | 725,9 | 230,0 | | | | 16,0 | | | 741,9 |
| Аксубай | 1230,3 | | | | | | | | 1230,3 |
| Әлки | 148,6 | 34,5 | | | | | | | 148,6 |
| Әлмәт | 380,1 | 41,4 | 1,3 | | | | | | 381,4 |
| Арча | 51,8 | 16,1 | | | | | | | 51,8 |
| Баулы | 135,0 | | | | | | | | 135,0 |
| Биләр | 422,0 | | | | | | | | 422 |
| Болгар | 584,0 | 45,8 | | | | | | | 584,0 |
| Бөгелмә | 361,0 | | 6,6 | | | 15,0 | | | 382,6 |
| Буа | 269,6 | 57,2 | | | | | | | 269,6 |
| Алабуга | 56,0 | | 13,7 | 13,7 | | | | | 69,7 |
| Зәй | 36,2 | 29,0 | | | | | | | 36,2 |
| Зеленодольск | 5,0 | 5,0 | 8,9 | 8,9 | | | | | 13,9 |
| Кайбыч | 419,0 | 12,0 | | | | | | | 419,0 |
| Кәләй | 0 | | 0,6 | 0,6 | | 102,1 | | | 102,7 |
| Кама | 482,9 | 358,1 | 10,0 | 10,0 | | | | | 492,9 |
| Кызыл Йолдыз | 182,7 | | | | | 45,7 | | | 228,4 |
| Лаеш | 697,2 | 355,5 | 9,0 | 9,0 | | 3,0 | | | 709,2 |
| Лениногорск | 682,3 | 7,1 | 73,6 | | | 13,0 | | | 768,9 |
| Мамадыш | 745,0 | 102,5 | 4,9 | 4,9 | | | | | 749,9 |
| Минзәлә | 1722,8 | 67,8 | 8,1 | | | | | | 1730,9 |
| Түбән Кама | 11584,6 | | | | | 25,2 | | | 11609,8 |

| Урманчылык | Чыганакларның мәйданы, га | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | авырулар төркеме | | | | | | | | |
| | кәүсә һәм кәүсәнең юан башы күгәреге | | некроз-рак авырулары | | тамыр күп авырулары | бактериаль авырулар | башка авырулар | | Барысы |
| | барлыгы | шул исәптән тамыр губкасы | барлыгы | шул исәптән соры рак | | | барлыгы | шул исәптән өнчыл чык | |
| Нурлат | 650,0 | 2,1 | | | | 3752,9 | | | 4402,9 |
| Идел буе | 402,5 | 12,9 | | | | | | | 402,5 |
| Шәһәр яны | 907,3 | 767,8 | | | | | | | 907,3 |
| Саба | 15,0 | 15,0 | 3,4 | | | 1,1 | | | 19,5 |
| Тәтеш | 441,9 | | | | | | | | 441,9 |
| Чирмешән | 2286,7 | | | | | 44,7 | | | 2331,4 |
| Барлыгы | 25908,2 | 2159,8 | 141,3 | 48,3 | | 4018,7 | | | 30068,2 |

Татарстан Республикасында урман авырулары чыккан иң зур мәйданнар «Түбән Кама урманчылыгы» ДКУдә – 11609,8 га, «Нурлат урманчылыгы» ДКУдә – 4402,9 га, «Чирмешән урманчылыгы» ДКУдә – 2331,4 га, «Минзәлә урманчылыгы» ДКУдә – 1730,9 га мәйданда (1.2.4.2.27 нче таблица).

Урман авырулары чыганакларының барлык мәйданыннан 73% тан артыгы ялган ку гөмбәсенә һәм кәүсә күгәрекләренә туры килә, нәкъ алар иң күп зыян китерүчеләр дип санала. Тамыр губкасы – утыртмаларның коруына китерергә мөмкин иң киң таралган авыру, Татарстан Республикасында хисап елы ахырына аның белән барлык авыруларның гомуми мәйданыннан 7,2% зарарланган иде.

2012 елда урман авыруларын таксацияләү барышында 93 га гомуми мәйданда, бу барлык авырулар чыганакларының кушма мәйданыннан 1% тан кимрәк, «Әлмәт урманчылыгы» ДКУдә, «Бөгелмә урманчылыгы» ДКУдә, «Лениногорск урманчылыгы» ДКУдә, «Минзәлә урманчылыгы» ДКУдә, «Саба урманчылыгы» ДКУдә кабат тирәк һәм усак кара рагы чыганакларының барлыгы ачыкланды.

1.2.4.2.28 нче таблица

**2012 ел ахырына урман авыруларының төрләре буенча күпләп таралган урыннары мәйданы**

| Урманчылык | Авыруларны китереп чыгаручыларның чыганаклары мәйданнары, га | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Тамыр губкасы | Кәүсә күгәреге | Ялган ку гөмбәсе | Чын ку гөмбәсе | Нарат губкасы | Сумала рагы | Бактериаль авырулар | Тирәк һәм усак рагы |
| Әгерже | | | 282,8 | | | 1,2 | | |
| Азнакай | 230,0 | 7,2 | 488,7 | | | | 16,0 | |
| Аксубай | | | 1230,3 | | | | | |
| Әлки | 34,5 | 16,0 | 98,1 | | | | | |

| Урманчылык | Авыруларны китереп чыгаручыларның чыганаклары мәйданнары, га | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Тамыр губкасы | Кәүсә күгәреге | Ялган ку гөмбәсе | Чын ку гөмбәсе | Нарат губкасы | Сума ла рагы | Бактери-аль авырулар | Тирәк һәм усак рагы |
| Әлмәт | 41,4 | 196,7 | 142,0 | | | | | 1,3 |
| Арча | 16,1 | 33,7 | 2,0 | | | | | |
| Баулы | | 21 | 114,0 | | | | | |
| Биләр | | 422,0 | | | | | | |
| Болгар | 45,8 | 334,0 | 204,2 | | | | | |
| Бөгелмә | | 291,8 | 58,2 | 11,0 | | | 15,0 | 6,6 |
| Буа | 57,2 | 212,4 | | | | | | |
| Алабуга | | 56,0 | | | | 13,7 | | |
| Зәй | 29,0 | | 7,2 | | | | | |
| Зеленодольск | 5,0 | | | | | 8,9 | | |
| Ары | | | | | | | | |
| Кайбыч | 12,0 | 363,6 | 43,4 | | | | | |
| Кәләй | | | | | | 0,6 | 102,1 | |
| Кама | 358,1 | 93,3 | 31,5 | | | 10,0 | | |
| Лаеш | 355,5 | 127,4 | 214,3 | | | 9,0 | 3,0 | |
| Лениногорск | 7,1 | 362,0 | 232,7 | 80,5 | | | 13,0 | 73,6 |
| Мамадыш | 102,5 | 544,8 | 97,7 | | | 4,9 | | |
| Минзәлә | 67,8 | 82,9 | 1055,7 | 516,4 | | | | 8,1 |
| Түбән Кама | | 39,0 | 10393,9 | 1019,6 | 132,1 | | 25,2 | |
| Нурлат | 2,1 | | 647,9 | | | | 3752,9 | |
| Идел буе | 12,9 | 389,6 | | | | | | |
| Шәһәр яны | 767,8 | 95,8 | 43,7 | | | | | |
| Саба | 15,0 | | | | | | 1,1 | 3,4 |
| Тәтеш | | 355,5 | 86,4 | | | | | |
| Чирмешән | | 1315,9 | 970,8 | | | | 44,7 | |
| Барлыгы | 2159,8 | 5370,6 | 16618,2 | 1627,5 | 132,1 | 48,3 | 4018,7 | 93 |

2012 елда урман авырулары чыганакларының гомуми мәйданы узган ел күрсәткечләреннән 2,3% ка кимрәк. Ел дәвамында авырулар белән зарарланган утыртмаларның яңа җирләре 2744,7 га мәйданда табылды (1.2.4.2.28 нчетаблица).

Авырулар чыганакларының 2012 елда ачыкланган иң зур мәйданнары ялган ку гөмбәсенә туры килә (1114,1 га). Шулай ук узган елда кәүсә күгәреге (872,5 га), тамыр губкасы (298,5 га), сумала рагы (209 га), чын ку гөмбәсе (47,5 га), шулай ук нарат губкасы, бактериаль авырулар, тирәк һәм усак кара рагы (203,1 га) белән зарарланган яңа урыннарның булуы билгеле булды. Авырулар чыганакларының 66% мәйданында санитария-чистарту эшләре башкарырга кирәк.

Узган елда шулай ук кәүсә күгәрегенең яңа мәйданнары ачылды.




1.2.4.2.8 нче рәсем. 10 елда урман авырулар күпләп таралган урыннары мәйданы

1.2.4.2.29 нчы таблица

**2012 елда урман авырулары күпләп таралган урыннары мәйданы динамикасы**

| Урманчылык | Чыганакларның мәйданы, га | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хисап елы башына | хисап елында ачыкланды | хисап елында санитария-чистарту чаралары үткәрелде | күрелгән чаралар нәтиҗәсендә ел әйләнәсендә юкка чыгарылды | табигый факторлар йогынтысында үзеннән-үзе бетте | хисап елы ахырына | шул исәптән санитария-чистарту чараларын үткәрүне таләп итә |
| Әгерже | 290,9 | | 6,9 | 6,9 | | 284 | 209 |
| Азнакай | 725,9 | 46,0 | 30 | 30 | | 741,9 | 526,5 |
| Аксубай | 1409,4 | 1 | 180,1 | 180,1 | | 1230,3 | 1018,5 |
| Әлки | 150,2 | 47,2 | 48,8 | 48,8 | | 148,6 | 148,6 |
| Әлмәт | 189,5 | 237,2 | 45,3 | 45,3 | | 381,4 | 340,5 |
| Арча | 60,2 | 162,1 | 170,5 | 170,5 | | 51,8 | 35,7 |
| Баулы | 114 | 21,0 | | | | 135,0 | 21,0 |
| Биләр | 422 | | | | | 422 | 153 |

| Урманчылык | Чыганакларның мәйданы, га | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хисап елы башына | хисап елында ачыкланды | хисап елында санитария-чистарту чаралары үткәрелде | күрелгән чаралар нәтиҗәсендә ел әйләнәсендә юкка чыгарылды | табигый факторлар йогынтысында үзеннән-үзе бетте | хисап елы ахырына | шул исәптән санитария-чистарту чараларын үткәрүне таләп итә |
| Болгар | 648,6 | 80,6 | 145,2 | 145,2 | | 584,0 | 117,2 |
| Бөгелмә | 341,8 | 47,2 | 6,4 | 6,4 | | 382,6 | 70,8 |
| Буа | 269,6 | | | | | 269,6 | 155,3 |
| Алабуга | 80,2 | | 10,5 | 10,5 | | 69,7 | 56,7 |
| Зәй | 36,2 | | | | | 36,2 | |
| Зеленодольск | 281,7 | 51,0 | 318,8 | 318,8 | | 13,9 | 4,4 |
| Ары | 24 | 371,7 | 395,7 | 395,7 | | 0 | |
| Кайбыч | 584,6 | 723,0 | 888,6 | 888,6 | | 419,0 | 380,6 |
| Кәләй | 102,7 | | | | | 102,7 | 102,7 |
| Кама | 506,6 | 64,2 | 77,9 | 77,9 | | 492,9 | 492,9 |
| Кызыл Йолдыз | 214,9 | 13,5 | | | | 228,4 | 218,4 |
| Лаеш | 729,2 | 37,0 | 57,0 | 57,0 | | 709,2 | 396,5 |
| Лениногорск | 661,3 | 110,5 | 2,9 | 2,9 | | 768,9 | 172,2 |
| Мамадыш | 704,7 | 58,1 | 12,9 | 12,9 | | 749,9 | 696,9 |
| Минзәлә | 1718,9 | 12,0 | | | | 1730,9 | 75,9 |
| Түбән Кама | 11626,7 | 49,2 | 66,1 | 66,1 | | 11609,8 | 10213,5 |
| Нурлат | 4402,9 | | | | | 4402,9 | 1707,6 |
| Идел буе | 444,4 | 292,4 | 334,3 | 334,3 | | 402,5 | 261,7 |
| Шәһәр яны | 1253,9 | 71,1 | 417,7 | 417,7 | | 907,3 | 312,5 |
| Саба | | 215,7 | 196,2 | 196,2 | | 19,5 | |
| Тәтеш | 453,7 | 33,0 | 44,8 | 44,8 | | 441,9 | 258,7 |
| Чирмешән | 2332,4 | | 1,0 | 1,0 | | 2331,4 | 1689 |
| Барлыгы | 30781,1 | 2744,7 | 3457,6 | 3457,6 | | 30068,2 | 19836,3 |

Авыруларның чыганакларының чынбарлыктагы таралышы, күп кенә авыруларның җәелә баруы беренче карашка күренмәгәнгә күрә, аларның булуы ачыкланган мәйданнан шактый артык. Урман авырулары таралуның төп сәбәпләре уңай булмаган табигать шартларында, шулай ук санитария-чистарту һәм урман хуҗалыгы чараларының үз вакытында уздырылмавында дип табыла. 2012 елда санитария-чистарту чаралары нәтиҗәсендә 3457,6 га мәйданда авырулар чыганаклары юкка чыгарылды, бу узган елның шул ук күрсәткеченнән 9,3% ка күбрәк.

1.2.4.2.30 нчы таблица

**Урман авыруларыныңкүпләп таралган урыннарынлокальләштерү һәм юкка чыгару буенча 2012 елда үткәрелгән чаралар**

| Урманчы-лык | Корткыч төре | Ел башына чыганаклар мәйданы, га | Шул исәптән 2012 елда локальләштерү һәм юкка чыгару буенча чаралар үткәрүне таләп итте | 2012 елда чаралар үткәрү планлаштырылган мәйдан, га | Эшкәртү эшләре башкарылды, га | Чараларның техник нәтиҗәлелеге, % | Чыганаклар юкка чыгарылды, га | 2012 елда кишәрлекләрдә утыртмаларның кимерелү | Чаралар үткәрелмәгән 2012 елда кишәрлекләрдә утыртмаларның кимерелү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Баулы | Ефәкче | 6363,7 | 440,6 | 440,6 | 40,0 | 95,0 | 40,0 | 0 | 10-20 |
| Бөгелмә | Ефәкче | 13601 | 6395 | 6400 | 3460 | 100 | 3460 | 0 | 25-50 |
| Буа | Яшел имән яфрактөргече | 197,7 | 197,7 | 197,7 | 197,7 | 90,0 | 197,7 | 0 | 65 |
| Кайбыч | Яшел имән яфрактөргече | 11748 | 5573,6 | 6040 | 6040 | 89,0 | 5491 | 10 | 10, 50-70 |
| Мамадыш | Гади чыршы кисмәне | 774,1 | 279,4 | 320,6 | 320,6 | 92,0 | 320,6 | 0 | 10-20 |
| Тәтеш | Яшел имән яфрактөргече | 16497 | 3000 | 3000 | 3037,6 | 91,3 | 3037,6 | 0 | 20 |
| Барлыгы | | 49181,5 | 15890,8 | 16698,9 | 13095,9 | 92,9 | 12546,9 | | |

2012 елда ефәкчекүпләп таралган урыннарын юкка чыгару һәм локальләштерү буенча чаралар җир өстен нефть продуктлары белән эшкәртү юлы белән «Баулы урманчылыгы» ДКУдә, «Бөгелмә урманчылыгы» ДКУдә үткәрелде. Эшкәртелгән мәйданның гомуми зурлыгы 3500 га тәшкил итте. «Буа урманчылыгы» ДКУдә, «Кайбыч урманчылыгы» ДКУдә 6237,7 га мәйданда ДЗЛ күпләп таралган урыннары авиация ярдәмендә сиптерелде. Лепидоцид препараты кулланылды. «Тәтеш урманчылыгы» ДКУдә 3037,6 га җир өслеге Арриво препараты белән эшкәртелде. «Мамадыш урманчылыгы» ДКУдә 320,6 га мәйданда гади чыршы кисмәнен юкка чыгару һәм локальләштерү буенча җир өсте чаралары Арриво препаратын кулланып үткәрелде. Күрелгән чаралардан соң чыганакларның күп өлеше юкка чыкты, ә «Кайбыч урманчылыгы» ДКУдә чыганакларның бер өлеше көчле булудан көчсезгә күчте.

2013 елда 25946,9 га гомуми мәйданда урман корткычлары күпләп таралган урыннарында чаралар үткәрү таләп ителә. Яшел имән яфрактөргечен локальләштерү һәм юкка чыгаруның 15914,2 га мәйданда таләп ителүе нигезләнде. Шулардан «Кайбыч урманчылыгы» ДКУдә – 7900 га, «Болгар урманчылыгы» ДКУдә – 1300,3 га, «Лаеш урманчылыгы» ДКУдә – 6431,5 га, «Идел буе урманчылыгы» ДКУдә – 282,4 га.

Урман саклау чаралары зарарлы организмнар күпләп таралган урыннарын локальләштерү һәм юкка чыгару, санитария-чистарту чараларына, урман авыруларын тикшерүгә һәм урман авыруларына мониторинг ясауга бүленә.

Чыганакларны локальләштерү һәм юкка чыгару чаралары, аларның исәбен иң чик дәрәҗәгә кадәр төшерү һәм утыртмаларның зарарлануы аркасында зыян китермәү максатында, корткычларның күпләп таралган урыннарында уздырыла. Мондый чаралар башкарылу ысулы буенча да (җир өстендә һәм авиация ярдәмендә), кулланыла торган препаратлар буенча да (химик һәм биологик) аерылалар.

Санитария-чистарту чараларына агачларны сирәкләп һәм тоташтан кисү, шулай ук авыру, корткычлар ияләшкән һәм зарарланган агачларны сирәкләү, чүп-чарлардан чистарту, корткычларны җыя торган агачлар салу, кәүсә корткычлары күпләп таралган урыннарында феромон тозаклар куллану, шулай ук профилактика чаралары керә. Санитар кисүләрнең һәм чүп-чарларны чистартуның төп максаты урманнарның санитар торышын яхшыртудан һәм агачларны югалтудан килә торган икътисадый зыянны киметүдән гыйбарәт. Профилактика чаралары (ясалма оялау урыннарын элү, кырмыска ояларын әйләндереп алу һәм тарату, ремизлар утырту һ.б.ш.) бөҗәкләр ашый торган кошларны, кырмыскаларны, энтомофагларны шул урыннарга китерү өчен күрелә, алар урман корткыч бөҗәкләре артуның билгеле бер этабында аларның күпләп үрчүен туктатып калырга сәләтле.

Урман авыруларын тикшерүләрнең төп максаты утыртмаларның санитария торышын билгеләүдән, зарарлы организмнарның популяция исәбен ачыклаудан һәм урманны саклау чараларын билгеләүдән гыйбарәт.

Урман авыруларына мониторинг ясау максатын урманнарны саклау өлкәсендә идарә итүне башкару өчен санитариягә кагылышлы һәм урман авырулары торышындагы үзгәрешләрне үз вакытында ачыклау, бәяләү һәм фаразлау, шулай ук урманнарда санитария иминлеген тәэмин итү тәшкил итә.

Профилактика чаралары урманнарның авыруларга каршы торучанлыгын саклап калу һәм аларга тискәре факторларның йогынтысын чикли торган шартлар тудыру өчен үткәрелә. Корткычларның яңа күпләп таралган урыннары барлыкка килүне урман саклауның актив алымнарын корткычларның үрчүе өчен уңай булмаган шартлар тудыруга юнәлтелгән урман хуҗалыгы чаралары белән бергә башкарганда гына кисәтеп була.

Урман фондын саклау гамәлләренең мөһим бер өлешен санитария-чистарту чаралары алып тора. Аларның төп бурычы урманнарның санитар торышын яхшыртудан һәм агачларны югалтудан килә торган икътисадый зыянны киметүдән гыйбарәт.

Кәүсә корткычлары күпләп таралган урыннары һәм куркыныч йогышлы авырулар барлыкка килүне кисәтү, шулай ук авырулар белән зарарланган, начар табигать шартларыннан һәм антропоген факторлардан зыян күргән кишәрлекләрне юкка чыгару максатларында авыруларга каршы торучанлыгы бозылган һәм юкка чыккан утыртмаларны 7326,2 га мәйданда бетерүгә мөмкинлек биргән чаралар үткәрелде, шул исәптән:

- санитар максатларда тоташтан кисүләр - 391,6 га,

- сирәкләп санитар кисүләр - 5155,8 га,
- урманны чүп-чардан чистарту - 1778,8 га

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында таләп ителгән санитар кисүләр күләме аларны башкару мөмкинлекләреннән күпкә артык, бу исә үлгән агачларның тупланып баруына китерә.

Узган елларда (2007, 2008, 2009, 2010 еллар) «Баулы урманчылыгы» ДКУдә, «Биләр урманчылыгы» ДКУдә, «Буа урманчылыгы» ДКУдә, «Зәй урманчылыгы» ДКУдә, «Лаеш урманчылыгы» ДКУдә, «Бөгелмә урманчылыгы» ДКУдә, «Әлки урманчылыгы» ДКУдә, «Кәләй урманчылыгы» ДКУдә, «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» ДКУдә, «Лениногорск урманчылыгы» ДКУдә, «Мамадыш урманчылыгы» ДКУдә, «Минзәлә урманчылыгы» ДКУдә, «Әлмәт урманчылыгы» ДКУдә, «Алабуга урманчылыгы» ДКУдә һәм «Шәһәр яны урманчылыгы» ДКУдә булып узган янгыннар 136,2 га мәйданда утыртмаларның авыруларга каршы торучанлыгы бозылуга китерде (табл.3.3.1.3). Бу кишәрлекләрдә, санитария-чистарту чараларын оператив үткәрмәүдән килгән зыянны билгеләү максатында, урман авыруларына өстәмә тикшерүләр үткәрергә кирәк.

1.2.4.2.31 нче таблица

**2010 – 2012 еллардагы янгыннардан зыян күргән утыртмалар турында белешмәләр (2013 елның 1 гыйнварына)**

| Урманчылык | Урман янгыннарыннан зыян күргән ел | Урман янгыннарыннан зыян күрү, га | Шулардан тикшерелде | | | Санитария-чистарту чаралары билгеләнде, га (зыян күргән вакыттан башлап) | | | | Санитария-чистарту чаралары үткәрелде, га (зыян күргән вакыттан башлап) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | га | % | шул исәптән юкка чыккан | ССР | ВСР | УЗ | Барлыгы | ССР | ВСР | УЗ | Барлыгы | |
| | | | | | | | | | | | | | га | % |
| Әгерже | 2010 | 12,1 | 12,1 | 100 | | | 11,3 | 0,8 | 12,1 | | 11,3 | 0,8 | 12,1 | 100 |
| Азнакай | 2010 | 4,2 | 4,2 | 100 | | | 4,2 | | 4,2 | | 4,2 | | 4,2 | 100 |
| Әлки | 2010 | 16,7 | 16,7 | 100 | 5,1 | 5,1 | 11,6 | | 16,7 | | 11,6 | | 11,6 | 69,5 |
| Әлмәт | 2010 | 1,5 | 1,5 | 100 | | | 1,5 | | 1,5 | | 1,5 | | 1,5 | 100 |
| Болгар | 2010 | 32,2 | 32,2 | 100 | 3 | 3 | 0,4 | 28,8 | 32,2 | 3 | 0,4 | 28,8 | 32,2 | 100 |
| Бөгелмә | 2010 | 7,1 | 7,1 | 100 | 6,1 | | 1 | 6,1 | 7,1 | | 1 | 6,1 | 7,1 | 100 |
| Алабуга | 2010 | 29 | 29 | 100 | 19,6 | 19,6 | 9,4 | | 29 | 5,2 | 9,4 | | 14,6 | 50,35 |
| Зәй | 2010 | 2,8 | 2,8 | 100 | | | 2,8 | | 2,8 | | 2,8 | | 2,8 | 100 |
| Ары | 2010 | 1,6 | 1,6 | 100 | | | 1,6 | | 1,6 | | 1,6 | | 1,6 | 100 |
| Кама | 2010 | 13,8 | 13,8 | 100 | | | 13,8 | | 13,8 | | 13,8 | | 13,8 | 100 |
| Кызыл Йолдыз | 2010 | 5,7 | 5,7 | 100 | | | 5,7 | | 5,7 | | 5,7 | | 5,7 | 100 |
| Кәләй | 2010 | 0,15 | 0,15 | 100 | | | 0,15 | | 0,15 | | 0,15 | | 0,15 | 100 |
| Лаеш | 2010 | 21,7 | 21,7 | 100 | 17 | 17 | 4,7 | | 21,7 | 16,3 | 1,6 | | 17,9 | 82,5 |
| Лениногорск | 2010 | 4 | 4 | 100 | 1,9 | 1,9 | 2,1 | | 4 | 1,2 | 2,1 | | 3,3 | 82,5 |
| Мамадыш | 2010 | 13 | 13 | 100 | 2,3 | 2,3 | 10,7 | | 13 | 2,3 | 4,8 | | 7,1 | 54,6 |
| Минзәлә | 2010 | 2,2 | 2,2 | 100 | 2,2 | | | 2,2 | 2,2 | | | 2,2 | 2,2 | 100 |
| Барлыгы (2010-2012 гг.) | | 167,8 | 167,8 | 100 | 57,2 | 48,9 | 81 | 37,9 | 167,8 | 28 | 72 | 35,7 | 137,9 | 82,2 |

2010 елгы янгыннар аркасында 167,8 га мәйданда урман утыртмалары һәлак булды. Янгын булган елда корыган утыртмаларның өлеше шушы сәбәп аркасында зыян килгән утыртмалар мәйданының 34,2% ын тәшкил итте.

2010 – 2012 елларда 2010 ел янгыннарыннан зыян күргән мәйданнарда авыруларга каршы торучанлыгы бозылган һәм юкка чыккан мәйданнарның 100% ында урман авыруларына тикшерүләр үткәрелде. Барлык кирәкле урыннарга санитария-чистарту эшләре билгеләнде. 2012 ел ахырына чаралар үткәрүнең оперативлылыгы 82,2% тәшкил итте. Арендаланган территорияләрдә чаралар үткәрелмәде.

1.2.4.2.32 нче таблица

**2012 ел ахырына төрле вакытларда булган янгыннар аркасында авыруларга каршы торучанлыгы кимегән һәм юкка чыккан утыртмалар мәйданының бүленеше**

| Урманчылык | Ел ахырына корый башлаган утыртмалар мәйданы, га | | | | | Шул исәптән корыган утыртмалар | | | Тирәсендә чүп-чар өелгән утыртмалар | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | шул исәптән кору дәрәҗәсе буенча | | | | быел | | агымдагы ел ахырына тамырлар гына калганнар, га*** | | |
| | | ≤ 4% | 4,1-10% | 10,1-40% | > 40% | мәйдан, га | запас, дес. м3 | | мәйдан, га | запас, дес. м3 |
| Әлки | 11,7 | | | 0,1 | 11,6 | | | 8,9 | | |
| Әлмәт | 1,7 | | 0,7 | | 1 | | | 1 | | |
| Баулы | 13,9 | | | 12,5 | 1,4 | | | 2,7 | | |
| Биләр | 0,9 | | | 0,4 | 0,5 | | | 0,5 | | |
| Болгар | | | | | | 1,3 | 9,5 | | | |
| Бөгелмә | 2,3 | | | | 2,3 | 2,3 | 21 | 2,3 | | |
| Буа | 2,9 | | | 2,9 | | | | | | |
| Алабуга | 14,4 | | | | 14,4 | | | 14,4 | | |
| Зәй | 1,6 | | | | 1,6 | | | 1,6 | | |
| Кызыл Йолдыз | 3,1 | | | 3,1 | | | | | | |
| Кәләй | 0,2 | | 0,2 | | | | | | | |
| Лаеш | 41,8 | | | 3,1 | 38,7 | | | 3,3 | | |
| Лениногорск | 7,7 | | | 7 | 0,7 | | | 0,7 | | |
| Мамадыш | 12,3 | 1 | | 5,9 | 5,4 | | | | | |
| Минзәлә | 6,7 | | | 6,7 | | | | | | |
| Шәһәр яны | 15 | | | 14 | 1 | | | 1 | | |
| Барлыгы | 136,2 | 1 | 0,9 | 55,7 | 78,6 | 3,6 | 30,5 | 36,4 | | |

Урманнарның януы һәм янгыннар аркасында коруы дәрәҗәсе берничә ел дәвамында төрле булды, бу климат шартларының вакыт-вакыт үзгәреп торуына бәйле. Татарстан Республикасында соңгы 10 елда, уттан зыян күреп, 145,3 га урман утыртмалары юкка чыкты.




1.2.4.2.9 нчы рәсем. 10 елда урман янгыннары аркасында корыган утыртмалар мәйданнары

Кәүсә һәм кәүсәнең төп башы күгәрекләре, агачлыкларның тоташтан коруына сирәк китерсәләр дә, утыртмаларның үсүе дәвам итүгә һәм продуктивлыгына йогынты ясый торган җитди фактор булып торалар. Күгәрекле авырулар белән көрәшү зарарланган агачларны һәм коры-сарыны кисүгә кайтып кала. Кәүсә һәм кәүсәнең төп башы күгәрекләренең таралуын профилактикалау буларак утыртмаларны үз вакытында һәм тиешенчә карау юлы белән аларның авыруларга каршы торучанлыгын арттыруга омтылырга кирәк.

Яфраклы агач токымнарының күгәрекле авыруларын китереп чыгара торган гөмбәләр арасында ялган һәм чын ку гөмбәләре күпләп таралган урыннары беренче урында тора. Урман авыруларына ясалган мониторинг күрсәткәнчә, күгәрекле авыруларның артуы турыдан-туры агачлыкларның яшенә бәйле. Алар күбрәк картрак агачлар булган урыннарда киң тарала.

Кәүсә һәм кәүсәнең төп башы күгәрекләре берничә ел рәттән Татарстан Республикасы урман фондында иң киң таралган гөмбә авыруларының берсе булып тора.

1.2.4.2.33 таблицасы

**2012 елда кәүсә күгәреге күпләп таралган урыннар мәйданнары динамикасы**

| Урманчылык | Чыганакларның мәйданы, га | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хисап елы башына | хисап елында ачыкланды | хисап елында санитария-чистарту чаралары үткәрелде | күрелгән чаралар нәтиҗәсендә ел әйләнәсендә юкка чыгарылды | табигый факторлар йогынтысында үзеннән-үзе бетте | хисап елы ахырына | шул исәптән санитария-чистарту чараларын үткәрүне таләп итә |
| Азнакай | 7,2 | | | | | 7,2 | 7,2 |
| Аксубай | 103,4 | | 103,4 | 103,4 | | 0 | |
| Әлки | 16 | 46,0 | 46,0 | 46,0 | | 16,0 | 16 |
| Әлмәт | 33,7 | 171,1 | 8,1 | 8,1 | | 196,7 | 179,5 |
| Арча | 51,4 | 82,1 | 99,8 | 99,8 | | 33,7 | 33,7 |
| Баулы | | 21,0 | | | | 21,0 | 21,0 |
| Биләр | 422 | | | | | 422,0 | 153 |
| Болгар | 368,5 | 2,6 | 37,1 | 37,1 | | 334,0 | |
| Бөгелмә | 291,8 | | | | | 291,8 | 6 |
| Буа | 212,4 | | | | | 212,4 | 98,1 |
| Алабуга | 66,5 | | 10,5 | 10,5 | | 56,0 | 56,0 |
| Зеленодольск | 221 | 51 | 272 | 272 | | 0 | |
| Ары | 0 | 112,9 | 112,9 | 112,9 | | 0 | |
| Кайбыч | 523,6 | 43,1 | 203,1 | 203,1 | | 363,6 | 337,6 |
| Кама | 93,3 | | | | | 93,3 | 93,3 |
| Кызыл Йолдыз | 10 | | | | | 10 | |
| Лаеш | 145,4 | 25,2 | 43,2 | 43,2 | | 127,4 | 127,4 |
| Лениногорск | 341 | 23,9 | 2,9 | 2,9 | | 362,0 | 21,0 |
| Мамадыш | 544,8 | | | | | 544,8 | 544,8 |
| Минзәлә | 79 | 3,9 | | | | 82,9 | |
| Түбән Кама | 39 | | | | | 39,0 | 22,9 |
| Идел буе | 430,1 | 62,9 | 103,4 | 103,4 | | 389,6 | 191 |
| Шәһәр яны | 95,8 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | | 95,8 | |
| Саба | 0 | 191,8 | 191,8 | 191,8 | | 0 | |
| Тәтеш | 355,5 | 33,0 | 33,0 | 33,0 | | 355,5 | 172,3 |
| Чирмешән | 1315,9 | | | | | 1315,9 | 1098,5 |
| Барлыгы | 5767,3 | 872,5 | 1269,2 | 1269,2 | | 5370,6 | 3179,3 |

2012 ел башына Татарстан Республикасы урманнарында кәүсә күгәреге күпләп таралган урыннар5767,3 га мәйданда 26 урманчылыкта бар иде. Урман авыруларын тикшерү һәм таксацияләү барышында яңа чыганаклар ачыкланды һәм искеләре кинәйде, бу үз чиратында әлеге авыруның кушма мәйданын 872,5 га арттырды. Моның белән бергә 1269,2 га мәйданда санитария-чистарту эшләре алып барылды. Нәтиҗәдә 2012 ел ахырына Татарстан Республикасы урман фондында кәүсә күгәреге күпләп таралган урыннарның гомуми мәйданы 5370,6

гатәшкил итте, шуларның 59,2% ында агачлар урта һәм югары дәрәҗәдә зарарланган, аларга санитария-чистарту чараларын үткәрү таләп ителә.

1.2.4.2.33а таблицасы

**2012 елда кәүсә күгәреге күпләп таралган урыннарында утыртмалар мәйданнарының зарарлану дәрәҗәсенә карап бүленеше**

| Урманчылык | Зараралану дәрәҗәсе буенча чыганакларның мәйданы, га | | | Барысы |
|---|---|---|---|---|
| | 11…20% | 21…30% | 30% артык | |
| Азнакай | | 7,2 | | 7,2 |
| Әлки | | 16 | | 16,0 |
| Әлмәт | 17,2 | 28,9 | 150,6 | 196,7 |
| Арча | | 33,7 | | 33,7 |
| Баулы | | 21,0 | | 21,0 |
| Биләр | 269,0 | 153 | | 422,0 |
| Болгар | 334,0 | | | 334,0 |
| Бөгелмә | 285,8 | | 6,0 | 291,8 |
| Буа | 114,3 | 98,1 | | 212,4 |
| Алабуга | | 48,5 | 7,5 | 56,0 |
| Кайбыч | 26,0 | 337,6 | | 363,6 |
| Кама | | 78,1 | 15,2 | 93,3 |
| Кызыл Йолдыз | 10,0 | | | 10 |
| Лаеш | | 127,4 | | 127,4 |
| Лениногорск | 341,0 | 21,0 | | 362,0 |
| Мамадыш | | 544,8 | | 544,8 |
| Минзәлә | 82,9 | | | 82,9 |
| Түбән Кама | 16,1 | 22,9 | | 39,0 |
| Идел буе | 198,6 | 6 | 185 | 389,6 |
| Шәһәр яны | 95,8 | | | 95,8 |
| Тәтеш | 183,2 | 172,3 | | 355,5 |
| Чирмешән | 217,4 | 610,3 | 488,2 | 1315,9 |
| Барлыгы | 2191,3 | 2326,8 | 852,5 | 5370,6 |

Кәүсә күгәрегенең хуҗалыкка китерә торган зыяны бик зур булырга мөмкин, һәм ул гөмбәләрнең авыруларны китереп чыгара алучанлыгына һәм агачны черетүдәге активлыгына, таралу дәрәҗәсенә нык бәйле. Китерелә торган зыянның зурлыгы шулай ук авыруның үз вакытында ачыклануына һәм аның белән көрәшүдә нәтиҗәле чараларның күрелүенә дә шактый бәйле.

Татарстан Республикасында урман корткычларының һәм авыруларының төп төрләре

Тамыр губкасы Татарстан Республикасының ылыслы урманнарында иң киң таралган авыруларның берсе, 2012 ел ахырына аның белән 2159,8 га жир,

шулардан 795,8 га – аз күләмдә, 842,7 га – уртача күләмдә, 521,3 га – зур күләмдә зарарланган иде. Авырулар күпләп таралган урыннарының гомуми мәйданында тамыр губкасы аркасында килеп чыккан чыганаклар 7,2% тәшкил итте. Әлеге авыру күпләп таралган урыннары бигрәк тә «Шәһәр яны урманчылыгы» ДКУдә, «Кама урманчылыгы» ДКУдә, «Лаеш урманчылыгы» ДКУдә, «Азнакай урманчылыгы» ДКУдә күп очрый. Тамыр губкасы, сазлыклы урыннар тыш, барлык типтагы урман-үсемлек шартларында урман һәм урман-дала зонасының ылыслы урманнарында аеруча киң таралган. Бик тыгыз үскән утыртмаларда үрчем бирә торган организмнарны түшәмә катламында бик нык көчсезләнгән агачларның тамыр муентыгына береккән халәттә табарга була, алар сирәк кенә агач төпләре өслегенә чыга, черемәгән урман түшәмәсендә тагы да сирәгрәк очрый. Зарарланган кишәрлекләрдәге туфрак шулай ук әлеге гөмбәне йоктыра торган чыганак булып тора.

Тамыр губкасы авыруының киң таралуы һәм аннан күрелгән иң зур зыян югары бонитетлы утыртмалар зарарланганда күзәтелә. Төрле еллык үсемлекләр зарарлана. Тамыр губкасы күпләп таралган урыннарының шәһәр яны урманнарында таралуына рекреация йөкләнешенең зур булуы сәбәпче була. Үз вакытында җыештырылмаган агачлар шулай ук чыганакларның артуына китерә.

Әлеге киң таралган һәм зыян китерә торган авыру белән көрәшүнең иң нәтиҗәле алымы булып профилактика һәм санитария-чистарту эшләре кала бирә.

Кайрыашар-типограф дигән кайрыашар коңгыз куркыныч корткыч булып тора, ул зур мәйданнарда кинәт үрчеп китәргә һәм көчсезләнгән утыртмаларның коруына китерергә мөмкин. Коңгызлар кайрыда кереп йөрү өчен түгәрәк тишекләр ясыйлар, аларның диаметры гәүдәләренең киңлегенә туры килә торган була, ә үрчү камералары һәм ана кортлар йөри торган юллар калын кайры астына яшерелә. Һәр ана корт, орлыкланганнан соң, үзенә йөрү өчен буйлыга юл сала, ул үрчү камерасыннан өскә һәм аска таба илтә торган була. Кортлар, туклана башлагач, ана коңгыз юлыннан читкә китә торган корт юлларын кимереп салалар, бу вакытта кабыкка, кайрының эчке катламына, камбийга һәм үзагачның өске ягына 1-2 мм тирәнлектә зыян китерәләр. Кәүсә өслегенең гомуми мәйданыннан процентларда исәпләнгән зарарланган өлеше турыдан-туры агачтагы кайрыашарларның санына бәйле.

Типограф үсә торган һәм киселгән агачлар кәүсәләренең юка һәм калын кабыгы тирәсенә, тамырларыннан арындырылмаган урман материалларына һәм кискәннән соң калган кисәкләргә кереп урнаша. Күпләп үрчегән вакытта әле үсәргә сәләтле яшел ылыслы агачларга, көчсезләндерүнең тышкы билгеләрен күрсәтмичә, актив һөҗүм ясый. Коңгызлар III класс яшендәге (60 еллык) һәм аннан картрак ылыслы агачларга күчә. Уртача яктылыктагы һәм дымлылыктагы шартларга өстенлек бирә.

Көнчыгыш май коңгызы Россиянең Европа өлешендә, Көнбатыш һәм Көнчыгыш Себердә таралган. Коңгызларның яратып ашый торган агач төрләренә имән, каен, алмагач, тирәк керә. Көнчыгыш май коңгызының ареалы зур, аның экологик шартларга карата таләпләре сизелерлек үзгәреп тора. Урман зонасының төньяк өлешендә коңгызлар иске киселгән урыннарга, 0,1-0,2 тыгызлыктагы яныкларга, урман аланнарына, сирәк рәтләргә, урманга тоташкан ачык урыннарга,

питомникларга яратып урнаша. Ул шулай ук арчанлы һәм мүкле нарат урманнарының агачлар иң сирәк үсә торган урыннарында очрый. Май коңгызы, кагыйдә буларак, балчык катнаш туфракларда очрамый. Россиянең төньяк яртысында, Татарстан Республикасы да шул территориягә керә, май коңгызлары якынча биш ел саен алышынып тора дип санарга мөмкин. Май коңгызының үрчүендә һәрвакытта да нинди дә булса бер яшьтәге кортлар күбрәк була. Болар – оча торган, ягъни башкалардан өстенлек алучы буын. Төрле урман массивларында аларның оча торган еллары туры килмәскә мөмкин. Хәтта бер урман массивы эчендә дә очу елы ике булырга мөмкин. Бу очракта өстенлек алган һәр буын еш кына билгеле бер үсү урыннары шартларына иялэшкән була. Оча торган еллары чагыштырмача бер төрле була. Ләкин үзгәрүчән шартларга бәйле рәвештә очу еллары вакыт ягыннан күчәргә дә мөмкин.

Кортлар 3 – 4 ел үсәләр. Яшәү чорында алар көз көннәрендә туфракның тирәнрәк, туң төшми торган катламнарына (80 – 120 см тирәнлеккә) көзге күченүләрен (миграцияләрен) башкаралар, ә яз көннәрендә өскә күтәреләләр һәм туклануның бөтен чорына 10 – 20 см тирәнлектә өске катламнарда калалар. Май коңгызы кортлары туфракта яшиләр һәм төрле үсемлекләрнең тамырлары белән туклананалар, ләкин шул урман кварталының вакытта төрлечә үсәләр. Алар өчен иң яхшысы нарат белән каен тамырлары. Алар аеруча нарат культураларына һәм комлы, комсу һәм җиңел балчыксыл туфраклардагы табигый яшь үсемлекләргә зур зыян китерәләр. Коңгызлар, туфрактан чыкканнан соң, өстәмә туклану өчен яфраклы агачларга таба юл алалар. Алар ялгыз торучы агачларга яки бернинчә агачка, урман очларына һәм нык сирәкләнгән утыртмаларга өстенлек бирәләр. Бөреләр ачыла һәм яфрак пластинкасы катылана барган саен коңгызлар бер агач токымыннан икенчесенә күчеп йөри. Коңгызлар кояш батканнан соңгы эңгер-меңгердә очалар, көндез исә яфраклары белән туклана торган агачта тыныч кына утыралар. Азык эзләп алар 10 км һәм аннан да күбрәк араларда очып йөри алалар. Очу вакыты ике ай тәшкил итә. Июль – август айларында алар курчакка төренәләр, һәм янә күпмедер вакыттан туфракта ятуларын дәвам итә торган һәм киләсе елның язында гына очып чыгачак коңгызларга әвереләләр, ләкин өстенлек алган буынга хас күпләп очу 4-5 елдан соң гына була.

1.2.4.2.34 нче таблица

**2009–2013 елларда санитария-чистарту чараларын үткәрү**

| Санитария-чистарту чараларының исеме | Еллар | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2009 | | 2010 | | 2011 | | 2012 | | 2013 | |
| | га | күләм, м3 | га | күләм, м3 | га | күләм, м3 | га | күләм м3 | га | күләм м3 |
| Сирәкләп санитар кисүләр | 4829,6 | 88670 | 4263,10 | 103535,10 | 6179,3 | 142954 | 6379,70 | 187485,30 | 5808,96 | 188585,94 |
| Тоташтансан | 137,9 | 1701 | 226,6 | 32447, | 509,5 | 5440 | 516,3 | 84062 | 861,0 | 129371 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| итар кисүләр | | 7 | 2 | 00 | | 0 | 6 | | 2 | ,83 |
| Урманнарны чүп-чардан арындыру | 3368, 50 | | 4455, 5 | | 5641, 70 | | 9804, 9 | | 9910 | |

### 1.2.4.3. Урманнарны яңадан үстерү. Урманнарны торгызу

*Татарстан Республикасы урманнарын яңадан үстерүнең кыскача тарихы*

Казан губернасында урман культураларының барлыкка килүе М.Зельгер, Я. Фалентин, Ф. Фокель кебек урман белгечләренең исемнәре белән бәйле, алар имән чикләвеген чәчү һәм яшь үсентеләрне утырту өчен яраклы (корабль ясауга яраклы агач материаллары бирә торган урманнар үстерү һәм булдыру өчен) урыннар табарга тиеш булганнар. 1731 елдан алып 1735 елга кадәрге чорда тәүге тапкыр орлыклар чәчелгән һәм үсентеләр утыртылган.

Күп кенә урманчылыклар территорияләрендә югары продуктив нарат, чыршы, карагай урман культураларының уникаль кишәрлекләре сакланып калган.

Урманнарны торгызуның тарихи тәҗрибәсенә таянып Татарстанда урманнар торгызуның нәтиҗәле алымнары барлыкка килгән, алар урманның табигый яңару сәләтен куллануны да, урманнарны ясалма торгызуны да күз алдында тота.

Хәзерге вакытта урманнарны ясалма торгызуның нәтиҗәле алымнарына һәм ысулларына нигезләнгән зур тәҗрибә тупланган, аларны урманнар үсә торган төрле шартларга һәм урман типларына карата кулланып була.

Республикада урманнарны киңәйтелгән яңадан үстерү эшләре башкарыла, шул ук вакытта урманнарны торгызу чаралары тоташтан кисү мәйданнарыннан 1,8 тапкырга зуррак булган мәйданнарда алып барыла. 2007 елда киселгән урман мәйданы 1,9 мең га тәшкил итте. 2012 елда урманнарны торгызу эшләре 2327 га мәйданда башкарылды, шул исәптән 1972 мең га мәйданда урман утыртылды һәм 334 га җирдә урманның табигый яңаруына ярдәм күрсәтелде.

Урман культураларын барлыкка китерү эшләре аланлыкларда, урман булмаган җирләрдә, шулай ук яңа гына киселгән урыннарда башкарылды.

Моңа бәйле рәвештә хәзерге вакытта урман культуралары фонды тулысынча диярлек тотып бетерелде, урманнарны торгызу эшләре нигездә яңа гына кисү белән билгеләнгән урман кишәрлекләрендә алып барыла. Кызганычка каршы, исәпле урман кисү күләме 1991 елдан башлап даими үтәлми, аның 2007 елда үзләштерелүе проценты бары тик 21,7% тәшкил итте. 2011 ел белән чагыштырганда 2012 елда урман торгызу эшләре 108 га мәйданга, ягъни 5% ка артты. Урман торгызу эшләре мәйданы абсолют саннарда тиешенчә 2219 га һәм 2327 га тәшкил итте. 2012 елда 2013 ел урман культураларын булдыру өчен җир әзерләү 1915 га мәйданда башкарылды.

2012 елда яшь үсентеләр кыйммәтле агач утыртмалары категориясенә кертелде – барлыгы 1,7 мең га мәйданда, шулардан урман культуралары үскән 0,3 мең га мәйдан урман каплаган мәйданнарга күчерелде.

Саклагыч урман утырту эшләре 2012 елда 1589 га мәйданда башкарылды, шулардан 322,5 га мәйдан алып торган текә кыялар урманлы булдылар.

Татарстан Республикасында 448 га гомуми мәйданда 55 даими урман питомнигы эшли.

Үстерелгән стандарт утырту материаллары барлыгы 76,0 млн. данә тәшкил итте.

1.2.4.3.1нче таблица

**Урман торгызу ысуллары буенча эшләр башкару**

| № т/с | Күрсәткечләр | Исәпләү берәмлеге | 2006 – 2010 (урта) | 2011 ел | 2012 ел | 2011елга карата 2012ел аермасы,% |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Урман торгызу мәйданы, барлыгы | га | 14690 | 2199 | 2306 | +5 |
| | шул исәптән ясалма | га | 13011 | 1869 | 1972 | +5 |
| | урманның табигый яңаруына ярдәм итү | га | 1679 | 330 | 334 | +2 |
| 2. | Ясалма торгызылган урман мәйданы | га | 13011 | 1869 | 1972 | +5 |
| 3. | Корыган утыртмалар мәйданы | га | 4 | 0 | 0 | 0 |
| 4. | 2007 елда ясалма торгызылган урман мәйданнарының корыган урман культуралары мәйданнарына карата нисбәте | % | 0,03 | 0 | 0 | 0 |
| 5. | Урман үсемлекләре белән капланган жирләргә күчерелгән урман культуралары мәйданнарының 2007 елда булдырылган мәйданнарга карата нисбәте | % | 0 | 0 | 0 | 0 |

1.2.4.3.2нче таблица

**2012 елда урман торгызу эшләрен башкару**

| Урман торгызу эшләре | Исәпләү берәмлеге. | Күләм | Федераль бюджет, меңсум | Башка чыганаклар, мең сум | Барлыгы мең сум | Ураннан файдаланучылар үз хисапларына башкарган эшләрнең күләме |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Урман утырту | га | 1972 | 1835,9 | 3621,3 | 5457,2 | 151 |
| Урман культураларына өстәмә | га | 5728 | 428,7 | 1610,1 | 2038,8 | 316 |
| Урман культураларын карау (бер тапкырга күчереп каралганда) | га | 16773 | 4304,7 | 6344,2 | 10648,9 | 819 |

| Урман торгызу эшләре | Исәпләү берәмлеге. | Күләм | Федераль бюджет, меңсум | Башка чыганаклар, мең сум | Барлыгы мең сум | Ураннан файдаланучылар үз хисапларына башкарган эшләрнең күләме |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Киләсе ел урман культураларынаҗир әзерләү | га | 1915 | 657,7 | 2815,6 | 3473,3 | 158 |
| Табигый яңаруга ярдәм итү | га | 334 | 4,7 | 109,6 | 114,3 | 131 |
| Утырту материалларын үстерү | мең данә | 70600 | 2010,9 | 11976,6 | 13987,5 | 715,6 |
| Урман орлыкчылыгы объектларына нигез әзерләү | га | 0 | 2,1 | 25,8 | 27,9 | 0 |
| Урман орлыкчылыгы объектларын карау | га | 0 | 0 | 6,4 | 6,4 | 0 |
| Урман орлыкларын әзерләү | кг | 14867,7 | 203,7 | 1126 | 1329,7 | 14867,7 |
| Орлыклар сатып алу | мең сум | 0 | 23 | 16 | 39 | 0 |
| Утырту материаллары сатып алу | мең сум | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Башка чыгымнар | мең сум | 0 | 96,1 | 0 | 96,1 | 0 |

2012 елда республикада урман культураларына нигез салу буенча эшләр алып барылды. Урман фондында 2012 елның 1 июненә урман культуралары 1972 га мәйданга утыртылды, 1972 га мәйданга планлаштырылган иде. Питомникларда 49,01 га мәйданга утыртылды, 49,01 га мәйданга планлаштырылган иде.

1.2.4.3.3 нче таблица

**2013 елның 1 гыйнварына исәпкә алынган урман культуралары мәйданы (урманчылыклар буенча)**

| Урманчылык исеме | Мәйдан, га | | | | Чагыштырма өлеш,% | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | урман җир-ләре | урман үсемлек-ләре белән капланган җирләр | урман культура-лары | урман буларак өлгермәгәнур ман культура-лары | урман үсемлекләре белән капланган җирләрдән урман буларак өлгергән культуралар | урман җирләренә караганда барлык урман культуралары |
| Әгерҗе | 43348 | 42237 | 14058 | 686 | 33 | 32 |
| Азнакай | 46103 | 42113 | 15004 | 369 | 36 | 33 |
| Аксубай | 29077 | 28808 | 5242 | 188 | 18 | 18 |
| Әлки | 36989 | 36552 | 7086 | 271 | 19 | 19 |

| Урманчылык исеме | Мәйдан, га | | | | Чагыштырма өлеш,% | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | урман жир-ләре | урман үсемлек-ләре белән капланган жирләр | урман культура-лары | урман буларак өлгермәгәнур ман культура-лары | урман үсемлекләре белән капланган жирләрдән урман буларак өлгергән культуралар | урман жирләренә караганда барлык урман культуралары |
| Әлмәт | 35174 | 34031 | 7145 | 507 | 21 | 20 |
| Арча | 31707 | 29894 | 19369 | 1546 | 65 | 61 |
| Баулы | 22051 | 21503 | 4465 | 121 | 21 | 20 |
| Биләр | 49520 | 48393 | 4280 | 571 | 9 | 9 |
| Болгар | 17787 | 17517 | 3785 | 160 | 22 | 21 |
| Бөгелмә | 41358 | 40578 | 10527 | 489 | 26 | 25 |
| Буа | 18094 | 18001 | 5724 | 87 | 32 | 32 |
| Алабуга | 39534 | 38111 | 13481 | 699 | 35 | 34 |
| Зәй | 57389 | 56648 | 13986 | 364 | 25 | 24 |
| Зеленодольск | 25027 | 24767 | 9658 | 165 | 39 | 39 |
| Ары | 16740 | 16585 | 6145 | 141 | 37 | 37 |
| Кайбыч | 24790 | 24415 | 11296 | 259 | 46 | 46 |
| Кәләй | 39706 | 38936 | 6506 | 415 | 17 | 16 |
| Кама | 52081 | 50655 | 20298 | 745 | 40 | 39 |
| Кызыл Йолдыз | 42345 | 39542 | 13530 | 1535 | 34 | 32 |
| Лаеш | 32886 | 32238 | 10343 | 449 | 32 | 31 |
| Лениногорск | 49067 | 48459 | 7683 | 298 | 16 | 16 |
| Мамадыш | 46532 | 45519 | 16682 | 941 | 37 | 36 |
| Минзәлә | 71918 | 62345 | 16282 | 1052 | 26 | 23 |
| Түбән Кама | 41688 | 41014 | 11813 | 488 | 29 | 28 |
| Нурлат | 85297 | 84478 | 14788 | 441 | 18 | 17 |
| Идел буе | 27187 | 26988 | 5966 | 98 | 22 | 22 |
| Шәһәр яны | 10430 | 10287 | 4669 | 65 | 45 | 45 |
| Саба | 58287 | 56876 | 24415 | 1223 | 43 | 42 |
| Тәтеш | 36393 | 35628 | 9228 | 333 | 26 | 25 |
| Чирмешән | 35243 | 34547 | 6539 | 528 | 19 | 19 |

| Урманчылык исеме | Мәйдан, га | | | | Чагыштырма өлеш,% | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | урман җир-ләре | урман үсемлек-ләре белән капланган җирләр | урман культура-лары | урман буларак өлгермәгәнур ман культура-лары | урман үсемлекләре белән капланган җирләрдән урман буларак өлгергән культуралар | урман җирләренә караганда барлык урман культуралары |
| Урманчылыклар буенча барлыгы | 1163748 | 1127665 | 319993 | 15234 | | |
| Болардан тыш | | | | | | |
| «Түбән Кама» милли паркы | 1735 | 16933 | 6101 | 0 | 36 | 352 |
| Идел-Камадәүләт тыюлыгы | 9236 | 9157 | 886 | 0 | 10 | 10 |
| Суслонгер хәрби урманчылыгы | 1691 | 1441 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Республика буенча барлыгы | 1176410 | 1155196 | 326980 | 15234 | 22,5 | 25,7 |

Республикада сакланып калган урман культураларының мәйданы 326980 мең га, шул исәптән урманчылыкларда 319993 мең га тәшкил итә. Урман культураларының капланган җирләргә күчерелгән мәйданнарының шул ук чорда булдырылган культуралар мәйданына карата нисбәте 86% тәшкил итә.

### *Урманнарны торгызу һәм урманнарны үрчетү буенча планлаштырылган һәм фактта башкарылган күләмнәре*

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы территориясендә урман фондында урманнарны торгызу һәм урманнарны үрчетү эшләре моны регламентлаштыра торган документлар нигезендә башкарыла: Россия Федерациясе Урман кодексы, Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 2007 елның 16 июлендәге 183 номерлы боерыгы белән расланган Урманнар торгызу кагыйдәләре һәм гамәлдәге башка документлар.

Урманнарны үрчетү, җир кишәрлекләре туфракларының урман үсә алу үзенчәлекләренә, агач һәм куак токымнарының урманнарда үсә алуы буенча биологик үзенчәлекләренә туры китереп, туфракның су, җил һәм башка эрозиясен булдырмау, саклагыч урманнар булдыру максатыннан гамәлгә ашырыла.

Урманнарны үрчетү тискәре факторлардан җирләрне һәм объектларны саклауны, территориянең урманнарга байлыгын арттыруны һәм әйләнә-тирә мохит шартларын яхшыртуны тәэмин итә.

Урманнарны үрчетү түбәндәгеләр өчен башкарыла:

– урманчылык, экологик һәм икътисадый мөнәсәбәтләрдәге иң нәтиҗәле ысуллар белән мөмкин булган кадәр кыска вакыт эчендә урман ресурсларын торгызу;

– урманнарның биологик төрлелеген саклап калу;

– урман фонды җирләреннән рациональ файдалану;

– урманнарның продуктивлыгын һәм сыйфатын арттыру;

– территорияләрдә кирәк кадәр урманнар булдыруны тәэмин итү;

– урманнарның мохитне саклау һәм мохитне хасил итү функцияләрен үтәүләрен тәэмин итү өчен аларның су саклау, саклагыч, санитар-гигиеник һәм башка файдалы үзлекләрен яхшырту.

Республикада урманнарны торгызу киселгән, корыган, зарарланган урманнарны яңадан үз халәтләренә кайтару өчен урманнарны табигый, ясалма яки кушма торгызу юлы белән башкарыла.

1.2.4.3.4нче таблица

**Республика урман культураларының төрләр буенча составы (2012 елның 1 гыйнварына)**

| Урманчылык исеме | Барлык культуралар, га | шул исәптән төрләр буенча | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Нарат | Чыршы | Имән |
| Әгерже | 15274 | 10634 | 4354 | 98 |
| Азнакай | 16015 | 11613 | 856 | 2330 |
| Аксубай | 5839 | 3042 | 793 | 1793 |
| Әлки | 8348 | 4529 | 1321 | 1594 |
| Әлмәт | 10336 | 7392 | 1533 | 1111 |
| Арча | 20456 | 10734 | 7445 | 609 |
| Баулы | 5045 | 3968 | 656 | 219 |
| Биләр | 6048 | 1279 | 1211 | 2704 |
| Болгар | 3970 | 1999 | 1043 | 613 |
| Бөгелмә | 11854 | 8993 | 1354 | 269 |
| Буа | 5984 | 2419 | 288 | 1398 |
| Алабуга | 9018 | 9982 | 3729 | 593 |
| Зәй | 16698 | 3264 | 8201 | 4374 |
| Зеленодольск | 10334 | 7490 | 1921 | 169 |
| Ары | 6537 | 5538 | 827 | 41 |
| Кайбыч | 12277 | 1556 | 495 | 9511 |
| Кәләй | 7957 | 3295 | 2619 | 1797 |
| Кама | 22001 | 8734 | 5012 | 5341 |
| Кызыл Йолдыз | 15807 | 3729 | 6116 | 4461 |
| Лаеш | 11385 | 6560 | 1151 | 2537 |
| Лениногорск | 9093 | 5881 | 1848 | 1180 |
| Мамадыш | 19445 | 9856 | 4229 | 3559 |
| Минзәлә | 17608 | 6968 | 4842 | 756 |
| Түбән Кама | 14114 | 6244 | 3733 | 2757 |
| Нурлат | 16373 | 9379 | 3098 | 3272 |
| Идел буе | 6747 | 1891 | 1204 | 2845 |
| Шәһәр яны | 9226 | 7830 | 948 | 197 |
| Саба | 40718 | 10025 | 16343 | 3374 |
| Тәтеш | 9620 | 1176 | 517 | 7723 |
| Чирмешән | 8770 | 4564 | 2084 | 1887 |
| Урманчылыклар буенча барлыгы | 372897 | 180564 | 89771 | 69112 |
| моннан тыш:<br>«Түбән Кама» милли паркы | | | | |

| Урманчылык исеме | Барлык культуралар, га | шул исәптән төрләр буенча | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Нарат | Чыршы | Имән |
| Идел-Кама дәүләт тыюлыгы Суслонгер хәрби урманчылыгы | 6295<br>11 | 5909<br>11 | 310<br>- | -<br>- |
| Республика буенча барлыгы:мең га<br>% | 379,2<br>100 | 186,5<br>49,2 | 90,1<br>23,7 | 69,1<br>18,2 |

Культуралаштырыла торган токымнар буларак нарат, чыршы, имән, каен, карагай, тирәк, тал кулланыла. Өстенлек нарат культураларына бирелә, ясалма утыртмаларның гомуми мәйданында аларның өлеше 2013 елда 49% тәшкил итте, төп төр буларак чыршыга 23,7%, сабакчыклы имәнгә 18,2% туры килде. 1986 елдан башлап фанера җитештерү базасын тәэмин итү өчен каен культуралары мәйданы киңәйтелә. Урманнар аз булган районнарда, үсеп китү өчен тиешле шартлар булганда, ясалма утыртмалар үстерелә.

Республикада карагай өстенлек алган урман культуралары мәйданы 5,5 мең га тәшкил итә. Алар яхшы хәлдә, утыртмалары югары бонитетлы (1 һәм аннан югарырак), кайбер кишәрлекләрнең яше 100 елга якын. Карагайның урман культураларын булдыру урманнарның биологик төрлелеген саклап калу өчен зарур.

1.2.4.3.5нчы таблица

**Урманнарны торгызу күрсәткечләре динамикасы**

| Күрсәткечләр | | Урманнар торгызылган мәйдан, барлыгы | шул исәптән утыртылган урман культуралары | Табигый яңаруга ярдәм итү |
|---|---|---|---|---|
| 2003 ел | план | 4200 | 4200 | 0 |
| | факт | 4275 | 4275 | 0 |
| | % | 102 | 102 | 0 |
| 2004 ел | план | 4200 | 4200 | 0 |
| | факт | 4222 | 4222 | 0 |
| | % | 100,5 | 100,5 | 0 |
| 2005 ел | план | 2800 | 2800 | 0 |
| | факт | 2826 | 2826 | 0 |
| | % | 101 | 101 | 0 |
| 2006 ел | план | 3000 | 3000 | 0 |
| | факт | 3031 | 3031 | 0 |
| | % | 101 | 101 | 0 |
| 2007 ел | план | 3500 | 3000 | 500 |
| | факт | 3509 | 3008 | 501 |
| | % | 100 | 100 | 100 |
| 2008 ел | план | 4000 | 3500 | 500 |
| | факт | 4003 | 3503 | 500 |

| Күрсәткечләр | | Урманнар торгызылган мәйдан, барлыгы | шул исәптән утыртылган урман культуралары | Табигый яңаруга ярдәм итү |
|---|---|---|---|---|
| | % | 100 | 100 | 100 |
| 2009 ел | план | 2248 | 1900 | 348 |
| | факт | 2248 | 1900 | 348 |
| | % | 100 | 100 | 100 |
| 2010 ел | план | 1916 | 1567 | 330 |
| | факт | 1916 | 1567 | 330 |
| | % | 100 | 100 | 100 |
| 2011 ел | план | 2219 | 1869 | 330 |
| | факт | 2219 | 1869 | 330 |
| | % | 100 | 100 | 100 |
| 2012 ел | план | 2327 | 1972 | 334 |
| | факт | 2327 | 1972 | 334 |
| | % | 100 | 100 | 100 |

1.2.4.3.6нче таблица

**1951 елдан башлап 2012 елга кадәр тоташтан киселгән мәйданнарның һәм ясалма утыртмалар булдыру күләмнәренең динамикасы**

(мең га)

| Чорлар | тоташтан киселгән мәйдан | ясалма утыртмалар мәйданы | ясалма юл белән булдырылган утыртмалар мәйдананың тоташтан киселгән мәйданга нисбәте, % |
|---|---|---|---|
| 1951-1955 | 70,7 | 31,3 | 44,3 |
| 1956-1960 | 89,8 | 39,3 | 43,8 |
| 1961-1965 | 72,7 | 67,9 | 93,4 |
| 1966-1970 | 58,8 | 57,9 | 98,5 |
| 1971-1975 | 50 | 50,1 | 100,4 |
| 1976-1980 | 40,4 | 42,4 | 105 |
| 1981-1985 | 41,1 | 40,9 | 99,6 |
| 1986-1990 | 33,5 | 39,4 | 117,6 |
| 1991-1995 | 14,8 | 31,6 | 213 |
| 1996-2000 | 11,5 | 25 | 217,4 |
| 2001-2005 | 10,7 | 19,2 | 179,4 |
| 2006-2010 | 10,9 | 13 | 119,3 |
| 2011-2012 | 4,3 | 3,8 | 88,4 |

| Чорлар | тоташтан киселгән мәйдан | ясалма утыртмалар мәйданы | ясалма юл белән булдырылган утыртмалар мәйдананың тоташтан киселгән мәйданга нисбәте, % |
|---|---|---|---|
| барысы | 509,2 | 461,8 | 90,7 |

Урманнарны торгызу эшләре нигездә аланлыкларда һәм яңа киселгән урыннарда алып барыла. Урманнар торгызу эшләренең 2012 елда үсү темплары 2011 ел белән чагыштырганда 0,11 мең га мәйданга, яки 5% ка артты (Урманнарны торгызу эшләренең абсолют саннардагы мәйданы тиешенчә 2,2 мең га һәм 2,3 мең га тәшкил итте).

Шуны исәпкә алырга кирәк: тоташтан киселгән мәйданнарның бер өлеше ЛЭП урнаштыру өчен файдаланыла, аларда урманнар торгызу башкарылмый.

1.2.4.3.7 нче таблица

**1998 – 2012 елларда урман үсемлекләре белән капланмаган җирләрдә урманнар торгызу ысулларының нисбәте**

| Еллар | Тоташтан киселгән мәйдан, га | | | Булдырылган урман культуралары, га | | | Урманнарның табигый рәвештә торгызылуы, га. | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | барысы | шул исәптән | | барысы | шул исәптән | | барысы | шул исәптән | |
| | | өлгергән һәм картайган агачларны кисү | санитар кисүләр | | чәчү | утырту | | сакланган үсмер агачлар | үзеннән-үзе үсү, минераллашу |
| 1998 | 2557 | 2527 | 30 | 5343 | 0 | 5343 | 1968 | 119 | 1146 |
| 1999 | 2888 | 2854 | 34 | 4423 | 658 | 3765 | 1698 | 275 | 1064 |
| 2000 | 2724 | 2708 | 16 | 4455 | 1 | 4454 | 1668 | 35 | 1147 |
| 2001 | 2545 | 2536 | 9 | 4410 | 2 | 4408 | 0 | 0 | 786 |
| 2002 | 2260 | 2253 | 7 | 4239 | 223 | 4016 | 0 | 0 | 758 |
| 2003 | 2070 | 2070 | 0 | 4275 | 108 | 4167 | 0 | 0 | 1548 |
| 2004 | 1974 | 1974 | 0 | 4222 | 10 | 4212 | 0 | 0 | 625 |
| 2005 | 1964 | 1964 | 0 | 2826 | 358 | 2458 | 0 | 0 | 1424 |
| 2006 | 2004 | 2004 | 0 | 3031 | 50 | 2981 | 0 | 0 | 1104 |
| 2007 | 1910 | 1887 | 23 | 3008 | 20 | 2988 | 501 | 100 | 542 |
| 2008 | – | – | – | 3505 | 54 | 3451 | 500 | 100 | 500 |
| 2009 | 0 | 0 | 0 | 1900 | 0 | 1900 | 348 | 50 | 298 |
| 2010 | 0 | 0 | 0 | 1567 | 0 | 1567 | 330 | 50 | 280 |
| 2011 | 0 | 0 | 0 | 1869 | 0 | 1869 | 330 | 50 | 280 |
| 2012 | 0 | 0 | 0 | 1972 | 0 | 1972 | 334 | 50 | 286 |
| Барлыгыга<br>% | 22896<br>100 | 22777<br>99,5 | 119<br>0,5 | 51045<br>100 | 1484<br>2,9 | 49561<br>97,1 | 12615<br>100 | 829<br>7 | 11788<br>93 |
| елына уртачага<br>% | 2290<br>100 | 2278<br>99 | 12<br>0,5 | 3403<br>174 | 15<br>0,6 | 3304<br>169 | 841<br>100 | 55<br>7 | 786<br>93 |

| Еллар | Тоташтан киселгән мәйдан, га | | | Булдырылган урман культуралары, га | | | Урманнарның табигый рәвештә торгызылуы, га. | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | барысы | шул исәптән | | барысы | шул исәптән | | барысы | шул исәптән | |
| | | өлгергән һәм картайган агачларны кисү | санитар кисүләр | | чәчү | утырту | | сакланган үсмер агачлар | үзеннән-үзе үсү, минераллашу |
| | | | | | | | | | |

Урман культураларын булдыруның төп технологик алымы буларак утырту кулланыла (96,5%), кисүләр башкарганда үсмер ылыслы агачларны саклап калу алымына табигый торгызыла торган урманнарның гомуми мәйданыннан 9,9% туры килә.

1.2.4.3.8 нчы таблица

**Кисүләрнең һәм урманнарны торгызуның үзара нисбәте**

| Еллар | Тоташтан кисүләр мәйданы, га | Урманнар торгызу, барлыгы | шул исәптән урман утырту, га | шулардан: | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | нарат | чыршы | карагай | эрбет | имән | юкә | каен | тирәк | корычагач | тал |
| 1980 | 9407 | 8223 | 8223 | 5415 | 2255 | 3 | 0 | 395 | 0 | 37 | 65 | 0 | 104 |
| 1981 | 9384 | 8252 | 8252 | 4619 | 2635 | | | 770 | 26 | 58 | 38 | | 106 |
| 1982 | 9264 | 8254 | 8283 | 2018 | 1863 | 130 | | 4134 | | 19 | 23 | | 96 |
| 1983 | 8698 | 8225 | 8280 | 2825 | 3648 | 63 | | 1524 | | 70 | 54 | | 96 |
| 1984 | 9038 | 8210 | 8210 | 3686 | 3379 | 160 | 1 | 761 | | 36 | 65 | | 122 |
| 1985 | 9090 | 8033 | 8033 | 1570 | 2078 | 114 | | 3980 | | 139 | 46 | | 106 |
| барысы | 45474 | 40974 | 41058 | 14718 | 13603 | 467 | 1 | 11169 | 26 | 322 | 226 | 0 | 526 |
| % | | 90,1 | 100 | 36 | 33 | 1 | | 27 | | 1 | 1 | 0 | 1 |
| 1986 | 9170 | 8051 | 8051 | 1759 | 4665 | 22 | | 1082 | | 323 | 64 | 13 | 123 |
| 1987 | 8997 | 8323 | 8323 | 3733 | 3437 | 276 | | 314 | | 363 | 100 | 1 | 99 |
| 1988 | 7901 | 8332 | 8332 | 3718 | 3861 | 110 | | 233 | | 266 | 63 | | 81 |
| 1989 | 7801 | 8425 | 7402 | 1522 | 2693 | 82 | | 2779 | | 194 | 20 | | 112 |
| 1990 | 7663 | 8368 | 7330 | 2774 | 2924 | 109 | 7 | 1160 | 6 | 204 | 20 | | 126 |
| барысы | 41532 | 41499 | 39438 | 13506 | 17580 | 599 | 7 | 5568 | 6 | 1350 | 267 | 14 | 541 |

| Еллар | Тоташтан кисүләр мәйданы, га | Урманнар торгызу, барлыгы | шул исәптән урман утырту, га | шулардан: | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | нарат | чыршы | карагай | әрбет | имән | юкә | каен | тирәк | корыч-агач | тал |
| % | | 99,9 | 100 | 34 | 45 | 2 | | 14 | | 3 | 1 | 0 | 1 |
| 1991 | 7502 | 8327 | 6516 | 3423 | 2146 | 27 | 1 | 712 | 1 | 109 | 55 | | 42 |
| 1992 | 6631 | 8312 | 6505 | 3160 | 2163 | 47 | 3 | 705 | | 336 | 38 | | 53 |
| 1993 | 5455 | 8336 | 6309 | 3466 | 1910 | 56 | 10 | 368 | | 382 | 81 | | 36 |
| 1994 | 4285 | 8168 | 6263 | 3008 | 2363 | 91 | 2 | 234 | 6 | 376 | 160 | | 23 |
| 1995 | 4274 | 8568 | 6019 | 1687 | 3778 | 29 | | 50 | | 358 | 110 | | 7 |
| барысы | 28147 | 41711 | 31612 | 14744 | 12360 | 250 | 16 | 2069 | 7 | 1561 | 444 | | 161 |
| % | | 148,2 | 100 | 47 | 39 | 1 | | 7 | | 5 | 1 | | 1 |
| 1996 | 4119 | 7453 | 5391 | 1854 | 2252 | 129 | | 799 | | 260 | 82 | 13 | 2 |
| 1997 | 3513 | 7376 | 5363 | 1612 | 1806 | 99 | | 1583 | | 208 | 48 | 1 | 6 |
| 1998 | 2527 | 7311 | 5343 | 1738 | 2293 | 42 | | 980 | | 256 | 23 | 4 | 7 |
| 1999 | 2854 | 6121 | 4423 | 1131 | 1336 | 304 | 4 | 1399 | | 231 | 14 | 4 | |
| 2000 | 2708 | 6123 | 4455 | 1268 | 1782 | 68 | 12 | 1161 | | 136 | 28 | | |
| барысы | 15721 | 34384 | 24975 | 7603 | 9469 | 642 | 16 | 5922 | | 1091 | 195 | 22 | 15 |
| % | | 218,7 | 100 | 30 | 38 | 3 | 0 | 24 | | 4 | | | |
| 2001 | 2536 | 4410 | 4410 | 1342 | 1857 | 90 | 2 | 909 | 15 | 135 | 54 | 6 | |
| 2002 | 2260 | 4239 | 4239 | 1345 | 1835 | 50 | | 729 | | 232 | 44 | 4 | |
| 2003 | 2070 | 4275 | 4275 | 1064 | 2589 | 20 | 6 | 372 | | 189 | 35 | 0 | 0 |
| 2004 | 1974 | 4222 | 4222 | 1437 | 2035 | 50 | 15 | 400 | | 203 | 73 | 9 | 0 |
| 2005 | 1964 | 2826 | 2826 | 829 | 1174 | 64 | 5 | 550 | | 176 | 23 | 5 | 0 |
| барысы | 10804 | 19972 | 19972 | 6017 | 9490 | 274 | 28 | 2960 | 15 | 935 | 229 | 24 | 0 |
| % | | 184,9 | 184,9 | 55,7 | 87,8 | 2,5 | 0,3 | 27,4 | 0,1 | 8,7 | 2,1 | 0,2 | 0,0 |
| 2006 | 2004 | 3031 | 3031 | 1274 | 1065 | 125 | 0 | 273 | | 236 | 55 | 0 | 3 |
| 2007 | 1910 | 3509 | 3008 | 1007 | 1397 | 25 | 0 | 313 | | 234 | 31 | 1 | 0 |
| 2008 | 4007 | 4005 | 3505 | 1059 | 1703 | 63 | 0 | 441 | | 212 | 20 | 6 | 0 |
| барысы | 3914 | 10545 | 9544 | 3340 | 4165 | 213 | 0 | 1027 | 0 | 682 | 106 | 7 | 3 |
| % | | 170,1 | 153,9 | 53,9 | 67,2 | 3,4 | 0,0 | 16,6 | 0,0 | 11,0 | 1,7 | 0,1 | 0,0 |
| 2009 | 1693 | 2248 | 1900 | 317,7 | 1047 | 47 | 0 | 288,2 | 0 | 165,7 | 32 | 2 | 0 |

| Еллар | Тоташтан кисүләр мәйданы, га | Урманнар торгызу, барлыгы | шул исәптән урман утырту, га | шулардан: | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | нарат | чыршы | карагай | әрбет | имән | юкә | каен | тирәк | корыч-агач | тал |
| 2010 | 1281 | 1916 | 1567 | 555,3 | 626 | 16 | 0 | 232,1 | 0 | 103,6 | 31 | 3 | 0 |
| 2011 | 2002 | 2219 | 1869 | 657,8 | 445,9 | 33 | 0 | 500,8 | 0 | 164,5 | 67 | 0 | 0 |
| барысы | 4976 | 6383 | 5336 | 1530,8 | 2118,9 | 96 | 0 | 1021,1 | 0 | 433,8 | 130 | 5 | 0 |
| % | | 128,3 | 107,2 | 30,8 | 42,6 | 1,9 | 0 | 20,5 | 0 | 8,7 | 2,6 | 0,1 | 0 |
| 2012 | 2273 | 2327 | 1972 | 432,7 | 532,5 | 14,3 | 0 | 824,5 | 0 | 80 | 88 | 0 | 0 |
| барысы | 2273 | 2327 | 1972 | 432,7 | 532,5 | 14,3 | 0 | 824,5 | 0 | 80 | 88 | 0 | 0 |
| % | | 102,4 | 86,8 | 19,0 | 23,4 | 0,6 | 0 | 36,3 | 0 | 3,5 | 3,9 | 0 | 0 |

1.2.4.3.9нчы таблица

## Урманны тәртипкә салу мәгълүматлары буенча, урман культураларының торышы

санаучы – урман үсемлекләре белән капланган җирләргә күчерелгәннәр
ваклаучы – урман буларак өлгермәгәннәр (мәйдан, мең га)

| Төп төр | Культураларның торышы | | | | | Корыган урман культуралары (1992-2005 еллар) (га) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Культураларның гомуми мәйданы | Яхшы | Канәгать-ләндерерлек | Канәгать-ләндерерлек түгел | Барысы | |
| Нарат | 162,2<br>8,4 | 81,7<br>1,6 | 71,9<br>6,4 | 5,6<br>0,4 | 159,2<br>8,4 | 2933,5<br>24,6 |
| Чыршы | 62,2<br>8,9 | 24,2<br>2,0 | 32,3<br>6,6 | 4,9<br>0,2 | 61,4<br>8,8 | 792,6<br>3,3 |
| Карагай | 4,9<br>0,6 | 2,6<br>0,1 | 2,2<br>0,4 | 0,1<br>0,1 | 4,9<br>0,6 | 21<br>0 |
| Каен | 17,0<br>0,7 | 6,8<br>0,4 | 9,6<br>0,3 | 0,5<br>- | 16,9<br>0,7 | 113.6<br>2.0 |
| Имән | 57,0<br>3,9 | 13,9<br>1,0 | 35,2<br>2,8 | 5,8<br>0,1 | 54,9<br>3,9 | 2135<br>3,4 |
| Тирәк | 2,2<br>0,1 | 0,7<br>- | 1,4<br>0,1 | 0,1<br>- | 2,2<br>0,1 | 19<br>6 |
| Барлыгы<br>% | 305,5<br>22,5<br>100<br>100 | 129,9<br>5,3<br>42,5<br>23 | 152,6<br>16,7<br>50<br>74 | 17,0<br>0,7<br>5,5<br>2.8 | 299,5<br>22,5<br>98<br>99,8 | 6014,7<br>39,3<br>2<br>0.2 |
| Моннан тыш урман чыбылдыгы астында | | | | | | |
| Нарат | 1,6<br>0,4 | 0,1<br>- | 1,0<br>0,3 | 0,5<br>0,1 | 1,6<br>04 | 0<br>0 |

| Төп төр | Культураларның торышы | | | | | Корыган урман культуралары (1992-2005 еллар) (га) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Культураларның гомуми мәйданы | Яхшы | Канәгатьләндерерлек | Канәгатьләндерерлек түгел | Барысы | |
| Чыршы | 8,5<br>3,5 | 0,7<br>0,2 | 4,4<br>3,1 | 3,6<br>1,1 | 8,7<br>3,4 | 111<br>0 |
| Урман чыбылдыгы астында барысы<br>% | 14,8<br>4,8<br>100<br>100 | 0,9<br>0,3<br>6<br>7 | 7,0<br>3,8<br>48<br>79 | 6,7<br>0,7<br>46<br>14 | 14,6<br>4,8<br>99<br>100 | 111<br>0<br>0,8<br>0 |
| Барысы<br>% | 320,3<br>27,4<br>100<br>100 | 130,8<br>5,6<br>41<br>21 | 159,6<br>20,5<br>50<br>75 | 23,7<br>1,4<br>7<br>5 | 314,1<br>27,3<br>98<br>99,8 | 6125,7<br>39,3<br>2<br>0,2 |

2013 елның 1 гыйнварынаурман культураларының гомуми мәйданыннан 41% – яхшы хәлдә, 52% – канәгатьләндерерлек, 7% – канәгатьләндерерлектүгел.

1.2.4.3.10нче таблица

## Урман культураларының үлү сәбәпләре

| Урманчылык исеме | Ревизия чорында корыганнар, барлыгы, га | Шул исәптән үлүнең төп сәбәпләре буенча | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | агротехника һәм технология бозылу | үз вакытында карамау һәм сыйфатсыз карау яки аның бөтенләй булмавы | йомшак яфраклы төрләр белән каплану | начар табигать шартлары | янгыннар | пошилар таптау | терлек таптау | үсү урыннары шартларының туры килмәве | урман корткычлары һәм авырулары | башкалар(ЛЭП, юллар һәм башкаларны төзү) |
| Әгерже | 84,4 | 0,3 | 0 | 22,4 | 50,2 | 0 | 0 | 3,4 | 0 | 0 | 0 |
| Азнакай | 15 | 0 | 5 | 0 | 10 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Аксубай | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Әлки | 288 | 10 | 0 | 199 | 30 | 0 | 45 | 3 | 0 | 0 | 0 |
| Әлмәт | 271 | 0 | 9 | 116 | 134 | 0 | 0 | 5 | 0 | 0 | 0 |
| Арча | 10 | 0 | 0 | 0 | 10 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Баулы | 127,6 | 0 | 0 | 17,6 | 91,2 | 7,8 | 0 | 11 | 0 | 0 | 0 |
| Биләр | 214 | 0 | 3 | 105 | 51 | 0 | 38 | 8 | 0 | 0 | 0 |
| Болгар | 26 | 0 | 0 | 0,7 | 0 | 11,4 | 0 | 4,1 | 0 | 9,8 | 0 |
| Бөгелмә | 25 | 0 | 4 | 4 | 2 | 0 | 0 | 2 | 0 | 0 | 0 |
| Буа | 81 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 43 | 0 | 0 | 38 |
| Алабуга | 542 | 0 | 11 | 188 | 271 | 0 | 0 | 52 | 0 | 0 | 0 |
| Зәй | 908,1 | 0 | 9,1 | 310 | 568 | 0 | 2 | 4 | 0 | 0 | 0 |
| Зеленодольск | 51 | 8 | 5 | 26 | 9 | 2 | 0 | 0 | 0 | 0 | 1 |

| Урманчылык исеме | Ревизия чорында корыганнар, барлыгы, га | Шул исәптән үлүнең төп сәбәпләре буенча | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | агротехника һәм технология бозылу | үз вакытында карамау һәм сыйфатсыз карау яки аның бөтенләй булмавы | йомшак яфраклы төрләр белән каплану | начар табигать шартлары | янгыннар | пошилар таптау | терлек таптау | үсү урыннары шартларының туры килмәве | урман корткычлары һәм авырулары | башкалар(ЛЭП, юллар һәм башкаларны төзү) |
| Ары | 140,6 | 5,9 | 5,6 | 115,8 | 11,3 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Кайбыч | 40 | 0 | 4 | 30 | 0 | 0 | 0 | 6 | 0 | 0 | 0 |
| Кәләй | 114,5 | 0 | 1,9 | 27,2 | 2,5 | 0 | 82,2 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Кама | 388 | 13 | 0 | 207 | 126 | 0 | 0 | 23 | 0 | 15 | 2 |
| Кызыл Йолдыз | 162 | 0 | 0 | 40 | 95 | 0 | 0 | 18 | 0 | 0 | 0 |
| Лаеш | 200,1 | 1 | 1,1 | 39,7 | 20,8 | 53,4 | 0 | 51,3 | 3,5 | 34,7 | 0 |
| Лениногорск | 274 | 0 | 30 | 106 | 22 | 0 | 82 | 26 | 0 | 5 | 0 |
| Мамадыш | 564,1 | 0 | 12,2 | 460 | 73,7 | 0 | 0 | 18 | 0 | 0 | 0 |
| Минзәлә | 241,8 | 17 | 17,9 | 102 | 15,1 | 0 | 0 | 89,8 | 0 | 0 | 0 |
| Түбән Кама | 402,7 | 0 | 0 | 217,4 | 48,1 | 3,3 | 128,7 | 2,8 | 0 | 0 | 2,4 |
| Нурлат | 272 | 18 | 98 | 0 | 24 | 1 | 0 | 50 | 70 | 0 | 11 |
| Идел буе | 593 | 89,3 | 0 | 317 | 60 | 0 | 0 | 82,4 | 5 | 0 | 7,5 |
| Шәһәр яны | 45,8 | 1 | 0 | 10,3 | 8,7 | 0,9 | 3,4 | 10,5 | 0 | 9,2 | 0 |
| Саба | 181 | 2 | 3 | 39 | 94 | 0 | 0 | 22 | 0 | 10 | 0 |
| Тәтеш | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Чирмешән | 399,3 | 0 | 0 | 14,8 | 274,4 | 0 | 48,9 | 4,4 | 0 | 0 | 0 |

| Урманчылык исеме | Ревизия чорында корыганнар, барлыгы, га | Шул исәптән үлүнең төп сәбәпләре буенча | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | агротехни-ка һәм технология бозылу | үз вакытында карамау һәм сыйфатсыз карау яки аның бөтенләй булмавы | йомшак яфраклы төрләр белән каплану | начар табигать шартлары | янгыннар | пошилар таптау | терлек таптау | үсү урыннары шартларының туры килмәве | урман корткычлары һәм авырулары | башкалар(ЛЭП, юллар һәм башкаларны төзү) |
| Барлыгы | 6335,8 | 165,5 | 219,8 | 2714,9 | 2102 | 79,8 | 430,2 | 539,7 | 78,5 | 83,7 | 61,9 |
| % | 100 | 2,4 | 3,3 | 40,8 | 32,9 | 1,2 | 6,4 | 8,5 | 1,2 | 1,3 | 1,0 |

Урманнарны соңгы тәртипкә китерү мәгълүматлары буенча, урман культуралары коруның һәм аларның торышы канәгатьләндерерлек булмауның төп сәбәпләреннән берсе йомшак яфраклы агач төрләренең тыгыз булып үсеп китүеннән гыйбарәт, бу утырткан агачларның һәм чәчкән орлыкларның йомшак яфраклы агач төрләре белән капланып китүенә китерә (40,8%). Тискәре табигать шартлары шулай ук урман культуралары коруның җитди сәбәпләренең берсе булып тора (32,9%), чөнки Татарстан игенчелектә көтелмәгән хәлләр туарга мөмкин зонага керә. Урман культураларының зур гына мәйданы (15%) пошилар һәм йорт хайваннары тарафыннан тапталды.

Урман культуралары белән эш итүдә иң соңгы этапны урман культураларын урманнар белән капланган җирләргә күчерү һәм утыртмаларны кыйммәтле агач төрләренең үсмерләре категориясенә кертү тәшкил итә, алар иң продуктив агачлыкларны хасил итү өчен нигез булып торалар.

Хуҗалык өчен кыйммәтле яшь агачларга ылыслы, каты яфраклы, шулай ук урман фондын яхшырта торган башка агач төрләре керә, алар төбәктәге урман үсү шартларына һәм халык хуҗалыгының икътисадый таләпләренә нык туры килә.

2012 елда хуҗалык өчен кыйммәтле агач утыртмалары категориясенә 1,7 мең га мәйдандагы яшь агачлар кертелде. Саклагыч урманнарны үрчетү буенча эшләр 2012 елда 1589 га мәйданда башкарылды, шулардан 322,5 га мәйдандагы текә ярларга урманнар утыртылды. Урман культураларын урман үсемлекләре белән капланган җирләргә күчерү сроклары Россия Федерациясенең Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы районында чыршы һәм нарат культуралары өчен 7 ел дип билгеләнгән

**Урман орлыкчылыгы**

Урман орлыкчылыгын тамырдан яхшыртуның төп бурычы урманнарны торгызу эшләрен районлаштырылган орлыклар белән тулысынча тәэмин итүдән, кыйммәтле генетик фондны саклап калудан һәм үрчетүдән, ә перспективада – урман орлыкчылыгы объектларында урман орлыкларын селекция нигезендә әзерләүгә күчүдән гыйбарәт.

Республикада урман орлыкчылыгы объектларын булдыру эше 1966 елда Кайбыч махсус орлыкчылык урман хуҗалыгын (имән буенча) оештырудан башланып китте. Махсус орлыкчылык урман хуҗалыгын оештыру проектын 1984 елда «Союзгипролесхоз» институты төзеде.

1983 елдан башлап Кайбыч махсус орлыкчылык урман хуҗалыгында ялганган утырту материалы белән 23 га урман имән орлыклары плантацияләре булдырылды, шулай ук 2147 га даими урман орлык кишәрлекләренә нигез салынды. Ләкин кыйммәтле генофондны табу һәм сайлап алу, урман орлык плантацияләренә нигез салу һәм даими урман орлык кишәрлекләрен булдыру буенча эшләр тиешле дәрәҗәдә фәнни яктан тәэмин ителмичә алып барылды, бу үзенең асылы буенча тәҗрибә ясау булып торган эшләрнең сыйфаты төшүгә китерде. Шуның нәтиҗәсе буларак Кайбыч махсус орлыкчылык урман хуҗалыгының барлык урман орлыклары объектлары, урман орлык плантацияләрендә ялгаулар начар нәтиҗә биргәнгә күрә һәм даими урман орлык

кишәрлекләренең 1978 – 1979 еллардагы ачы салкын кыштан зыян күрүләре аркасында гамәлдәге таләпләргә туры килмәүләре сәбәпле, 1990 елның 1 гыйнварына урман орлыкчылыгы объектларын инвентарьләштерү йомгаклары буенча объект буларак исемлектән төшерелделәр.

Кайбыч махсус орлыкчылык урман хуҗалыгының урман орлыкчылыгы объектларын булдыруның чираттагы баскычы итеп 1988 елны санарга мөмкин, ул вакытта республикада авыруларга иң яхшы каршы торучан һәм яхшы үрчи торган имән һәм башка төр утыртмаларның массивлары һәм кишәрлекләре Татарстан ЛОС ВНИИЛМ (К.В. Краснобаева) тарафыннан эшләнгән методика буенча генетик резерватларга бүлеп бирелде. Республикада имәнлекләрнең хәзерге вакыттагы торышы, аларда хәзергә кадәр 1978 – 1979 еллардагы суыклардан соңгы интенсив кибә бару һәм таркалу процессы дәвам иткәнгә күрә, кишәрлекләрне Россия Федерациясендә гамәлдә булган таләпләргә җавап бирерлек генетик резерватлар өчен бүлеп бирү мөмкин түгел диярлек.

Имәнлекләрнең бүгенге көндәге торышын исәпкә алып, генетик резерват сыйфатында югары бонитетлы имән һәм катнаш утыртмаларның 743 га мәйдан тәшкил иткән иң кыйммәтле, яхшы сакланып калган аерымланган кишәрлеге бүлеп бирелде, анда күптән түгел республиканың иң яхшы имәнлекләре урнашкан иде һәм хәзерге вакытта имән генофонды иң тулы сакланган.

Республикада урман генетик резерватларын плюслы агачларны һәм утыртмаларны сайлап алу өчен кулланалар. Минуслы агачлар соңыннан юк ителү өчен билгеләп куела.

1989 елдан башлап резерват терриориясендә корып баручы һәм корыган агачларны алу эшләре алып барылды, барлыгы 20 мең $м^3$ коры-сары киселде. Кисү эшләрен башкарганда генетик резерватларда хуҗалык алып бару кагыйдәләрен җитди бозулар булмады.

Шулай ук имәнлекләрнең корый баруы билгеләнде. Соңгы 4 – 5 ел эчендә кайбер бүлендекләрдә агачларның якынча 40% ы корыды, һәм бу, утыртмаларның торышына карап, агачлар санынннан елына 5-10% тәшкил итә.

Тикшерүләр вакытында имән утыртмаларында, аеруча плюслы агачларда, имәннәрнең куртинлап-төркемләп табигый яңаруы 1 га мәйданга 1 мең данәдән кимрәк (1988 ел уңышыннан чыгып), куртин мәйданы 0,1 га кадәр, куртиннарның саны, утыртмаларның торышына һәм аларның структурасын карап, 1 га мәйданга 3 – 5 данә булуы ачыкланды. Сан ягыннан күп булмасалар да, алар генрезерватларның төп имәннәрен торгызу өчен зур әһәмияткә ия.

1997 елда беренче этап тәгәлләнгәннән соң, утыртмалар имән һәм юкәнең генетик резерваты буларак рәсмиләштерелделәр.

1971 елдан алып 1991 елга кадәр Зеленодольск, Алабуга, Арча урман хуҗалыкларында 25 га дан артык мәйданда нарат һәм чыршының урман орлык плантацияләре һәм ана агач коллекцион плантацияләре булдырылды.

Соңгы елларда республикада төп игътибар ТатЛОС ВНИИЛМ әйдәүче фәнни хезмәткәре, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты К.В. Краснобаева тарафыннан тәкъдим ителгән методика нигезендә имәннең даими урман орлык кишәрлекләрен булдыруга бирелде.

Әлеге методиканың асылы шунда ки, гамәлдәге даими урман орлык кишәрлегендә эксплуатация төгәлләнгәнче 5 – 7 ел кала эре утырту материаллары белән киләсе даими урман орлык кишәрлегенә нигез салына, әлеге материаллар плюслы агачлардан җыелган орлыклардан яисә шул ук урман орлык кишәрлегендәге агачларның орлыкларыннан үстерелгән була. Шуннан соң үз эшен башкарган агачлар киләсе уңыш елында орлыкларны мөмкин булган күп әзерләүне исәптә тотып киселә.

К.В. Краснобаева урманнарны селекцион яхшырту юнәлешләренең берсе буларак биеклеге һәм үсеше буенча башкалардан аерылып тора торган яшь утыртмаларда хуҗалык билгеләре буенча агачлыкның уртача күрсәткечләреннән яхшырак булган иң әйбәт орлыклык агачларны сайлап алуны үткәрү тәкъдим ителгән иде. Орлык бирә торган агачлар агачлык үсүнең бөтен чоры дәвамында сакланып кала, аларны даими карап торалар.

Орлык агачларын сайлап алуның төп билгеләнеше түбәндәгеләрдә:

– әлеге утыртмадагы төп төрнең яхшыртылган буыны белән табигый яңаруын тәэмин итү;

– урманнарны ясалма торгызу өчен аларны орлыклар алу чыганагы буларак куллану.

Әлеге чараны урманнарны хасил итүче төп төрләрнең хуҗалык алып бару урманнарның табигый торгызылуы өчен башкарыла торган барлык табигый утыртмаларында үткәрү тәкъдим ителгән иде. Мондый ысулны кулланганда, сирәкләп һәм тоташтан кисүләр орлык бирерлек агачларның барлыкка килүен һәм аларның табигый яңаруын саклап калуны һәм урманның яңа, сыйфатлырак буынын булдыруны тәэмин итәргә тиеш.

1988 – 2002 елларда мондый ысул Бөгелмә, Зеленодольск, Кама, Кайбыч, Кызыл Йолдыз, Саба, шәһәр яны урман хуҗалыкларында 3 мең га артык мәйданда кулланылды.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында урман селекция орлыкчылыгын алга таба үстерү өчен тиешле база бар (1.2.4.3.11нче таблица).

1.2.4.3.11нче таблица

**Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы буенча даими урман орлык базасы объектлары (2013 елның 1 гыйнварына)**

| Төр | Плюслы агачлар данә. | Плюслыутыртма-лар, га | Урман орлык плантацияләре (га.) | | | Даими урман орлык кишәрлекләре, га | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлы-гы | шулардан: Аттеста-ция узган | шулардан: Уңыш бирәләр | бар-лыгы | шулардан: Аттеста-ция узган | шулардан: Уңыш бирәләр |
| Нарат | 304 | 112,7 | 33,4 | 33,4 | 33,4 | 47,8 | 47,8 | 47,8 |
| Чыршы | 95 | 83,1 | | | | 25,9 | 25,9 | 25,9 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Карагай | 23 | | | | | 10 | 10 | 10 |
| Имән | 86 | 126,9 | 17,5 | 17,5 | 17,5 | 1070,5 | 1070,5 | 1070,5 |
| Юкә | | 68 | | | | 97 | 97 | 97 |
| Барлыгы | 508 | 390,7 | 50,9 | 50,9 | 50,9 | 1251,2 | 1251,2 | 1251,2 |

Республикада «Рослесозащита» ФБУ филиалы – Татарстан Республикасы Урманны яклау үзәге эшли, ул Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләренең (алга таба – ТР ДБУ) орлык фондын тикшереп торуны тәэмин итә, республиканың урман орлыклары резерв фондын саклауны тикшереп тора.

Югары сыйфатлы ылыс орлыкларын алу өчен киптерү хуҗалыгы югары дәрәҗәдә оештырылган булырга тиеш. «Арчаурман» ТР ДБУ моның ачык мисалы булып тора, ул соңгы 5 ел дәвамында, яңа киптерү бинасын төзеп һәм бөтен технологик процессны тиешле дәрәҗәдә оештырып, ел саен 750-900 кг күләмдә бары тик 1-2 класслы орлыклар җитештерә.

Моңа бәйле рәвештә күркәләрне киптерү биналарын төзү һәм реконструкцияләү буенча билгеле бер эшләр башкарылды. 4 ел эчендә «Саба уку-тәҗрибә урман хуҗалыгы», «Зеленодольск тәҗрибә авыл хуҗалыгы», «Минзәләурман», «Буаурман» ТР ДБУдә яна күркә киптерү биналары төзелде, «Арыурман» һәм «Мамадышурман» ТР ДБУдә реконструкция эшләре алып барылды.

Республика соңгы 10 дәвамында читтән урман орлыклары кертми, орлыкларга ихтыяҗны үзебездә әзерләнгәннәр белән тәэмин итә. Ылыслы агачлар орлыкларының резерв фонды булдырылды, ул республиканың еллык ихтыяжын канәгатьләндерә ала; тик соңгы 7 елда нарат, чыршы, карагай орлыклары уңышы булмау сәбәпле 3 еллык орлыклар резервы 1 еллыкка калды.

Гади нарат һәм гади чыршы орлыкларының һәм үсентеләренең үсү, тишелеп чыгу энергиясен, авыруларга каршы торучанлыгын арттыру өчен 2000 елдан башлап орлыклар А.Н. Туполев исемендәге Казан дәүләт техника университетының Гамәли электродинамика фәнни-тикшерену үзәге тарафыннан уйлап табылган «Шытым» микродулкын җайланмасында электромагнит кыры белән эшкәртелә.

**Селекция-генетикага нигезләнеп урман орлыкчылыгын үстерү перспективалары**

Россия Федерациясе Урман кодексы нигезендә (65 статья), урманнарны яңадан үстергәндә урман үсемлекләренең яхшыртылган һәм сортлы орлыклары яисә, андый орлыклар булмаса, урман үсемлекләренең яхшы орлыклары кулланылырга тиеш. Шуңа күрә перспективадагы чорда орлыклар хәзерләүнең гомуми күләмендә яхшыртылган селекцион категориядәге орлыкларның өлеше арттырылырга һәм урман орлыкчылыгын эзлекле рәвештә сортлы нигезгә күчерү өчен база булдырылырга тиеш.

Республика буенча орлыкларга ихтыяҗ 18 т тәшкил итә, шул исәптән: вак ылыслылар – 0,54 т, яфраклы төрләр – 17,1 т, шулардан имән – 16,7 т, башкалар – 0,4 т.

Орлыклар хәзерләүнең гомуми күләме хәзерге вакытта урман культураларын җитештерү ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерә. Шул ук вакытта даими урман орлык базасы объектларыннан, шул исәптән яхшыртылган нәсел үзлекләренә ия объектларыннан, бары тик 2 т орлык хәзерләп куела, шулардан вак ылыслылар – 0,14 т тәшкил итә, бу хәзерләп куелган орлыкларның гомуми күләменнән 2 – 4% дигән сүз.

2007 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кергән еллык исәп урман кисүе 1785,5 мең $м^3$ тәшкил итә, шул исәптән ылыс хуҗалыгы буенча 65,4 мең $м^3$, каты яфрак хуҗалыгы буенча – 124,9 мең $м^3$ һәм йомшак яфрак хуҗалыгы буенча – 1595,5 мең $м^3$. Исәп урман кисүен тулысынча үзләштергән очракта тоташтан кисүләр 10 мең га якын мәйдан тәшкил итәчәк. Киселә торган җирләрнең 20% ын кисүләр вакытында хуҗалык өчен кыйммәтле төрләрнең үсмер агачларын табигый яңару өчен, шулай ук I һәм аннан югарырак бонитетлы усаклыкларны табигый җәелеп үсү өчен калдыруны исәпкә алсак, урман торгызуның еллык фонды аерым-аерым нарат, чыршы, карагай һәм имән өчен 2 мең га тәшкил итәчәк.

Хәзерге вакытта республикада плюслы утыртмаларны һәм агачларны (карагайның плюслы агачларыннан тыш) аерып алу төгәлләнгән диярлек. Аларны яхшыртылган орлыклар хәзерләү максатыннан даими урман орлык базасын булдыру өчен башлангыч база буларак кулланылуын тәэмин итәргә, беренче рәт урман орлык плантацияләрен урман культураларын җитештерүнең яхшыртылган нәсел үзлекләренә ия орлыкларга ихтыяҗын тәэмин итәрлек күләмнәрдә утыртуны төгәлләргә кирәк.

1.2.4.3.12 нче таблица

**Урман үсемлекләре төрләре буенча орлыкларга ихтыяҗ, кг**

| Төр | еллар | | | | | | | | | | гомуми күләм |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | |
| Нарат | 700 | 700 | 700 | 700 | 700 | 555 | 555 | 555 | 555 | 555 | 6275 |
| Чыршы | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 550 | 550 | 550 | 550 | 550 | 5250 |
| Карагай | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 185 | 185 | 185 | 185 | 185 | 1925 |
| Имән | 15000 | 15000 | 15000 | 15000 | 15000 | 13690 | 13690 | 13690 | 13690 | 13690 | 143450 |
| Юкә | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 185 | 185 | 185 | 185 | 185 | 1925 |
| Корычагач | 250 | 250 | 250 | 250 | 250 | 222 | 222 | 222 | 222 | 222 | 2360 |
| Каен | 2500 | 2500 | 2500 | 2500 | 2500 | 2220 | 2220 | 2220 | 2220 | 2220 | 23600 |
| Сары сәрви агачы | 400 | 400 | 400 | 400 | 400 | 370 | 370 | 370 | 370 | 370 | 3850 |

| Төр | еллар | | | | | | | | | | гомуми күләм |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | |
| Миләш | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 185 | 185 | 185 | 185 | 185 | 1925 |
| Алмагач | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 45 | 45 | 45 | 45 | 45 | 475 |
| Слива | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 93 | 93 | 93 | 93 | 93 | 965 |
| Чия | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 93 | 93 | 93 | 93 | 93 | 965 |
| Вак гөлҗимеш | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 107 | 107 | 107 | 107 | 107 | 1535 |
| Барысы | 20400 | 20400 | 20400 | 20400 | 20400 | 18500 | 18500 | 18500 | 18500 | 18500 | 194500 |

Республика урман хуҗалыгы җитештерүенең яхшыртылган нәсел үзлекләренә ия орлыкларга ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен урман орлыкчылыгының гамәлдәге объектларын исәпкә алсак, урман орлык плантацияләрен өстәмә утыртырга кирәк, якынча исәпләүләр буенча гади наратны – 4 га, гади чыршыны – 3 га, карагайны – 11 га, сабаклы имәнне – 10 га мәйданда.

Нарат, чыршы һәм карагай урман орлык плантацияләрен утыртканда вегетатив ысулга өстенлек бирергә кирәк. Имән урман орлык плантациясен булдырганда төп алымның төп ысулы буларак плюслы агачларның орлыктан үрчүен кулланырга кирәк.

Урман хасил итүче төп агач төрләренең яна даими урман орлык кишәрлекләрен булдырганда урман культураларын һәм табигый үсеп чыккан яшь агачларны сирәкләү юлыннан баш тартсаң яхшы, чөнки мондый урман орлык кишәрлекләреннән алынган орлыклар яхшы орлыклар категориясенә керә. Даими урман орлык кишәрлекләреннән яхшыртылган орлыклар алу өчен мондый кишәрлекләрне плюслы утыртмаларда, плюслы агачлардан яисә беренче рәт клон урман орлык плантацияләрендә әзерләнгән орлыклардан үстерелгән чәчкеннәрне утырту юлы белән булдырырга кирәк.

Сайлап алынган плюслы агачларның генофондын саклау калу максатында клоннар архивларына нигез салу таләп ителә, аларны шулай ук югары генетик кыйммәткә ия һәм икенче рәт урман орлык плантацияләрен булдыру өчен плюслы агачлар арасыннан иң перспективалыларын сайлап алу максатында плюслы агачларны комплекслы бәяләү өчен кулланырга була. Хәзерге вакытка сайлап алынган плюслы агачларның клоннары архивлары мәйданы, алдан исәпләүләр буенча, түбәндәге зурлыкларда булырга тиеш: гади нарат – 8 га, чыршы – 6 га, сабаклы имән – 4 га.

Югары генетик кыйммәткә ия һәм икенче рәт урман орлык плантацияләрен утыртуга күчү өчен, тәҗрибә культураларын барлыкка китерү эшләрен плюслы агачларның орлык бирерлек буыннары белән булдыру белән интенсивлаштырырга кирәк. Методик таләпләрдә каралганча, плюслы агачларның киләсе буыннарының сынала торган культуралары мәйданы сабаклы имән буенча якынча 7 га тәшкил итәчәк. Буыннар буенча генетик бәяләүгә шулай ук плюслы утыртмаларны һәм беренче рәт урман орлык плантацияләрен кертергә кирәк, бу киләчәктә урман орлыкчылыгын сортлы нигезгә күчерүне тәэмин итәчәк.

Урман орлыкчылыгы объектларын (урман орлык плантацияләре, плюслы агачларның орлык бирә торган буыннарының тәҗрибә культуралары, даими урман орлык кишәрлекләре), күркә киптерү һәм орлык саклау биналарын да кертеп, проектлау һәм төзү эшләре үсү өчен иң уңай шартлар булган урманчылыкларда урманнарны хасил итүче төп төрләрнең бергә туплануын күз алдында тота: чыршы һәм карагай буенча – Саба урманчылыгында, имән буенча – Кайбыч урманчылыгында, нарат буенча – Зеленодольск урманчылыгында һәм Шәһәр яны урманчылыгында.

2025 елга кадәр чорга Татарстан Республикасында бердәм урман орлыкчылыгы объектларын булдыру һәм куллану концепциясендә куелган бурычларны гамәлгә ашыру өчен алга таба 2025 елга кадәр чорга Татарстан Республикасында бердәм урман орлыкчылыгы объектларын проектлау, булдыру һәм куллану программасын эшләргә кирәк, аны башкару өчен таләп ителә торган финанс, матди һәм техник ресурслар нигезләнгән булырга тиеш.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының Урман селекция-орлыкчылык үзәге эшли, ул тамыр системасы ябык булган утырту материалларын һәм сыйфатлары яхшыртылган урман орлыкларын җитештерү буенча заманча технологияләрне үз эченә алган инновацион комплекс булып тора. Европада иң эре автоматлаштырылган урман селекция-орлыкчылык үзәген тәшкил итүче әлеге комплекс BCC AB компаниясенең (Швеция) заманча җиһазлары белән җиһазландырылган. Урман селекция-орлыкчылык үзәген җитештерү куәте 2,0 тонна ылыслы агач төрләре орлыкларыннан, тамыр системасы ябык булган 12 млн. утырту материалыннан гыйбарәт.

Россия Федерациясе Хөкүмәте каршындагы Урман комплексын үстерү советы утырышының Беркетмәсе нигезендә, аңа Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисенең Беренче урынбасары рәислек итә, Федераль урман хуҗалыгы агентлыгына (Россия урман хуҗалыгы) Татарстан Республикасында имән чикләвекләрен җитештерү һәм саклау буенча орлыкчылык комплексын төзү турындагы мәсьәләне өйрәнергә йөкләмә бирелде. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы Коллегиясе карары белән шулай ук мондый үзәкнең төзелүе максатка ярашлы була дип билгеләнде.

Үткәрелгән оператив киңәшмәләре нәтиҗәләре буенча, имәнлекләрне үстерү, имән чикләвекләрен саклау буенча дөньякүләм тәҗрибәне өйрәнеп әлеге мәсьәләгә карата гомуми караш урнашты. Шулай итеп, Татарстан Республикасында «Россия имәнлекләре» фәнни-җитештерү үзәген төзү максатка ярашлы була дигән карар кабул ителде.

«Россия имәнлекләре» фәнни-җитештерү үзәге имән чикләвекләрен саклау урынын, питомникны, фәнни лабораторияне, «in vitro» лабораториясен, ДНК-маркерларны, уку классларын, урман орлыкчылыгы объектларын үз эченә алырга тиеш. «Россия имәнлекләре» фәнни-җитештерү үзәге Россия Федерациясендә имәнлекләрнең мәйданнарын арттыру, имәннәрне урманда үрчетү технологияләрен үстерү, микроклональ үрчетү, агачларның кыйммәтле төрләрен маркировкалау өчен оештырыла. «Россия имәнлекләре» фәнни-җитештерү үзәге имән орлыкларының федераль фондын һәм Россия Федерациясе субъектларының иминият фондларын саклау мөмкинлекләрен тәэмин итәргә, халыкара фәнни

хезмәттәшлек урнаштырырга һәм белем алуны гамәлгә ашырырга тиеш, имәннәрне үстерү буенча белем һәм тәҗрибәнең үзара кушылу үзәге, халыкара һәм бөтенроссия җитештерү, фәнни һәм белем бирү мәйданы булырга тиеш.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 15 маендагы 759-р номерлы боерыгы белән Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына «Россия имәнлекләре» фәнни-җитештерү үзәге» объекты буенча проект-смета документларын эшләү өчен 14,92 млн. сум акча бүлеп бирелде. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы проект-смета документларын эшләүне тәэмин итте, 2012 елның 15 декабрендә Татарстан Республикасы Дәүләт ведомстводан тыш экспертизасының Төзелеш һәм архитектура идарәсеннән (Татарстан Республикасы Дәүләт экспертизасы) «Россия имәнлекләре» фәнни-җитештерү үзәге»капиталь төзелеш объекты буенча дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе алынды (№ 16-1-4-0747-12). Объектның смета буенча бәясе 495 750,05 мең сум тәшкил итә.

«Россия имәнлекләре» фәнни-житештерү үзәге Россия Федерациясе имәнлекләрен торгызу өлешендә дөньякүләм белемнәрнең һәм тәҗрибәнең бер-берсенә кушылуның халыкара, бөтенроссия бердәм мәйданына әверелергә тиеш. Урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле барлык башкарма хакимият органнарының имәнлекләрне өйрәнү һәм саклап калу мәсьәләләренә кушылуы һәм җәлеп ителүе «Россиянең илкүләм урман сәясәте» программасын үстерергә һәм гамәлгә ашырырга ярдәм итәчәк.

Республика урманчылыкларында урман орлыкчылыгы объектларының булуы турында белешмәләр 1.2.4.3.13 нче таблицада китерелде.

1.2.4.3.13нче таблица

## Урманчылыкларда булган урман орлыкчылыгы объектлары

| Урманчылык исеме | Плюслы агачлар, данә. | | | Плюслыутыртмалар, га | | | | Урман орлык плантацияләре, га | | | | Даими урман орлык кишәрлекләре, га | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | Е | | С | | Лц. | | Д.ч. | | Лп | | барысы | |
| | | | | | | | | | | | | барлыгы | шул исәптән аттест. | барлыгы | шул исәптән аттест. | барлыгы | шул исәптән аттест. | барлыгы | шул исәптән аттест. | барлыгы | шул исәптән аттест. | барлыгы | шул исәптән аттест. |
| | С | Е Лц | Д | С | Е | Д.ч. | Лп | С | Е | Д.ч. | барысы | | | | | | | | | | | | |
| Әгерже | 42 | | | 27,5 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Арча | | 14 7 | | | 48,1 | | | | | | | 25,9 | 25,9 | | | | | | | | | 25,9 | 25,9 |
| Алабуга | 19 | | | 3,6 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| шул исәптән Лубян | 19 | | | 3,6 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Зеленодольск | 59 | | | 41,6 | | | | 14,4 | | | 14,4 | | | 12 | 12 | | | | | | | 12 | 12 |
| Ары | 137 | | | 40 | | | | 17 | | | 17 | | | 30 | 30 | | | | | | | 30 | 30 |
| Кайбыч | | | 71 | | | 126,9 | 68 | | | 17,5 | 17,5 | | | | | | | 1032,2 | 1032,2 | 97 | 97 | 1129,2 | 1129,2 |
| Кама | | | | | | | | | | | | | | | | | | 11,8 | 11,8 | | | 11,8 | 11,8 |
| Кызыл Йолдыз | | | | | | | | | | | | | | | | | | 16,5 | 16,5 | | | 16,5 | 16,5 |

Урманда хуҗалык эшләре агачлы үсемлекләрнең төр һәм форма составы кимүгә китерә. Генетик резерватларны аерып кую генетик фондны саклап калу алымнарының берсе булып тора.

Урман генетик резерваты (алга таба – УГР) – үзенең фитоценоз, урманчылык һәм урманда үсә торган үсемлекләрнең күрсәткечләре буенча шул табигать-климат районы өчен типик булган, билгеле бер төрнең генофондын саклап калу максатларында бүлеп алына торган урман кишәрлеге. УГР аеруча әһәмиятле төрләрнең генетик мөмкинлекләрен, алга таба генетика-селекция эшләрен башкару өчен агач төрләре формаларын, экотипларын һәм аерым популяцияләрен саклап калу өчен булдырыла.

Узган чорда генетик резерватлар элеккеге СССР Дәүләт урман комитеты рәисенең 1982 елның 13 августындагы 112 номерлы боерыгы белән расланган СССР урманнарында агач төрләренең генетик фондын аерып алу һәм саклап калу турында нигезләмәдә каралган тәртипкә һәм таләпләргә нигезләнеп аерып алынган иде.

2013 елның 1 гыйнварына, селекция үзәге мәгълүматлары буенча, генетик резерватларның гомуми мәйданы 911 га (табл. 1.2.4.3.14) тәшкил итә.

1.2.4.3.14нче таблица

**Генетик резерватлар урнашкан урыннар**

| Урманчылык исеме | Участок урманчылыгы | Кварталларның номеры | Гомуми мәйдан, га | Генрезерват |
|---|---|---|---|---|
| Арча | Сурнар | 77 | 118 | Европа чыршысы |
| Ары | Илет | 43 | 50 | Гади нарат |
| Кайбыч | Балтай | 40,43,44,45 | 620 | Сабаклы имән |
| | | 41,42 | 123 | Вак яфраклы юкә |
| Барлыгы | | | 911 | |

Илдәге урманнарны генетик яхшырту гомуми программасының мөһим бер өлешен урман хасил итүче төп төрләрне орлык агачларны районлаштыру алып тора.

Орлык агачларны районлаштыру орлык агачлар базасын булдыруның нигезен тәшкил итә. Орлык агачларны районлаштыруның төп бурычы төрләрнең географик үзгәрүчәнлеген югары продуктив һәм авыруларга каршы торучан урман утыртмаларын үстерү өчен рациональ кулланудан, урман хасил итүче төп төрләрнең генофондын саклап калудан гыйбарәт. Агач токымнарының киң ареаллардагы генетик төрлелеге урман хасил итүче төп төрләрнең орлыкларын куллануга хәзерләүне, нәсел үзлекләрен һәм үсү урыннары шартларын исәпкә алып, катгый тәртипкә китерүне таләп итә.

Урманнарны тәртипкә салуны проектлаганда Татарстан Республикасы шартлары өчен орлыкларны икенче җиргә күчерүне билгеләнгән орлык агачлар районнарында, шулай ук күрше районнардан һәм кече районнардан башкару

рөхсәт ителә. Соңгы 10 елда урман орлыкларын әзерләү күләме 1.2.4.3.15 нче таблицада күрсәтелде.

1.2.4.3.15 нче таблица

**1998 – 2012 елларда урман орлыкларын хәзерләү турында белешмәләр**

| Еллар | Орлыкларга ихтыяж, кг | Орлык хәзерләү планы, кг | Әзерләнгән орлыклар, кг | | | ихтыяждан % | планнан % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы | шул исәптән | | | |
| | | | | С | Е | | |
| 1998 | 236000 | 236000 | 236461 | 366 | 778 | 100,2 | 100,2 |
| 1999 | 12800 | 12800 | 12800 | 451 | 1007 | 100 | 100,0 |
| 2000 | 6000 | 6000 | 6013 | 812 | 1190 | 100,2 | 100,2 |
| 2001 | 72000 | 72000 | 72174 | 1049 | 257 | 100,3 | 100,3 |
| 2002 | 79500 | 79500 | 79605 | 1544 | 232 | 100,1 | 100,1 |
| 2003 | 8000 | 8000 | 8030 | 1363 | 74 | 100,4 | 100,4 |
| 2004 | 138000 | 138000 | 138077 | 982 | 777 | 100,1 | 100,1 |
| 2005 | 26000 | 26000 | 26109 | 834 | 58 | 100,4 | 100,4 |
| 2006 | 4850 | 4850 | 4861 | 1204 | 54 | 100,2 | 100,2 |
| 2007 | 31500 | 31500 | 31741 | 400 | 65 | 100,8 | 100,8 |
| 2008 | 56526 | 56526 | 56526 | 288 | 523 | 100 | 100 |
| 2009 | 1397 | 1397 | 1397 | 153 | 232 | 100 | 100 |
| 2010 | 166362 | 166362 | 166362 | 607 | 195 | 100 | 100 |
| 2011 | 6617 | 6617 | 6617 | 679 | 182 | 100 | 100 |
| 2012 | 4602 | 4602 | 4602 | 475 | 97 | 100 | 100 |
| Барысы | 860153 | 850153 | 851374 | 11208 | 5721 | 100,1 | 100,1 |
| елына уртача | 56677 | 56677 | 56758 | 747 | 381 | | |

1.2.4.3.16нче таблица

**Урманчылыкларда хәзерләнгән орлыкларны сыйфат класслары буенча бүлү**

| Еллар | Класслар буенча нарат орлыклары | | | | Класслар буенча чыршы орлыклары | | | | Класслар буенча барлык орлыклар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | I | II | III | гә житкерел | I | II | III | кондиция гә житкерел | I | II | III | гә житкерел | барысы |
| 1998 | 149 | 197 | 20 | 0 | 346 | 276 | 156 | 0 | 495 | 473 | 176 | 0 | 1144 |

| Еллар | Класслар буенча нарат орлыклары | | | | Класслар буенча чыршы орлыклары | | | | Класслар буенча барлык орлыклар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | I | II | III | житкерел гә | I | II | III | кондиции житкерел гә | I | II | III | житкерел гә | барысы |
| 1999 | 27 | 197 | 227 | 0 | 769 | 72 | 166 | 0 | 796 | 269 | 393 | 0 | 1458 |
| 2000 | 127 | 445 | 240 | 0 | 513 | 562 | 115 | 0 | 640 | 1007 | 355 | 0 | 2002 |
| 2001 | 193 | 363 | 487 | 6 | 71 | 66 | 120 | 0 | 264 | 429 | 607 | 6 | 1306 |
| 2002 | 414 | 787 | 333 | 10 | 11 | 73 | 148 | 0 | 425 | 860 | 481 | 10 | 1776 |
| 2003 | 67 | 443 | 733 | 120 | 57 | 0 | 17 | 0 | 124 | 443 | 750 | 120 | 1437 |
| 2004 | 420 | 335 | 227 | 0 | 577 | 125 | 75 | 0 | 997 | 460 | 302 | 0 | 1759 |
| 2005 | 164 | 614 | 56 | 0 | 39 | 19 | 0 | 0 | 203 | 633 | 56 | 0 | 892 |
| 2006 | 654 | 399 | 151 | 0 | 19 | 26 | 9 | 0 | 673 | 425 | 160 | 0 | 1258 |
| 2007 | 97 | 185 | 118 | 0 | 35 | 11 | 19 | 0 | 132 | 196 | 137 | 0 | 465 |
| 2008 | 32 | 220 | 36 | 0 | 399 | 124 | 0 | 0 | 824,8 | 38913 | 17528 | 0 | 56526 |
| 2009 | 118 | 35 | 0 | 0 | 196 | 31 | 5 | 0 | 664 | 498 | 236 | 0 | 1397 |
| 2010 | 156 | 355 | 96 | 0 | 177 | 0 | 18 | 0 | 62516 | 94295 | 9551 | 0 | 166362 |
| 2011 | 321 | 233 | 126 | 0 | 167 | 2 | 14 | 0 | 1946 | 2479 | 2192 | 0 | 6617 |
| 2012 | 282 | 184 | 10 | 0 | 71 | 2 | 24 | 0 | 417 | 476 | 3709 | 0 | 4602 |
| Барысы | 3221 | 4991 | 2860 | 136 | 3447 | 1388 | 886 | 0 | 71116 | 141855 | 36633 | 136 | 249740 |
| % | 28,7 | 44,5 | 25,5 | 1,0 | 60,2 | 24,3 | 15,5 | 0 | 28,5 | 56,8 | 14,7 | 0,1 | 100 |

Соңгы 10 елда (1998 елдан башлап 2012 елга кадәр) елына уртача 56758 кг орлык хәзерләнә иде. Орлыклар хәзерләү планы 100,1% ка үтәлде. Хәзерләнгән 1 сортлы орлыкларның күләме гомуми күләмнән 28,5% тәшкил итте.

2018 елга кадәр булачак чорда яхшырак нәсел үзлекләренә ия орлыкларны түбәндәгечә җыю планлаштырыла (җыелган орлыкларның гомуми күләме массасыннан %):

2014 елда – 2,9%;

2015 елда – 3,0%;

2016 елда – 3,2%;

2017 елда – 3,4%;

2018 елда– 3,6%.

### 1.2.4.4. Урман питомниклары

Агач һәм куак утырту материалларына ихтыяҗны канәгатьләндерү өчен республика урманнарында урман питомниклары булдырылды һәм уңышлы эшләп килә. Урман питомниклары үзләренең зурлыклары һәм гамәлдә булу сроклары буенча вакытлыча һәм даими питомникларга бүленәләр. Вакытлыча урман питомниклары урман торгызу өчен утырту материалларын үстерү максатын күздә тотып оештырыла. Вакытлыча урман питомникларының гамәлдә булу срогы 5 елдан артып китми. Аларның мәйданы гадәттә зур түгел, 1 – 3 га кадәр. Даими урман питомниклары утырту материалын озак вакыт дәвамында үстерү өчен билгеләнә. Мәйдан буенча аларны кечкенә (5 га кадәр), урта (5-15 га) һәм эре (15 га артык) питомникларга бүлеп карыйлар. Утырту материалы белән берничә урманчылыкны тәэмин итә торган, утырту материалын үстерүнең заманча технологияләрен һәм эшләр башкаруны комплекслы механикалаштыруны куллана торган даими урман питомникларын база урман питомниклары дип йөртәләр.

1.2.4.4.1 нче таблица

**2013 елның 1 гыйнварына урман питомниклары һәм урманчылыклардагы теплицалар турында белешмәләр**

| Күрсәткечләр | Исәп берәмлеге | 2013 елның 1 гыйнварына гамәлдә |
|---|---|---|
| 1. Питомниклар | | |
| 1.1. Даими: | | |
| Саны | данә | 55 |
| Гомуми мәйданы | га | 472,4 |
| шул исәптән: | | |
| әйләнештәге | га | 384 |
| күчереп утырткач үстерү өчен каралганы (мәктәп) | -»- | 64,4 |
| Питомникларның гомуми санын (вакытлыча+даими) зурлыклары буенча бүлеп карау: | | |
| 5 га кадәр | данә | 32 |
| 6-10 га | -»- | 17 |
| 11-15 га | -»- | 10 |
| 16-25 га | -»- | 5 |
| 26-50 га | -»- | 1 |
| Даими питомникнын уртача мәйданы | га | 5,9 |
| 1.2. Вакытлыча: | данә | 10 |
| Гомуми мәйданы | га | 17,2 |
| Вакытлыча питомникның уртача мәйданы | -»- | 1,7 |
| 1.3. Барлык питомниклар | | |
| Саны | данә | 65 |

| | | |
|---|---|---|
| Гомуми мәйданы | га | 489,6 |
| Питомникның уртача мәйданы | -»- | 7,5 |
| 2. Теплицалар: | | |
| Саны | данә | |
| Мәйданы | м$^2$ | |
| Теплицаның уртача мәйданы | м$^2$ | |

2013 елга гомуми мәйданы 472,4 га тигез 55 даими урман питомнигы һәм 17,2 га мәйданны алып торган 10 вакытлыча питомник эшләп килә.

1.2.4.4.2нче таблица

**2013 елның 1 гыйнварына урман питомниклары**

| Урманчылык исеме | урман питомниклары | | | | | | | питомниклар мәктәбе | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | данә | Мәйдан, га | шул исәптән эшләнештә | стандарт үсентеләр саны, мең данә | | | | стандарт үсентеләр саны, мең данә | | | |
| | | | | барысы | С | Е | Башкалар | барысы | С | Е | Башкалар |
| Әгерҗе | 2 | 10,3 | 9,75 | 707 | 400 | | | 9 | | | 9 |
| Азнакай | 1 | 19 | 19 | | | | | 9 | | 9 | |
| Аксубай | 2 | 13,0 | 11,0 | 47 | 32 | | 17 | 336 | | | 336 |
| Әлки | 1 | 7,5 | 3,8 | 409 | 388 | | 21 | 101 | | | 101 |
| Әлмәт | 1 | 15 | 13,5 | 506 | 6 | | 500 | 88 | 24 | 2 | 62 |
| Арча | 5 | 28 | 25,3 | 1529 | 1514 | | 15 | 389 | | 389 | |
| Баулы | 3 | 9,4 | 8,1 | 206 | 191 | | 15 | 169 | | | 169 |
| Биләр | 1 | 6,5 | 5 | 634 | 288 | | 346 | 65 | | | 65 |
| Болгар | 1 | 11,3 | 7,7 | 525 | 460 | 50 | 15 | 250,8 | 185 | | 65,8 |
| Бөгелмә | 1 | 10,5 | 7,31 | 273 | | | 273 | 141 | 100 | | 41 |
| Буа | 1 | 14 | 12,9 | 175 | 59 | | 116 | 120 | | 2 | 118 |
| Алабуга | 2 | 29,5 | 23,1 | 1233,2 | 828,2 | 348 | 57 | 101,7 | 15,4 | 3,3 | 83 |
| Зәй | 1 | 29 | 16 | 654 | 600 | 54 | | | | | |
| Зеленодольск | 1 | 12 | 9,9 | 312 | 304 | 3 | 5 | | | | |
| Ары | 1 | 11,1 | 9,84 | 366 | 221 | | 145 | 1 | | | 1 |
| Кайбыч | 5 | 27,7 | 26,2 | 1782 | 738 | | 1044 | 142 | | | 142 |
| Кәләй | 1 | 7 | 6,2 | 344 | 130 | | 214 | 275 | | | 275 |
| Кама | 4 | 15,5 | 13,88 | 641 | 487 | | 154 | | | | |
| Кызыл Йолдыз | 1 | 14,8 | 11,08 | 479 | 374 | | 105 | | | | |
| Лаеш | 2 | 8 | 6,9 | 286 | 237 | | 49 | 104 | | 6 | 98 |
| Лениногорск | 1 | 7,6 | 7,33 | 33 | 30 | | 3 | 14 | | 2 | 12 |
| Мамадыш | 5 | 10 | 10 | 1329 | 634 | 609 | 86 | 545 | 242 | 210 | 93 |
| Минзәлә | 6 | 32,6 | 17,3 | 986 | 725 | 91 | 170 | 7 | | | 7 |
| Түбән Кама | 2 | 19,5 | 16,66 | 1125 | 1093 | 10 | 22 | 39,08 | 2,9 | | 36,18 |

| Урманчылык исеме | урман питомниклары | | | | | | | питомниклар мәктәбе | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | данә | Мәйдан, га | шул исәптән эйләнештә | стандарт үсентеләр саны, мең данә | | | | стандарт үсентеләр саны, мең данә | | | |
| | | | | барысы | С | Е | Башкалар | барысы | С | Е | Башкалар |
| Нурлат | 1 | 7,3 | 6,5 | 496 | 329 | 99 | 68 | 20 | | 5 | 15 |
| Идел буе | 1 | 2,9 | 2,9 | 476 | 162 | | 314 | 85 | | | 85 |
| Шәһәр яны | 1 | 57,4 | 33,3 | 3011 | 1120 | 1565 | 326 | 508 | 16 | 101 | 391 |
| Саба | 6 | 26,9 | 26,7 | 1931 | 800 | 735 | 396 | 650 | | | 650 |
| Тәтеш | 3 | 15,1 | 6,91 | 802,5 | | | 802,5 | 159 | | | 159 |
| Чирмешән | 2 | 11,2 | 10 | 375 | 250 | 90 | 35 | 49 | | | 49 |
| Барысы | 65 | 489,6 | 384,08 | 22199,7 | 13232,2 | 3654 | 5313,5 | 4376,58 | 585,3 | 729,3 | 3061,98 |

Аерым хуҗалыкларда даими урман питомнигы мәйданы 2,1 га алып57 га арасында тирбәлә. Барлык даими питомникларның 94% ы зур һәм уртача категориягә керә, ә кечкенә питомниклар 6% тәшкил итә. Барлык даими питомникларның әйләнештәге мәйданы аларның гомуми мәйданыннан барлыгы 26% алып тора.

Даими урман питомникларында чәчү (ачык һәм ябык грунт) һәм мәктәп бүлекләре бар. Чәчү бүлегендә ачык һәм ябык грунтта (теплицаларда) урман культураларына һәм питомникларда мәктәпләргә нигез салу өчен чәчкеннәр үстерәләр. Мәктәп бүлегендә үсентеләрне агачларның урман, декоратив һәм җиләк-җимеш төрләре чәчкеннәреннән яисә чыбыкчаларыннан үстерәләр. Чәчкеннәрдән аермалы буларак, үсентеләрнең тамыр системасы көчлерәк һәм җир өстендә кала торган өлеше дә ныгыган була. Мондый утыртмалар тиз җайлашып китә. Тайга зонасында урман утырту өчен билгеләнгән үсентеләр өчен ГОСТлар эшләнгән. Үсентеләрне үстерү дәвамлылыгы аларның билгеләнешенә бәйле. Урман культуралары өчен үсентеләрне 2 – 3 ел үстерәләр. 4 – 6 еллык үсентеләрне беренче мәктәптә үстерәләр. Үстерү өчен озаграк вакыт таләп ителгән очракта, үсентеләрне икенче һәм өченче мәктәпләргә күчереп утырталар.

Вакытлыча урман питомниклары урман культуралары фондының керү кыенлашкан кишәрлекләрендә урман торгызу эшләре өчен ылыслы агач төрләренең утырту материалларын үстерү максатыннан булдырылды. Даими питомниклар техниканы тупларга һәм белгечләрнең хезмәтеннән нәтиҗәле файдаланырга мөмкинлек бирсә, вакытлыча питомникларның да үз уңай яклары бар. Беренчедән, алар чәчкеннәрне киселгән урыннар янәшәсендә үстерергә мөмкинлек бирәләр, моның белән транспорт чыгымнары һәм утырту материалларын югалту ихтималы кими. Икенчедән, питомниктан кыска вакытлы файдалану урман туфрагының табигый ундырышлылыгын кулланырга, кырларда гербицидлар кулланмыйча гына чүп үләннәренең үстермәскә мөмкинлек бирә. Моңа өстәп, вакытлы питомникларда чәчкеннәр киселгән урыннарга охшаш мохиттә үсәләр. Урман культуралары мәйданнары төрле җиргә таралган шартларда вакытлыча питомниклардан файда, ерактa урнашкан даими питомникларга караганда, күбрәк тә булырга мөмкин. Утырту материалын

урманчылыкларда үстергәндә органик һәм минераль ашламалар, гербицидлар кулланыла, төп процессларны механикалаштыру гамәлгә ашырыла. Питомникларның утырту бүлекләренә аммиак селитрасы, суперфосфат һәм калий хлориды кертелә. Питомниклардагы чүп үләннәре белән көрәшү өчен чәчүлекләр симазин, атразин һәм раундап белән эшкәртелде, шуның нәтиҗәсендә чәчкеннәрне чистартып тору эшләре саны 2 – 3 тапкырга кимеде.

Югары сыйфатлы чәчкеннәрне кыска вакыт эчендә алуның перспективалы ысулларыннан тагын берсе – аларны полиэтилен ябылган теплицаларда үстерү. Аларда үсемлекләр үсү өчен иң уңай шартлар тудырыла: һаваның җылылык дәрәҗәсе, анын чагыштырмача дымлылыгы арта, төнге сәгатьләрдә кырау төшүдән зыян килү ихтималы кими, вегетация чоры озая, һавада углекислый газ күләме арта. Теплицаларда, көйләп була торган мохит шартларында, махсус субстратта чәчкеннәр алу срогы бер елга кыскара, орлыкларның туфракта тишелеп чыгу дәрәҗәсе 3 – 5 тапкырга арта, бу аларга тотыла торган чыгымнарны киметә, чәчкеннәрнең чыгуы берничә тапкырга арта.

Хәзерге вакытта гамәлдә булган питомникларның һәм теплицаларның мәйданнары урманчылыкларның утырту материалларына булган ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерә. Урман утырту күләмнәрен алга таба арттыру утырту материалларын шактый арттыруны таләп итәчәк. Киләсе чорда республика урман хуҗалыгының утырту материалларына ихтыяҗы, шәһәр һәм поселокларның яшелләндерү максатларына бәйле ихтыяҗын исәпкә алсак, якынча 60 млн. данә тәшкил итәчәк.

### 1.2.4.5. Урманнарны үзләштергәндә транспорт куллану мөмкинлекләренә характеристика

Татарстан Республикасы урманчылыкларында урман хуҗалыгы һәм урман ташу юлларының озынлыгы 1.2.4.5.1 нче таблицада китерелде.

1.2.4.5.1 нче таблица

**Татарстан Республикасы урманчылыкларында урман хуҗалыгы һәм урман ташу юлларының озынлыгы**

| Урманчылык исеме | Юлларның озынлыгы, км | | | | | | 1000 гаурман фондына туры килә торган юллар озынлыгы, км | | | мон нан тыш. кыш көне йөри торганнары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | шул исәптән | | | | | барлыгы | шул исәптән ел әйләнсендә кулланыла торганнары | канәгатьләндерерлек холдә булган юлларның нисбәте % | |
| | | тимер юл | автомобиль | шулардан каты өслекле | өслек түшәлмәгән | шулардан ел әйләнсендә кулланыла торганнары | | | | |
| Әгерҗе | 275 | – | 275 | 2 | 273 | 27 | 6 | 0,6 | 70 | – |
| Азнакай | 144 | – | 144 | 6 | 138 | 21 | 3 | 0,5 | 50 | – |

| Урманчылык исеме | Юлларның озынлыгы, км | | | | | | 1000 гаурман фондына туры килә торган юллар озынлыгы, км | | | моннан тыш. кыш көне йөри торганнары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | шул исәптән | | | | | барлыгы | шул исәптән ел әйләнәсендә кулланыла торганнары | канәгатьләндерерлек хәлдә булган юлларның нисбәте % | |
| | | тимер юл | автомобиль | шулардан каты өслекле | өслек түшәлмәгән | шулардан ел әйләнәсендә кулланыла торганнары | | | | |
| Аксубай | 218 | – | 218 | 1 | 217 | 9 | 7 | 0,3 | 45 | – |
| Әлки | 186 | – | 186 | | 186 | 44 | 5 | 1,2 | 44 | – |
| Әлмәт | 148 | – | 148 | 6 | 142 | 21 | 3 | 0,4 | 55 | – |
| Арча | 237 | – | 237 | 1 | 236 | 14 | 7 | 0,4 | 50 | – |
| Баулы | 186 | – | 186 | 52 | 134 | 59 | 8 | 2,6 | 45 | – |
| Биләр | 324 | – | 324 | 2 | 322 | 186 | 6 | 3,7 | 45 | – |
| Болгар | 147 | – | 147 | 125 | 22 | 125 | 21 | 8,2 | 60 | – |
| Бөгелмә | 251 | – | 251 | 17 | 234 | 41 | 6 | 0,9 | 50 | – |
| Буа | 146 | – | 146 | 5 | 141 | 139 | 8 | 7,9 | 50 | – |
| Алабуга | 918 | – | 918 | 64 | 854 | 657 | 12 | 4,3 | 50 | – |
| Зәй | 327 | – | 327 | 12 | 315 | 76 | 5 | 1,3 | 50 | – |
| Зеленодольск | 216 | – | 216 | 15 | 201 | 41 | 8 | 1,5 | 50 | – |
| Ары | 131 | – | 131 | 13 | 118 | 0 | 8 | 0,6 | 25 | – |
| Кайбыч | 181 | – | 181 | 0 | 181 | 32 | 7 | 0,4 | 50 | – |
| Кәләй | 245 | – | 245 | 12 | 233 | 0 | 6 | 0 | 50 | – |
| Кама | 562 | – | 562 | 10 | 552 | 304 | 10 | 5,6 | 55 | – |
| Кызыл Йолдыз | 3307 | – | 3307 | 167 | 3140 | 890 | 11 | 2,2 | 60 | – |
| Лаеш | 291 | – | 291 | 12 | 279 | 188 | 8 | 5,6 | 50 | – |
| Лениногорск | 357 | – | 357 | 14 | 343 | 30 | 7 | 1,7 | 54 | – |
| Мамадыш | 424 | – | 424 | 21 | 403 | 0 | 9 | 5,4 | 64 | – |
| Минзәлә | 343 | – | 343 | 5 | 338 | 67 | 5 | 0,7 | 50 | – |
| Түбән Кама | 3672 | – | 3672 | 154 | 3518 | 1391 | 8 | 3,2 | 60 | – |
| Нурлат | 803 | – | 803 | 17 | 786 | 91 | 9 | 1,0 | 60 | – |
| Идел буе | 1436 | – | 1436 | 60 | 1376 | 32 | 5 | 0,1 | 50 | – |
| Шәһәр яны | 254 | – | 254 | 25 | 229 | 14 | 6 | 0.1 | 60 | – |
| Саба | 406 | – | 406 | 21 | 385 | 111 | 7 | 2,1 | 50 | – |
| Тәтеш | 1874 | – | 1874 | 16 | 1858 | 447 | 5 | 1,2 | 40 | – |
| Чирмешән | 226 | – | 226 | 3 | 223 | 48 | 6 | 1,3 | 70 | – |
| Барысы | 23314 | 18 | 23296 | 905 | 22391 | 7195 | 6,9 | 2,0 | 50 | – |

Урманчылыкларның урман фонды аша уза торган юлларның гомуми озынлыгы 23314 км тәшкил итә, шулардан автомобиль юлларына 23296 км туры килә: 905 км– каты өслек түшәлгән,22391 км– өслек түшәлмәгән, шул исәптән ел әйләнәсендә йөреп була торган юллар – 7195 км (табл. 1.2.5.1). 1000 гаурман фонды мәйданына туры килә торган барлык төр юлларның уртача озынлыгы 6,9 км тәшкил итә. Аерым урманчылыклар буенча 1000 гаурман фонды мәйданына туры килә торган юлларның озынлыгы – 3 кмалып 21 км кадәр. Линияле объектларның (үткәргеч торбалар һ.б.) иң зур саны Әлмәт урманчылыгы

һәм Азнакай урманчылыгы территориясе аркылы уза, аларда автомобиль йөрү юллары да бар.

Урманнардагы барлык юллар теге яки бу дәрәҗәдә урман хуҗалыгы максатларында файдаланыла. Урман хуҗалыгы юллар челтәре белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителгән дип санала (1000 га мәйданга иң уңае 7-12 км булса, чынбарлыкта исә 6,9 км тәшкил итә). Ел әйләнәсендә файдаланыла торган каты өслек түшәлгән яхшыртылган юлларга кытлык бар.

Урманчылыкларда ел саен урман хуҗалыгы һәм янгынга каршы билгеләнештәге юлларны төзү һәм ремонтлау эшләре башкарылып килде.

Билгеләнешенә карап, урман хуҗалыгы юллары түбәндәге өч типка бүленә:

I тип – магистраль юллар, алар II һәм III типлардагы юллар челтәрен берләштерә һәм урман массивларын гомуми файдаланудагы юллар белән тоташтыра. Аларның өслек киңлеге – 6,5 м һәм аннан кинрәк, автомобиль йөри торган өлешнең киңлеге – 4,5 м.

II тип – урман фонды территориясе өлешләренә хезмәт күрсәтә торган һәм магистраль юнәлештәге юлларга алып чыга торган юллар. Аларның өслек киңлеге – 4,5 – 6,5 м, автомобиль йөри торган өлешнең киңлеге – 3,5 м.

III тип – урман хуҗалыгында кулланыла торган тар билгеләнешле юллар, боларга янгынга каршы юллар, урман киселә торган урыннарга керү юллары, питомникларга, орлык агачлар кишәрлекләренә һәм плантацияләргә килә алу, киселгән урыннардан агачларны алып чыгу өчен салынган юллар һ.б. Аларның өслек киңлеге – 4,5 м, автомобиль йөри торган өлешнең киңлеге – 3 м.

Урман массивында юллар челтәре аннан урманнарны эксплуатацияләү, урман хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен, урман химиясе һәм башка чимал хәзерләү өчен комплекслы файдалануны исәпкә алып проектланырга тиеш.

Салынган һәм проектлана торган юллар тәртипкә китерелә торган урманчылыкта Юллар челтәре схемасын төзү өчен нигез булып тора, әлеге схема план-картография материалларында күрсәтелә. Урман хуҗалыгының җитештерү ихтыяҗларын юллар белән тәэмин итү мәсьәләләре урманнарны үзләштерү проектларында һәм урман хуҗалыгы регламентларында бәян ителә, алга таба алар һәр урманчылыкның Урманнарның транспорт белән үзләштерелүе схемасын эшләгәндә кулланыла торган була.

## 1.3. Татарстан Республикасының урманлы районнары буенча урман хасил итүче төп агач төрләрен кисү еллары

Урманнарның максатчан билгеләнешенең һәр төре ылыслы һәм йомшак яфраклы хуҗалыкларга бүленә. Хуҗалыклар үз чиратында хуҗалык секцияләренә аерыла, алар күпчелекне тәшкил итүче агач төрләренең бергә үсеп утыруы, бердәй авыл хуҗалыгы чаралары системасы, киселгән агачларның бертөрле әйләнеше, билгеле бер агач төрен үстерүне максат итү белән берләштерелгән утыртмаларның һәм урманнар белән капланмаган мәйданнарның җыелмасыннан гыйбарәт.

Агач хәзерләү рөхсәт ителә торган (эксплуатацияләнә торган һәм саклагыч урманнар) һәр хуҗалык секциясе өчен урманны кисү яше (өлгерү яше) билгеләнә.

Урманны кисү еллары урманнарны тәртипкә салганда яисә фәнни тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Татарстан Республикасы урманнарында урманны кисү еллары СССР Дәүләт урман хуҗалыгының «Урманнар хасил итүче төп агач төрләре буенча илнең төрле районнары өчен урманны кисүнең иң яраклы елларын раслау турында» 1978 елның 17 августындагы 114 номерлы, «Эрбет агачы урманнарында урманны кисүнең иң яраклы елларын раслау турында» 1978 елның 29 декабрендәге 177 номерлы боерыклары һәм Россия урман хуҗалыгының «2008 елның 10 февралендәге 37 номерлы боерыкка өстәмәләр кертү турында» 2008 елның 6 октябрендәге 283 номерлы боерыгы нигезендә билгеләнә иде. Урманны кисүләрнең әлеге елларына карата бернинди каршылыклы фикерләр дә булмады һәм алар 2001 – 2005 елларда урман хуҗалыкларын соңгы тапкыр тәртипкә китергәндә кулланылды.

Урманны кисүләрнең иң кулай еллары эшкә яраклы үзагачларның эшкә яраклы вак, урта һәм эре үзагачлар җыелмасы чыгуга туры килде. Кискәндә өстенлек ылыслы продуктив утыртмаларга бирелгәндә һәм баланс үзагачка сорау белән тәкъдимнең үзара тигезлеге булганда урманны кисүнең иң яраклы еллары реаль икътисадый шартларга туры килде.

Урманны кисүләрнең иң яраклы еллары, республиканың барлык территорияләре өчен бертөрле булып, ылыслы һәм йомшак яфраклы агач төрләре өчен аерылып торды.

Урман фондын кирәгеннән артык бүлеп бетерүдән һәм үзагачны җибәрүне катлауландырудан качу өчен өстәмә хуҗалык секцияләрен аерып кую берничә кагыйдә белән регламентлаштырыла. Беренчедән, хуҗалык секциясенең мәйданы, кагыйдә буларак, эксплуатацияләнә торган һәм саклагыч урманнарның һәр категориясе кысаларында урман каплаган хуҗалык җирләре мәйданының 10% ыннан ким булмаска тиеш.

Моннан тыш, практикада утыртмаларны хуҗалык секцияләренә бүлүнең өстәмә шартлары кулланыла. Беренчедән, әгәр нинди дә булса хуҗалык секциясе буенча урманны кисү исәпләнгән урман кишәрлекләре киселә торган урманның нормаль мәйданыннан кимрәк билгеләнсә, практик яктан аны бүлү максатка ярашлы булмый. Һәм, ниһаять, өстәмә хуҗалык секциясе белән бергә урманны кисү исәпләнгән урман кишәрлекләре киметелсә, ә сортиментларны максатчан үстерү зарурлыгы булмаса, ул бүлеп бирелми.

Урманны кисүләрнең яңа еллары «Урманны кисүләрнең елларын билгеләү турында» Федераль урман хуҗалыгы агентлыгының 2008 елның 19 февралендәге 37 номерлы боерыгы белән расланды.

Таләп ителгән зурлыклардагы һәм сыйфаттагы үзагачны мөмкин булган кадәр зуррак күләмнәрдә алу эксплуатацияләү өчен каралган урманнарда урман хуҗалыгы җитештерүенең төп максаты булганга күрә, урманны кисү яше дә утыртмалар җитештерүчәнлегенең иң югары сан һәм сыйфат күрсәткечләре буенча, ягъни урманның исәп ягыннан һәм техник өлгереш ягыннан елларын исәпкә алып билгеләнергә тиеш.

Урманның исәп ягыннан өлгерү яше, ул иң күп уртача артым чоры белән билгеләнә, урманны кисүнең шуннан да түбән булырга тиеш түгел иң түбән чик яшен күрсәтә, юкса хуҗалык үзагач чималын югалтачак. Хуҗалыкта әйдәп баручы сортиментлар төркеме буенча утыртмаларның исәп ягыннан өлгереше булып торучы техник өлгереш урманны кисү яшен билгеләгәндә исәпкә алына торган төп фактор булып тора.

Агачлыклар иң мөһим урман сортиментларын әзерләү өчен яраклы үзагачның иң зур еллык артымы булган һәм утыртмаларның еллык артымы бәясе иң югары булган яшькә җиткәч техник яктан өлгергән дип санала. Эксплуатацияләнә торган урманнар өчен урманны кисү яше практикада сәнәгать өчен кирәкле сыйфатлары булган продукциянең төп төре артымы кими башлаган чорда билгеләнә.

Алга таба, кабул ителгән техник өлгерешкә нигезләнеп, урманны кисү яше классы, ә аның буенча – шул хуҗалык секциясендә утыртмаларның норматив һәм факттагы эксплуатация мәйданнары билгеләнә.

Урманны кисүнең кулланыла торган яшен нигезләгәндә аның исәп урман кисүе күләменә йогынты ясавы исәпкә алыну һәм анализлану әһәмиятле өлешне алып тора.

Катнаш һәм төрле еллык агачлар үсә торган урманнарда урманны кисү еллары урманның төп өлеше буенча (иң күп үсә торган агач токымнары һәм еллары буенча) билгеләнә.

Әгәр максатлы токым башкалардан артык булмаса, әмма яхшылап караганнан соң торгызыла алса, мондый вакытлыча хуҗалык секцияләрендә урман кисү яше максатлы токым яше буенча алынырга мөмкин.

Утыртмалар запасы эрелек категориясе буенча – эшкә яраклы үзагачка, товар таблицалары буенча – утынга һәм калдыкларга бүленә. Республика агачлыклары өчен товарлыкның II классы хас. Запасның гомуми уртача үзгәреше техник үзгәреш яшендә кими: нарат – 90 ел; каен – 65 ел; усак – 50 ел.

Эшкә яраклы эре һәм уртача үзагачны үстерү өчен техник өлгерү яше турында мәгълүматларга нигезләнеп, ылыслы агач токымнарының эксплуатацияләнә торган урманнарында урман кисү яше 81 – 100 елга тигез.

Каен хуҗалык секцияләрендә урманны кисү яшен техник өлгерү елларын исәпкә алып билгеләргә кирәк, ул эшкә яраклы барлык үзагач өчен һәм эксплуатацияләнә торган урманнардагы эре һәм урта зурлыклардагы, ягъни VII класслы яшь чикләрендәге (61 – 70 еллык) эшкә яраклы үзагач өчен билгеләнә.

Усак хуҗалык секцияләрендә, усакның биологик җитешсезлекләрен (30 – 40 еллыкларның күгәрекле авыруларга тиз бирешүчәнлеген) исәпкә алып, эксплуатацияләнә торган урманнарда агач кисү яше сан ягыннан өлгерүе буенча, ягъни V класслы яшь чикләрендә (41 – 50 еллык) билгеләнгән.

Татарстан Республикасының урманлы районнары буенча урман хасил итүче төп токымнарны кисү еллары 5 нче кушымтада китерелде.

Урман утыртмаларының үзагачын хәзерләү максатларында төп агач токымнары өчен югарыда күрсәтелгән яшь чикләрен хәзерге вакытта республиканың саклагыч һәм эксплуатацияләнә торган урманнарында кулланалар.

Урманны кисү яше урман хуҗалыгын алып баруның бары тик кисү өчен билгеләнгән формасы өчен генә хас. Урман хуҗалыгын алып баруның сирәкләү формасында хуҗалык әйләнеше саклана. Сирәкләп кисү хуҗалыгында кисү объекты булып аерым агачлар торганга күрә, ә тулаем бөтен агачлык түгел, бары тик агачлыкның бер өлеше генә торгызыла. Шуңа күрә «хуҗалык әйләнеше» термины еш кына «кабатлану чоры» термины белән алыштырыла. Шулай итеп, хуҗалык әйләнеше – агачлыкта киселә торган агачларны кисү һәм торгызу өчен исәпләнгән кабатлану чоры ул.

Республикада, нигездә ылыслы һәм киң яфраклы урманнар булган районнарда, урман фондының 8% тан артыгын төрле еллык утыртмалар алып тора. Ләкин бу агачлыклардан тулысынча файдалану өчен аларда хуҗалыкның сирәкләп кисү формасын оештырырга кирәк, ул төрле еллык агачлыкларның үсү барышы закончалыкларына нигезләнгән булырга тиеш. Төрле еллык агачлыкларда хуҗалыкның сирәкләп кисү формасы булганда урман үстерүнең максаты буларак урман мәйданнарының өзлексез файдалануы шартларында эре һәм яхшы сыйфатлы агачларны үстерүгә өстенлек бирү алына. Таләп ителә торган товар структурасына караган урман запасын булдыру чоры хуҗалык әйләнешенең дәвамлылыгын билгели. Һәр кисү барышында агачлыкны сирәкләү интенсивлыгы кабатлану чорына тыгыз бәйләнгән һәм хуҗалыкның сирәкләп кисү формасы төп өлешләренең берсе булып тора. Безнең очракта хуҗалык әйләнеше 15 – 20 елга тигез була. Кабаттан кисү эшләре башланганчы яшь һәм товар структуралары оешкан булырга тиеш, алар хуҗалыкның сирәкләп кисү формасын алга таба башкаруны тәэмин итәчәк.

Урман ресурсларыннан тагы да тулырак һәм рациональ файдалануны оештыруга якын килүне алга таба камилләштерү юлларын эзләү өлгерү елларының, кисүләр әйләнешләренең, хуҗалык әйләнешләренең һәм урманны кисү елларының асылын һәм күрсәткечләрен аларның функциональ билгеләнешен конкретлаштыруны исәпкә алып төгәл дифференциацияләүне таләп итәчәк.

# 1.4. Урман чималлары потенциалына һәм аннан файдалануга характеристика, җәмгыятьнең урманнарга һәм урман ресурсларына ихтыяҗын билгеләү

## 1.4.1. Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясында каралган урманнардан файдалануның төрләре буенча аерым-аерым урманнардан файдалануга характеристика

### 1.4.1.1. Агач әзерләүнең мөмкин булган һәм чынбарлыктагы күләмнәре

Татарстан Республикасы урманнарында әзерләнә торган чимал ресурсларының төп һәм иң күп кулланыла торган төрен өлгергән үзагач тәшкил итә, ул халык хуҗалыгының күп кенә тармаклары өчен алыштыргысыз чимал булып тора. Соңгы елларда эшкә яраклы һәм утын ясый торган үзагачка гомуми ихтыяҗ тулысынча диярлек республика урманнарыннан канәгатьләндерелде.

Урманнарда үзагач әзерләү өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын кискәндә (тоташтан һәм сирәкләп кискәндә), корыган һәм зарарланган урман утыртмаларын кискәндә (санитар кисүләр), сирәкләгәндә, юллар салу өчен кискәндә, яңарту, реконструкцияләү һәм яңадан оештыру максатыннан кискәндә (урманны чистартып тору), шулай ук урман, урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын төзү, реконструкцияләү, урман инфраструктурасын төзү белән бәйле булмаган объектларны төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен билгеләнгән урман кишәрлекләрендә урман утыртмаларын кискәндә (башка кисүләр) башкарыла.

Өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын кискәндә урманны кисү исәпләнгән урман кишәрлекләре тулаем республика буенча 1785,8 мең $м^3$ тәшкил итте. 2007 елда аның барлыгы 21,7% ы кулланылды. Ылыслы хуҗалык буенча исәп урман кисүе 44,1%, яфрак хуҗалыгы буенча – 20,4% кулланылды. Арча, Мамадыш, Зеленодольск урманчылыкларында исәп урман кисүеннән файдалануның 81 – 100% ка кадәр җиткән очраклары булды.

2013 елның 1 гыйнварына өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын кискәндә исәп урман кисүе тулаем республика буенча 1406,37 мең $м^3$ тәшкил итте. 2012 елда ул бары тик 14% күләмендә файдаланылды. Ылыслы хуҗалык буенча исәп урман кисүе 38%, яфрак хуҗалыгы буенча – 13% кулланылды.

Исәп урман кисүенең тулысынча үзләштерелмәве бигрәк тә урман кишәрлекләренең төп транспорт юлларыннан ерак урнашуына, халык саны аз булган районнарда юл челтәренең начар үсүенә, өлгергән урманның төп запаслары тупланган районнарда эре урман әзерләүчеләрнең булмавына бәйле.

Өлгергән һәм картайган үзагачны әзерләү күләмнәре урман әзерләүчеләргә урман утыртмаларын арендага бирү яисә кишәрлекләрне арендага тапшырмыйча урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләрен төзү хисабына артырга мөмкин.

Өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын кискәндә республика буенча үзагач әзерләүнең чынбарлыктагы күләме 2012 елда 199,26 мең $м^3$ ликвид үзагачны тәшкил итте. Өлгергән һәм картайган урман утыртмаларында башкарыла торган кисүләргә урман әзерләүнең гомуми күләменнән 26% туры килә; корыган һәм зарарланган утыртмаларга – 32%; урманны чистартканда

уртаяшьтәге, өлгереп килүче, өлгергән һәм картайган утыртмаларга – 26%; объектларны чүп-чардан арындырганда, төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә (башка кисүләр) барлык үсү чорындагы урман утыртмаларына – 14%.

Хәзерге вакытта үзагач әзерләү «Үзагач әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 1 августындагы 337 номерлы Россия урман хуҗалыгы боерыгына нигезләнеп гамәлгә ашырыла.

Урманны кисүләрнең барлык төрләрендә үзагач әзерләүнең урманчылыклар буенча 2013 елның 1 гыйнварына гомуми күләме 6 нчы кушымтада китерелде.

Өлгергән һәм картайган урман утыртмаларында тоташтан һәм сирәкләп кисүләр башкарганда үзагач әзерләүнең урманчылыклар буенча күләме 7 нче кушымтада китерелде.

Урманны чистартканда, корыган һәм зарарланган урман утыртмаларын кискәндә, шулай ук Россия Федерациясе Урман кодексының 13, 14, 21 статьяларында каралган объектларны төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен билгеләнгән урман кишәрлекләрендә урман утыртмаларын кисүнең 2013 елның 1 гыйнварына гомуми күләме 8 нче кушымтада китерелде.

### 1.4.1.2. Сагыз әзерләү

Сагыз әзерләнми һәм аны әзерләү планлаштырылмый.

### 1.4.1.3. Агач булмаган, ашарга яраклы урман ресурсларын һәм дару үләннәрен әзерләүнең мөмкин булган һәм чынбарлыктагы күләмнәре

Базар мөнәсәбәтләре шартларында урман хуҗалыгының керемле булуын арттыруга бары тик урман ресурсларының барлык төрләрен, алар арасында агач булмаган һәм ашарга яраклы урман ресурслары мөһим урын алып тора, исәпкә алып һәм аларны рациональ кулланып кына ирешеп була. Агач булмаган урман продукциясе үстерү өчен чыгымнар тотылмый, чөнки аларның төп энергия чыганагы – ул кояш. Таләп ителгән чыгымнар аларны җыю, эшкәртү һәм экологик чиста продукцияне саклау белән бәйле була.

Агач булмаган урман ресурсларын куллану урманның гомуми продуктивлыгын һәм урман хуҗалыгының икътисадый потенциалын арттырырга ярдәм итә. Урман хуҗалыгының барлык предприятиеләре аларны күбрәк һәм комплекслырак кулланырга тиеш.

Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыю Россия Федерациясе Урман кодексы, «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, шулай ук «Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 5 декабрендәге 512 номерлы Россия урман хуҗалыгы боерыгы һәм «Ашарга яраклы урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыю кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 5 декабрендәге 511 номерлы Россия урман хуҗалыгы боерыгы белән регламентлаштырыла.

Югарыда күрсәтелгән документлар нигезендә агач булмаган урман ресурсларына агач төпләре, каен тузы, агач һәм куак кайрысы, коры-сары, мунча себеркесе, киселгән чыршы, ак чыршы, нарат ботаклары, яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар, мүк, урман түшәмәсе, камыш, курак һәм охшаш урман ресурслары керә. Ашарга яраклы урман ресурсларына кыргый үсә торган җиләк-җимеш, чикләвек, гөмбә, орлык, каен суы һәм охшаш урман ресурслары керә.

Агач булмаган, ашарга яраклы урман ресурсларын һәм дару үләннәрен әзерләү һәм жыю тиешле урман ресурсларын алу, саклау һәм урманнан алып чыгу белән бәйле эшкуарлык эшчәнлеге булып тора, яисә халыкның үз ихтыяҗлары өчен башкарыла. Әлеге эшчәнлекне урман хужалыгы регламенты нигезендә урманчылыклар тикшереп тора.

Агач булмаган, ашарга яраклы урман ресурсларын әзерләүнең һәм дару үләннәрен җыюның тулаем Татарстан Республикасы буенча мөмкин булган һәм чынбарлыктагы күләме 1.4.1.3.1 нче таблицада, ә урманчылыклар буенча – 12 нче кушымтада китерелде.

1.4.1.3.1 нче таблица

**Агач булмаган, ашарга яраклы урман ресурсларын әзерләүнең һәм дару үләннәрен җыюның мөмкин булган һәм чынбарлыктагы еллык күләме**

| Ресурсның исеме | | Исәп берәмлеге | Биологик запаслар | Әзерләүнен мөмкин булган күләме | Әзерләүнең чынбарлыктагы күләме |
|---|---|---|---|---|---|
| Барлыгы | Ашарга яраклы урман ресурслары | | | | |
| | Җиләкләр | тонна | 268,4 | - | 9,8 |
| | Гөмбәләр | тонна | 1511,4 | | - |
| | Каен суы | тонна | 7786,4 | | 1,4 |
| Барысы | Дару үләннәре | тонна | 6,13 | - | 3,03 |
| Барлыгы | Агач булмаган урман ресурслары (яңа ел чыршылары) | мең данә | 26,40 | 60,0 | 14,23 |
| Барлыгы | Агач һәм куак кайрысы | тонна | 8263,3 | | |
| | Каен тузы | тонна | 1399,3 | | |
| | Чыбык-чабык | мең $м^3$ | 1573,0 | | |
| | Агач яшеллеге | тонна | 4201,3 | | |
| | Ботаклардан азык | тонна | 3149,6 | | |
| | Мунчала | тонна | 492,0 | - | – |

Урман планын эшләгәнгә кадәрге чорда агач булмаган, ашарга яраклы урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен жыю зур булмаган күләмнәрдә башкарылды, әзерләү күләмнәренең исәбе алып барылмады.

**Агач яшеллеген эзерлэү**

Агач яшеллегенә ылыслы һәм яфраклы агач токымнарының башланган урыныңдагы диаметры 8 мм кадәр булган яфраклар, бөреләр, ылыс һәм ян ботаклар керә.

Ылыслы-витаминлы он җитештерү өчен агач яшеллеген әзерләү бары тик сирәклэп һәм тоташтан урман кисүләрне башкарганда урманны кисү урыннарында киселгән агачлардан гына рөхсәт ителә, шуңа күрә агач яшеллеген әзерләүнең булырга мөмкин күләмен исәпләү исәп урман кисүеннән чыгып башкарыла.

Аксубай, Лениногорск, Мамадыш, Минзәлә, Тәтеш урманчылыкларында мондый әзерләүләрнең иң зур потенциалы бар.

Киселгән урман кишәрлекләрендә кала торган агач яшеллеген куллану азык протеинын, каротинны, С витаминын, чын күзәнәк суын һәм халык хуҗалыгы өчен кирәкле башка продуктларны алырга мөмкинлек бирә.

Наратның агач яшеллеген эшкәртү нәтиҗәсендә пинифол кислотасы концентратын алырга була, ул җиләк-җимеш агачларын кимерүчеләргә каршы кулланыла, агулы химикатлар кулланырга тиешле, ләкин кулланмасаң яхшырак, төрле биналарны эшкәртү өчен файдаланыла. Исле матдәләр һәм ис стабилизаторлары җитештерү өчен нигез була торган изоабиенол концентраты эшкәртүнең мөһим продукты булып тора.

Ак чыршының агач яшеллеге үзендәге кушылмаларның уникаль составы белән азык буягычлардан һәм органик синтез өчен чималдан башлап антиоксидантларга, биологик актив матдәләргә, үсемлекләрне яклау чараларына, авыл хуҗалыгы үсемлекләрен үстерү стимуляторларына, дәвалау һәм профилактикалау өчен каралган препаратларга кадәр алырга мөмкинлек бирә.

Барлык токымнарның агач яшеллеге хлорофиллы һәм каротинлы препаратлар, көнкүреш химиясе һәм косметика чаралары өчен композицияләр, терлекчелек һәм ветеринария өчен витаминнар концентратларын һәм антисептиклар алу өчен эшкәртелә ала.

**Агач төпләрен әзерләү (нарат агачы төбен әзерләү)**

Нарат агачы төбе дип өлгергән нарат агач төбенең һәм тамырларының сумалалы матдәләр алу өчен чимал буларак кулланыла торган үзәк өлешен атыйлар.

Нарат агачы төбе әзерләү өчен түбәндәгеләр чимал булып тора:

– яңа һәм коры туфраклы наратлар киселгән, тик яңадан үсмәгән урыннар;

– наратлар киселгән урыннарда иң күбе 13 еллык, бонитетның I-IV классларындагы, ылыслы утыртмаларда 0,3-0,7 тыгызлыкта һәм яфраклы утыртмаларда 0,3-0,8 тыгызлыкта үсүче ылыслы һәм яфраклы яшь агачлар, боларга махсус саклагыч кишәрлекләр керми;

– наратлар киселгән урыннарда ялганып үсеп китүчәнлеге 40-50% булган (урман буларак өлгермәгән культуралар өчен) 4 – 5 еллык һәм рәтләр арасындагы киңлек 2,5 м булганда 0,4 – 0,6 тыгызлыгы белән 6 – 12 еллык урман культуралары;

–бонитетның I-IV классларына караган ревизия чорындагы нарат урманын кисү урыннары.

Узган елларда нарат утыртмаларын кисүләрнең күләмнәренә ясалган анализ һәм өлгергән, картайган нарат утыртмаларының булуы нарат агачы төбенең төп ресурслары Түбән Кама, Әгерҗе, Зәй, Чирмешән урманчылыкларында тупланган дигән нәтиҗәгә килергә җирлек тудыра. Нарат агачы төбен әзерләү утыртмаларга, яшь үсентеләргә яисә яшь агачларга зыян китерелми торган теләсә нинди максатчан билгеләнештәге урманнарда рөхсәт ителә, моңа су объектлары буендагы тау битендә һәм чокырларда урнашкан ярсаклагыч һәм туфраксаклагыч кишәрлекләрдәге эрозиягә каршы, шулай ук 0,8 – 1,0 тыгызлыгындагы яшь урманнар керми.

Нарат агачы төбен әзерләү эше канифоль-экстракцион җитештерү ресурсларын тутыру өчен алып барыла.

**Кайры һәм юкәр әзерләү**

Кайры һәм юкәр ел дәвамында агачларны һәм куакларны кискәндә әзерләнә.

Тал кайрысы кайрыда кимендә 7% дуплау матдәләре булган (дымлылык 16% тәшкил иткәндә) тал төрләренә караган агачлардан әзерләнә, моның өчен 5 еллык һәм аннан картрак куак таллар, 15 еллык һәм аннан картрак агачсыман таллар яраклы була.

Талларның агачсыман төрләреннән иң кыйммәтлеләре – кәҗә талы, куба тал, сазлык талы, бишсеркәчле тал, агач-куак төрләреннән – өчсеркәчле тал, чыбык тал, соры тал.

Тал куаклыклары иң күбе тугайларда үсә. Республиканың гидрографик челтәре шактый үскән, шуңа күрә тал кайрысын әзерләү аның бөтен территориясендә диярлек башкарыла ала.

Каен тузын әзерләү кисү өчен бүлеп куелган урман утыртмаларында кисү эшләрен башлауга 1 – 2 ел кала (фанер кискәләрен һәм махсус сортиментлар әзерләү өчен билгеләнгән агачлардан тыш), шулай ук сирәкләп һәм тоташтан кисүләр башкарганда урманны кискән урыннарда яңа киселгән агачлардан рөхсәт ителә. Каен тузын әзерләүнең мөмкин булган күләмен исәпләү каен хуҗалык секциясе буенча исәп урман кисүеннән чыгып башкарыла. Каен тузының иң зур запаслары Әгерҗе, Азнакай, Зәй, Минзәлә, Саба урманчылыкларында бар.

Кайры, икенче дәрәҗәдәге продукт булып, ягулык, сүс, мульча, шулай ук таннид җитештерү өчен компонент буларак кулланырга мөмкин. Таннид – хайваннар тиресен эшкәртү өчен һәм азык-төлек сәнәгатендә кулланыла торган мөһим продуктларның берсе. Актив күмер, кристаллсыман кремний җитештерүдә кулланыла торган агач чимал күмерен алу кайры эшкәртүнең перспективалы юнәлеше булып тора.

**Яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар һәм (яки) башка ылыслы токымнар агачларын әзерләү**

Яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар һәм (яки) башка ылыслы токымнар агачларын әзерләү махсус плантацияләрдә, чистартылырга тиешле урман кишәрлекләрендә (урман кварталлары арасындагы ызан, минераллаштырылган

полосалар, янгынга каршы өземтәләр, янгынга каршы трассалар һәм урман хуҗалыгы юллары, алмаш агачларны һәм утыртмаларны саклап калу таләп ителми торган башка мәйданнар) башкарыла ала. Яңа ел чыршыларын һәм башка ылыслы токымнар агачларын әзерләү шулай ук үзагач әзерләгәндә башкарылырга, шул исәптән киселгән агачларның оч өлешләреннән алынырга мөмкин.

Яңа ел бәйрәмнәре өчен бер елга бер гражданга иң күбе бер чыршы һәм башка ылыслы агач әзерләү рөхсәт ителә. Әзерлек эшләре яңа ел чыршыларына һәм ылыслы токымга кергән башка агачларга ихтыяҗ белән билгеләнә торган күләмдә барлык урманчылыкларда да башкарылырга мөмкин.

**Мүк, урман түшәмәсе, коелган яфраклар, камыш, курак әзерләү**

Мүк, урман түшәмәсе, коелган яфраклар, камыш, курак әзерләү аларны төзелеш өчен, шулай ук авыл хуҗалыгы терлегенә азык һәм аслык яки компост әзерләү өчен ярдәмче материал буларак куллану максатыннан башкарыла. Аларны әзерләгәндә әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян килергә тиеш түгел.

Түшәмәне җыю аның бөтен калынлыгын алмыйча гына өлешчә башкарылырга тиеш.

Ресурсның әлеге төре сәнәгатьтә кулланылмый.

**Урман кишәрлекләрендә агачларны, куакларны әзерләп (казып) кую**

Урман кишәрлекләрендә агачларны, куакларны әзерләп (казып) кую эшләре яшьнең I классындагы ылыслы утыртмаларда, яшьнең I һәм II классларындагы яфраклы утыртмаларда үткәрелергә мөмкин.

Урман кишәрлекләрендә куаклыкларда куаклар әзерләү (казып чыгару) уртача яки куе куелыктагы һәм составын күбесенчә әзерләнә торган төр тәшкил иткән куаклыкларда үсүче утыртмаларда башкарылырга мөмкин. Әзерләнә торган төрнең казып чыгарганнан соң калган куаклары саны гектарына 1000 данәдән ким булырга тиеш түгел.

**Мунча себеркеләре, себерке һәм читән өчен ботаклар һәм куаклыклар әзерләү**

Мунча себеркеләре, себерке һәм читән өчен яфраклы токымнардан (каен, усак, тал һ.б.) ботаклар һәм куаклыклар әзерләү чистартылырга тиешле урман кишәрлекләрендә (урман кварталлары арасындагы ызан; янгынга каршы өземтәләр; янгынга каршы трассалар һәм урман хуҗалыгы юллары; печән чабу урыннары; автомобиль юлларына, тимер юлга, үткәргеч торбаларга бүлеп бирелгән полосалар, алмаш агачларны һәм утыртмаларны саклап калу таләп ителми торган башка мәйданнар), шулай ук сирәкләп һәм тоташтан кисүләр алып барганда урманны кисү урыннарындагы киселгән агачлардан җыела ала.

Ресурсның әлеге төре сәнәгать масштабларында әзерләнми.

**Чыбык-чабык әзерләү**

Чыбык-чабык дип агачларның аскы өлеше 4 см кадәр диаметрлы булган киселгән нәзек кәүсәләренә, шулай ук киселгән агач очларына, агачларның нәзек ботакларына һәм сабакларына әйтәләр. Озынлык буенча чыбык-чабык ике категориягә бүленә: 2 – 4 см озынлыктагылар һәм 4 см озынраклар.

Ресурсның әлеге төре, халыкның аңа ихтыяҗы булу-булмаудан чыгып, барлык урманчылыкларда әзерләнергә мөмкин.

**Миллек әзерләү**

Миллек дип кайбер яфраклы һәм ылыслы агач токымнарының яшь ботакларыннан терлеккә ашату өчен әзерләнгән 1,5 см кадәр калынлыктагы ботакларны йөртәләр.

Миллек әзерләү өчен яфраклы (каен, усак, өрәңге, чикләвек агачы, юкә, тирәк, корычагач һ.б.) һәм ылыслы (нигездә, чыршы) агач токымнарының ботакларын кулланалар.

Миллек әзерләү сирәкләп һәм тоташтан кисүләр алып барганда киселгән агачлардан җыела ала.

Ресурсның әлеге төре халыкның аңа ихтыяҗы булу-булмаудан чыгып, барлык урманчылыкларда әзерләнергә мөмкин.

**Ашарга яраклы урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыю**

Республикада хәзерге вакытта экология торышының шактый начараюы күзәтелә, димәк, кешеләрнең сәламәтлеге дә шактый какшый. Кешеләрнең сәламәтлеген яхшыртуның иң үтемле юлларының берсе буларак коррекцияләү туклануы продуктларын фәнни нигезләнгән технологик уйлап табуларны карарга кирәк. Мондый туклану продуктларына ашарга яраклы сусләр, бифидобактерияләр һәм лактобактерияләр, олигосахаридлар булган, составларында антиоксидантлар һәм органик кислоталар һ.б. булган продуктлар керә.

Ашарга яраклы урман ресурслары арасында нарат җиләге һәм мүк җиләге аерым урын алып тора, алар биологик яктан мөһим матдәләр – шикәрләр, органик кислоталар, витаминнар, макро- һәм микроэлементлар, феноль кушылмалар, пектин һәм дуплау матдәләре чыганагы булып торалар.

Күп кенә гөмбәләрнең кыйммәтле азык сыйфатларына ия булулары гына түгел, ә дәвалау үзлекләре булу да билгеле. Соңгы ун елда гөмбәләрне антибиотик һәм дару күпләп таралган урыннары буларак кызыксынып өйрәнә башладылар.

Шулай ук ашарга яраклы кыйммәтле урман ресурсына каен суы керә, анда органик кислоталар, дуплау матдәләре, минераль матдәләр, тимер, калий, кальций, глюкоза, фруктоза, фитонцидлар бар, болар барысы да медицина өлкәсендә киң кулланыла.

**Кыргый рәвештә үсә торган җиләк-җимешне әзерләү**

Татарстан Республикасы территориясендә кыргый рәвештә үсә торган җиләк-җимешләргә сәнәгать ягыннан зур әһәмият бирелми, аларны җирле халык җыя. Әзерләүнең мөмкин булган күләме 268,4 тонна.

1.4.1.3.2 нче таблица

**Татарстан Республикасында төрле урман җиләк-җимешләренең якынча уртача уңышы (уңыш күп булган елларда)**

| Үсемлек төре | Уңыш алу, кг/га | Уңыш алу ешлыгы | Үсемлек төре | Уңыш алу, кг/га | Уңыш алу ешлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| Нарат җиләге | 200 | 1 – 2 | Каен җиләге | 50 | 1 – 2 |
| Күк җиләк | 150 | 1 – 2 | Кура җиләге | 250 | 1 – 2 |
| Каражиләк | 150 | 1 – 2 | Миләш, 2500 куак/га | 1500 | 1 – 2 |
| Карлыган | 300 | 1 – 2 | | | |
| Гөлҗимеш | 1000 | 2 – 3 | Артыш | 50 | 1 – 2 |
| Мүк җиләге | 250 | 2 – 3 | Кызыл бөрлегән | 50 | 1 – 2 |

***Гөмбә әзерләү***

Гөмбә әзерләгәндә чимал базасына тулылыгы 0,8 булган, иң күбе 10 еллык яфраклы яшь агачлар һәм иң күбе 20 еллык чыршылар үсә торган утыртмалар керми (гөмбә аз була торган кырлар буларак). Шулай ук кисү яшенә җиткән агачлыклар, гөмбә җыярга ярамаган саклана торган территорияләр бу исәптән төшереп калдырыла.

Иң күп гөмбә кымызлык, кара җиләк, нарат җиләге (көртмәлек) үсә торган наратлыкларда, кымызлык үсә торган киң яфраклы, кара җиләк үсә торган вак яфраклы каенлыкларда, кымызлык һәм кара җиләк үсә торган чыршылыкларда, кымызлык үсә торган киң яфраклы һәм кара җиләк үсә торган киң яфраклы усаклыкларда очрый.

Әгерҗе, Азнакай, Зәй, Минзәлә, Саба урманчылыкларында гөмбәләр әзерләү өчен иң зур мөмкинлекләр бар.

1.4.1.3.3 нче таблица

## Татарстан Республикасының төрле типтагы урманнарында җиләк-җимеш үсемлекләренең һәм ашарга яраклы гөмбәләрнең уңышы

| Урман тибы | Гади мүк жиләге | | Нарат жиләге | | Кара жиләк | | Урман кура жиләге | | Миләш | | Гөмбәләр | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | урманның гомуми мәйданына карагандa жиләкле мәйдан % | уртача уңыш күләме, кг/га | урманның гомуми мәйданына карагандa жиләкле мәйдан % | уртача уңыш күләме, кг/га | урманның гомуми мәйданына карагандa жиләкле мәйдан % | уртача уңыш күләме, кг/га | урманның гомуми мәйданына карагандa жиләкле мәйдан % | уртача уңыш күләме, кг/га | урманның гомуми мәйданына карагандa жиләкле мәйдан % | уртача уңыш күләме, кг/га | урманның гомуми мәйданына карагандa гөмбәле мәйдан % | уртача уңыш күләме, кг/га |
| **Наратлыклар** | | | | | | | | | | | | |
| Юкәле | | | | | | | | | | | 10 | 120 |
| Үләнле | | | | | | | | | | | 50 –яшь утыртмалардан, 10 – карт утыртмалардан | 30 |
| Лишайникле | | | | | | | | | | | 10 | 100 |
| Көртмәлекле | | | 10 | 100 | | | | | | | 10 | 50 |
| Кара жиләк булган | | | | | 20 | 200 | | | | | 5 | 20 |
| Күке житене мүге җәелгән | | | 5 | 200 | 5 | 200 | | | | | | |
| Мамыкбаш-торф мүкләре булган | 30 | 500 | | | | | | | | | | |
| Торф мүкләре булган | 20 | 350 | | | | | | | | | | |
| **Чыршылыклар** | | | | | | | | | | | | |
| Юкәле | | | | | | | | | | | 10 | 50 |
| Үләнле | | | | | | | | | | | 10 | 30 |
| Кара жиләкле | | | | | 20 | 250 | | | | | | |
| Күке житене мүге җәелгән | | | | | 5 | 200 | | | | | | |
| **Каенлыклар** | | | | | | | | | | | | |
| Юкәле | | | | | | | | | | | 10 | 200 |
| Үләнле | | | | | | | | | | | 50 | 200 |
| Лишайникле | | | | | | | | | | | 5 | 100 |
| Көртмәлекле | | | | | 10 | 150 | | | | | 1 | 50 |
| **Усаклыклар** | | | | | | | | | | | | |
| Юкәле | | | | | | | | | | | 10 | 150 |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Үләнле | | | | | | | | | | | 10 | 150 |
| Лишайниклы | | | | | | | | | | | 10 | 50 |
| Көртмәлекле | | | | | | | | | | | 1 | 20 |
| **Имәнлекләр** | | | | | | | | | | | | |
| 3-5 еллык кисенде | | | | | | | 20 | 300 | | | | |
| үлән басып килә торган кисенделәр | | | | | | | | | 60 | 76 | | |

1.4.1.3.4 нчетаблица

**Урта Идел буе урман типларының төрле төркемнәрендә кыргый рәвештә үсә торган җиләкләрнең уртача еллык уңышы**

санаучы – биологик уңыш,
ваклаучы – җыелган уңыш

| Урман типлары төркеме | 100% җиләклекләр белән капланганда уңыш, кг/га. | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Начар | Уртача | Яхшы | Күп | 10 елга уртача еллык |
| **Нарат җиләге** | | | | | |
| Күке җитене мүге җәелгән наратлыклар | 60/- | 160/80 | 280/140 | 400/200 | 170/70 |
| Көртмәлекле наратлыклар | 40/- | 100/50 | 170/85 | 250/125 | 100/45 |
| Көртмәлекле-күрәнле каенлыклар | 30/- | 80/- | 140/70 | 200/100 | 85/35 |
| Көртмәлекле һәм күке җитене мүге җәелгән наратлыклар, көртмәлекле-күрәнле каенлыклар кисенделәре | 70/- | 200/100 | 350/185 | 500/250 | 210/90 |
| Уңышлар нисбәте | 4 | 3 | 2 | 1 | |
| **Кара җиләк** | | | | | |
| Кара жиләкле наратлыклар һәм чыршылыклар | 80/- | 220/110 | 380/190 | 550/275 | 230/110 |
| Кара җиләкле вак үләнле каенлыклар һәм усаклыклар | 60/- | 160/80 | 280/140 | 400/200 | 170/80 |
| Уңышлар нисбәте | 3 | 4 | 2 | 1 | |
| **Мүк җиләге** | | | | | |
| Торф мүкле наратлыклар | 70/- | 200/100 | 350/175 | 500/250 | 210/90 |
| Күрәнле-торф мүкле наратлыклар | 90/- | 240/120 | 420/210 | 600/300 | 250/110 |
| Уңышлар нисбәте | 4 | 3 | 2 | 1 | |

**Дару үләннәрен җыю**

Дару үләннәре җыела торган мәйданнарга дару үләннәре 70% артык мәйданда очрый торган урыннар керә. Әгәр алар 10% кимрәк мәйданда очраса, кыргый рәвештә үсә торган дару үләннәре исәпкә алынмый.

Дару үләннәре республика территориясенең бөтен җирендә бар. Медицинада кулланырга рөхсәт ителгән дару үләннәренең барлык төрләренең 65% ын кыргый рәвештә үсә торганнары алып тора, аларның да күп өлеше урманнарда очрый.

Экологик вәзгыять катлаулы булганга күрә, дару үләннәрен әзерләп кую киңәш ителми.

Дару чималын жыеп әзерләп кую барлык урманчылыкларның территориясендә үсемлекләрнең үз вакытында яңадан үсүен һәм чимал запасларының торгызылуын тәэмин итәрлек күләмнәрдә башкарылырга мөмкин.

1.4.1.3.5 нчетаблица

**Үсемлекләрнең атамалары һәм яңа жыелган үсемлекләрдән киптерелгән-коры дару чималы чыгуның якынча проценты**

| № т/с | Үлән атамасы | Чимал төре | Киптерелгән-коры чимал чыгышы | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Эксперименталь белешмәләр | Әзерләү буенча белешмәлек, 1985 ел | Башка китаплардагы белешмәләр | % |
| 1 | Ир тамыры | Үзәк тамыр | 38 + 1 | 30 | 25 | 30 |
| 2 | Песи борчагы | Тамырлар | - | 22 | 2- | - |
| 3 | Үгез күзе | Төркем чәчәкләр | - | 20-22 | - | - |
| 4 | Саз чабыр куагы | Үлән | - | 32-26 | - | - |
| 5 | Кара тилебәрән | Яфраклар | - | 16-18 | 20 | - |
| 6 | Иянке каен (ак каен) | Бөреләр | - | 40 | 30.3 | - |
| 7 | Комлык үлмәс чәчәге | Төркем чәчәкләр | 46 + 2 | 25-30 | 23-25 | 33 |
| 8 | Дүләнә | Чәчәкләр | - | 18-20 | - | - |
| 9 | Дүләнә | Җимешләр | - | 25 | - | - |
| 10 | Нарат җиләге | Яфраклар | 56 + 1 | 45 | - | 45 |
| 11 | Кара бохар миләше | Чәчәкләр | - | 18-20 | 12.5 | - |
| 12 | Дарулы песи үләне | Тамырлар белән үзәк тамыр | 35 ± 3 | 25 | 22 – 36 | 25 |
| 13 | Кукчәчәк | Чәчәкләр | - | 20 | - | - |
| 13 | Кондыз үләне (трифоль) | Яфраклар | - | - | - | - |
| 14 | Кабызлык (елан тамыры) | Үзәк тамыр | - | 25 | 33.7 | - |
| 15 | Борыч кырлач (су борычы) | Үлән | - | 20-22 | 25 | - |
| 16 | Бүсер кырлачы | Үлән | - | 20-22 | - | - |
| 17 | Озын андыз | Тамырлар белән үзәк тамыр | 36 ± 2 | 30 | - | 30 |
| 18 | Гади имән | Кайры | - | 40 | - | - |
| 19 | Гади тилерткеч | Яфраклар | - | 12 – 14 | - | - |
| 20 | Гади мәтрүшкә | Үлән | - | 25 | - | - |
| 21 | Кошкунмас агач | Җимешләр | - | 17 | - | - |
| 22 | Тишек яфраклы сары мәтрүшкә | Яфраклар | - | 20 | - | - |
| 23 | Урман каен җиләге | Яфраклар | - | 20 | - | - |
| 24 | Урман каен җиләге | Җимешләр | - | 14-16 | - | - |
| 25 | Кече кызыл чатыр | Үлән | 35 ± 2 | 25 | 25 – 26 | 25 |
| 26 | Гади балан | Кайры | - | 40 | - | - |
| 27 | Ике өйле кычыткан | Яфраклар | 30 ± 2 | 22 | 20-25 | 22 |
| 28 | Әвернә уты | Тамырлар белән үзәк тамыр | 32 ± 1 | - | - | - |
| 29 | Дарулы кызылбаш | Тамырлар белән үзәк | - | 25 | - | - |

| № т/с | Үлән атамасы | Чимал төре | Киптерелгән-коры чимал чыгышы | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Экспериментальные бєлешмәләр | Әзерләү буенча бєлешмәлек, 1985 ел | Башка китаплардагы бєлешмәләр | % |
| | | тамыр | | | | |
| 30 | Мурт эт шомырты | Кайры | - | 40 | 37 | - |
| 31 | Сары тәнбоек | Үзәк тамыр | 14 – 1 | 8 – 10 | - | 11 |
| 32 | Кукуруз | Җимешлек авызчыгы белән баганачык | - | 25 | - | - |
| 33 | Май ландышы | Яфраклар | 23 ± 1 | 20 | 20 – 23 | 20 |
| 34 | Май ландышы | Үлән | 21 ± 0.5 | 20 | 20-23 | 20 |
| 35 | Май ландышы | Чәчәкләр | 19 ± 1 | 14 | - | 14 |
| 36 | Төз тәпичә | Үзәк тамыр | - | 28-32 | - | - |
| 37 | Кытай лимоннигы | Җимешләр | 25 + 15 | - | - | 20 |
| 38 | Йөрәксыман яфраклы юкә | Чәчәкләр | 31 + 1 | 25 | 30 – 25 | 25 |
| 39 | Гади кура җиләге | Җимешләр | - | 16 – 18 | 20 | - |
| 40 | Үги ана яфрагы | Яфраклар | 18 – 1 | 15 | 19-20 | 15 |
| 41 | Гади артыш | Күркә-җиләкләр | - | 30 | - | |
| 42 | Дарулы тузганак | Тамырлар | - | 33-35 | - | - |
| 43 | Ак зирек (һәм җилемле зирек) | Тәлгәшләр (күркәләр) | - | 38 – 40 | - | - |
| 44 | Кәтүче сумкасы | Үлән | - | 26-28 | - | - |
| 45 | Гади гөлбадран | Төркем чәчәкләр | - | 25 | - | - |
| 46 | Чукмарсыман күкерт үләне (һәм башка төрләре) | Споралар | - | 6-7 | - | - |
| 47 | Зур бака яфрагы | Яфраклар | 20 ± 1 | - | 22-23 | 15 |
| 48 | Ачы әрем | Үлән | - | 22 | - | - |
| 49 | Ачы әрем | Яфраклар | - | 24 – 25 | - | - |
| 50 | Йөрәксыман яфраклы арыслан койрыгы | Үлән | - | 25 | - | - |
| 51 | Аптека ромашкасы | Төркем чәчәкләр | 27 ± 1 | 20 | 20 – 27 | 20 |
| 52 | Исле ромашка | Төркем чәчәкләр | - | - | 20 | - |
| 53 | Зәңгәр күкчәчәк | Үзәк тамыр | - | 30-32 | - | - |
| 54 | Скополия | Үзәк тамыр | 27 ± 2 | 30-32 | 30-32 | - |
| 55 | Кара карлыган | Җимешләр | - | 18-20 | - | - |
| 56 | Гади нарат | Бөреләр | - | 40 | - | - |
| 57 | Кыр касшкыраны | Тамырлар | 47 ± 1 | 30 ± 32 | 30 ± 32 | - |
| 58 | Шуышма чабыр үләне (рәйхан) | | - | 25-30 | - | - |
| 59 | Саз кипкәре | Үлән | | 23-25 | - | - |
| 60 | Гади аю җиләге | Яфраклар | 60 ± 3 | 50 | - | 50 |
| 61 | Гади меньяфрак | Үлән | 0 | 22 | - | - |
| 62 | Ала миләүшә | Үлән | 27 ± 2 | 20 | 20-22 | 20 |
| 63 | Кыр наратбашы | Үлән | - | 25 | - | - |
| 64 | Лобель аксыргагы | Тамырлар белән үзәк тамыр | - | 25 | - | - |

| № т/с | Үлән атамасы | Чимал төре | Киптерелгән-коры чимал чыгышы | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Эксперименталь бәлешмәләр | Әзерләү буенча бәлешмәлек, 1985 ел | Башка китаплардагы бәлешмәләр | % |
| 65 | Өч җәймәле эт тигәнәге | Үлән | 19 ± 1 | 15 | 25 | 15 |
| 66 | Гади шомырт | Җимешләр | - | 42 – 45 | - | - |
| 67 | Кара җиләк | Җимешләр | 16 ± 1 | 13 | 15 – 18.3 | 13 |
| 68 | Зур канлут | Үлән | - | 23 – 25 | - | - |
| 69 | Май гөлҗимеше (һәм күп витаминлы башка төрләре) | Җимешләр | 46 ± 2 | 32 – 35 | 32 – 35 | 32 |
| 70 | Эт борыны (һәм аз витаминлы башка төрләре) | Җимешләр | 58 ± 3 | 32 – 35 | - | 23 |
| 71 | Ир абага | Үзәк тамыр | - | 30 | - | - |
| 72 | Чыбыксыман эвкалипт | Яфраклар | 50 ± 3 | - | - | 43 |
| 73 | Шарсыман эвкалипт | Яфраклар | 50 ± 3 | - | - | 43 |
| 74 | Җәелеп үсүчән якорецлар | Үлән (тамырлары белән) | - | - | 3- | - |

**Каен суын әзерләү**

Киртләү өчен тулылыгы кимендә 0,4 булган һәм бер гектарда кимендә 200 данә агач үскән бонитетның I-III классларындагы сәламәт урман кишәрлекләре сайлап алына. Киртләү өчен күкрәк биеклегендәге диаметры 20 см һәм аннан зуррак булган агачлар алына.

Чимал базасына түбәндәге типларга керә торган утырмалар кертелми:

– дымлы һәм юеш урман типларында үсә торганнар;

– көчсезләнгәннәр;

– файдалану исәбеннән чыгарылганнар;

– яшел зона урманнарында үсә торганнар һәм кыр саклагычлар;

– химик чараларныкулланып корткычларга каршы гамәлләр башкарган вакыттан 2 елдан кимрәк вакыт узган территорияләрдә үсә торганнар.

Киртләү өчен түбәндәге агачлар билгеләнми:

– Крафт буенча IV һәм V үсү һәм үсеш классларындагы;

– көчсезләнгәннәр һәм механик зарарланганнар;

– махсус сортиментлар әзерләү өчен сайлап алынганнар;

– плюслы.

Каен суын сәнәгать күләмнәрендә әзерләүнең иң зур потенциалы Әгерҗе, Азнакай, Зәй, Минзәлә, Саба, Кама, Лениногорск урманчылыкларында бар.

Киртләү бары тик кисү өчен билгеләп куелган агачларда гына башкарыла, шуңа күрә әлеге ресурстан файдалана алу дәрәҗәсе үзагач әзерләү мөмкинлекләренә бәйле. Киртләүнең икътисадый яктан файдаланырлык булуы турыдан-туры үзагач әзерләүнең икътисадый мөмкинлекләренә карый.

**1.4.1.4. Урманнардагы авыл хуҗалыгын алып бару өчен яраклы авыл хуҗалыгы җирләренә характеристика һәм алардан файдалану дәрәҗәсе**

Татарстан Республикасы территориясендә урман фонды җирләрен авыл хуҗалыгын алып бару өчен файдалану нәтиҗәсезлеге сәбәпләренең берсе авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге буш җирләрнең күп булуында.

Авыл хуҗалыгын алып бару өчен файдалана торган урман фонды җирләренең торышы канәгатьләндерерлек.

Урман фонды җирләре сөрү, печән чабу, терлек көтү, умартачылык һәм башка авыл хуҗалыгы эшчәнлеге белән шөгыльләнү өчен файдаланыла.

Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы җирләренең гомуми мәйданы, 2013 елның 1 гыйнварына урман фондын исәпләү буенча, 13,4 мең га тәшкил итә.

Татарстан Республикасы урманнарында авыл хуҗалыгы җирләренең булуы һәм аларга характеристика 1.4.1.4.1 нче таблицада китерелде.

1.4.1.4.1нче таблица

**Татарстан Республикасы урманнарында авыл хуҗалыгы җирләре һәм аларга характеристика**

| № т/с | Файдалану төрләре | Исәп берәмлеге | 2013 елның 1 гыйнварына исәпкә алынган |
|---|---|---|---|
| 1. | Сөрүлек итеп файдалану | мең га | 0,6 |
| 2. | Печән чабу | мең га | 7,2 |
| 3. | Терлек көтү | мең га | 5,5 |
| | а) урманда | мең га | 0,8 |
| | б) утлавыкта, көтүлектә | мең га | 4,7 |
| 4. | Умартачылык | ц | 270 |

**Сөрүлекне файдалану**

Татарстан Республикасы территориясендә, 2013 елның 1 гыйнварына исәпкә алынган буенча, сөрүлек җирләренә 0,6 га туры килә. Сөрүлек җирләренең хәзерге торышы канәгатьләндерми. Аларның күбесе озак еллардан бирле файдаланылмый, шуңа күрә агачлы һәм үләнле үсемлекләр белән капланып бара.

Сөрүлекләрнең күбесе кыргый хайваннарны ашату, бөртекле, кузаклы һәм тамыразыклы культуралар чәчү өчен файдаланыла.

**Печән чабу**

Печән чабу өчен урман булмаган җирләр, шулай ук киләчәктә урман үсми торган киселгән урман җирләре, аланлыклар һәм урман үсемлекләре белән капланмаган башка җирләр аларда урман торгызу эшләре алып барылганчы файдаланыла.

Печән чабу эшләре кышкы чорга йорт терлеге өчен печән хәзерләү өчен башкарыла.

Печән чабу өчен файдаланыла торган җирләргә, 2013 елның 1 гыйнварына урман фондын исәбе буенча, 7,2 мең га туры килә.

Татарстан Республикасы территориясендә урман фондының печән чабу өчен яраклы җирләре, агач-куаклар белән капланып, яраксыз хәлгә киләләр, моның аркасында үләннәрнең сыйфаты һәм печән хәзерләү шартлары начарая. Сакланып калган печәнлекләрнең уңдырышлылыгы түбән һәм 1-5 ц/га тәшкил итә.

Файдаланыла торган печәнлеләрнең мәйданы киму йорт терлекләренең баш саны кимүгә, күпчелек печәнлекләрнең түбән уңыш бирүенә, аларга алып килә торган юлларның начар хәлдә булуына һәм файдаланылмый торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең булуына бәйле.

Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгын алып бару өчен яраксыз урман җирләрендә урман торгызу гамәлләрен үткәрү (урман культураларын барлыкка китерү) планлаштырыла.

**Терлек көтү**

Авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү өчен урман булмаган җирләр, шулай ук киләчәктә урман үсми торган киселгән урман җирләре, утыртмалар сирәк үсә торган урыннар, аланлыклар һәм урман үсемлекләре белән капланмаган башка җирләр аларда урман торгызу эшләре алып барылганчы файдаланыла.

Татарстан Республикасы урман фонды исәбе буенча, 5,5 мең га якын көтүлек бар. Көтүлекләргә терлек көтү өчен чынбарлыкта файдаланыла торган урмансыз җирләр керә. Азык таба торган җирләр буларак урман көтүлекләренең сыйфаты югары түгел. Үләннәр арасында күбрәк калын һәм каты ботаклы үләннәр һәм мүкле-куаклы үсемлекләр очрый.

Терлек көтү өчен тәкъдим ителә торган төп урман типларының ВО «Леспроект» мәгълүматлары буенча азык бирүчәнлеге 1.4.1.4.2 нче таблицада китерелде.

1.4.1.4.2 нче таблица

**Терлек көтү өчен тәкъдим ителә торган төп урман типларының азык бирүчәнлеге**

| Урман типлары төркемнәре | уңыш, ц/га | | ашала торган көтүлек азыгы, ц/га | азык бирәмлекләре запасы | шартлы рәвештә 1 баш мөгезле эре терлеккә туры килүче гектарларда алынган көтү нормасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | китерелгәч авырлыгы | яшел массада | | | |
| Сәрдәле сәрин | 6 – 12 | 15 – 31 | 8 – 16 | 150 – 300 | 6,9 – 3,4 |
| Сәрдәле дымлы | 9 – 19 | 30 – 66 | 15 – 33 | 280 – 620 | 3,7 – 1,7 |
| Куян кузгалаклы | 7 – 9 | 23 – 30 | 12 – 15 | 230 – 280 | 4,6 – 3,7 |
| Яшел мукле | 7 – 10 | 23 – 33 | 12 – 17 | 230 – 320 | 4,6 – 3,2 |

Урман көтүлекләре алардагы үләннең туклыклылык дәрәҗәсе түбән булу, агулы үләннәрнең, чыбык-чабыкның һәм тамырларның күп булуы белән аерылып тора.

Урманнарда терлек көтеп, аларның тулысынча тукlануына ирешеп булмый, терлекне ерак җирләргә алып бару аларның хәлен ала.

Урман көтүлекләренең күпме үлән бирүен белү өчен нормативлар булмаганда ВО «Леспроект»ның «Урманнарны таксацияләү өчен гомумсоюз нормативлары» белешмәлелеге (СССР Дәүләт урман комитетының 1989 елның 28 февралендәге 38 номерлы боерыгы белән расланган) кулланыла.

1.4.1.4.3нче таблица

**Терлек көтүнең сезонлы норма күләмнәре**[2]

| Урман көтүлекләренә характеристика | Терлек көтү нормасы, 1 баш мөгезле эре терлеккә яисә 7 сарыкка туры килә торган га |
|---|---|
| Күбесенчә 0,5 – 0,6 тыгызлыкта каен үсә торган яфраклы урманнар | 2,0 |
| 0,5 тыгызлыкта чиста каенлыклар | 1,5 |
| Терлек көтү өчен яраклы калган утыртмалар | 4,0 – 5,0 |
| Куаклыклар һәм яшь үсентеләр булмаган киселгән урыннар | 0,75 |

**Умартачылык**

Татарстан Республикасында, аның территориясендә бал үсемлекләренең күп төрләре үскәнгә күрә, элек-электән умартачылык белән шөгыльләнәләр.

Баллы үсемлекләрнең чәчәк ату вакытлары төрле булганга күрә, бал җыю өчен барлык вегетация чорында уңай шартлар була.

Умартачылык продуктларына бал, балавыз, умарта агуы, бал икмәге керә.

Республика территориясендә юкәдән тыш кырлыган, үги ана яфрагы, кыр тукранбашы, күкебаш кебек бал үсемлекләре очрый.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында умартачылык, умартачылык продукциясенә ихтыяҗ зур булганга күрә, перспективалы тармак буларак карала.

Авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдалану күләме буенча урман планын эшләгәнгә кадәрге чорга караган мәгълүмат җитәрлек түгел, шуңа күрә урман планы гамәлдә булу чорында урманнардан файдалану күләмнәре планлаштырылмады яисә аз гына планлаштырылды.

**Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясында каралган башка эшчәнлек төрләре өчен урманнардан мөмкин булган файдалану**

[2]Курлович Л.Е., Николаев Г.В., Черкасов А.Ф., Косицин В.Н. Руководство по учету и оценке второстепенных лесных ресурсов и продуктов побочного лесопользования. М.: ВНИИЛМ, 2003.

Республиканың урман территорияләрендә эшчәнлекнең башка төрләрен (элек карап үтелгәннәрдән тыш) үстерү максатка ярашлы булыр дип уйланыла, аларның шактый югары икътисадый һәм социаль перспективалары бар. Алар арасында:

– фәнни-тикшеренү һәм белем бирү эшчәнлеге;

– рекреация эшчәнлеге;

– урман плантацияләрен булдыру һәм аларны эксплуатацияләү;

– җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар күпләп таралган урыннарыннан аларны чыгару эшләрен башкару;

– сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын, шулай ук гидротехник корылмалар һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү;

– электртапшыргыч линияләр, юллар, үткәргеч торбалар һәм башка линияле объектлар төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү;

– үзагачны һәм башка урман ресурсларын эшкәртү;

– дини эшчәнлек.

### 1.4.1.5. Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген һәм белем бирү эшчәнлеген башкару

Татарстан Республикасы урманнары фәнни һәм мәгариф оешмалары тарафыннан фәнни-тикшеренү һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланырга мөмкин. Моның өчен урман кишәрлекләре дәүләт учреждениеләренә һәм муниципаль учреждениеләргә – даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, башка фәнни һәм мәгариф оешмаларына арендага бирелә.

Урманнардан фәнни-тикшеренү максатларында файдалану урманның экологик системасы турында яңа белемнәр алуга, аеруча әлеге белемнәрне практик максатларга ирешү өчен һәм урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызу өлкәсендә төгәл бурычларны хәл итү өчен кулллануны күз алдында тоткан гамәли фәнни тикшеренүләр үткәрүгә корылган эксперименталь яисә теоретик эшчәнлекне үз эченә ала.

Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалануга урманнарны, табигатьнең башка компонентларын өйрәнү, файдалану, саклау, яклау, торгызу өлкәсендә уку-тәҗрибә объектларын (полигоннар, урман табигатен өйрәнү, урманны таксацияләү, урман утыртмаларын кисү, урман торгызу эшләрен, урманнарны саклау, яклау, яңадан утырту эшләрен һәм башка гамәлләрне башкару алымнарына өйрәтү өчен тәҗрибә мәйданчыклары) һәм белем алучыларның махсус белемнәрен, осталыкларын һәм күнекмәләрен практикада ныгыту өчен кирәкле урман инфраструктурасы объектларын урман кишәрлекләрендә булдыру һәм файдалану керә.

Фәнни-тикшеренү һәм белем бирү эшчәнлеген Татарстан Республикасының барлык урманнарында, аларның максатчан билгеләнеше нинди булуга карамастан, 70 мең га мәйданда гамәлгә ашырырга мөмкин.

Казан краенда урман тәҗрибәсе эше революциягә кадәрге елларда ук башлангыч ала.

1918 елда Казан университеты каршында урман хуҗалыгы факультетын ачу турында карар кабул ителгәннән соң, урман факультетына уку практикаларын

үткәрү һәм фәнни-гамәли тикшеренүләр өчен стационар тәҗрибә объектларына нигез салу өчен база буларак Раифа урман дачасын беркетү турында карар кабул ителә.

1922 елда университетның урман факультеты һәм политехника институтының авыл хуҗалыгы факультеты базасында авыл хуҗалыгы һәм урман бүлекләре белән Казан авыл хуҗалыгы һәм урманчылык институты төзелә, 1927 елда алар агрономия һәм урман факультетларына үзгәртеп төзеләләр.

1922 елда Декрет белән институтка уку-тәҗрибә участоклары буларак гомуми мәйданнары 60 мең дисәтинә тәшкил иткән Мари өлкәсенең Сретен, Вятка өлкәсенең Можга урманчылыклары, шулай ук 3 мең дисәтинә мәйданда Раифа уку-тәҗрибә урманчылыгы беркетелә.

1930 елда СССР Совнаркомы карары белән Казан авыл хуҗалыгы һәм урманчылык институтының урман факультеты базасында Казан урман техник интитуты төзелә, 1932 елда аның исеме Идел буе урман техник институты дип үзгәртелә һәм Йошкар-Ола шәһәренә күчерелә.

Республиканың урман хуҗалыгы өчен югары мәктәп белгечләрен әзерләү кирәк булганга күрә, 2000 елда Казан авыл хуҗалыгы академиясендә «Урман хуҗалыгы» белгечлеге ачыла, 2003 елның март аенда урман хуҗалыгы һәм экология факультеты төзелә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 15 октябрендәге 1679-р номерлы күрсәтмәсе белән Саба урманчылыгының гомуми мәйданы 60292 гектар (637 кв.) тәшкил иткән урман кишәрлекләре фәнни-тикшеренү һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен «Саба уку-тәҗрибә урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениесенә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга тапшырылды.

ТАССР ЦИКның 1926 елның 12 июлендәге «Татариядә урман тәҗрибәсе эше турында» карары нигезендә Казан тәҗрибә урманчылыгы базасында урман тәҗрибә станциясе төзелә. Дүрт ел дәвамында ул Татнаркомземның Урманнарга идарә карамагында була, ә 1930 елда урман һәм сал агызу институтының Идел-Кама филиалы белән берләшә. 1932 елда станция ВНИАЛМИ системасына керә.

Татарстан Урман тәҗрибә станциясе 1936 елдан башлап хәзергәчә ВНИИЛМның структур бүлеге булып тора.

Станция коллективы хәл итә торган төп бурыч – Урта Идел буенең урман хуҗалыгын алып баруны фәнни тәэмин итү. Хезмәт күрсәтү зонасы – Татарстан, Чувашия, Удмуртия, Мордовия, Марий Эл республикалары һәмУльяновск өлкәсе.

Татарстан Урман тәҗрибә станциясе эшләү чорында тәҗрибә һәм тәҗрибә-житештерү объектлары челтәре төзелде, аңа урман хуҗалыгының төрле юнәлешләре һәм мәсьәләләре буенча 500 артык стационар керә. Татарстан Республикасы тәҗрибә объектларына инвентаризация үткәрелде һәм каталог нәшер ителде. Фәнни, тәҗрибә, тәҗрибә-житештерү объектлары бөтен республикада диярлек бар, ләкин алар аеруча «Зеленодольск урманчылыгы», «Шәһәр яны урманчылыгы», «Саба урманчылыгы», «Арча урманчылыгы», «Лаеш урманчылыгы» һәм «Кама урманчылыгы» дәүләт бюджет учреждениеләрендә тупланган.

Стационар участокларда даими һәм аерым бер вакыт аралыгында күзәтүләр алып барыла, аларның дәвамлылыгы аерым очракларда 50-80 ел тәшкил итә.

1948 елда станция хезмәткәрләре Казан шәһәрендә дендробакча булдыралар, 1981 елда аңа табигать ядкәре статусы бирелде – «Казан дендрариясе». Станция хезмәткәрләре җитәкчелегендә чокыр-озын чокыр системаларында «Кишангер», «Никольская», «Фәхри Яры», «Наратлы Сыза» һәм «Каменная» урман мелиорация объектлары (120 га мәйданда) шулай ук табигать ядкәрләре булып тора.

«Лубян урман техник колледжы» урта һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениесе урта махсус уку йорты булып тора. Лубян урман техник колледжы Татарстан АССР Наркомземының 1921 елның10 мартындагы карары белән 1893 елдан башлап эшләп килгән Биклән урман мәктәбен үзгәртеп төзү юлы белән оештырыла.

Урман хуҗалыгы белгечләренең беренче чыгарылышы 1924 елда чыга, алар 29 кеше булалар.

1942 елда Лубянга барлык студентлары, профессор-мөгаллимнәре һәм аларның гаиләләре белән, алар арасында профессорлар Тюрин, Каппер, Огиевский һәм башкалар була, Воронеж урман хуҗалыгы институты эвакуацияләнә.

1970 елның декабрендә РСФСР Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән Лубян урман хуҗалыгы техникумы һәм Лубян уку-тәҗрибә урман хуҗалыгы базасында Кукмара муниципаль районы территориясендә урнашкан Лубян урман хуҗалыгы техникумы төзелә.

Техникум эшләгән 85 ел эчендә аны 8 меңнән артык урман хуҗалыгы белгече тәмамлый. 1988 елның октябрендә техникум каршында эшче кадрларны яңадан әзерләү буенча укыту пункты ачыла, 1993 елда ул Урта һәм түбән баскыч эшче кадрларын һәм урман хуҗалыгы белгечләрен әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү буенча Татарстан уку пунктына үзгәртеп төзелә.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 25 декабрендәге 2359-р номерлы күрсәтмәсе белән «Лубян урман хуҗалыгы техникумы» урта һөнәри белем бирү федераль бюджет мәгариф учреждениесе Татарстан Республикасы карамагына тапшырылды.

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 2012 елның 27 гыйнварындагы 51 номерлы карары нигезендә «Лубян урман хуҗалыгы техникумы» Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы буйсынуына кертелде.

2012 елның август аенда Лубян урман хуҗалыгы техникумы исеме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән Лубян урман техник колледжына үзгәртелде.

Колледж ике белгечлек буенча кадрлар әзерли: 250110 «Урман һәм урман-парк хуҗалыгы», 250203 «Бакча-парк һәм ландшафт төзелеше» һәм 080110 «Икътисад һәм бухгалтерлык исәбе».

Колледжда 30 укытучы эшли.

Колледж төп белгечлектән тыш урман егучы, тракторчы, эш өчен кәрҗин үрүче кебек эшче һөнәрләр буенча белгечләр әзерләп чыгара.

«Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең 2440,3 га гомуми мәйданны тәшкил иткән урман кишәрлекләре (86-91,97-101,106-108, 112- 114,117-122, 195 нче урман кварталларында) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 28 мартындагы 471-р номерлы күрсәтмәсе белән «Лубян урман хуҗалыгы техникумы» урта һөнәри белем бирү

дәүләт мәгариф учреждениесенә фәнни-тикшеренү һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирелде.

Татарстан Республикасында фәнни-тикшеренү эшчәнлеген шулай ук Идел буе дәүләт технология универститеты, Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан техник университеты, Казан дәүләт аграр университеты һәм башкалар гамәлгә ашыра. Урман кишәрлекләренең исемлеге (сынаулык мәйданчыклары, уку-тәҗрибә полигоннары һ.б.ш.) «Татарстан Республикасы урман хуҗалыгының тәҗрибә һәм тәҗрибә-хуҗалык объектларын инвентарьләштерү» җыентыгында (Казан, 1993) бирелгән. Фәнни-тикшеренү эшләре алып барыла торган кишәрлекләр урманчылыкларның регламентларында билгеләп куелган.

Урманны саклау, яклау һәм карау гамәлләре исемлеге һәм күләме һәм урман хуҗалыгының башка чаралары урманнарны үзләштерү проектларында билгеләнәчәк.

### 1.4.1.6. Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану

Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урман кишәрлекләре дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә – даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, башка учреждениеләргә, оешмаларга һәм затларга арендага тапшырыла.

Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелә торган урман кишәрлекләренең зурлыкларын билгеләгәндә, урман утыртмаларына һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян салу шартлары үтәлгән очракта, әлеге эшчәнлекнең урман экосистемасына артып китмәгән рекреацион йөкләнеше белән җитәкчелек итәргә кирәк.

Урман булган һәр район өчен урман мәйданнарына рөхсәт ителә торган рекреацион йөкләнеш нормалары («Урманнарны таксацияләү өчен гомумсоюз нормативлары», ул СССР Дәүләт урман комитетының 1989 елның 28 февралендәге 38 номерлы боерыгы белән расланган) (100 га мәйданга кеше саны), ВО «Леспроект» мәгълүматлары буенча, 1.4.1.6.1 нче таблицада китерелде.

1.4.1.6.1 нче таблица

**Рөхсәт ителә торган рекреацион йөкләнеш нормалары**

| Урман тибы | РФ Европа өлешенең көньяк-тайга районы | | | РФ Европа өлешенен ылыслы-киң яфраклы урманнары районы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | туризм | экскурсияләр | күпләп ял итү | туризм | экскурсияләр | күпләп ял итү |
| Лишайниклы наратлыклар,ак мүкле чыршылыклар, ак мүкле каенлыклар | 5 | 40 | 10 | 5 | 40 | 10 |
| Көртмәлекле, күке җитене мүге җәелгән, | 10 | 80 | 20 | 20 | 120 | 30 |

| Урман тибы | РФ Европа өлешенең көньяк-тайга районы | | | РФ Европа өлешенең ылыслы-киң яфраклы урманнары районы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | туризм | экскурсияләр | күпләп ял итү | туризм | экскурсияләр | күпләп ял итү |
| кара җиләкле, кара җиләкле-вак үләнле, елга буе-үләнле наратлыклар, елга буе-эре үләнле каенлыклар һәм усаклыклар | | | | | | |
| Кара җиләкле наратлыклар, куян кузгалаклы, куян кузгалаклы-вак үләнле чыршылыклар, көртмәлекле-күрәнле каенлыклар | 30 | 200 | 50 | 40 | 280 | 70 |
| Куян кузгалаклы, куян кузгалаклы-киң үләнле наратлыклар, куян кузгалаклы-вак үләнле, кара җиләкле-вак үләнле, кара җиләкл-киң үләнле каенлыклар һәм усаклыклар | 60 | 400 | 10 | 80 | 520 | 130 |
| Куян кузгалаклы-кин үләнле каенлыклар һәм усаклыклар | 90 | 600 | 150 | 120 | 800 | 200 |

Территорияне рекреацион эшчәнлек зоналарына функциональ бүлү республикада урманнарны тәртипкә салганда башкарылмады.

Урманнардан файдаланучы затлар ял, туризм оештыру, физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрү максатларында туристлык сукмакларын һәм трассаларын сала, туристлык станцияләрен оештыра, мәдәни-гаммави чаралар үткәрә, җәяү, велосипедта, чангыда һәм атларда (атланып һәм/яисә арбага утырып) йөри, рәсем сәнгате дәресләрен, өйрәнү һәм экологик экскурсияләрне, спортның урманда үткәрү өчен туры килгән аерым төрләре буенча спорт ярышларын, физкультура-спорт фестивальләрен һәм тренировка җыеннарын оештыра алалар, шулай ук рекреацион эшчәнлекне оештыруның башка төрләрен куллана алалар.

Рекреацион эшчәнлекне республиканың максатчан билгеләнеше теләсә нинди булган барлык урманнарында 3,5 мең га мәйданда гамәлгә ашырырга мөмкин.

Рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен объектлар (физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм спорт-техник корылмалар) төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү күз алдында тотылган урманнарны планлаштырыла торган үзләштерү зоналары 1.4.1.6.2 нче таблицада китерелде.

1.4.1.6.2 нче таблица

**Урманнарны планлаштырыла торган үзләштерү зоналары**

| № т/с | Урманчылык исеме | Участок урманчылыгы исеме | Кварталларның номерлары | Мәйдан, га |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Азнакай | Мәлбагыш | 1 | 0,08 |
| | | Азнакай | 148 | 3,8 |
| | | | 148 | 4,7 |
| | | | 146 | 4,75 |
| | Барлыгы: | | | 13,33 |
| 2. | Әлмәт | Поташ Аланы | 134 | 10 |
| | | | 119, 120, 134, 135 | 69,1 |
| | | | 114 | 11,32 |
| | | | 155, 156 | 15,86 |
| | | | 114 | 14,5 |
| | | | 5 | 13 |
| | | | 134 | 11,8 |
| | | | 155, 156 | 13,09 |
| | | | 114 | 4,54 |
| | Барлыгы: | | | 163,21 |
| 3. | Лубян | - | 113 | 1,83 |
| | | | 113 | 0,14 |
| | | | 39 | 0,5 |
| | Барлыгы: | | | 2,47 |
| 4. | Түбән Кама | Баграж | 2, 90 | 6,3 |
| | | | 2 | 0,93 |
| | | | | 7,23 |
| 5. | Шәһәр яны | Матюшино | 71 | 1,5 |
| | | Матюшино | 11 | 10,28 |
| | | Биектау | 60 | 36,0 |
| | Барлыгы: | | | 47,78 |
| | Барлыгы: | | | 234,02 |

### 1.4.1.7. Урман плантацияләрен булдыру өчен урманнардан файдалану һәм аларны эксплуатацияләү

Урман эшкәртү предприятиеләрен чимал белән тәэмин итү өстенлекле бурыч булып тора. Чималның житәрлек дәрәҗәдә булмавы урманнардан файдалануны һәм урманнар үстерүне оештыруга яңа юнәлешләр кертүне таләп итә. Урман плантацияләрен булдыру мондый юнәлешләрнең берсе булып тора.

Урман плантацияләрен булдыру һәм аларны эксплуатацияләү билгеле бер махсус токымнарның урман утыртмаларын, аларга алдан уйлап куелган үзлекләр хас үзагач алуны тәэмин итә торган ясалма үстерелгән урман утыртмалары керә, үстерү белән бәйле эшкуарлык эшчәнлеген тәшкил итә.

Урман плантацияләре урман фондының түбәндәге төр җирләрендә булдырылырга мөмкин:

– урман үсемлекләре белән капланмаган (киселгән, янган урыннар, аланлыклар һ.б.);

– урман каплаган (тоташтан кисү өчен билгеләнгән урман кишәрлекләре һәм реконструкцияләнергә тиешле аз кыйммәтле утыртмалар кишәрлекләре);

– урманныкы булмаган җирләрнең аерым категорияләрендә (печән чабу җирләре һ.б.).

Урман плантацияләрендә урман утыртмаларын кисү һәм киртләү эшләрен башкаруга бернинди чикләүләр дә юк.

Табигать һәм башка объектларны яклау функцияләрен башкара торган су саклау зоналарында урнашкан урманнардан, кыйммәтле урманнардан һәм махсус саклагыч кишәрлекләрдә урнашкан урманнардан файдаланып урман плантацияләрен булдыру рөхсәт ителми.

Урман плантацияләрен булдыруны һәм аларны эксплуатацияләүне 3,2 мең га мәйданда башкарырга мөмкин.

Хәзерге вакытта агач эшкәртү предприятиеләре агач чималын төп кулланучылар булып торалар. Алар эшкә яраклы үзагачны гына түгел, ә утын булырлык үзагачны да кулланалар. Чимал чыганагы төп проблема булып кала. Мондый предприятиеләр янәшәсендәге кисү өчен билгеләнгән урман фонды тулысынча үзләштерелгән.

Ерак урнашкан кишәрлекләрдән яисә башка регионнардан чимал кайтарту продукциянең кыйммәтләнүенә китерә. Килеп туган хәлдән чыгу юлларының берсе – экстенсив урман үстерүдән интенсив урман үстерүгә күчү. Утыртмаларны плантация тибында үстерү тармакны интенсивлаштыру юнәлешләренең берсе булып тора.

Урман плантацияләрен зур мәйданнарда булдыру өчен нәтиҗәле инвестицияләр кертү белән кызыксынган урман эшкәртүче эре предприятиеләрне җәлеп итәргә кирәк.

Урманнарны максатчан үстерү объектларын урнаштыру кертелгән акчаларның кире кайтуына, аларның тиз арада файда китерә башлавына ярдәм итәчәк, экологик һәм социаль әһәмияткә ия булачак.

Плантацияләрне проектлау һәм аларга нигез салу табигый урманнарны яклау, торгызу һәм саклап калу бурычларын үтәүгә ярдәм итәргә тиеш, әмма табигый урманнарга тискәре йогынты ясарга, аны тагын да көчләләндерергә тиеш түгел.

Плантацияләрне планлаштырганда, урман хуҗалыгы гамәлләренең масштабыннан чыгып, төрле еллык һәм төрле вакытларда киселәчәк утыртмалар булдыру күз алдында тотыла. Плантацияләрнең зурлыгы һәм янәшә урнашуы җирле ландшафтка хас табигый урман утыртмаларының характерына туры килергә тиеш.

Урманнарның икътисадый, экологик һәм социаль тотрыклылыгын арттыру өчен составлары төрле булган агачлыклар булдыруга өстенлек бирелә. Төрлелек карала торган ландшафт чикләрендә хуҗалык бүлемтекләренең зурлыкларындагы аермада һәм пространствода бүлеп куелуында, агачлыклар төрләренең санында һәм генетик составында, яшь классларында һәм структурасында чагылыш табарга мөмкин.

Плантацияләр булдыру өчен агач токымнарын сайлап алганда үсү урыны шартларына һәм авыл хуҗалыгын алып бару максатларына аларның туры килү

дәрәҗәсе исәпкә алына. Начарлана башлаган урман утыртмаларының биологик төрлелеген плантацияләрне проектлаганда һәм торгызганда саклап калу өчен өстенлек, читтән кертеп җайлаштырылганнар, ягъни интродуцентлар белән чагыштырганда, җирле төрләргә бирелергә тиеш. Интродуцентлар, продуктивлыгы һәм экологик кыйммәте югарырак булган очракта, җирле төрләрне алмаштыра алалар һәм яфракларның табигый булмаган коелуын, корткычларның, авыруларның кинәт килеп чыгуын һәм башка тискәре экологик нәтиҗәләрне үз вакытында ачыклау максатыннан җитди тикшерелеп торырга тиеш.

Туфракларның структурасын, уңдырышлылыгын һәм биологик активлыгын саклап калу һәм яхшырту буенча чаралар күрергә кирәк. Кулланыла торган технологияләр, урман хәзерләү күләмнәре, юллар һәм сөйрәмә җирләр төзү һәм эксплуатацияләү, шулай ук плантацияләр булдыру өчен агач токымнарын сайлап алу озак еллардан соң туфракларның начарая баруына, су сыйфатының начарлануына һәм су күләме үзгәрүгә яисә гидрологик режимның нык үзгәрүенә китерергә тиеш түгел.

Плантацияләрне үстергәндә корткыч бөҗәкләрнең саны артып китүне, авырулар таралуны һәм янгыннарны кисәтү һәм туктатып калу буенча чаралар күрелергә тиеш. Корткычлар белән көрәшү чаралары комплексы урман хуҗалыгы чаралары планында каралган булырга тиеш, шул ук вакытта өстенлек, химик пестицидлар һәм ашламалар куллану белән чагыштырганда, алар белән көрәшүнең профилактик һәм биологик алымнарына бирелергә тиеш.

Плантацияләргә мониторинг ясауны планлаштырырга кирәк, ул исә авыл хуҗалыгы гамәлләре нәтиҗәсендә урман хуҗалыгы предприятиесе территориясендә дә, шулай ук аннан читтә дә барлыкка килергә мөмкин тискәре экологик һәм социаль нәтиҗәләргә (мәсәлән, табигый яңару, су ресурсларына һәм туфракның уңдырышлылыгына йогынты ясау, социаль тәэминат системасына һәм җирле халыкның иминлегенә тискәре йогынты ясау) даими бәя биреп торуны үз эченә алырга тиеш. Мониторинг масштаблары урман хуҗалыгы чараларының масштабыннан һәм спектрыннан чыгып билгеләнә.

### 1.4.1.8. Урман җимеш, җиләк, декоратив һәм дару үсемлекләрен үстерү өчен урманнардан файдалану

Урман җимеш, җиләк, декоратив һәм дару үсемлекләрен үстерү өчен урман фонды җирләре составыннан урман булмаган җирләр; урманнар яңадан үсмәгән урман киселгән җирләр, аланлыклар һәм урман үсемлекләре белән капламаган башка җирләр, аларда урман культураларын булдырганчы урманның яңаруы мөмкин түгел, шулай ук рекультивацияләнергә тиешле җирләр файдаланыла. Реконструкцияләнүе планлаштырылмый торган аз кыйммәтле утыртмалар кишәрлекләрен файдалану максатка ярашлы булыр дип уйланыла.

Җирләрне сөргәндә урман җимеш, җиләк, декоратив һәм дару үсемлекләрен үстерү рөхсәт ителми.

Саклагыч урманнарны һәм урманнарның махсус саклагыч кишәрлекләрен, Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләрен урман җимеш, җиләк, декоратив һәм дару үсемлекләрен үстерү өчен файдалану тыела.

Эшчәнлекнең әлеге төре Татарстан Республикасында максатка ярашлы түгел.

**1.4.1.9. Җир асты байлыкларын геологик тикшерү эшләрен башкару һәм файдалы казылмалар күпләп таралган урыннарыннан аларны чыгару өчен урманнардан файдалану**

Җир асты байлыкларын геологик тикшерү эшләрен башкарганда һәм файдалы казылмалар күпләп таралган урыннарыннан аларны чыгару эшләрен башкарганда кирәкле объектларны урнаштыру максатларында, иң элек, урман булмаган җирләр, ә урман кишәрлегендә мондый җирләр булмаса – яңарып өлгермәгән агач киселгән, янгын булган, буш урыннар, аланлыклар, шулай ук сирәк кенә бик үк кыйммәтле булмаган урман утыртмалары үсә торган мәйданнар файдаланыла.

Күрсәтелгән максатлар өчен башка урман кишәрлекләреннән файдалану җир асты байлыкларын геологик тикшерү эшләрен башкарганда һәм файдалы казылмалар күпләп таралган урыннарыннан аларны чыгару эшләрен башкарганда кирәкле объектларны урнаштыру өчен башка вариантлар булмаган очракта рөхсәт ителә.

Яшел зоналарда, урман-паркларда һәм фәнни, тарихи әһәмияткә ия урманнарда файдалы казылмалар күпләп таралган урыннарыннан аларны чыгару тыела.

Җир асты байлыкларын геологик тикшерү эшләрен башкару, файдалы казылмалар күпләп таралган урыннарыннан аларны чыгару өчен 8,3 мең га мәйданда урманнардан файдаланырга мөмкин.

**1.4.1.10. Сусаклагычлар һәм бүтән ясалма су объектлары, шулай ук гидротехник корылмалар һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану**

Сусаклагычлар һәм бүтән ясалма су объектлары, шулай ук гидротехник корылмалар һәм махсуслаштырылган портлар төзү өчен дәүләт милкендәге урман кишәрлекләре юридик затларга – арендага, вакыты чикләнмәгән даими файдалануга һәм вакыты чикләнгән түләүсез файдалануга, гражданнарга арендага тапшырыла.

Сусаклагычлар һәм бүтән ясалма су объектлары, шулай ук гидротехник корылмалар һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү эшләрен башкарганда кирәкле объектларны урнаштыру максатларында, иң элек, урман булмаган җирләр, ә урман кишәрлегендә мондый җирләр булмаса – яңарып өлгермәгән агач киселгән, янгын булган, буш урыннар, аланлыклар, шулай ук сирәк кенә бик үк кыйммәтле булмаган урман утыртмалары үсә торган мәйданнар файдаланыла.

Тиешле эшләрне башкару срогы беткәннән соң гидротехник корылмалар су законнары нигезендә туктатып ябылырга яисә юкка чыгарылырга тиеш.

Сусаклагычлар һәм бүтән ясалма су объектлары, шулай ук гидротехник корылмалар һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен файдаланылган җирләр рекультивацияләнергә тиеш.

Эшчәнлекнең әлеге төрен 90 га мәйданда башкарып була.

### 1.4.1.11. Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану

Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен урман кишәрлекләре гражданнарга – арендага һәм вакыты чикләнгән түләүсез файдалануга, ә юридик затларга вакыты чикләнмәгән даими файдалануга, арендага һәм вакыты чикләнгән түләүсез файдалануга тапшырыла.

Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү максатларында, иң элек, урман булмаган җирләр, ә урман кишәрлегендә мондый җирләр булмаса – яңарып өлгермәгән агач киселгән, янгын булган, буш урыннар, аланлыклар, шулай ук сирәк кенә бик үк кыйммәтле булмаган урман утыртмалары үсә торган мәйданнар файдаланыла.

Күрсәтелгән максатлар өчен башка урман кишәрлекләреннән файдалану линияле объектларны урнаштыру өчен башка вариантлар булмаган очракта рөхсәт ителә.

Электртапшыргыч линияләр, элемтә линияләре, юллар, үткәргеч торбалар һәм башка линияле объектлар төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен 17,8 мең га мәйданда урманнардан файдаланырга мөмкин.

### 1.4.1.12. Үзагач һәм бүтән урман ресурсларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану

Үзагач һәм бүтән урман ресурсларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану урман материалларын һәм эшкәртү нәтиҗәсендә алынган бүтән продукцияне җитештерүгә бәйле эшкуарлык эшчәнлеген күз алдында тота.

Үзагач һәм бүтән урман ресурсларын эшкәртү өчен урман кишәрлекләре гражданнарга һәм юридик затларга арендага бирелә.

Үзагач һәм бүтән урман ресурсларын эшкәртү өчен арендага бирелгән урман кишәрлекләрендә урман эшкәртү инфраструктурасы төзелә.

Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын урнаштыру максатларында, иң элек, урман булмаган җирләр, ә урман кишәрлегендә мондый җирләр булмаса – яңарып өлгермәгән агач киселгән, янгын булган, буш урыннар, аланлыклар, шулай ук сирәк кенә бик үк кыйммәтле булмаган урман утыртмалары үсә торган мәйданнар файдаланыла.

Күрсәтелгән максатлар өчен башка урман кишәрлекләреннән файдалану урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен башка вариантлар булмаган очракта рөхсәт ителә.

Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын урнаштыру саклагыч урманнарда һәм урманнарның махсус саклагыч кишәрлекләрендә рөхсәт ителми.

Үзагач һәм бүтән урман ресурсларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану планлаштырылмый.

### 1.4.1.13. Дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану

Урман кишәрлекләре дини оешмаларга дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен вакыты чикләнгән түләүсез файдалануга бирелә.

Дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен бирелгән урман кишәрлекләрендә дини һәм хәйрия билгеләнешендәге биналар, төзелмәләр, корылмалар төзү рөхсәт ителә.

Дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру урман планында 18,95 га мәйданда планлаштырыла.

Урман планын гамәлгә ашыру барышында санап кителгән файдалану төрләре буенча урманнардан файдалану, файдаланучылар барлыкка килгәннән соң, Россия Федерациясе Урман кодексы һәм урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентлары нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.

### 1.4.2. Татарстан Республикасы урманнарының экологик, санитария-чистарту потенциалына характеристика

Урманның экологик потенциалы урман утыртмаларының су саклау, суны көйләү, эрозиягә каршы тору, климатны көйләү һәм санитария-гигиена функцияләре белән характерлана.

Урманның экологик потенциалы аларның мохит тудыруда тоткан урынына, техноген, рекреацион һәм башка йөкләнешләр булганда саклагыч үзлекләренә һәм компенсация мөмкинлекләренә нигезләнә. Экологик яктан тигезләшкән авыл хуҗалыгы җитештерүендә урман утыртмаларының стабильләштерү роле су һәм һава режимнарын көйләү, эрозияне булдырмый калу, микроклимат шартларын яхшырту, халык яшәеше өчен уңайлы шартлар тудыру, агроландшафтларның эстетик һәм санитар-гигиеник үзлекләрен арттыру аша һәркемгә мәгълүм. Урманнарның экологик продуктивлыгының мөһим күрсәткечләренең берсе үзләрендә углеродны туплый алуларыннан гыйбарәт.

Углерод туплауны исәпләп чыгару нигезенә түбәндәгеләр алынды:

– урман хасил итүче төп токымнар үзагачының иң гади составы;

– урман үсемлекләре белән капланган мәйданны урман хасил итүче төп токымнар һәм агачлыкларның яшь төркемнәре буенча бүленүен бәяләү;

– урман хасил итүче төп токымнар һәм агачлыкларның яшь төркемнәре өчен кәүсә үзагачы запаслары белән агачлыкларның бөтен фитомассасы арасындагы нисбәтлелекне, фитомасса запасларындагы һәм ел саен йотыла торган углерод күләмендәге үзгәрешләрне бәяләү.

Углеродны иң яхшысы яшь агачлар йота, алар 300,5 мең га (25,6%) мәйдан алып тора. Алар йотыла торган углеродның гомуми күләменнән яртысыннан артыгын үзләрендә туплыйлар. Урта яшьтәге утыртмалар углеродны, яшь агачлар белән чагыштырганда, азрак туплыйлар, алар биләп торган мәйдан 415,4 мең га (35,5%) тәшкил итә. Өлгереп килүче, өлгергән һәм карт утыртмалар 454,9 мең га (38,8%) биләп торалар, алар углеродны начар йоталар.

Шулай итеп, экологик күзлектән караганда, яшь, актив үсә торган урманнар иң файдалы урманнар булып тора, шуңа күрә өлгергән һәм карт агачларның күпләп туплануын булдырмаска кирәк. Әлеге нәтиҗә саклагыч урманнарның аерым категорияләрендә агачларны табигый өлгерү яшенә җиткәч кенә кисү зарурлыгына шик белән карата. Саклагыч урманнарның аерым категорияләре өчен экологик өлгерү яшен билгеләргә кирәк, ул әлеге утыртманың экологик нәтиҗәлелегенең максималь күрсәткече буенча билгеләнергә тиеш.

Урман саклагыч функцияләрне үтәп кенә калмыйча, эстетик функцияләр дә башкара.

Утыртмаларны бәяләү урман үсә торган төрле шартларда рөхсәт ителгән рекреацион йөкләнешләрнең бергә кушылган еллык нормаларын исәпкә алып башкарыла. Шул ук вакытта урманның матурлык коэффициенты һәм торак пунктларда яшел зоналарның булуы исәпкә алынырга тиеш.

Рекреация урманнары дип ял һәм туризм өчен файдаланыла торган табигать ресурслары атала.

Ландшафт урманнары, кагыйдә буларак, шәһәр урманнарының кеше күп йөри торган кишәрлекләрендә, шәһәр тирәсендәге яшел зоналарның урман-парк өлешләрендә була.

Ял, туризм, физкультура-сәламәтләнү һәм спорт эшчәнлеген оештыру максатларында рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен республика территориясендә ял базалары, шифаханәләр, курортлар бар.

Урманның рекреацион потенциалы дигәндә табигать ресурсларының күплеге күз алдында тотыла, һәм ул туризмда, ял көнендә ял итүдә һәм стационар ялда рекреацион махсуслашу өчен җирлек булдыра. Татарстан Республикасында хәзерге вакытта урман рекреация ресурсларының бүлеп карала торган барлык төркемнәрен һәм төрләрен булдыру өчен кирәкле табигать алшартлары бар.

Урманнарның экологик һәм санитар-чистарту потенциалын тәэмин итү һәм аңа ярдәм итү өчен янгынга каршы һәм санитар кагыйдәләрне үтәргә, эшләрне туфрак эрозиясе барлыкка килүне булдырмый торган һәм алга таба җәелдерми торган ысуллар белән башкарырга, табигать ресурсларын дөрес файдалану һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча мәҗбүри планнарны һәм чараларны үтәү буенча эшчәнлек алып барырга, табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә законнарны, кагыйдәләрне һәм нормативларны үтәргә кирәк.

### 1.4.3. Татарстан Республикасының үзагачка һәм башка урман ресурсларына еллак ихтыяҗы, аны канәгатьләндерү дәрәҗәсе (әзерләү һәм куллану күләмнәре нисбәте)

Татарстан Республикасы урманчылыкларында үзагач әзерләүнең максималь күләме урман кичү өчен исәпләнгән мәйданның зурлыгы белән билгеләнә (2007 елда – тулаем ТР буенча 1,78 млн. $м^3$ ликвид үзагач, 2012 елда – 2231,1 млн. $м^3$ , 2013 елда – 2,39 млн. $м^3$).

2007 елда урман кичү өчен исәпләнгән кишәрлекләр 21,7%, 2012 елда – 31% үзләштерелде.

1.4.3.1 нче таблица

**Урманнардан файдалану күрсәткечләре динамикасы, аны оештыруга бәя**

(мең $м^3$ ликвид)

| Күрсәткечләр | Исәп берәмлеге | 2007 ел | 2012 ел | (2012 елга карата динамика) |
|---|---|---|---|---|
| Урман кичү өчен исәпләнгән мәйдан | мең $м^3$ | 1785,8 | 2231,1 | +445,3 |
| Чынбарлыкта киселгән (барлыгы) | мең $м^3$ | 388,6 | 748,16 | +359,56 |

| Күрсәткечләр | Исәп берәмлеге | 2007 ел | 2012 ел | (2012 елга карата динамика) |
|---|---|---|---|---|
| шул исәптән | | | | |
| ылыслылар | мең $м^3$ | 65,4 | 235,08 | +169,68 |
| каты яфраклылар | мең $м^3$ | 124,9 | 27,6 | -97,3 |
| йомшак яфраклылар | мең $м^3$ | 1595,5 | 485,48 | -1110,02 |
| Сирәкләп кисүләр | га | 571,0 | 20278 | 19707 |
| Тоташтан кисүләр | га | 1886,6 | 2273 | +386,4 |
| Барысы | га | 2457,6 | 22551 | +20093,4 |
| Урман кисү өчен исәпләнгән кишәрлекләрдән файдалану | | | | |
| ылыслылар | % | 67,4 | 68 | +0,6 |
| каты яфраклылар | % | 8,2 | 19 | +10,8 |
| йомшак яфраклылар | % | 20,4 | 25 | +4,6 |
| Барлыгы | % | 21,7 | 31 | +9,3 |

Өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын кисү өчен исәпләнгән кишәрлекләр 2006 елга Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы буенча 1703,9 мең $м^3$ күләмендә билгеләнгән иде һәм Россия урман хуҗалыгының 2006 елның 28 апрелендәге 98 номерлы боерыгы белән расланган иде. 2007 елга урман кисү өчен исәпләнгән кишәрлекләрнең мәйданы, урманнарны тәртипкә салуны исәпкә алып, үзгәртелде һәм 1785,8 мең $м^3$ күләмендә Россия урман хуҗалыгының 2006 елның 13 декабрендәге 312 номерлы боерыгы белән расланды.

2007 елда фактта 388,6 мең $м^3$ (ликвидта) әзерләп куелды.

2007 елда урман кисү өчен исәпләнгән кишәрлекләр 21,7% ка файдаланылды, шул исәптән ылыслы хуҗалык буенча – 67,4%, каты яфраклы хуҗалык буенча – 8,2%, йомшак яфраклы хуҗалык буенча – 20,4%.

2012 елда урман кисү өчен исәпләнгән кишәрлекләр 31% ка файдаланылды, шул исәптән ылыслы хуҗалык буенча – 68%, каты яфраклы хуҗалык буенча – 19%, йомшак яфраклы хуҗалык буенча – 25%.

### 1.4.4. Үзагачны һәм башка урман ресурсларын төп әзерләүчеләр һәм кулланучылар, үзагач һәм башка урман ресурсларын әзерләү өчен урманнарны урман һәм урман эшкәртү инфраструктурасын төзеп үзләштерүнең инвестиция проектлары

Республикада үзагачны төп кулланучылар һәм әзерләүчеләр:

– республиканың урман эшкәртүче эре предприятиеләре – «ПФМК» эшчеләр ЯАҖ (НП) һәм «ЗФЗ» ААҖ.

– республиканың урман әзерләүче һәм урман эшкәртүче урта предприятиеләре, шул исәптән утыз ике «Урман» дәүләт бюджет учреждениесе.

– республика шәһәрләрендә һәм районнарында урман эшкәртүче күпсанлы вак һәм урта, шулай ук мебель ясау предприятиеләре.

Түбәндәге инвестиция проектларының бизнес-планнары эшләнә:

– «Нур-Массив» ААҖнең «Агач эшкәртү производствосын төзү». Проектта урман һәм урман эшкәртү сәнәгате базарында югары куллану характеристикаларына ия агач эшкәртү продукциясенең югары рентабельле төрләрен эшләп чыгару (ылыслы агач токымнарыннан такталыклар, яфраклы һәм ылыслы агач токымнарыннан ярдырылган такта, җилем белән ябыштырылган борыс), агач өйләр салу һәм экологик чиста ягулык төрен – пеллетлар җитештерү карала.

– «Җилем белән ябыштырылган модуль конструкцияләрдән йорт төзү комбинаты» ЯАҖнең «WWCB плитәләрен җитештерү өчен икеләтә бүленешле IV фазасы автоматлаштырылган WWCB заводы (Алабуга ш.). Әлеге проектны гамәлгә ашыру кыйммәт булмаган социаль торак төзү өчен фибролит производствосын ачуны һәм аз керемле халык катламының торакка ихтыяҗын канәгатьләндерүне тәэмин итәчәк.

– «НП «ПФМК» ЯАҖнең «Татарстан Республикасының урман чималы ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану», ул урман кисү өчен исәпләнгән кишәрлекләрнең үзләштерелүен һәм Арча, Зеленодольск, Кызыл Йолдыз, Лаеш, Мамадыш һәм Саба урманчылыкларында урман эшкәртү комплексларын төзүне күз алдында тота.

– «ЗФЗ» ААҖнең «Кама урманчылыгының урман сәнәгате комплексын озак вакытка арендалау хокукында эшләтү». «Кама урман хуҗалыгы +» ҖЧҖнең Кама урманчылыгы территориясендә урман фондын арендалау һәм европа сыйфатларына туры килә торган продукцияне агачны калдыксыз эшкәртеп җитештерүне оештыру (погонаж, вагонка, идән рейкасы, фанера, ягулык гранулалары).

### 1.4.5. Аучылык хуҗалыгын оештыруга характеристика (аучылык җирләренең булуы һәм аларның торышы, өйрәнелеше һәм файдаланылуы, аучылык инфраструктурасы, шулай ук аучылык ресурсларын саклау зоналары чикләре)

Урманнардан комплекслы файдалануга аучылык хуҗалыгы кыргый хайваннарның үрчүенә дөрес идарә итү һәм ел саен продукция алу рәвешендә үзеннән өлеш кертә.

Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы бик бай. Монда имезүче хайваннарның 60 артык төре, кошларның 270 артык төре, балыкларның 50 якын төре бар.

Республика аучылык җирләренең гомуми мәйданы 6537,5 мең га тәшкил итә.

1.4.5.1 нче таблица

### Татарстан Республикасыныңаучылык хуҗалыгы алып бару һәм ау өчен файдаланыла торган территорияләренең структурасы

| № т/с | Район | Район мәйданы, мең га | Аучылык хуҗалыгы алып бару һәм ау өчен файдаланыла торган территорияләр | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Беркетелгән территорияләр | Дәүләт аучылык заказниклары | Һәркем файдалана алырлык аучылык биләмәләре | Барлыгы, мең га | Район мәйданыннан өлеш, % |
| 1 | Әгерҗе | 179,662 | 95,2 | 30,9 | 53,562 | 179,662 | 100 |
| 2 | Азнакай | 214,611 | 60,47 | 0 | 149,992 | 210,462 | 98,07 |
| 3 | Аксубай | 143,916 | 90,3 | 7,02 | 46,596 | 143,916 | 100 |
| 4 | Актаныш | 203,400 | 203,4 | 0 | 0 | 203,4 | 100 |
| 5 | Алексеевск | 207,441 | 26,947 | 3,52 | 176,974 | 207,441 | 98,26 |
| 6 | Әлки | 172,676 | 100,514 | 0 | 72,162 | 172,676 | 100 |
| 7 | Әлмәт | 242,794 | 200,662 | 0 | 42,132 | 242,794 | 100 |
| 8 | Апас | 104,752 | 99,4 | 0 | 0 | 99,4 | 94,89 |
| 9 | Арча | 184,365 | 177,049 | 6,9 | 0 | 183,949 | 99,84 |
| 10 | Әтнә | 68,136 | 68,136 | 0 | 0 | 68,136 | 100 |
| 11 | Баулы | 120,466 | 0 | 0 | 120,466 | 120,466 | 100 |
| 12 | Балтач | 109,450 | 102,85 | 6,6 | 0 | 109,45 | 100 |
| 13 | Бөгелмә | 140,520 | 115,1 | 0 | 25,42 | 140,52 | 100 |
| 14 | Буа | 152,845 | 152,845 | 0 | 0 | 152,845 | 100 |
| 15 | Югары Ослан | 130,282 | 93,995 | 23,7 | 0 | 117,695 | 90,34 |
| 16 | Бисктау | 157,425 | 98,33 | 0 | 58,146 | 156,476 | 99,40 |
| 17 | Чүпрәле | 102,954 | 17,3 | 0 | 85,654 | 102,954 | 100 |
| 18 | Алабуга | 135,229 | 96,2 | 0 | 21,328 | 117,528 | 86,91 |
| 19 | Зәй | 184,240 | 170,262 | 0 | 0 | 170,262 | 92,41 |
| 20 | Зеленодольск | 140,199 | 122,75 | 0 | 11,528 | 134,278 | 95,78 |
| 21 | Кайбыч | 99,536 | 78,012 | 0 | 21,524 | 99,536 | 100 |
| 22 | Кама Тамагы | 119,880 | 107,894 | 0 | 0 | 107,894 | 90,00 |
| 23 | Кукмара | 149,000 | 149 | 0 | 0 | 149 | 100 |
| 24 | Лаеш | 209,443 | 136,341 | 0 | 68,932 | 205,273 | 98,01 |
| 25 | Лениногорск | 181,272 | 151,5 | 0 | 29,672 | 181,172 | 99,94 |
| 26 | Мамадыш | 261,252 | 163,132 | 10,8 | 87,32 | 261,252 | 100,00 |
| 27 | Менделеевск | 74,490 | 74,49 | 0 | 0 | 74,49 | 100 |
| 28 | Минзәлә | 191,975 | 187,73 | 0 | 0 | 187,73 | 97,79 |
| 29 | Мөслим | 146,431 | 116,654 | 0 | 29,777 | 146,431 | 100 |
| 30 | Түбән Кама | 161,715 | 141,6 | 0 | 20,115 | 161,715 | 100 |
| 31 | Яңа Чишмә | 131,752 | 54,43 | 0 | 77,322 | 131,752 | 100,00 |
| 32 | Нурлат | 229,371 | 59,2 | 2,36 | 167,811 | 229,371 | 100 |

| № т/с | Район | Район мәйданы, мең га | Аучылык хуҗалыгы алып бару һәм ау өчен файдаланыла торган территорияләр | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Беркетелгән территорияләр | Дәүләт аучылык заказниклары | Һәркем файдалана алырлык аучылык биләмәләре | Барлыгы, мең га | Район мәйданыннан өлеш, % |
| 33 | Питрәч | 133.954 | 100,364 | 32.3 | 0 | 132,664 | 99.04 |
| 34 | Балык Бистәсе | 204.141 | 125,159 | 44.465 | 27,619 | 197,243 | 96.62 |
| 35 | Саба | 109.774 | 103,677 | 6,097 | 0 | 109,774 | 100 |
| 36 | Сарман | 138.556 | 43,5 | 0 | 95,056 | 138,556 | 100 |
| 37 | Спас | 202.214 | 99,87 | 0 | 102.344 | 202,214 | 100 |
| 38 | Тәтеш | 163.842 | 112,552 | 0 | 46,879 | 159,431 | 97.31 |
| 39 | Тукай | 172.949 | 57,417 | 0 | 103,57 | 160,987 | 93.08 |
| 40 | Теләче | 84,408 | 30,761 | 50.538 | 0 | 81,299 | 96.32 |
| 41 | Чирмешән | 136.428 | 62,138 | 0 | 74.29 | 136,428 | 100 |
| 42 | Чистай | 176.567 | 74,05 | 0 | 102.517 | 176,567 | 100 |
| 43 | Ютазы | 76,057 | 72,41 | 0 | 0 | 72,41 | 95,2 |
| 44 | Район составына кермәгән шәһәр муниципаль берәмлекләре | 133,374 | | | - | | |
| БАРЛЫГЫ | | 6783,744 | 4393,591 | 225.2 | 1918,708 | 6537,499 | 96,88* |

* –Татарстан Республикасы мәйданыннан өлеш

1.4.5.2 нче таблица

### Ау белән шөгыльләнергә ярамый торган территорияләр

| № т/с | Махсус саклана торган табигать территориясенең атамасы | Муниципаль район | Мәйдан, гектар |
|---|---|---|---|
| 1 | «Чатыр-Тау» төбәк әһәмиятендәге комплекслы профильле дәүләт табигать заказнигы | Азнакай | 4149,5 |
| 2 | «АюУрманы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле | Арча | 416,2 |
| 3 | «Түбән Кама» милли паркы | Алабуга | 17701,0 |
| | | Тукай | 8951,0 |
| 4 | Идел-Кама биосфералы дәүләт табигать тыюлыгы | Зеленодольск | 5921,0 |
| | | Лаеш | 4170,0 |
| 5 | «Щучьи горы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле | Тәтеш | 4010,66 |
| 6 | «Долгая поляна» төбәк әһәмиятендәге комплекслы профильле дәүләт табигать заказнигы | | 400,1 |
| БАРЛЫГЫ | | | 45719,46 |

Татарстан Республикасының башка махсус саклана торган табигать территорияләренсаклау режимы аучылык ресурсларын теге яки бу дәрәҗәдә файдалануны рөхсәт итә.

Татарстан Республикасының ау хайваннары фаунасы урман-дала өчен характерлы. Монда аюлар һәм селәүсеннәр, шулай ук дала өчен типик җәнлекләр – чуар йомран, зур кушаяк, дала чуар күбәләге, сөркә, күзсез тычкан һәм соры әрлән очрый. Хайваннарның бер өлеше тайга фаунасына карый, аның үзәген поши, кыр тычканы, борындык тәшкил итә. Бу төркемгә шулай ук аккуян, очкалак тиен, ас керә. Көньяк тайга фаунасына кошлардан суер, божыр, ала чумгалак, карчыга ябалак, йонлы аяклы чырайсыз ябалак, өч бармаклы тукран һәм кара тукран, чыршы чукыры, корташар, балан чыпчыгы, сызгырак чыпчык керә. Свиязь үрдәге, лачын-дерябник, елак карчыга, аерымланган кишәрлегенең көртлек, суер, божыр һ.б. төньяк тайга кошлары булып торалар. Көньякта яши торган төрләр чагыштырмача аз. Республика территориясендә җофар, гигант кичке ярканат, кушаяк, чуар йомран, соры әрлән, үр куяны, дала көзәне, сөркә-байбак; кошлардан – кече күлбога, елан карчыгасы, шөпшәашар, тилгән, болын карчыгасы һ.б. очрый.

Кызыл китапка кертелгән төрләр: җофар (Desmana moschata), аккойрык бөркет (Haliaeetus albicilla), чыелдык каз (Anser erythropus), каракош (Aquila chyrysaetos), зур кроншнеп (Numenius arquatus) һ.б.

Җәнлекләрнең төп аучылык-сунарчылык төрләре: поши (Alces alces), кабан (Sus scrofa), болан-кәҗә (Capreolus capreolus), селәүсен (Felis lynx), бүре (Canis lupus), төлке (Vulpes vulpes), бурсык (Meles meles), янутсыман эт (Nyctereutes procyonoides), аакуян (Lepus timidus), үр куяны (Lepus europaeus), ондатра (Ondatra zibeticus), тиен (Sciurus vulgaris), сусар (Martes martes), кондыз (Castor fiber) (яңа климатка яраклашкан). Ләкин ау хайваннарының кайбер төрләренең саны бик аз.

Аучылык кәсебенең төп кошлары: суер (Tetrao urogallus), көртлек (Lyrurus tetrix), божыр (Tetrastes bonasia), кыр үрдәге (Anas platyrhynchos), алмабаш чүрәкәй (Anas querquedula), сыбызгы чүрәкәй (Anas crecca), свиязь (Anas penelope), кызыл башлы чумгалак (Aythya ferina), киң борын (Anas clypeata), тәлләтәвеч (Scolopax rusticola), чуллык (Gallinago gallinago), урман үрдәге (Gallinago media) (очкан вакытта аулау), бытбылдык (Coturnix coturnix), соры көртлек (Perdix perdix).

Татарстан Республикасының аучылык җирләрендә яши торган кыргый җанварлар һәм кошлар барысы бергә Дәүләт аучылык фондын тәшкил итә, алардан Татарстан Республикасы территориясендә аучылык кагыйдәләрен үтәп кенә файдалану рөхсәт ителә.

Кыргый хайваннар һәм кошлар яши торган, аучылык белән шөгыльләнергә мөмкинлек булган җир мәйданнары, урманнар һәм сулыклар аучылык җирләре булып тора.

Аучылык кәсебе җанварларына һәм кошларына фаунаның аучылык объекты булып торучы һәм ит, тире, йон рәвешендә продукция алу өчен файдаланыла торган төрләре керә. Җирле фаунаның кайбер төрләре аучылык кәсебе өчен үз мәгънәсен югалтты, сирәк очрый яисә бетеп баралар. Хайваннар дөньясын саклап калу максатларында, Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы

Кызыл китабына кертелгән сирәк очрый торган һәм бетү куркынычы янаган кыргый җанварларны һәм кошларны аулау тыела.

Аучылык объекты булган хайваннардан һәм аларның яшәү тирәлегеннән файдалануның, аларны саклауның һәм үрчетүнең хокукый нигезләре «Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклап калу һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясе Урман кодексында, Россия Федерациясенең башка законнарында һәм норматив-хокукый актларында билгеләнгән. Дәүләткә һәм иҗтимагый оешмаларга карый торган җирләрдә аучылык белән шөгыльләнү бу оешмаларның язмача рөхсәтләре белән генә башкарыла. Оешмаларга беркетелмәгән җирләрдә аучылык итү аучылык хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органнары тарафыннан җайга салына. Тыюлыклар, заказниклар һәм яшел зоналар территорияләрендә аучылык итү тыела.

Татарстан Республикасы территориясендә аучылык хуҗалыкларының түбәндәге категорияләре эшли:

– төрле милек рәвешләрендәге юридик затларга беркетелгән аучылык хуҗалыклары;

– дәүләт аучылык заказниклары;

– оешмаларга беркетелмәгән һәм һәркем файдалана алырлык аучылык биләмәләре;

– торак пунктларның яшел зоналары (аучылык рөхсәт ителми торган җирләр).

Аучылык хуҗалыгын алып бару әйләнә-тирә мохиткә, табигать ресурсларына, кеше сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян китерми торган ысуллар белән башкарылырга һәм түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

– җәмгыятьнең аучылык продукциясенә ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен аулау ресурсларыннан өзлексез, запасларга зыян китермичә файдалануны;

– аулана торган җәнлекләрне үрчетүне, аучылык җирләренең сыйфатлы һәм продуктив булуына ирешүне, шулай ук аулау ресурсларын саклауны;

– биологик төрлелекне саклап калуны.

Аулана торган җәнлекләрдән нәтиҗәле файдалануны, аларны саклауны һәм үрчетүне, аларның яшәү мохитен саклап калуны һәм торгызуны оештыру, шулай ук сан һәм сыйфат ягыннан үзгәрешләрне ачыклау өчен бу җәнлекләр дәүләт тарафыннан исәпкә алына. Ау җәнлекләреннән законнарда билгеләнгән тәртиптә озак вакыт дәвамында файдаланучы юридик затлар, Федераль законнар нигезендә билгеләнгән кагыйдәләр буенча, ел саен аларның исәбен алалар һәм аулау күләмен исәплиләр.

Аучылык жирләрен саклау – аучылык хуҗалыгы эшчәнлегенең иң мөһим өлеше. Аулау ресурсларын саклауны оештыруның рациональ булмавы, контрольсез аучылык итү фактлары аучылык хуҗалыгы үсешен тоткарларга мөмкин.

Аучылык хуҗалыкларын оештыру һәм үстерү чараларын җентекләп эшләү һәм оештыру өчен урман эшләре башкарырга кирәк. Комплекслы эшләр нәтиҗәсендә һәр хуҗалыкның паспорты төзелә, анда аучылык җирләренең, фондның табигате һәм икътисадый шартлары, аучылык хуҗалыгын оештыру һәм алып бару өчен тәкъдимнәр кертелә.

Аучылык хуҗалыклары төрләре. Аучылык җирләре һәм кыргый хайваннар, кошлар җыелмасыаучылык хуҗалыгын оештыруның һәм үстерүнең табигый ресурслары яисә күпләп таралган урыннары булып тора. Аучылык җире төрләре, бер-берсеннән нык аерылып тору белән бергә, кыргый хайваннарның азык табу, саклану һәм оялау шартларын үз эченә алган яшәү мохите турында кузаллау тудырырга тиеш. Урмандагы аучылык җирләрен төрләргә бүлүнең төп билгеләре агачларның яшенә, составына, алар үсә торган мәйданга һәм шартларга бәйле.

Аучылык жирләре урман (урманнар шул исәптән агачларның төрләре һәм яшьләре буенча төркемнәргә, ачык урман пространстволарына бүленә), кыр, ачык су өсте, сазлык жирләргә бүленә.

Республикада аучылык җирләренең төрләре буенча урман хуҗалыгын оештыру һәм алып бару материалларында теркәлгән урман фонды классификациясе«Аучылык һәм урманчылык хуҗалыкларын проектлау буенча техник күрсәтмәләр» нигезендә башкарылган һәм 1.4.5.3 нче таблицада бирелә.

Республиканың урман фонды территориясендә яфраклы (52,7%) һәм катнаш (26,4%) урманнар күбрәк, аларда поши, кабан дуңгызы, төлке, куян һәм башкалар яши.

1.4.5.3нче таблица

**Татарстан Республикасы урман фонды территориясенең аучылык җирләре төрләре буенча бүленеше**

| Аучылык жирләренә характеристика | Гомуми мәйдан, га | шул исәптән аучылык жирләре төрләре буенча: | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ылыслы урманнар | яфраклы урманнар | катнаш урманнар | аланнар, кисенделәр | басулар, көтүлекләр, печәнлекләр | сулыклар, сазлыклар |
| Яшь агачлар (1 – 20 яшьлек) | 198,1 | 54,8 | 93,8 | 49,6 | | | |
| Урта яшьтәге агачлар | 431,7 | 57,1 | 242,3 | 132,3 | | | |
| 40 елдан картрак агачлар | 536,1 | 88,7 | 307,1 | 140,3 | | | |
| Урманнарга карамаган һәм агачлар белән капланмаган жирләр | 54,6 | | | | 28,0 | 16,1 | 10,5 |
| Барлыгы | 1220,5 | 200,6 | 643,1 | 322,2 | 28,0 | 16,1 | 10,5 |
| % | 100 | 16,4 | 52,7 | 26,4 | 2,3 | 1,3 | 0,9 |

Аучылык җирләре бонитеты. Аучылык җирләренең һәр төре территориясендә хайваннар дөньясының шул җиргә генә хас вәкилләре яши. Бу җирләрнең аерым төрләрендә аучылык фаунасының билгеле бер вәкилләренә яраклы шартларны бәяләү өчен аучылык җирләре бонитеты төшенчәсе кертелә.

Бонитет – аучылык җирләрен төрле яклап гомумиләштерелгән бәяләү, бу мәйданнарның кыргый хайваннар яшәү өчен яраклылыгын, табигый азык

базаларын, саклану урыннарын һәм оя кору өчен мөмкинлекләрен ачыклау, икенче төрле әйткәндә, ау җанварларының төп төрләре өчен бонитет классын билгеләү. Бонитетклассы комплекслы табигый-икътисадый шартларныңхуҗалык үсешенә ничек йогынты ясавын күзалларга мөмкинлек бирә. Аучылык җирендәазыкка мохтаҗлык күрмичә 1000 га мәйданда яши алучы кошлар һәм җанварлар саны шуның күрсәткече булып тора. Аучылык фаунасының оптималь саны билгеләнә, аучылык хуҗалыгы шуна омтылырга тиеш.

Аучылык җирләре биш бонитет классына бүленә, алар аучылык җиренең продуктивлыгын һәм аучылык фаунасының аерым төрен саклап калудагы ролен чагылдыра.

Кыргый хайваннарның аерым бер төре өчен төп яшәү стадиясе булган җирләр яхшы аучылык җирләре дип санала. Алар төрледән-төрле һәм ел буена тотрыклы азык базасына ия һәм җанварлар өчен ышанычлы. Мондый җирләрдә кыргый хайваннарның аерым төрләре күпләп яши, алар кеше тарафыннан ашатуга һәм башка ярдәмгә мохтаж түгел.

Сыйфаты ягыннан уртача дип танылган җирләргә канәгатьләнерлек азык базасы һәм саклану шартлары хас. Кыргый хайваннарның бу җирләрдә яшәве мәйдан ягыннан да, елларга бүлеп караганда да бертөрле генә түгел. Биотехник чаралар мондый мәйданнарда азык базасын яхшыртырга, мохитнең бик үк әйбәт булмаган факторларын йомшартырга яисә яхшыртырга ярдәм итә. Бу җирләр планлаштырыла торган төп аучылык хуҗалыгы чаралары һәм биотехник чаралар объекты, хуҗалыкның гомумән продуктивлылыгын арттыру резервы булып тора.

Начар җирләргә янгын куркынычы булу хас. Бу җирләрдә азык аз, кыргый хайваннарга качу һәм яшәү өчен канәгатьләнерлек урыннар юк. Мондый җирләрдә биотехник чаралар үткәрү тиешле нәтиҗәләр бирми.

Соңгы тапкыр үткәрелгән урман эшләре материалларына караганда, аучылык җирләрен бонитировкалау уртача күрсәткеч буенча билгеләнгән, 3 нче бонитет классы база итеп һәм биотехник чаралар нормативларын куллану өчен уртачабуларак кабул ителгән.

Республиканың аучылык җирләре, гомумән алганда, поши, кабан дуңгызы, кыр кәҗәсе, ак куян, төлке, көртлек, божыр һ.б кыргый хайваннар яшәү өчен уңайлы.

Кыргый хайваннарның һәр төре өчен бонитетлар даими зурлык түгел. Кешенең урман мохитенә катышуы (урманнарны тулысынча кисүләр, чистартулар, санитария таләпләрен үтәп кисүләр һәм башка чаралар) аркасында бонитет теге яки бу якка үзгәрергә мөмкин. Болар барысы да аулана торган кыргый хайваннарның аерым төрләре өчен яшәү мохите үзгәрүгә һәм аларның бу мәйданнарда күчеп йөрүенә (миграциясен) китерергә мөмкин.

Урманнардан файдалануның Урман планында каралган төрләре һәм күләмнәре аучылык җирләренең торышына һәм сыйфатына кире йогынты ясамаячак, моның өчен агач әзерләү, агач утырту һәм башка эшләр вакытында аучылык хуҗалыгы мәнфәгатьләрен истә тотарга кирәк. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Көртлекләр һәм суерлар оялаган урыннарда терлекләр көтүне һәм печән чабуны тыю.

2. Күл буйларында су кошлары ояларга мөмкин урыннардан кимендә 10 м киңлектәге мәйданда агач, куаклар кисүне һәм печән чабуны тыю.

3. Урманнарны тулысынча кискәндә кыргый хайваннар өчен аерым агачлар, куаклар, шулай ук зур булмаган кишәрлекләр калдыру.

4. Урманнарны чистарту һәм санитария таләпләрен үтәп кисүләрне кыргый хайваннарның күбесендә үрчү чоры беткәннән соң, җәйнең икенче яртысында яисә көзен башкару.

5. Урманнарны чистарту өчен кискәндә урман кошлары оялау өчен куаклыклар, куышлы агачлар калдыру.

6. Төп файдаланудагы урман бүлентекләрендә киселгән агачларны һәм чистарту өчен киселгән агачларны язгы-җәйге чорда аучылык җирләренең оя коруга яраклылыгын һәм кышын азык буларак кулланыла торган агач-ботак материалы запасларын арттыру өчен бер күчкә өеп кую.

7. Аучылык фаунасы тупланган урыннарда чабылмаган үлән мәйданнары калдыру.

Аучылык хуҗалыгы җирләрендә үрчемгә зыян китерми торган аучылык белән шөгыльләнү өчен әлеге мәйданның мөмкинлекләре исәпкә алына, ул ау үткәрелә торган вакытка аучылык җиренең күләменә, андагы кыргый хайваннарның санына бәйле. Мәйданның мөмкинлекләре килеп туган вәзгыятьтә һәм хәзерге вакытта җанварларны һәм кошларны ату нормаларыннан чыгып билгеләнә, аның ике төре – факттагы һәм планлаштырыла торганмөмкинлекләр бар. Факттагы мөмкинлекләр – хуҗалыктагы аучыларга аучылык белән шөгыльләнергә ярый торган көннәрнең төгәл саны һәм рөхсәт ителә торган чорларда һәм вакытларда аучылык җирләрендә ау рөхсәт ителә торган вакыт. Аның күрсәткечләре бирелгән юлламалар буенча һәр чор ахырында санала. Бу күрсәткеч хуҗалыкта җитештерү эшчәнлегенең төп якларын чагылдыра һәм киләсе ел дәвамында аучылык җирләрендә индивидуаль һәм коллектив ау оештыруның һәм үткәрүнең торышын үз эченә ала.

Киләсе ел өчен планлаштырыла торган яисә проекттагы мөмкинлекләр хуҗалыкта һәр ау сезоны башланыр алдыннан фаразланырга тиеш. Исәп-хисаплар кыргый хайваннарның һәр төр буенча исәбе, аларны аулауның сезонлы һәм еллык нормалары, шулай ук бер аучының бер көнлек индивидуаль нормасы нигезендә башкарыла.

Ау хуҗалыклары мөмкинлекләре һәм бонитеты буенча Татарстан Республикасы территориясендә аулана торган җанварларның даими санын тәэмин итә торган уртача аулау нормалары кулланыла.

Хуҗалыктагы аучылык фаунасының рөхсәт ителә торган оптималь яисә хуҗалык өчен кирәкле күләме ул – аучылык җирләренең җитештерүчәнлеге тулысынча файдаланыла, ә кыргый хайваннарның халык хуҗалыгына китергән зарары сизелми торган күләм.

Европа өлешенең Татарстан Республикасы керә торган үзәк өлкәләре өчен аучылык фаунасының төп төрләренең төрле бонитетлардагы 1000 га җирләр буенча оптималь уртача күләме билгеләнгән (1.4.5.4 нче табл.).

1.4.5.4 нче таблица

**Аулана торган кыргый хайваннарның оптималь саны**

| Хайванның төре | Бонитет класслары | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Поши | 10 һәм 13 артык | 10-6<br>8 | 6-4<br>5 | 4-2<br>3 | 2 һәм азрак<br>1 |
| Кабан дуңгызы | 15 һәм күбрәк<br>20 | 15-10<br>12 | 10-6<br>8 | 6-2<br>4 | 2 һәм азрак<br>1 |
| Кыр кәҗәсе | 60 һәм күбрәк<br>75 | 60-39<br>50 | 39-21<br>30 | 21-9<br>15 | 9 һәм азрак<br>5 |
| Ак куян | 120 һәм күбрәк<br>140 | 120-70<br>95 | 70-40<br>55 | 40-10<br>25 | 10 һәм азрак<br>5 |
| Соры куян | 60 һәм күбрәк<br>80 | 60-40<br>50 | 40-20<br>30 | 20-10<br>15 | 10 һәм азрак<br>5 |
| Суер | 100 һәм күбрәк<br>80 | 80-50<br>65 | 50-30<br>40 | 30-10<br>20 | 10 һәм азрак<br>5 |
| Көртлек | 200 һәм күбрәк<br>250 | 200-130<br>165 | 130-70<br>100 | 70-30<br>50 | 30 һәм азрак<br>15 |
| Соры кыр тавыгы | 300 һәм күбрәк<br>375 | 300-195<br>247 | 195-105<br>150 | 105-45<br>75 | 45 һәм азрак<br>22 |
| Су киек кошлары | 1000нән артык | 1000-700 | 700-300 | 300-100 | 100дән азрак |

Искәрмә: бүлүчедә кыргый хайваннарның оптималь санының минималь һәм максималь күрсәткечләре, бүленүчедә – оптималь санның уртача күрсәткече бирелә.

Урман җирләренең азык белән тәэмин ителеше 1.4.5.5 нче таблицада бирелә

1.4.5.5нче таблица

**Татарстан Республикасы урман җирләренең азык белән тәэмин ителеше**

| Категориясе | Азык җирләре термины | Җир өстендәге фитомассаградациясе кг/га | Урман утыртмалары |
|---|---|---|---|
| 1 | Бик яхшы | 1000 һәм артыграк | 10 яшькә кадәрге үсентеләр, урман кисенделәре һәм азык кырлары, нарат җиләге үсә торган 0,5-0,6 куелыктагы наратлыклар, кара җиләк үсә торган V класслы наратлыклар, күрәнчәләр семьялыгы тибындагы урман утыртмалары |

| Категориясе | Азык җирләре термины | Җир өстендәге фитомассаградациясе кг/га | Урман утыртмалары |
|---|---|---|---|
| 2 | Яхшы | 501-1000 | Май чәчәге-нарат җиләге һәм кара җиләк үсә торган,II–IV класска караучы яшьтәге, 0,5-0,6 куелыктагы наратлыклар; кара җиләк үсә торган,III-IV класска караучы яшьтәге, 0,7-0,8 куелыктагы наратлыклар; IV класска караучы яшьтәге, 0,5-0,6 куелыктагы каенлыклар, усаклыклар |
| 3 | Уртача | 251-500 | II–IV класска караучы яшьтәге, 0,7-0,8 куелыктагы, IV класска караучы яшьтәге, 0,9-1,0 куелыктагы наратлыклар; II класска караучы яшьтәге, 0,7-0,8 куелыктагы каенлыклар; II–VI класска караучы яшьтәге зиреклекләр; V-VI класска караучы яшьтәге усаклыклар |
| 4 | Начар | 126-250 | Ак мүкле,IV класска караучы яшьтәге;кара җиләк үсә торган,II класска караучы яшьтәге, 0,9-1,0 куелыктагы наратлыклар; кара җиләк үсә торган, IV-V класска караучы яшьтәге, 0,5-0,6 куелыктагы чыршылыклар; II–IV класска караучы яшьтәге каенлыклар |
| 5 | Бик начар | 0-125 | Ак мүк һәм нарат җиләге үсә торган, II-III класска караучы яшьтәге наратлыклар; кара җиләк үсә торган, II-IIIкласска караучы яшьтәге чыршылыклар; III-IV класска караучы яшьтәге, 0,9-1,0 куелыктагы каенлыклар, усаклыклар |

Тояклы кыргый хайваннар тарафыннан азык запасын үзләштерүнең бездә 30 проценты,(Юргенсон буенча, 1965 ел), Көнбатыш Европада 20 проценты азык ресурсларыннан файдаланунының иң югары чиге булып санала.

Хайваннар дөньясы объектлары урман хуҗалыгына зыян китергән очракта, аучылык хуҗалыклары бу зыяннарны кире кайтарырга тиеш.( «Хайваннар дөньясы турында» ФЗ56 ст.).

Кыргый хайваннарның оптималь саны аучылык җирләренә туры килергә, урман утыртмаларына кыргый хайваннар китергән зыянны юкка чыгара торган урман биогеоценозларының бер өлеше булган үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы, ерткычлар һәм аларның корбаннары арасында экологик һәм хуҗалык нисбәтен тәэмин итәргә тиеш.

Кыргый хайваннарның урманнарга йогынтысы уңай да, тискәре дә булырга мөмкин. Тотрыклы урман экосистемаларында бу йогынтылар бер үк дәрәҗәдә.

Арендага алынган урман кишәрлекләрендә урман хуҗалыклары эшчәнлекләрен һәм урманнардан файдалануны планлаштырганда түбәндәгеләр исәпкә алынырга тиеш:

– суерлар оялаган урыннарны һәм кондызлар яши торган елгаларны ОЗУ өчен бүлеп бирүдән тыелу;

– язгы-җәйге чорда урман кошлары оя корган һәм яшь кыргый хайваннар күпләп җыела торган урыннарда эшләрне чикләү;

– агулы химикатлар һәм минераль ашламалар куллануны чикләү.

«Хайваннар дөньясы турында» Федераль закон нигезендә урманчылыкларда кыргый хайваннарның яшәү тирәлеген саклап калу, аларга үрчү, йөрү, ял һәм күчеп йөрү, саклану өчен шартлар тудырылырга тиеш.

Биологик ресурслардан рациональ файдалану өчен гамәли экологиянең төп өч нигезен истә тотарга кирәк:

– минимумда саналучы экологик факторларны;

–территориянең сыйдырышлылыгын;

–экологик куыш булдыруны.

Республиканың урман фондын, чикләүләр булган кишәрлекләрдән (урман-парк зоналары, ООПТ һәм ОЗУ урманнары) тыш, тулысынча диярлек аучылык белән шөгыльләнү өчен аучылык хуҗалыкларына бүлеп бирү яисә дәүләт резерв фондына кертү күздә тотыла. Аучылык хуҗалыгы алып баруның һәм аучылык фаунасы өчен биотехник чаралар күрүнең барлык мәсьәләләре, Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы органнары белән килештерелеп, Россия Федерациясе Урман кодексы нигезендә башкарылырга тиеш.

Аучылык хуҗалыклары урман фондының арендага алынган кишәрлекләрендә аучылык белән шөгыльләнергә һәм расланган документлар нигезендә биотехник гамәлләр башкарырга тиеш.

Хайваннар дөньясы объектларын (шул исәптән аулана торган җәнлекләрне) саклап калу һәм арттыру максатларында, урман хуҗалыкларында һәм урманнардан файдалану эшләрендә хуҗалык эшчәнлеге хайваннар дөньясын һәм аларның яшәү тирәлеген саклауны истә тотып башкарылырга тиеш. Хәзерге вакытта аучылык хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен урманнардан файдалану мәсьәләсе Россия Федерациясенең Урман кодексы белән (36 ст.) җайга салынган, аның буенча, урманнардан файдалану һәм урман хуҗалыгы эшчәнлеге кыргый хайваннарның яшәү тирәлеге өчен уңайлы шартларны саклап калу зарурлыгын истә тотып башкарылырга тиеш.

Урман планында түбәндәгеләр карала:

– арендатор һәм арендаторның агач әзерләү эшләрен башкара торган белгечләре тарафыннан хайваннар дөньясы объектларын, шул исәптән аулана торган җанварларны мониторинглау, үзгәрешләр һәм хокук бозулар турында районның тиешле хезмәтләренә җиткерү. Моның өчен агач әзерләү предприятиесендә хайваннар дөньясы объектларын мониторинглау буенча җаваплы вазыйфаи затны (урман фонды инженерын, мастерны) билгеләп кую турында күрсәтмә (боерык) чыгарыла. Предприятиенең бу күрсәтмәсе (боерыгы) нигезендә эшчеләргә агач әзерләү эшләре вакытында эшкә үзләре белән утлы корал йөртү тыела;

– киселә торган мәйданнарда сусарга оя кору өчен куышлы агачлар калдыру (5-6 га/шт.);

– эре ерткыч кошлар оялаган агачларны саклап калу.

Урман фонды кишәрлекләрен «Хайваннар дөньясы турында» Федераль закон һәм «Аучылык һәм аулау ресурсларын саклап калу турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә арендага алган аучылык хуҗалыклары аучылык җирләрендә гамәлдәге нормативлар нигезендә махсус биотехник чаралар үткәрергә тиеш.

Язын кошлар оя корган һәм күкәй салган чорда агач әзерләү эшләрен туктатып торырга кирәк. Урман кисүләрне планлаштырганда хайваннарның күчеп йөрүе өчен яшел коридор калдыру мөһим. Арендага алынган территориядә агач кисүләрне оештырганда тулысынча, аз-азлап һәм сайлап кисү алымнарын куллану кулайрак (кисүнең нинди дә булса алымы урманнарны үзләштерү проектында билгеләнә). Болай эшләгәндә төрле яшьтәге, төрле токымлы, төрле рәвешләрдәге утыртмаларның мозаик урнашуына, шулай ук күпяруслы агачлар һәм ачык җирләр (кисүләрдән зыян күрмәгән) булдыруга ирешергә мөмкин;

– көртлек ояларында урман культуралары эшләрен һәм аларны чистартуны тыю;

– химик ашлаулар һәм урман культураларын тукландырулар вакытында химикатлар һәм минераль ашламалар куллану нормаларын һәм кагыйдәләрен төгәл үтәү;

– питомникларда һәм урман культураларын барлыкка китергәндә агу белән эшкәртелгән орлыкларны җиргә тирән утырту.

Бу гамәлләр хайваннар дөньясы объектлары яшәү тирәлегенең, шул исәптән аучылык җирләренең азык һәм саклану үзенчәлекләрен яхшыртырга мөмкинлек бирә.

Районда аучылык буенча җаваплы затларның урманчылыклар һәм арендага алучылар белән берлектә даими тикшереп торуы һәм гамәли эше урман җирләренең каралучы кишәрлекләрендәге хайваннар дөньясы объектларының яшәү мохите торышы начарлануны булдырмый калырга мөмкинлек бирә.

Планлаштырыла торган чараларның хайваннар дөньясы яшәү тирәлегенә йогынтысы Россия Федерациясе Дәүләт экология комитетының 2000 елның 16 маендагы 372 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү турында нигезләмә буенча бәяләнә.

Хайваннар дөньясына агач әзерләүләр аркасында килергә мөмкин (алдан исәпләүләр буенча) зыянның күләмен хәзерге вакытта санап булмый, чөнки мондый зыянны ачыклау буенча юридик яктан рәсмиләштерелгән норматив документлар юк. Төрле институтларның аерым, берләштерелмәгән эшләнмәләре бар, аларда төп куллану өчен башкарыла торган агач кисүләрнең хайваннар дөньясының яшәү тирәлегенә уңай һәм тискәре йогынтысының барлык вариантлары да исәпкә алынмый.

Проектланган чараларны үтәмәү нәтиҗәсендә хайваннар дөньясына һәм аларның яшәү тирәлегенә реаль зыян китерелгән очракта, ул арендага алучыдан түләттерелә. «Хайваннар дөньясы турында» Федераль закон һәм «Хайваннар

дөньясын юкка чыгарудан һәм аларның яшәү тирәлеген бозудан зарарны бәяләү һәм китерелгән зыян күләмен исәпләү методикасы» түләтү өчен нигез булып тора. «Хайваннар дөньясы турында» Федераль законның 22 статьясы нигезендә хайваннар дөньясы объектлары урман хуҗалыгына зыян салырга тиеш түгел. Хуҗалык эшчәнлеге чикләнгән саклау участоклары (суер ояларын, елга ярларындагы кондыз полосаларын һәм башка участокларны) билгеләнгән очракта, арендага алучыга Россия Федерациясе законнары һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә компенсация түләнергә тиеш.

Аучылык хуҗалыклары һәм урмандагы аучылык хуҗалыклары нинди дә булса бер урманчылык территориясендә оештырылганда аучылык хуҗалыгын комплекслы үстерү чараларын башкарырга кирәк, аларны урман эшләречаралары уздырылганнан соң, аучылык хуҗалыкларының махсус заказы буенча шартнамәчел нигездә эшләү максатка ярашлы. Шул ук вакытта бу эшләр Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган норматив документлар нигезендә башкарылырга тиеш.

Гражданнарның, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның аучылык хуҗалыгы тармагындагы эшчәнлек төрләре өчен урманнардан файдалануы Россия Федерациясе Урман кодексының 25, 36 статьялары таләпләре нигезендә билгеләнә.

Россия Федерациясе Урман кодексының 36 статьясы нигезендә гражданнарның, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның аучылык хуҗалыгы тармагындагы эшчәнлек төрләре өчен урманнардан файдалануы урман кишәрлекләрен арендага алу шартнамәсе буенча башкарыла.

Урман планы буенча 2018 елга аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлек төрләре өчен 220,7 мең гектар мәйданда урман кишәрлекләре бирү планлаштырыла.

# IIБҮЛЕК. УРМАННАРДАН ФАЙДАЛАНУНЫҢ, АЛАРНЫ САКЛАУНЫҢ ҺӘМ ТОРГЫЗУНЫҢ ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

Урманнарның торышы яхшыру санга һәм сыйфатка бәйле түбәндәге максатчан күрсәткечләр буенча билгеләнә:

– урман үсемлекләре белән капланган мәйданнарның артуы;

– урман утыртмаларында кыйммәтле токымлы агачларның артуы;

– урман янгыннарыннан, зарарлы организмнардан һәм башка тискәре факторлар тәэсиреннән юкка чыккан урман мәйданнарының кимүе;

– урманнар торышын яхшыртуның башка максатчан күрсәткечләре.

Урманнардан даими, зарар китерми торган, күпмаксатлы файдалану урманнар белән идарә итүнең төп принцибы булып тора. Шулай да урман хуҗалыгы һәм урман сәнәгате комплексы тармагында дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының нәтиҗәле инвестиция проектларын хуплауга, урман ресурслары бүлеп бирүгә, сәнәгать мәйданнарын сайлауга, социаль-житештерү инфраструктурасын булдыруга юнәлдерелгән гамәлләрен координацияләү таләп итеүә торган проблемалар да бар.

Катлаулы проблемаларны хәл итү өчен Урман планында максатчан программа ысулы кулланыла, ул кызыксынучы барлык якларның тырышлыгын берләштерергә, бер үк мәсьәләләрне берничә тапкыр чишүне булдырмаска, төрле чыганаклардан финансларны бергә тупларга мөмкинлек бирә.

Идарә органнары һәм хуҗалык субъектлары арасында үзара хезмәттәшлекнең гамәлдәге шартларында урман хуҗалыгы һәм урман сәнәгате проблемалары традицион идарә кысаларында хәл ителә алмый. Икътисадның урман тармагын үстерү юлларын, Россия Федерациясе Урман кодексына нигезләнеп, тамырдан үзгәртергә кирәк. Бу үзгәрешләр республиканың урман хуҗалыгын һәм урман сәнәгате комплексын нәтиҗәле үстерүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен тармакара җайга салуны, кадрлар мәсьәләсен, матди чараларны, финанс, мәгълүматчараларын килештереп хәл итүне таләп итә.

Максатчан программа ысулы түбәндәгеләргә нигезләнә:

– барлыкка килгән проблемаларның мөһимлегенә;

– проблемаларны тиз генә хәл итеп булмауга;

– алдынгы фәнни-техник казанышларны кертү зарурлыгына;

– өстенлекле юнәлешләрдә тырышлыкны һәм ресурсларны туплауның мөһимлегенә.

Урман хуҗалыгында хәл ителмәгән актуаль мәсьәләләр түбәндәге яңа проблемалар китереп чыгара:

– урман эшләрен үз вакытында уздырмау урман хуҗалыгы чаралары билгеләнгән урман кишәрлекләре булмауга китерә;

– урман хуҗалыгы чараларын үз вакытында уздырмау карт һәм түбән сыйфатлы урман утыртмалары тагын да артуга, урманнарда авырулар һәм корткычлар таралуга китерә;

– агач әзерләү күләменең кимүе урман хуҗалыгын алып бару өчен финанс чаралары кимүгә китерә;

– финанс чараларын, моңа бюджет акчалары да, арендага алган затлар акчалары да керә, нәтиҗәсез файдалану урманнарны торгызу, саклау һәм яклау күләмнәре кимүгә китерә;

– янгынга каршы чараларның кимүе урман янгыннарыннан зыян күргән урман җирләре артуга китерә.

Урман хуҗалыгында хәл ителмәгән мәсьәләләрнең күп булуы урман сәнәгате комплексы эшендә түбәндәге токкарлыкларны китереп чыгара:

– агач ташу өчен юллар булмау сәбәпле, еракта урнашкан яңа урман массивларын үзләштерү мөмкин булмау;

– сыйфатлы һәм конкурентлылыкка сәләтле продукция бирми торган искергән төп фондлар арту;

– эш күләме киму аркасында урман (авыл) поселокларында социаль киеренкелек арту;

– җитештерелә торган продукция рентабельле булмау һәм предприятиеләрнең банкротлыгы;

– хезмәт хакының түбән булуы аркасында урман поселокларында кадрлар мәсьәләсе кискенләшү.

Әлеге проблемалар комплекслы хәл итүне таләп итә. Аларны чишүдә системалылык булмау урман хуҗалыгында һәм, гомумән, икътисадның урман сәнәгате тармагында вәзгыятьнең кискенләшүенә китерергә, үсешнең ирешелгән темплары кимүгә, конкурентлылык сәләте югалуга, базар шартларында эшләү сәләтен югалтуга китерергә мөмкин.

Татарстан Республикасында түбәндәгеләр планлаштырыла:

– ресурсларны дөрес бәяләү һәм алардан рациональ файдалануны оештыру өчен урман эшләреүткәрү;

– аренда мөнәсәбәтләрен үстерү һәм камилләштерү;

– агач әзерләүнең гомуми күләмендә урманнарны чистарту өчен кисүнең күләмен арттыру;

– урман кисү эшләре технологиясен камилләштерү, заманча машина комплекслары ярдәмендә агач кисү технологияләрен республика шартларына яраклаштыру;

– урманнарның торышын, урманнардан файдалануны, урман янгыннарын мониторинглау өчен геомәгълүмат технологияләреннән (ГИС) файдалану;

– урманнарны бозудан саклауны урманнар турында гамәлдәге законнар нигезендә камилләштерү;

– урман фондының торышына, урман ресурсларыннан рациональ файдалануга һәм урманнардан файдалануның барлык төрләрендә урманнарны саклау һәм экология таләпләрен үтәүгә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген тәэмин итү;

– урманнарның биологик төрлелеген саклап калу һәм аларның биологик потенциалын арттыру;

– флора һәм фауна өченің зарарсыз булган яңа биологик препаратлар белән эш итү һәм урманнарны корткычлардан һәм авырулардан саклаганда аларны куллану;

– хуҗалык өчен кыйммәте югары токымлы агачлар үсмәгән урман кисенделәрендә урманнарны торгызуны эре утырту материалларын утырту юлы белән гамәлгә ашыру;

– элиталы орлыкчылык системасын камилләштерүне дәвам итү;

– агач орлыкларының гамәлдәге даими базасына инвентаризация үткәрүне төгәлләү һәм аны алга таба үстерүне планлаштыру;

– гамәлдәге киптерү системаларын ремонтлау яисә реконструкцияләү максатыннан, аларга инвентаризация үткәрү;

– аеруча саклана торган территорияләр, саклагыч урманнар һәм урманның аеруча саклана торган кишәрлекләре режимын үтәү, урманчылыкларның урман фонды чикләрендә урнашкан аеруча саклана торган табигать объектларын һәм территорияләрен тиешенчә саклауны тәэмин итү һәм аларның торышын яхшырту чараларын үтәү;

– республика урманнарына ирекле урман сертификаты системасын кертү;

– урман фонды мәйданының бер берәмлегеннән максималь керем алуга ирешү.

Урман хуҗалыгы белән тотрыклы идарә итү урман фондына хезмәт күрсәтүне һәм аларның продуктивлыгын, үрчү сәләтен, биологик төрлелеген саклап, хәзерге вакыттаһәм киләчәктә җирле, милли һәм дөнья күләмендә экологик, икътисадый һәм социаль функцияләрне башкару өчен потенциалын үстереп, алардан файдалануны күздә тота.

## 2.1. Урманнар торышын яхшыртуның күләме һәм сыйфаты буенча максатчан күрсәткечләр

### 2.1.1. Урман үсемлекләре белән капланган мәйданнарны арттыру

Урман үсемлекләре белән капланган мәйданнарның вакытлыча кимүе агачларны тулысынча кисү, урман янгыннары, зарарлы организмнар, авырулар, начара тәэсир итә торган һава торышы аркасында барлыкка килә.

Урман үсемлекләре белән капланган мәйданнарның артуы яисә кимүе, күп очракта, файдаланыла торган урманнарда хуҗалык эшчәнлеген алып бару дәрәҗәсенә бәйле. Бу очракта тулысынча кисүләр урманнарны торгызуның күләмен билгели.

Урман фонды исәбе буенча, Татарстан Республикасының урман каплаган җирләре 2013 елның 1 гыйнварына урман фондының гомуми мәйданының 93 процентын тәшкил итә. Шул исәптән урман культуралары 26 процентны, сыгылмалылыгы түбән урман культуралары нибары 1 процентны билэп тора.

Урманнарны торгызу фонды нигездә кисенделәрдән һәм аланнардан тора. Берәмлекләр буенча алганда кисенде 5,6 гектар, буш җирләр һәм аланнар 2,4 гектар җирне тәшкил итә. Урманнарны торгызу өчен 8 мең гектар урман җирләре таләп ителә. Торгызу табигый, ясалма һәм катнаш ысуллар белән башкарыла.

Урманнарда токымнарга өстенлек урман хуҗалыгын алып бару һәм урманнардан файдалану максатыннан чыгып бирелә. Тыюлык режимы урнаштырылган урманнарда максатчан агачлар билгеләнми.

Хуҗалык секцияләре булдыру белән беррәттән, урман хуҗалыгында үстерелергә тиешле агач токымнары да сайланып алына. Әлеге мәсьәләне хәл иткәндә урманчылыкларда агач токымнары утыртмаларының булу-булмавын истә тотарга кирәк. Урман хуҗалыгында өстенлекле токымнар һәм төп токымнар аерып карала.

Утыртмалар арасында зуррак запаска ия һәм агачлар саны күбрәк булган, хуҗалыктагы агач токымнары төркемендә состав коэффициенты югары агачтокымнарыөстенлекле токымнар дип санала. Утыртмалар составында ике яисә өч агач токымы бертигез булган очракта, урманнарның максатчан билгеләнешенә яисә урман үстерү шартларына күбрәк туры килә торганы өстенлекле була.

Катнаш урман утыртмалары составына ылыслы яисә каты яфраклы төркемнән бер генә агач токымы керсә һәм утыртмалар составында аның өлеше кимендә 5 берәмлек булса, мондый токымлы агачлар өстенлекле дип санала.

Урман утыртмалары арасында аерым агач токымнарының саны 2 берәмлектән артык булмаганда, урман үстерү шартларының мондый төре (урман төре) өчен хуҗалык әһәмияте зуррак булган агач токымы өстенлекле дип санала.

Аерым бер икътисадый һәм урман үстерү шартларында хуҗалык һәм экологик максатларга күбрәк туры килә торган агач токымыхуҗалыкның төп токымы була. Төп токымнарга продуктивлыгы югары булган, физик-механик һәм химик үзенчәлекләре яхшырак саналган һәм утыртмаларының саклану, рекреация, табигатьне саклау һәм башка файдалы үзлекләре югары агачлар керә. Ике токым үскән урманнарда төп токымның гомуми запасы өлгергән агачларның төп ярусында гомуми запасның 50 процентын, яшь агачлар ярусында кимендә 30 процентын алып торса, төп токым урманның нигезен тәшкил итүче дип санала.

Урман хуҗалыгында төп бурычларның берсе – өстенлекле токымнары, икенчел токымнар белән рациональ чагыштырганда, төп төкымнар дип танылган утыртмалар үстерү. Барлык өстенлекле токымнар төп токымнар булып саналучы хуҗалыкларда туфрак һәм климат шартлары тулы күләмдә файдаланыла һәм кыйммәте ягыннан әһәмиятлерәк утыртмалар үстерелә.

Төп токымнарны сайлаганда икенчел агач токымнарының хуҗалык әһәмиятен төрле яклап анализларга һәм утыртмалар составында аларның өлеше күпме булуын өйрәнергә кирәк.

Саклагыч урманнарда төп токымнар төрле категорияләрдәге урманнарның билгеләнешеннән чыгып сайлана. Саклагыч урманнар өчен озак яши торган, югары саклагыч һәм туфрак ныгыту үзлекләренә ия агач токымнары төп токым итеп билгеләнә. Мондый токымнарга нарат, карагай, каен һәм башка агач токымнары керә. Берничә токымны бергә утырту туфрак-климат (табигый-географик) шартларыннан һәм тупланган тәҗрибәдән чыгып башкарыла. Суларны көйләү урманнары һәм сусаклагыч урманнар өчен төп токымнар итеп нарат, чыршы, ак чыршы, карагай һәм башка агач токымнарын утырту тәкъдим ителә.

Файдаланыла торган урманнарда төп токымнар теге яки бу сортка ихтыяҗдан чыгып билгеләнә. Сортлар агач материалын кулланунын икътисадый шартларын истә тотып сайлана. Утыртмаларны товар буларак һәм аерым бер сорттагыларын үстерү белән шөгыльләнә торган урман хуҗалыгын алып барганда максатчан токым

куелган максатлардан чыгып билгеләнә. Бу фанера өчен чимал һәм такта яру өчен агач алына торган яфраклы урман утыртмаларына кагыла.

### 2.1.2. Кыйммәтле агач токымыннан булган урман утыртмалары өлешен арттыру

Агач материалына һәм аннан ясала торган продукциягә эчке һәм тышкы базарларда җәмгыятьнең ихтыяҗы зур булган агач токымнары республика урманнарында хуҗалык өчен әһәмиятле агач токымнары булып санала.

Хәзерге вакытта мондый токымнарга, ылыслы һәм каты яфраклы токымнардан тыш, продуктивлыгы югары булган (I-II бонитет класслы) каен һәм усак утыртмалары да керә. Каен оптималь шартларда кыйммәте югары булган сортиментлар бирә – фанера, чаңгы, корал ясау өчен һ.б. Икенче ярусы итеп чыршылар утыртылган каенлыклардан агач материалын ике тапкыр: беренчесендә – өлгергән каеннарны, икенчесендә өлгергән чыршыларныкисәргә мөмкин. Агач токымнарын сайлаганда аларның табигый ареалларын, урманнарның табигый зоналарын истә тотарга кирәк.

Максатчан утыртмаларны үстерү түбәндәге таләпләрне үтәп башкарыла:

– утыртмаларның составыһәм структурасы туфракның потенциаль уңдырышлылыгыннантулысынча файдалануны тәэмин итәргә тиеш;

– утыртмалар составы хуҗалык ягыннан әһәмияткә ия токымнардан торырга тиеш, бу токымнар икътисадый шартларда һәм урман үстерү шартларында мөхимрәк, перспективалырак, югары сыйфатлы утыртмалар эталонына якынрак һәм аларга әйләнә-тирә мохитнең урманнарнын үсү шартлары тибына яисә урманнар тибы төркеменә хас биологик төрлелеккә бәйле уңайсыз шартларына күбрәк дәрәҗәдә каршы тору хас;

– файдаланыла торган урманнарда утыртмаларның товар буларак структурасы базар һәм җирле кулланучылар ихтыяҗларына юнәлдерелгән булырга тиеш.

Югарыда саналган таләпләрдән чыгып, Татарстан Республикасы урман фондында нарат, чыршы, шулай ук каен һәм усак төп максатчан токымнар булып тора дигән нәтиҗә ясарга мөмкин.

Максатчан утыртмаларны урманнарны саклану категориясенә бүлүне исәпкә алып үстерү урман хуҗалыгы чаралары системасы төгәл үтәлгән очракта гына башкарылырга мөмкин.

Республика территориясендә ылыслы агачлар өчен уңайлы шартларда үсә торган ылыслы агачларның күбрәк каен һәм усак агачларыннан торган йомшак яфраклы утыртмалар белән алышыну процессы күзәтелә, токымнарның бу кирәкмәс алышынуын булдырмас өчен урман хужалыгында тиешле чаралар күрергә кирәк.

Республика шартларында максатчан токымнарны торгызуның төп ысуллары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– урман белән капланмаган, табигый яңару кыен яисә кирәкмәгән юнәлештә бара торган җирләргә максатчан урман культуралары утырту;

– сайлап кисү ысулын күпләп куллану;

– урманнарны тоташтан кисү вакытында кыйммәтле агач токымыннан булган үсентеләрне саклап калу;

– яфраклы утыртмаларны чистарту өчен кискәндә кыйммәтле токымнар яңару өчен шартлар тудыру;

– ылыслы токымнар белән катнаш үскән яфраклы үсмер агачларны чистарту өчен интенсив кисүләр үткәрү;

– кыйммәте булмаган йомшак яфраклы токым утыртмаларын реконструкцияләү.

Урманнарны агач токымы ягыннан яхшыртуның югарыда саналган ысуллары Татарстан Республикасы урман хуҗалыгында киң кулланыла. Киләчәктә дә урман хуҗалыгы технологияләрен үтәргә, урман хуҗалыгын алып баруның интенсив рәвешләрен камилләштерергә һәм гамәлгә ашырырга кирәк. Урманнарны торгызу буенча планлаштырыла торган чаралар 17 нче кушымтада бирелә.

### 2.1.3. Урман янгыннарында юкка чыккан, корткыч организмнардан һәм башка тискәре факторлар йогынтысыннан зыян күргән урман мәйданнарын киметү

Урман янгыннарыннан юкка чыккан урман мәйданнарын алга таба да киметү өчен янгынга каршы профилактик чаралар, урман янгыннарының килеп чыгуын кисәтү, аларны вакытында күреп алу һәм сүндерү чаралары үткәрергә кирәк.

Урман янгыннары килеп чыгуны кисәтү өчен чаралар комплексы үткәрелә: махсус полосалар ясала, янгынга каршы барьерлар тәртипкә китерелә, аншлаглар куела, халык арасында аңлату эшләре алып барыла.

Урман янгыннарын вакытында күреп алу һәм сүндерү өчен түбәндәге чаралар комплексын үткәрергә кирәк:

– янгынга каршы билгеләнештәге юллар төзү;

– элемтә чараларын төзек хәлдә тоту;

– җирдән һәм һавадан патрульлек итү.

Моннан тыш, урман янгыннарына каршы формированиеләр һәм ПХС янгын очракларында оператив чыгып китәр өчен әзер булып торырга тиеш.

Урман утыртмаларының юкка чыгуына китерә торган башка сәбәпләр гөмбәчекләр китереп чыгарган, вируслы һәм бактериаль авырулардан, корткыч бөҗәкләрдән һәм уңайсыз һава шартларыннан гыйбарәт.

Саналган сәбәпләрдән урманнарның юкка чыгуын булдырмас өчен түбәндәге чаралар үткәрелә:

– зарарлы чыганакларны юкка чыгару;

– күптән түгел генә зарарланган агачларны кису (санитар кисүләр);

– питомникларда утырту материалларын эшкәртү;

– авыруларга тиз бирешүчән, корткычлардан зарарланган, авыру үсентеләрне ачыклау;

– урманның зарарлануын анализлау, агачларның санитар урман патологиясе торышын, коркычларның һәм авыру күпләп таралган урыннарының артуын, популяциясен фаразлау, урманны саклау буенча нәтиҗәле чаралар планлаштыру буенча карарлар кабул итү.

### 2.1.4. Урманнар торышын яхшыртуның максатчан башка күрсәткечләре

Урманнар торышын яхшырту буенча максатчан башка күрсәткечләрнең берсе – урманны сертификацияләүнең ихтыярый системасын кертү.

Урманны сертификацияләү – базар икътисады шартларында урманнарга тотрыклы идарә итүнең иң мөхим икътисадый алымнарның берсе.

Россия Федерациясендә урманнардан файдалануның ихтыярый системасын булдыру ил икътисадының урман тармагы белән идарә итүнең тотрыклы заманча ысулларына күчүгә һәм агач чималы, урман продукциясе әзерләүне халыкара базарның экологик, икътисадый һәм социаль тотрыклылык принципларына туры китерү таләпләренә бәйле.

Россия Федерациясендә урманнардан файдалануның ихтыярый системасы Россия урман сертификациясенең гомуми схемасына керә, бу схема шулай ук урман ресурсларын һәм агач эшкәртү производстволарын сертификацияләүне дә үз эченә ала.

Урманнардан файдалануны сертификацияләү урманнар белән идарә итүнең икътисадый, экологик һәм социаль сфералардабилгеләнгән тотрыклылык принципларына туры килүен раслаудан гыйбарәт.

Россия урман сертификациясенең гомуми схемасы урманда төп эшчәнлек субъектларының базар шартларында үзара эшчәнлеген чагылдыра һәм базар шартларының барлык этапларына хас булган сертификация системаларының үзара бәйләнешен күрсәтә.

Икътисадның урман секторында базар мөнәсәбәтләрен гамәлгә ашыруның беренче акты урман кишәрлекләрен арендага бирүдән (сату-алу) гыйбарәт.

Бу очракта «сатучы» ролен, дәүләт исеменнән, региональ урман хуҗалыгы органнары, ә «сатып алучы» ролен урманнардан файдаланучылар башкара. Бу стадиядә урман ресурслары, яисә «үсеп утырган килеш сатыла торган агач һәм икенчел урман ресурслары» сертификацияләнә.

Урман икътисады тармагында чираттагы базар мөнәсәбәтләре күренеше булып урманнардан файдаланучылар әзерләгән йомры агач материалларын реализацияләү тора.

Әлеге стадиядә урман сертификациясенең объекты – урманнардан файдалану, аңа түбәндәгеләр керә:

– агач үзерләү технологиясе;

– технологияне гамәлгә ашыра торган техник чаралар;

– урманнардан файдалануның җитештерү процессын оештыру;

– урман мохитен саклап калу һәм торгызу чаралары;

– урманнардан файдаланучының хакимият органнары һәм җирле халык белән хезмәттәшлеге.

Мондый сертификацияләүне уткәрүгә төп кызыксынучы як булып урманнардан файдаланучы – предприятие тора, чөнки урманнардан файдалану процессының урманнар белән тотрыклы идарә итү процессына туры килүен күрсәтә торган сертификат булу предприятиенең абруен күтәрә һәм ул эшләп чыгарган агач продукциясенең дөнья базарында һәм эчке базарда конкурентлылык сәләтен арттыра. Агач экспортын стимуллаштыру һәм җайга салу максатларында халыкара

таләпләр, шулай ук Бөтендөнья сәүдә оешмасы (БСО) таләпләре буенча бу өлкәдә лицензияләүнең, квоталауның, сертификацияләүнең һ.б директив чаралары кулланылмаска тиеш.

Әлеге таләпләр нигезендә, агач продукцияләрен экспортка чыгарганда урманнардан файдалануны сертификацияләү бары тик ихтыярый гына була ала.

Урман секторында базар мөнәсәбәтләрен гамәлгә ашыруның ахыргы акты агач эшкәртү продукциясен (төзелеш материаллары, целлюлоза, кәгазь, җиһаз, һ.б) базарга чыгарудан гыйбарәт. Бу этапта урман сертификациясе агач эшкәртү процессына, шулай ук продукт әзерләнгән агач чималын ташуның барлык баскычларына кагыла.

Агач чималын ташуны сертификацияләү агач эшкәртү продукциясе ясалган чималның урманнар белән тотрыклы идарә итү принципларыннан чыгып, димәк, бу принципларга туры килүгә сертификаты булган предприятиеләр тарафыннан ташылуын раслау өчен башкарыла.

Агач эшкәртүне сертификацияләү агач чималын эшкәртүче предприятие мөрәҗәгате буенча үткәрелә. Урман сертификациясенең әлеге стадиясе дә ихтыярый булырга тиеш, чөнки халыкара оешмаларның, шул исәптән БСОның башка товарлар өчен билгеләнгән таләпләре экспортка чыгарыла торган агач эшкәртү продукциясенә дә кагыла. Базарда тәкъдим ителә торган товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне ихтыярый сертификацияләү бу таләпләрнең берсе булып тора.

Шулай итеп, Россиянең һәм Татарстан Республикасының урман комплексында базар мөнәсәбәтләрен гамәлгә ашыру актларына сертификацияләүнең түбәндәге төрләре туры килә:

– урман ресурсларын сертификацияләү;
– урманнардан файдалануны сертификацияләү;
– урман эшкәртүне сертификацияләү.

Бу процедуралар Россия урман сертификациясенең гомуми схемасына керә торган тиешле сертификация системалары ярдәмендә башкарыла.

Сертификацияләү системаларының гомуми схемасына керә торган һәр система автоном, ләкин алар үзара бәйләнештә һәм бер-берсен тулыландыра.

Россиядә урманнардан файдалануны ихтыярый сертификацияләү Россия Урман сәнәгате һәм урман экспорты белән шөгыльләнүчеләр берлеге, Россия Федерациясенең Урман хуҗалыгы министрлыгы, урман комплексы хезмәткәрләренең тармак һөнәр берлеге тәкъдиме һәм ярдәме белән эшләнде. Системаны эшләүдә, карауда һәм сынауда урман сертификациясе өлкәсендә тармак институтлары һәм югары уку йортлары галимнәре, Россия Федерациясе субъектларының урман комплексы белгечләре, дәүләтнеке булмаган оешмалар вәкилләре катнашты.

Республикада урманнардан файдаланучылар арасында ихтыярый урман сертификациясе белән кызыксынучылар әлеге юк.

## 2.2. Урманнарны планлаштырылган үзләштерү зоналарына бүлү (шул исәптән алардан файдалану төрләре һәм үзләштерү интенсивлыгы буенча)

### 2.2.1. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш программаларын һәм территориаль планлаштыру документларын исәпкә алып, республикада урманнарныүзләштерү перспективаларын гомуми бәяләү

Татарстан Республикасы урман хуҗалыгында Россиягә һәм гомумән бу өлкәгә хас булган проблемалар бар:

– хисапланган урман кисүләрдән тулысынча файдаланмау;

– урман хуҗалыгындагы эшне механикалаштыруның түбән дәрәҗәдә булуы;

– югары квалификацияле кадрлар җитмәү;

– агач эшкәртү предприятиеләренең республика территориясендә рациональ урнашмавы;

– җитештерүнең түбән рентабельле булуы;

–машина-трактор паркының искергән булуы;

– урман кишәрлекләрен агач әзерләү өчен арендага алучыларның булмавы;

– урманнарны рөхсәтсез кисүләрдән һәм рөхсәтсез агач әйләнешеннән саклауны, яңа урман законнары нигезендә язгы-җәйге чорда урманнарны янгыннардан саклауны оештыру.

Моннан тыш, табигать шартлары һәм социаль-икътисадый шартлар китереп чыгарган түбәндәге проблемалар да бар:

– урман үстерү өчен кыен шартлар;

– урманнарның аз булуы;

– урманнарда товар сыйфаты түбән булган йомшак яфраклы урман утыртмаларының күбрәк булуы;

– эрозиягә дучар ителгән җирләрнең шактый зур мәйданнар биләве;

– имәнлекләрнең һәрьяклап кысылуы;

– техноген йогынты аркасында килеп туган катлаулы экологик хәл.

Татарстан Республикасында урман хуҗалыгы өлкәсендәге проблемаларны хәл итү өчен дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарыныңнәтиҗәле инвестиция проектларын хуплауга, урман ресурслары бүлеп бирүгә, сәнәгать мәйданнарын сайлауга, социаль-җитештерү инфраструктурасын булдыруга юнәлдерелгән гамәлләренкоординацияләү таләп ителә.

Катлаулы проблемаларны хәл итү өчен максатчан программа ысулы кулланылырга тиеш, ул кызыксынучы якларның тырышлыгын берләштерергә, бер үк мәсьәләләрне параллель чишүне булдырмаска, төрле чыганаклардан финансларны бергә тупларга мөмкинлек бирә.

Хәзерге вакытта республиканың урман хуҗалыгы эшчәнлеген җайга салу Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән түбәндәге рәсми документларга нигезләнеп алып барыла:

1.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 22 октябрендәге 763 номерлы карары белән расланган 2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы җитештерү көчләрен кластерларга таянып үстерү һәм алып бару программасы («Агач эшкәртү сәнәгате» бүлеге).

Программаның максаты: йомшак яфраклы агачны заманча технологияләр,югары җитештерүчәнлеккә ия җайланмаларярдәмендә тулысынча эшкәртү, булган куәтләрне модернизацияләү нигезендә заманча технологияләр, яңа заводлар һәм комплекслар төзү юлы белән дәүләтнең, халыкның һәм бизнесның агач продукциясенә ихтыяҗын канәгатьләндерү максатларында конкурентлылыкка сәләтле агач эшкәртү комплексын булдыру

Куелган максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителергә тиеш.

1.1. Урман хуҗалыгында:

– урманнардан даими, зарар китерми торган, рациональ файдалану, урман хуҗалыгын алып баруның интенсивлыгы һәм урман фонды кишәрлекләрен озак вакытка арендага алып, урманнарның продуктивлыгын үз вакытында торгызунигезендә агач әзерләүнең тотрыклы базасын булдыру.

1.2. Агач эшкәртү һәм агачтан әйберләр ясау производствосында:

– агачны тулысынча эшкәртеп базарда ихтыяҗ зур булган товарга әйләндерү юлы белән агач эшкәртү продуктларыннан тулысынча файдалану;

– файдаланылмый торган йомшак яфраклы усак һәм каен урманнары үскән урыннарда югары сыйфатлы, конкурентлылыкка сәләтле ябыштырылган конструкцияләр эшләп чыгара торган заводлар һәм торак төзелеше предприятиеләре төзү;

– экологик яктан куркыныч булмаган агач эшкәртү производстволары булдыру;

– гамәлдәге предприятиеләрне техник яктан җиһазлау, агачны заманча технологияләр, прогрессив кисү һәм эшкәртү механизмнары кулланып эшкәртүче, йомшак яфраклы, юка һәм түбән сыйфатлы агачтан югары сыйфатлы продукция җитештерүче яңа үзәкләр булдыру;

– агач эшкәртү һәм агач әзерләү калдыкларыннан җылылык һәм электр энергиясе эшләп чыгару.

2. 2011 елның 22апрелендәге 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш программасы.

**2.2.2 Урманнарны планлаштырылган үзләштерү зоналарына файдалану максатыннан чыгып бүлүне үзләштерү интенсивлыгы буенча нигезләү (аларның максатчан билгеләнешен, экологик яктан кыйммәтен, урманнардан файдалануның планлаштырыла торган чорда өстенлекле булган төрләрен, республиканың территориаль планлаштыру документларын истә тотып)**

Республикада төп токым агачларының эксплуатацияләнә торган запаслары өч төбәк буенча бүленгән (2.2.1.1 нче рәсем).




2.2.1.1. рәс.

I – Идел, Кама һәм Нократ елгалары арасында урнашкан («Кама алды») – 2517 мең м$^3$ (14,4%);

II – Кама һәм Идел арасында урнашкан («Кама аръягы») –13873 мең м$^3$ (79,4%);

III – Идел артында урнашкан («Идел алды») – 1073 мең м$^3$ (6,2%).

Агач запасларын сәнәгать максатларында файдаланудан чыгып караганда, беренче төбәк – «Кама алды» башкаларга караганда алгарак киткән, бу төбәк Башкала, Төньяк, Кама, Көнбатыш икътисадый районнарында урнашкан һәм аңа Әгерҗе, Арча, Биектау, Алабуга, Зеленодольск, Лаеш, Питрәч, Мамадыш һәм Саба муниципаль районнары керә. Хисапланган урман кисүләрдә Зеленодольск, Мамадыш һәм Саба муниципаль районнары алга киткән. Бу төбәктә каенны эшкәртү белән шөгыльләнә торган эре предприятиеләр – «Зеленодольск фанера заводы» ААҖ, «Идел буе фанера-җиһаз комбинаты» ЯАҖ (НП) (алга таба «ЗФЗ» ААҖ, «ПФМК»ЯАҖр (НП), Васильево урман сәнәгате комбинаты «Квинта-Холдинг» ЯАҖ һәм агач эшкәртүче, җиһаз ясаучы башка бик күп предприятиеләр урнашкан. Шулай ук «Арча урманы» ДБУ, «Саба уку-тәҗрибә урман хуҗалыгы» алга киткән.

«Идел алды» төбәге бу юнәлештә бик акрын үсә, ул Көнбатыш икътисадый районында урнашкан, бу төбәккә Апас, Буа, Чүпрәле, Кайбыч һәм Тәтеш муниципаль районнары керә.

«Кама алды» төбәгендә урман ресурсларын үзләштерү түбән дәрәҗәдә, анда барлык агач запасының 4/5 үсә, шуңа карамастан бары тик 12 – 16 процент кына хисаплы урман кисүләр башкарыла. Бу төбәк Көньяк, Кама, Нефть һәм Көнбатыш икътисадый районнарына урнашкан, аңа Азнакай, Аксубай, Әлки, Алексеевск,

Әлмәт, Баулы, Спас, Бөгелмә, Зәй, Лениногорск, Минзәлә, Түбән Кама, Нурлат һәм Чирмешән муниципаль берәмлекләре керә.

Агач материалларының шактый өлеше (50 проценттан артык) йомры рәвештә яисә чистартылмаган агач материалы буларак киптерелмичә сатыла. Татарстан Республикасы урманнарын планлаштырылган үзләштерү зоналарының файдалану төрләре буенча бүленгән схема рәвешендәге картасы 2.2.1.2 нче рәсемдә бирелә.




2.2.1.2. рәс. Урманнарны планлаштырып үзләштерү зоналары буенча территорияләрне бүлү

2.2.2.1 нче таблица

**Татарстан Республикасы икътисадый районнарының административ-территориаль составы**

| Икътисадый район исеме | Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары исеме |
|---|---|
| Башкалаикътисадый районы | Казан<br>Әтнә<br>Югары Ослан<br>Биектау<br>Зеленодольск<br>Лаеш<br>Питрәч |
| Көнбатышикътисадый районы | Апас<br>Буа<br>Чүпрәле<br>Кайбыч<br>Кама Тамагы<br>Тәтеш |
| Төньякикътисадый районы | Арча |

| Икътисадый район исеме | Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары исеме |
|---|---|
| | Балтач<br>Кукмара<br>Мамадыш<br>Саба<br>Балык Бистәсе<br>Теләче |
| Көньяк икътисадый районы | Әлки<br>Алексеевск<br>Аксубай<br>Чистай<br>Яңа Чишмә<br>Нурлат<br>Спас |
| Кама икътисадый районы | Чаллы<br>Түбән Кама<br>Алабуга<br>Менделеевск<br>Зәй<br>Тукай |
| Нефть икътисадый районы | Әлмәт<br>Бөгелмә<br>Лениногорск<br>Сарман<br>Чирмешән |
| Көнчыгыш икътисадый районы | Әгерҗе<br>Актаныш<br>Минзәлә<br>Мөслим<br>Азнакай<br>Ютазы<br>Баулы |

2.2.3.1 нче рәсемдә Татарстан Республикасы административ бүленешенең урманчылыклар һәм урман парклары күрсәтелгән схема рәвешендәге картасы күрсәтелә.




2.2.3.1. рәс. Районнар һәм урманчылыклар

2.2.2.2нче таблица

**Урманчылыкларның Татарстан Республикасы административ районнары буенча бүленеше**

| Административ район | Урманчылык |
|---|---|
| Әгерҗе | Әгерҗе |
| Азнакай | Азнакай, Бөгелмә, |
| Аксубай | Аксубай, Биләр, Нурлат, |
| Актаныш | Минзәлә |
| Алексеевск | Биләр |
| Әлки | Биләр, Болгар, Нурлат, |
| Әлмәт | Әлмәт, Зәй, Кәләй, Лениногорск |
| Апас | Буа, Кайбыч, Идел буе, Тәтеш |
| Арча | Арча, Саба |
| Әтнә | Ары |
| Баулы | Баулы, Бөгелмә, |
| Балтач | Арча, Саба |
| Бөгелмә | Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Лениногорск |
| Буа | Буа, Тәтеш |
| Югары Ослан | Идел буе |

| Административ район | Урманчылык |
|---|---|
| Биектау | Зеленодольск, Ары, Шәһәр яны, Саба |
| Чүпрәле | Буа, |
| Алабуга | Алабуга, Мамадыш, |
| Зәй | Әлмәт, Зәй, Кәләй, Түбән Кама |
| Зеленодольск | Зеленодольск, Кайбыч, Идел буе |
| Кайбыч | Кайбыч, Идел буе |
| Кама Тамагы | Идел буе |
| Кукмара | Лубян, Мамадыш, Саба |
| Лениногорск | Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск |
| Лаеш | Лаеш, Шәһәр яны |
| Мамадыш | Кама, Кызыл Йолдыз, Мамадыш, Саба, |
| Менделеевск | Алабуга, |
| Минзәлә | Минзәлә |
| Мөслим | Азнакай, Минзәлә |
| Түбән Кама | Зәй, Түбән Кама |
| Яңа Чишмә | Аксубай, Зәй, Кәләй |
| Нурлат | Биләр, Нурлат |
| Питрәч | Лаеш, Шәһәр яны, Саба |
| Балык Бистәсе | Кама, Кызыл Йолдыз, Лаеш, |
| Саба | Кызыл Йолдыз, Саба |
| Сарман | Азнакай (Җәлил һәм Сарман уч.урманчылыклары), Әлмәт, Минзәлә, Түбән Кама |
| Спас | Болгар, |
| Тәтеш | Буа, Тәтеш |
| Тукай | Алабуга, Минзәлә, Түбән Кама |
| Теләче | Кызыл Йолдыз, Саба |
| Чирмешән | Лениногорск, Чирмешән |
| Чистай | Аксубай, Биләр, Кама |
| Ютазы | Бөгелмә |

Урманчылыкларның төбәкләр буенча урнашуы:

I. «Кама алды»:

Әгерҗе, Арча, Алабуга, Зеленодольск, Ары, Кама, КызылЙолдыз, Лаеш, Любян, Мамадыш, Шәһәр яны, Саба.

II. «Идел алды»:

Буа, Кайбыч, Идел алды, Тәтеш.

III. «Кама аръягы»:

Азнакай, Аксубай, Әлки, Әлмәт, Баулы, Биләр, Болгар, Бөгелмә, Зәй, Кәләй, Лениногорск, Минзәлә, Түбән Кама, Нурлат, Чирмешән.

## 2.3. Урманнардан файдаланукүрсәткечләре (урманнардан файдалану төрләре буенча планлаштырылган күләмне дә кертеп)

Урманнарның функциональ билгеләнешен Россия Федерациясенең Урман кодексына туры китерү нәтиҗәсендә эксплуатацияләнә торган урманнар, су саклау зоналарын, гомуми файдаланудагы тимер юлларны, федераль автомобиль юлларын, Татарстан Республикасы милкендәге гомуми файдалану автомобиль юллары буенда үскән саклагыч урман полосаларын аеру исәбеннән, шактый кимеде. Шулай ук мондый урманнардагы өлгергән һәм картайган урман утыртмаларының саны да кимеде, бу агач әзерләү мөмкинлекләрен (хисаплы урман кисүләрне) ачыклауның зарурлыгына китерде.

Агач әзерләү күләмен планлаштыру 2018 елга кадәр Татарстан Республикасы урман комплексын үстерү стратегиясендә куелган максатлардан һәм бурычлардан чыгып эшләнде.

Агач әзерләүне планлаштыруның елларга бүленгән күләме 13 нче кушымтада бирелә.

Татарстан Республикасы буенча урманнардан тулаем файдалану күләмнәре 14 нче кушымтада бирелә.

2.3.1 нче таблица

**Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматлары буенча 2009 елның 1 гыйнварына һәм 2014 елның 1 гыйнварына хисаплы урман кисүләрнең урманчылыклар буенча бүленеше**

| Урманчылык исеме | 2009елның 1 гыйнварына | | | | 2014 елның 1 гыйнварына | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Өлгергән һәм картайган агачларны кисү | Урманнарны чистарту өчен кисү | Санитар кисүләр | Барлыгы | Өлгергән һәм картайган агачларны кисү | Урманнарны чистарту өчен кисү | Санитар кисүләр | Төзелеш, реконструкция һәм объектлардан файдалану өчен каралган урман үсентеләрен кисү (РФ ЖК 13, 14, 21 ст.) | Барлыгы |
| | **шул исәптән ылыслы** | **шул исәптән ылыслы** | **шул исәптән ылыслы** | **шул исәптән ылыслы** | **шул исәптән ылыслы** | **шул исәптән ылыслы** | **шул исәптән ылыслы** | **шул исәптән ылыслы** | **шул исәптән ылыслы** |
| 1. Әгерҗе | 50,5 | 15,8 | 1,2 | 67,5 | 50,5 | 15,8 | 1,2 | 0,4 | 67,9 |

| Урманчылык исеме | 2009елның 1 гыйнварына | | | | 2014 елның 1 гыйнварына | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Өлгергән һәм картайган агачларны кисү | Урманнарны чистарту өчен кисү | Санитар кисүләр | Барлыгы | Өлгергән һәм картайган агачларны кисү | Урманнарны чистарту өчен кисү | Санитар кисүләр | Төзелеш, реконструкция һәм объектлардан файдалану өчен каралган урман үсентеләрен кисү (РФ ЖК 13, 14, 21 ст.) | Барлыгы |
| | шул исәптән ылыслы | шул исәптән ылыслы | шул исәптән ылыслы | шул исәптән ылыслы | шул исәптән ылыслы | шул исәптән ылыслы | шул исәптән ылыслы | шул исәптән ылыслы | шул исәптән ылыслы |
| | 20,1 | 10,9 | 0,9 | 31,9 | 20,1 | 10,9 | 0,9 | 0,2 | 32,1 |
| 2. Азнакай | 62,1 | 14,3 | 4,8 | 81,2 | 62,1 | 14,34 | 8,2 | 3,2 | 87,84 |
| | | 10,1 | 4,5 | 12,9 | 0 | 10,14 | 4,54 | 0,6 | 15,28 |
| 3. Аксубай | 63,8 | 6,6 | 0,1 | 70,5 | 63,8 | 6,61 | 0,11 | 0,5 | 71,02 |
| | 0,2 | 0,3 | | 0,5 | 0,2 | 0,32 | 0,02 | 0 | 0,54 |
| 4. Әлмәт | 35,2 | 23,2 | 18,9 | 77,3 | 35,2 | 23,18 | 18,86 | 5,3 | 82,54 |
| | 1,2 | 3,1 | 2,3 | 6,6 | 1,2 | 3,07 | 2,26 | 0,6 | 7,13 |
| 5. Арча | 16,2 | 9,1 | 5,6 | 30,9 | 16,2 | 9,1 | 5,6 | 0,1 | 31 |
| | 1,2 | 5,6 | 1,3 | 8,1 | 1,2 | 5,62 | 1,26 | 0 | 8,08 |
| 6. Баулы | 30,2 | 8 | 5,3 | 43,5 | 30,2 | 8,04 | 5,28 | 2,2 | 45,72 |
| | 0,2 | 5,6 | 1,1 | 6,5 | 0,2 | 5,61 | 1,12 | 0,1 | 7,03 |
| 7. Биләр | 125,5 | 16 | 5,2 | 146,7 | 125,5 | 16 | 5,2 | 0,3 | 147 |
| | | 1,7 | 1,6 | 3,3 | 0 | 1,7 | 1,6 | 0 | 3,3 |
| 8. Бөгелмә | 33,5 | 13,6 | 7,8 | 55 | 33,5 | 13,58 | 14,27 | 1 | 62,35 |
| | | 9,3 | 2,2 | 11,1 | 0 | 9,17 | 2,16 | 0,1 | 11,43 |
| 9. Буа | 4,8 | 10,3 | 5,2 | 22,4 | 4,8 | 10,32 | 5,22 | 0,1 | 20,44 |
| | | 5,4 | 0,1 | 5,5 | 0 | 5,42 | 0,11 | 0 | 5,53 |
| 10. Алабуга | 32,8 | 22,4 | 8,8 | 64 | 32,8 | 22,4 | 11,7 | 0,5 | 67,4 |
| | 6,6 | 13,5 | 8,4 | 28,5 | 6,6 | 13,5 | 8,4 | 0,3 | 28,8 |
| 11. Зәй | 109,5 | 80,2 | 0,5 | 190,2 | 109,5 | 80,2 | 15,84 | 2,8 | 208,34 |
| | 2,6 | 5,7 | | 8,3 | 2,6 | 5,71 | 0,01 | 0,2 | 8,52 |
| 12. | | 16,7 | 1,5 | 18,2 | 7,67 | 6,12 | 12,88 | 0,5 | 27,17 |
| Зеленодольск | | 7,4 | 1,2 | 8,6 | 2,18 | 5,3 | 8,5 | 0,2 | 16,18 |
| 13. Арча | 8,1 | 17,5 | 3,8 | 29,4 | 8,1 | 17,54 | 3,81 | 0,2 | 29,65 |
| | 0,3 | 4,1 | 1,8 | 6,2 | 0,3 | 4,17 | 1,77 | 0,1 | 6,34 |
| 14. Кама | 30,6 | 27,9 | 14,6 | 72,8 | 30,6 | 27,9 | 14,6 | 0,9 | 74 |
| | 2,6 | 11,9 | 1,2 | 15,6 | 1,5 | 11,9 | 1,2 | 0,3 | 14,9 |
| 15. Кайбыч | 10,6 | 1,5 | 3,2 | 15,3 | 9,8 | 1,67 | 7,04 | 0,1 | 18,61 |
| | | 0,1 | 1,6 | 1,7 | 0,1 | 0,87 | 0,91 | 0 | 1,88 |
| 16. Кызыл- | 20,7 | 14,1 | 2,5 | 37,3 | 20,7 | 14,05 | 2,5 | 0,4 | 37,65 |
| Йолдыз | 0,2 | 4,9 | 0,3 | 5,4 | 0,2 | 4,93 | 0,25 | 0 | 5,38 |
| 17. Кәләй | 84,7 | 3,7 | 0,2 | 88,6 | 84,7 | 3,82 | 3,05 | 3,1 | 94,67 |
| | 1,6 | 1,1 | | 2,7 | 1,6 | 1,08 | 0 | 0,5 | 3,18 |
| 18. Болгар | 8,8 | 18,5 | 12,1 | 39,4 | 8,8 | 18,53 | 12,08 | 0,3 | 39,71 |
| | 0,2 | 3,7 | 4,2 | 8,1 | 0,2 | 3,71 | 4,22 | 0 | 8,13 |
| 19. Лаеш | 2,9 | 18,1 | 12,6 | 33,7 | 2,9 | 18,13 | 12,6 | 0,2 | 33,83 |
| | | 6,1 | 1,6 | 7,7 | 0 | 6,12 | 1,6 | 0 | 7,72 |
| 20. | 84,5 | 31,6 | 6,3 | 122,4 | 84,5 | 31,7 | 11,8 | 2,4 | 130,4 |
| Лениногорск | | 2,4 | 1,2 | 3,6 | 0 | 2,4 | 1,2 | 0,1 | 3,7 |
| 21. | 25,5 | 12,7 | 5,6 | 43,8 | 26,5 | 12,71 | 5,6 | 0,3 | 45,11 |
| Мамадыш | 4,4 | 5,6 | 4,5 | 13,8 | 4,4 | 5,64 | 4,51 | 0 | 14,55 |
| 22. Минзәлә | 83,5 | 38,4 | 9,8 | 131,7 | 83,5 | 38,4 | 10,4 | 0,6 | 132,9 |
| | 2,6 | 9,4 | 3 | 15 | 2,6 | 9,4 | 3 | 0,1 | 15,1 |
| 23. Түбән | 75,8 | 26,4 | 8,8 | 111 | 75,8 | 26,4 | 12,6 | 0,8 | 115,6 |
| Кама | 5,3 | 11 | 0,5 | 16,7 | 8,5 | 11 | 0,5 | 0,2 | 20,2 |
| 24. Нурлат | 193,5 | 19,7 | 5,7 | 218,8 | 193,5 | 19,8 | 29,7 | 1,2 | 244,2 |
| | 0,8 | 4,2 | 0,1 | 5,1 | 0,8 | 4,2 | 0,1 | 0 | 5,1 |
| 25. Идел буе | 9,9 | 10,1 | 9,4 | 29,2 | 9,9 | 10,4 | 9,5 | 0,2 | 30 |
| | | 0,8 | 0,9 | 1,7 | 0 | 0,8 | 0,9 | 0 | 1,7 |

| Урманчылык исеме | 2009елның 1 гыйнварына | | | | 2014 елның 1 гыйнварына | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Олгергән һәм картайган агачларны кисү | Урманнарны чистарту өчен кисү | Санитар кисүләр | Барлыгы | Олгергән һәм картайган агачларны кисү | Урманнарны чистарту өчен кисү | Санитар кисүләр | Төзелеш, реконструкция һәм объектлардан файдалану өчен каралган урман үсентеләрен кисү (РФ ЖК 13, 14, 21 ст.) | Барлыгы |
| | шул исәптән ылыслы | шул исәптән ылыслы | шул исәптән ылыслы | шул исәптән ылыслы | шул исәптән ылыслы | шул исәптән ылыслы | шул исәптән ылыслы | шул исәптән ылыслы | шул исәптән ылыслы |
| 26. Шәһәр | | 14,5 | 3,2 | 17,7 | 0 | 9 | 44,7 | 0,6 | 54,3 |
| яны | | 11,6 | 1,5 | 13,1 | 0 | 8 | 27,7 | 0,4 | 36,1 |
| 27. Саба | 75,1 | 50,8 | 5,3 | 131,2 | 68,7 | 23,59 | 51,37 | 0,3 | 143,96 |
| | 1,9 | 13,3 | 2,9 | 18,1 | 4,6 | 16,22 | 27,36 | 0,2 | 48,38 |
| 28. Тәтеш | 8,1 | 12,4 | 1,7 | 22,2 | 8,1 | 12,4 | 1,72 | 0,1 | 22,32 |
| | 0,2 | 0,3 | | 0,5 | 0,2 | 0,34 | 0,03 | 0 | 0,57 |
| 29. | 56,5 | 25,6 | 0,6 | 82,7 | 56,5 | 25,6 | 4,25 | 0,3 | 86,65 |
| Чирмешән | 1,5 | 1,4 | 0,1 | 3 | 1,5 | 1,42 | 0,11 | 0 | 3,03 |
| 30. Әлки | 62 | 67,2 | 7,2 | 136,5 | 62 | 67,2 | 7,2 | 0,2 | 136,6 |
| | | 2,6 | 0,4 | 3 | 0 | 2,6 | 0,4 | 0 | 3 |
| **Барлыгы** | **1404,9** | **646,9** | **177,5** | **2231,1** | **1406,37** | **604,53** | **348,88** | **29,1** | **2388,88** |
| | **53,7** | **173,1** | **49,4** | **272,8** | **60,78** | **171,26** | **106,64** | **4,2** | **342,88** |

Хисапланган урман кисүләрнең артуы Россия Федерациясе Урман кодексының 13, 14, 21 нче статьяларында төзелеш, объектларны реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен билгеләнгән урман утыртмаларын кисү буенча хисапланган урман кисүләрне кертүгә һәм санитар кисүләргә төзәтмәләр кертүбелән бәйле.

Агач әзерләүнең планлаштырыла торган күләмнәре, өлгергән һәм картайган агачларны кисүләрне дә кертеп, 13 нче кушымтада бирелә.

Урман ресурсларыннан файдалану ресурсның һәр төре буенча аерым кагыйдәләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла. Урманнардан файдалану, икътисадый мөнәсәбәтләр объекты буларак, финанс оешмасы аша алып барылырга тиеш. Агач әзерләүдән тыш, урманнардан файдалануның башка төрләре дә бар, алар республика икътисады өчен дә, урман хуҗалыгы өчен әһәмиятле булырга мөмкин.

Урманнардан файдалануның төрләр буенча планлаштырылган күләмнәре 14 нче кушымтада бирелә.

Файдалануның һәр төре буенча җитештерү күләме һәрвакыт үзгәрештә һәм бик күп факторларга бәйле, ресурслардан файдалана алу мөмкинлеге һәм инвестиция проектлары бу факторларның иң мөһимнәре булып тора.

## 2.4. Урманнардан нәтиҗәле файдалану эшчәнлегенең төп юнәлешләре һәм аны гамәлгә ашыру чаралары исемлеге

### 2.4.1. Агач әзерләү, агач эшкәртү, целлюлоза-кәгазь һәм агач кулланучы башка производстволарның планлаштырылган үсеше

Урман сәнәгате комплексының планлаштырылган үсеше түбәндәге юнәлешләр буенча максатчан программалар ярдәмендә гамәлгә ашырылырга тиеш:

1. Төзелеш комплексы өчен агач әйберләр номенклатурасын киңәйтү һәм аларны җитештерү күләмнәрен арттыру. Сәнәгатьне һәм төзелеш тармагын халыкның реаль акча керемен нисбәтле рәвештә үстерү Россия базарында урман продукциясенең барлык төрләренә ихтыяҗның артуына китерәчәк. Үткәрелгән тикшеренүләр соңгы елларда эчке базарда агач эшкәртү продукциясенә ихтыяҗ төзелеш тармагында – 2,8 мәртәбә (төзелеш материаллары, ябыштырылган фанера, плитәләр (ДСП, МДФ, OSB), җиһаз җитештерүдә 2,5 мәртәбә артуны күрсәтә. Республикада торак төзелешен ел саен кимендә 50 мең $м^2$га арттыру планлаштырыла. Хәзерге вакытта Европа урман базарында төзелеш өчен һәм җиһаз ясау өчен югары сыйфатлы продукциягә сорау арту күзәтелә.

2. «Россия гражданнарына һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак» федераль максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында агачтан торак төзүне оештыру. Торак төзелешен үстерү, заманча технологияләр нигезендә югары әзерлектәге өйләр комплектын эшләп чыгару буенча җитештерү индустриясе булдыру күздә тотыла. Россия Федерациясе Агачтан торак төзү ассоциациясе якын киләчәккә әлеге юнәлеш потенциалын, дәүләт ярдәме күрсәтелгән очракта, елына 24 млн. $м^2$ дип исәпли.

3. Агач эшкәртү калдыкларын күләмнең кимүе, агач ягулык брикеты, агач күмере эшләп чыгаруны оештыру юлы белән калдыксыз җитештерүгә ирешү, бу агач эшкәртүнең файдаланылмый торган калдыкларын шактый киметергә һәм энергия саклау технологияләрен кертү кысаларында республикадагы экологик хәлне яхшыртырга мөмкинлек бирәчәк.

4. Дәүләт ярдәме күрсәтү, ул түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- урман сәнәгате комплексы предприятиеләренең сезонара чимал запаслары һәм ягулык өчен кредит оешмаларыннан алган кредитлары буенча процент ставкасын субсидияләү;
- урман сәнәгате комплексы предприятиеләренең инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен кредит оешмаларыннан алган кредитлар буенча процент ставкасын, шулай ук лизинг компанияләреннән алынган җитештерү җайланмалары, җитештерү билгеләнешендәге күчемсез мөлкәт объектлары, транспорт чаралары һәм махсус техника өчен лизинг түләүләре өлешен субсидияләү;
- урман комплексы предприятиеләренә оешмалар табышына салым һәм оешмалар мөлкәтенә салым буенча законнарда каралган ташламалар ясау.

2009 – 2018 елларда агач чыгаруның планлаштырылган күләмнәрен тәэмин итү өчен һәм агач әзерләү предприятиеләренең тотрыклы эшчәнлеге өчен гомуми озынлыгы 145 км булган урман ташу юллары төзү күздә тотыла.

Агач эшкәртү производствосының үсеш потенциалы түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- функциональ производстволарны проектта каралган куәтләренә җиткерү;
- агач кисү һәм агач эшкәртү җайланмаларын модернизацияләү;
- кече бизнесны үстерү, агач эшкәртү продукцияләрен җитештерүдә кече предприятиеләрнең өлешен гомуми санның 25 процентына кадәр җиткерү, хәзерге вакытта ул бары тик 14,3 процентны тәшкил итә.

Билгеләнгән өстенлекләрне гамәлгә ашыру урман сәнәгате комплексын югары рентабельле тотрыклы эшчәнлек белән тәэмин итәчәк.

Урман сәнәгате комплексын тизләтелгән үстерүнең төп проектларын гамәлгә ашыру өчен 10 млрд. сумнан артыграк инвестицияләр таләп ителә.

Планлаштырылган чаралар урман сәнәгате продукциясен эшләп чыгаруны арттырырга мөмкинлек бирәчәк. Шулай итеп, 2018 елга житештерү күләме, 2012 елга караганда, 1,7 тапкыр артачак.

Республикада агач эшкәртү һәм агачтан әйберләр ясау производстволарын 3 төп төркемгә бүләргә мөмкин:

– эре агач эшкәртү һәм җиһаз предприятияләре – Зеленодольск, Алабуга районнары;

– »Урман» ДБУ агач әзерләү һәм агач эшкәртү производстволары;

– Казан шәһәрендә һәм республиканың башка торак пунктларында урнашкан агач эшкәртү һәм җиһаз ясау предприятиеләре.

Республиканың эре агач эшкәртү предприятиеләре – «ПФМК» ЯАЖр (НП) һәм «ЗФЗ» ААҖ, фанера сату буенча уңайлы конъюнктурадан файдаланып,продукциянең тиешле сыйфатына ирешеп, ерак чит илләр базарлары белән хезмәттәшлек итә, «ПФМК»ЯАЖр (НП) эшләп чыгарыла торган җиһаз продукциясенең 90 процентка якыны һәм «ЗФЗ» ААҖжитештерелә торган фанераның 85 процентка якыны экспортка озатыла.

Татарстан Республикасы урман хуҗалыгының икенче төркеме «Урман» дәүләт бюджет учреждениеләренә тупланган, аңа төп агач әзерләүчеләр булган утыз предприятие керә, базарда аларның продукциясе әлеге конкурентлылыкка сәләтле түгел.

Агач эшкәртү һәм агачтан әйберләр ясау буенча өченче төркем предприятиеләргә республика шәһәрләрендә һәм районнарында урнашкан күпсанлы вак һәм урта предприятиеләр керә, алар нигездә читтән кайтартылган сыйфатлы чимал, күп очракта ылыслы агачлар белән эшли.

Хәзерге вакытта бу тармак реформа стадиясендә.

Хәзерге вакытта гамәлдә булган агач әзерләү һәм агач эшкәртү куәтләре нык тузган һәм әзерләнә торган барлык агачны арадашчы буларак та эшкәртеп битерә алмый.

Татарстан Республикасы районнарында яңа житештерү комплекслары төзергә кирәк.

Ябыштырылган агач конструкцияләр җитештерүчеләр һәм кулланучылар ассоциациясе (НО РАДеКК) һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан «Агачны тулысынча эшкәртеп бетерү нигезендә аз катлы торак төзү индустриясе өчен житештерү куәтләрен булдыру» буенча бизнес-план проекты эшләнә, аның максаты елына 500 мең кв.м һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак төзү, төзелеш материаллары җитештерү, агач эшкәртү калдыкларын пеллетлар эшләп чыгару өчен яңадан эшкәртү.

Татарстан Республикасында урманнарны тулысынча үзләштерү һәм товар буларак сыйфаты түбән агачны эшкәртү өчен «Алабуга» махсус икътисадый зонасында төрек компаниясе «Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» ЖЧҖ тарафыннан завод төзелә. Төзелгән шартнамәләр нигезендә 2013 елда заводта 834 мең $м^3$ агач эшкәртү планлаштырыла. 2014 елда заводка – 1 млн. 400 мең $м^3$, 2015 елда 2 млн. 100 мең$м^3$ агач таләп ителәчәк.

Югары технологияле җайланмаларны кулланып агач әзерләүне оештыру һәм агач белән тәэмин итү мәсьәләсен хәл итү өчен урман тармагын модернизацияләү кысаларында 2011 елда Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан югары технологияле агач әзерләү техникасы – 8 берәмлек Харвестер һәм 8 берәмлек Форвардер машиналары сатып алынды. Әлеге агач әзерләү машиналарының җитештерүчәнлеге бер сменага 100 $м^3$дан 150 $м^3$ га кадәр тәшкил итә. «Саба уку-тәҗрибә урман хуҗалыгы» ДБУ базасында бу урман техникасында эшләү өчен операторларны өйрәтү оештырылды.

«2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә урманнарны торгызуга һәм урман ресурсларыннан файдалануга бәйле чаралар өчен агач әзерләү техникасын сатып алуга 100,0 млн. сум бюджет инвестициясе бирелде, аңа 4 берәмлек Харвестер һәм 4 берәмлек Форвардер машиналары сатып алу планлаштырыла.

Агач ташуларны оештыру өчен «Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» ҖЧҖ мәйданчыгында «Урман транспорт компаниясе» ААҖ оешты, аның составында КАМАЗ автомобиле базасындагы 20 махсус машина эшли. Агымдагы елның 25 сентябреннән «Урман транспорт компаниясе» ААҖ «Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» ҖЧҖ заводына агач ташый башлады.

2013 елда «Саба урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе территориясендә түбән сортлы агачларны эшкәртү буенча агач эшкәртү комплексы кулланылышка тапшырылды. Әлеге агач эшкәртү комплексының проект куәте елына 179,6 млн. сумлык 600 мең агач поддон, 182,8 млн. сумлык 32,0 мең $м^3$ гомуми кулланылыштагы төзелеш материаллары, 93,7 млн. сумлык 6,0 мең тонна агач оны һәм 79,5 млн. сумлык 22,0 мең тонна пеллетлар (ягулык гранулалары) җитештерүне һәм реализацияләүне күздә тота, товарның барлык төрләре буенча реализацияләнгән продукция суммасы елына 535,7 млн. сум тәшкил итәчәк. Агач эшкәртү комплексының агачка еллык ихтыяҗы– 141,0 тыс. $м^3$ тәшкил итә.

«Энерголеспром» ҖЧҖ инновация компаниясе һәм «Казан милли-тикшеренү технологик университеты» ЮҺБ ДМУ галимнәре белән берлектә «Уку-тәҗрибә Шәһәр яны урман хуҗалыгы» ДБУ базасында товар сыйфаты түбән булган агачны сыек биоягулык һәм агач күмере эшләп чыгару өчен термохимик эшкәртү технологиясен эшләү буенча инновация проекты гамәлгә ашырыла. Кече инновация компаниясе «Энерголеспром» ҖЧҖ «Сколково» инновация үзәге резиденты булып тора һәм Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрлыгы, «Татарстан Республикасы инновация-венчур фонды» дәүләт коммерциягә карамаган оешмасы ярдәме белән һәм техник фәннәр докторы профессор А.Н. Грачев җитәкчелегендә товар сыйфаты түбән агачны, агач кисү калдыкларын эшкәртү өчен җитештерүчәнлеге сәгатенә 50 кг булган (КПД 80 – 85%) тәҗрибә-эксперимент җайланмалары эшләде һәм аларны Столбище урман хуҗалыгында сынап карый. 2012 ел нәтиҗәләре буенча Столбище участок урманчылыгындагы пилот кишәрлеге кысаларында 1000 $м^3$ артыграк товар сыйфаты түбән агач һәм калдыклар эшкәртелде. Бу эшчәнлеккә капиталь һәм агымдагы чыгымнар 4 млн. сум, эшкәртүнең энергетика нәтиҗәлелеге 65 – 70 процент тәшкил итә. Калдыкларны

юкка чыгару, эчке куллану һәм торак-коммуналь хуҗалык өчен товар продукциясен реализацияләү уңай экологик нәтиҗәләргә китерә.

Хәзерге вакытта компания товар сыйфаты түбән булган агачны, агач кисү калдыкларын эшкәртү өчен җитештерүчәнлеге сәгатенә 500–1000 кг (йомычка 3,3-3,6 $м^3$/с.) булган күчмә җитештерү комплексларын эшли.

Татарстан Республикасында «Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә агач продукциясе ташый торган 17 дәүләт казна учреждениесенең (Азнакай, Аксубай, Әлмәт, Баулы, Биләр, Бөгелмә, Алабуга, Зәй, Кәләй, Кама, Кызыл Йолдыз, Лениногорск, Мамадыш, Минзәлә, Түбән Кама, Нурлат, Чирмешән урманчылыклары) урман белән идарә итүен сертификацияләү буенча пилот проекты гамәлгә ашырыла башлады.

Проектны гамәлгә ашыру кысаларында 27 сентябрьдә Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында урманчылык һәм министрлык белгечләре өчен «Урман белән идарә итү буенча сертификат алуга әзерләнүнең гамәли мәсьәләләре» темасына урман FCS сертификаты буенча өйрәтү семинары үткәрелде. Урман белән идарә итүгә һәм урманнан файдалануга аудит үткәрү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 2013 елның 10 сентябрендәге 1701-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына 250 мең сум акча бүлеп бирелде, хәзерге вакытта башлангыч аудит үткәрү өчен аукцион документлары әзерләнә.

Татарстан Республикасы урманчылыкларын сертификацияләү чимал ташуга FSC сертификатын алган агач әзерләү һәм урман эшкәртү компанияләренең артуына китерәчәк, чөнки урманнардан файдалану сертификат алган территорияләрдә (урманчылык сертификацияләнгән очракта) башкарылачак һәм FSC таләпләре урман мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның барысына да кагылачак.

### 2.4.2. Агачка булган ихтыяҗның фаразлана торган үзгәрешләре

Татарстан Республикасы урман сәнәгатендәге вәзгыять тулысынча илнең бу тармагындагы күренешне кабатлый, ә агач әзерләү һәм агач чыгару тармакларында хәл катлаулырак. Статистика белешмәләренә караганда, хәзерге вакытта урман сәнәгате комплексы ВВП җитештерүенең 1 процентка якынын һәм Россия Федерациясендә сәнәгать продукциясе җитештерүнең гомуми күләменең 4 процентка якынын тәэмин итә.

Татарстан Республикасында урманнарны тулысынча үзләштерү һәм товар сыйфаты түбән булган агачны эшкәртү өчен «Алабуга» махсус икътисадый зонасында төрек компаниясе «Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» ҖЧҖ тарафыннан завод төзелә. Төзелгән шартнамәләр нигезендә, 2013 елда заводта 834 мең $м^3$ агач эшкәртү планлаштырыла. 2014 елда заводка – 1 млн. 400 мең $м^3$, 2015 елда 2 млн. 100 мең$м^3$ агач таләп ителәчәк.

2013 елда «Саба урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе территориясендә түбән сортлы агачларны эшкәртү буенча агач эшкәртү комплексы кулланылышка тапшырылды. Агач эшкәртү комплексының агачка еллык ихтыяҗы 141,0 мең $м^3$тәшкил итә.

Соңгы биш елда агачны һәм целлюлоза-кәгазь әйберләрен экспортка чыгарудан керемнәр 2,9 тапкыр артты, эшкәртелмәгән агачны экспортлау 6,6 тапкыр, эшкәртелгән агачны экспортлау 40 процентка артты. Татарстан Республикасында агач эшкәртү продукцияләрен экспортлау динамикасы буенча белешмәләр 2.4.2.1 нче таблицада бирелә.

2.4.2.1 нчетаблица

**2012 елда Татарстан Республикасы урман сәнәгате комплексы продукциясенең төп төрләрен экспортлау**

| Продукция исеме | Күләме, мең $м^3$ |
|---|---|
| Фанера | 48 |

Россия Федерациясенең экспортка чыгарыла торган продукциясе арасында агачны һәм агач әйберләрен экспортлау өлеше 4,0 процент тәшкил итә, бу Татарстан Республикасы күрсәткечләренә караганда берничә тапкыр артык.

Агач-кәгазь продукциясенә чит илләрдә сорауның артуы бу илләр икътисадында урман секторының тоткан урыны ныгый баруны күрсәтә. 2015 елга дөнья базарында агач-кәгазь продукциясенә ихтыяҗ түбәндәгечә артыр дип фаразлана:

– эшкә яраклыагачбуенча 1906 млн. $м^3$;

– төзелеш материаллары буенча 425 млн. $м^3$;

–фанераһәм плитә рәвешендәгепродукция буенча 403 млн. $м^3$.

Үткәрелгән тикшеренүләр Россия Федерациясенең эчке базарында да 2016 елга агач-кәгазь продукциясенә сорауның артачагын күрсәтә:

– эшкә яраклыагачбуенча 224,2 млн. $м^3$;

– төзелеш материаллары 35,0 млн. $м^3$;

– фанерабуенча 3,8 млн. $м^3$.

## 2.4.3. Агач ресурсларын исәпкә алуның төгәллеген арттыру, урман өлкәсендәге законнарның үтәлешен тикшереп тору

Урман ресурсларын исәпкә алуның төгәллеген арттыру

Урман фонды җирләрендә урман ресурсларын исәпкә алу урман эшләрен башкарган вакытта яисә махсус тикшеренүләр вакытында үткәрелә. Урман эшләре үз эченә ала торган чаралар һәм аларны үткәрү тәртибе Россия Федерациясе Урман кодексында (67 – 70 статьяларда) һәм Федераль урман хуҗалыгы агентлыгының 2011 елның 12 декабрендәге 516 номерлы «Урман эшләре инструкциясен раслау турында» боерыгында билгеләнгән.

Урман фонды җирләрендә, торак пунктлар җирләрендә, оборона һәм иминлек органнары җирләрендә, аеруча саклана торган табигать территорияләре җирләрендә урнашкан урманнарда урман эшләренең составы, ысулы һәм төгәллеге ягыннан

таләпләр Россия урман хуҗалыгының 2011 елның 12 декабрендәге 516 номерлы боерыгында билгеләнгән.

Махсус тикшеренүләр үткәрүгә таләпләр методикалар, техник шартлар, техник биремнәр нигезендә билгеләнә.

Урман эшләре инструкциясе буенча, урман ресурларын исәпләүнең төгәллегенә ирешү өчен һәр урманчылык, урман-парк яисә урман кишәрлеге өчен урман эшләре разряды билгеләнә.Урман эшләре разряды урман кварталы һәм таксация кишәрлеге күләмнәренә бәйле.

Татарстан Республикасында урман эшләре законнар, методик һәм норматив документлар нигезендә I разрядлы төгәллек белән 2001 – 2005 елларда (шулай ук 2011 елда Шәһәр яны, Зеленодольск, Кайбыч һәм Сабаурманчылыкларында) үткәрелде.

Таксация күреп санау ысулы кулланып үткәрелде, бу ысул күрү һәм аралаштырып санау таксацияләренә нигезләнә һәм аның нигезендә алынган белешмәләр урманда таксация кишәрлегенең таксация характеристикаларын төзү өчен нигез булып тора.

Урман таксациясенең җентекле һәм төгәл булуына таләпләр аларның максатчан билгеләнешенә һәм географик урнашуына, өйрәнелү дәрәҗәсенә, урманга антропоген йогынтының интенсивлыгына бәйле.

Сынап карау мәйданнары өчен утыртмалар кишәрлекләрен сайлау ысулы һәм техникасы«Урман эшләрен сынап карау мәйданнары. Эшләү ысуллары»ОСТ 56-69-83 һәм «Урман эшләренең һәм урман хуҗалыгының натураль билгеләре. Төрләре, күләме һәм гомуми техник таләпләр»ОСТ 56-44-80 тармак стандартлары, шулай ук «Урманнарны таксацияләү өчен гомумсоюз нормативлары» белән җайга салына.

Урман эшләре үзенчәлекләрен төрле яклау тикшерү максатларында ике киңәшмә үткәрелә. Беренче киңәшмә кырлардагы урман эшләре башланырга кимендә ике ай кала, икенчесе – кырда җыелган материалларны камераль тикшерү тәмамланганнан соң үткәрелә. Урман эшләре киңәшмәләрендә кабул ителгән карарлар законнарга, урман хуҗалыгын алып бару һәм урманнардан файдалану буенча гамәлдә булган инструкция нигезләмәләренә һәм башка норматив документларга каршы килергә тиеш түгел. Алар урман эшләре белән шөгыльләнә торган оешмалар, урманнардан файдаланучылар, урман хуҗалыгы белән идарә итүнең территориаль органнары тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш.

Урман фонды торышы турында актуаль мәгълүмат алу һәм хуҗалык эшләрен билгеләү өчен Татарстан Республикасы урманчылыкларында 2011 елдан 2017 елга кадәр урман эшләре үткәрү планлаштырыла. Урман эшләренең планлаштырыла торган күләме һәм аны үткәрү чыгымнары 2.4.3.1 нче таблицада бирелә.

2.4.3.1 нче таблица

**Урман эшләренең планлаштырыла торган күләмнәре һәм аларны уздыру чыгымнары**

| Урманчылык | Мәйдан, мең га | Мәйдан, га / чыгымнар, мең сумнарда | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2009 ел | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | Барлыгы |
| Әгерҗе | 45,3 | | | | | | | 45346 | | | | 45346 |
| | | | | | | | | 10087,7 | | | | 10087,7 |
| Азнакай | 46,1 | | | | | | | 46103 | | | | 46103 |
| | | | | | | | | 10256,1 | | | | 10256,1 |
| Аксубай | 29,6 | | | | | | | 29622 | | | | 29622 |
| | | | | | | | | 6589,7 | | | | 6589,7 |
| Әлки | 37,5 | | | | | | | | 37462 | | | 37462 |
| | | | | | | | | | 8333,8 | | | 8333,8 |
| Әлмәт | 50,2 | | | | | | | 50166 | | | | 50166 |
| | | | | | | | | 11159,9 | | | | 11159,9 |
| Арча | 32,2 | | | | | | 32203 | | | | | 32203 |
| | | | | | | | 5440,4 | | | | | 5440,4 |
| Баулы | 23,4 | | | | | | | 23437 | | | | 23437 |
| | | | | | | | | 5213,8 | | | | 5213,8 |
| Биләр | 50,8 | | | | | | | | 50775 | | | 50775 |
| | | | | | | | | | 1129,54 | | | 1129,54 |
| Болгар | 18,9 | | | | | | | 18852 | | | | 18852 |
| | | | | | | | | 4193,8 | | | | 4193,8 |
| Бөгелмә | 44,1 | | | | | | | 44133 | | | | 44133 |
| | | | | | | | | 9817,8 | | | | 9817,8 |
| Буа | 18,6 | | | | | | 18567 | | | | | 18567 |
| | | | | | | | 3136,7 | | | | | 3136,7 |
| Алабуга | 29 | | | | | | 29053 | | | | | 29083 |
| | | | | | | | 4939 | | | | | 4939 |
| Зәй | 58,9 | | | | | | | 58897 | | | | 58897 |
| | | | | | | | | 13102,2 | | | | 13102,2 |

| Урманчылык | Мәйдан, мең га | Мәйдан, га / чыгымнар, мең сумнарда | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2009 ел | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | Барлыгы |
| Зеленодольск | 26,4 | | | 26356 | | | | | | | | 26356 |
| | | | | 2885,98 | | | | | | | | 2885,98 |
| Ары | 17,2 | | | | | | 17182 | | | | | 17182 |
| | | | | | | | 2902,9 | | | | | 2902,9 |
| Кайбыч | 25,3 | | | 25291 | | | | | | | | 25291 |
| | | | | 2769,37 | | | | | | | | 2769,37 |
| Кәләй | 41,7 | | | | | | | 41680 | | | | 41680 |
| | | | | | | | | 9272,1 | | | | 9272,1 |
| Кама | 54,2 | | | | 9939 | | 44227 | | | | | 54166 |
| | | | | | 1000 | | 7518,6 | | | | | 8518,6 |
| Кызыл Йолдыз | 42,6 | | | | | | 42602 | | | | | 42602 |
| | | | | | | | 7242,3 | | | | | 7242,3 |
| Лаеш | 34 | | | | | | 34031 | | | | | 34031 |
| | | | | | | | 5785,3 | | | | | 5785,3 |
| Лениногорск | 52,8 | | | | | | 52837 | | | | | 52837 |
| | | | | | | | 8982,3 | | | | | 8982,3 |
| Лубян | 13 | | | | 12996 | | | | | | | 12966 |
| | | | | | 570 | 950 | | | | | | 1520 |
| Мамадыш | 47,8 | | | | | | 47772 | | | | | 47772 |
| | | | | | | | 8070,6 | | | | | 8070,6 |
| Минзәлә | 71,9 | | | | | | | | 71918 | | | 71918 |
| | | | | | | | | | 15998,9 | | | 15998,9 |
| Түбән Кама | 43,5 | | | | | | | | 43486 | | | 43486 |
| | | | | | | | | | 9673,9 | | | 9673,9 |
| Нурлат | 88,5 | | | | | | 88545 | | | | | 88545 |
| | | | | | | | 14958,8 | | | | | 14958,8 |
| Идел буе | 28,2 | | | | | | 28166 | | | | | 28166 |
| | | | | | | | 4758,4 | | | | | 4758,4 |
| Шәһәр яны | 30,4 | | | 30401 | | | | | | | | 30401 |
| | | | | 3328,91 | | | | | | | | 3328,91 |
| Саба | 60,3 | | | 60292 | | | | | | | | 60292 |
| | | | | 6601,97 | | | | | | | | 6601,97 |

| Урманчылык | Мәйдан, мең га | Мәйдан, га / чыгымнар, мең сумнарда | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2009 ел | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | Барлыгы |
| Тәтеш | 37,6 | | | | | | 37632 | | | | | 37632 |
| | | | | | | | 6357,6 | | | | | 6357,6 |
| Чирмешән | 36,4 | | | | | | 36373 | | | | | 36373 |
| | | | | | | | 6169,6 | | | | | 6169,6 |
| Барлыгы | 1236,4 | 0 | 0 | 142340 | 22935 | 0 | 509190 | 358236 | 203641 | 0 | 0 | 1236342 |
| | | 0 | 0 | 15586,2 | 1570 | 950 | 86262,5 | 79693,1 | 35136,1 | 0 | 0 | 219197,97 |

# Урманнар белән идарә итү һәм урманнар өлкәсендә законнар үтәлешен тикшереп тору

Федераль дәүләт урман күзәтчелегенең (урманны саклау) һәм Урман янгыннарына каршы федераль дәүләт күзәтчелегенең төп максаты урманнар өлкәсендә законнар үтәлешен тикшереп тору, аларга түбәндәгеләр керә:

Россия Федерациясе Урман кодексы;

«Федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урманны саклау) гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 22 июнендәге 394 номерлы карары;

«Дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге) мәсьәләләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 5 июнендәге 476 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урманны саклау) Россия Федерациясе норматив хокукый актларына һәм урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә тапшырылган вәкаләтләрне башкару өчен эшләнгән түбәндәге Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына таянып гамәлгә ашыра:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы турында» 2006 елның 22 декабрендәге УП-581 номерлы Указына;

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урманнарда янгыннарга каршы таләпләрнең үтәлешен тикшереп тору һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү юлы белән урман янгыннарына каршы федераль дәүләт күзәтчелеге буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламентын раслау хакында» 2013 елның 4 июлендәге УП-594 номерлы Указына;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урманнар өлкәсендә законнарның үтәлешен тикшереп тору һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү юлы белән федераль дәүләт урман күзәтчелеге (урман сагы) буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламентын раслау хакында» 2013 елның 13 июлендәге УП-627 номерлы Указына;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте регламентын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 5 декабрендәге 563 номерлы карарына;

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 12 февралендәге 38 номерлы карарына;

«Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы белән идарә итү органнарын реформалау чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 27 июлендәге 332 номерлы карарына;

«Татарстан Республикасы урман инспекторының хезмәт таныклыгы турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 13 августындагы 385 номерлы карарына;

«Урманнарда федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урманны саклау) һәм урман янгыннарына каршы федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыра торган вазыйфаи затлар исемлеген раслау хакында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетынын 2010 елның 12 ноябрендәге 893 номерлы карарына

һәм түбәндәге ведомство норматив хокукый актларына, шул исәптән «Административ хокук бозулар турында эшләрне башкарганда процессуаль документларны раслау турында» Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2011 елның 12 августындагы 367-төп номерлы боерыгына.

Федераль дәүләт урман күзәтчелеге һәм урманнарда янгынга каршы федераль дәүләт күзәтчелеге өлешендә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен үтәүне тикшереп тору Федераль урман хуҗалыгы агентлыгына йөкләнгән. Федераль дәүләт урман күзәтчелеге һәм урманнарда янгынга каршы федераль дәүләт күзәтчелеге, Россия Федерациясе Урман кодексының 81 – 83 статьяларында билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында, Россия Федерациясе Урман кодексының 96 һәм 97 статьялары нигезендә дәүләт хакимияте органнары карамагына бирелгән.

Республика территориясендә урманнарга идарә итү Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасында урман хуҗалыгын алып баруны оештыруның идарә һәм административ функцияләре дәүләт казна учреждениеләренә – урманчылыкларга тапшырылган.

Урманнардан комплекслы һәм рациональ файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы дәүләт казна учреждениеләре – урманчылыклар эшчәнлегенә дәүләт идарәсен һәм аларны тикшереп торуны гамәлгә ашыра.

Республикада федераль дәүләт урман күзәтчелеге (урманны саклау) һәм урманнарда янгынга каршы федераль дәүләт күзәтчелеге түбәндәге вазыйфаи затлар тарафыннан башкарыла:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында:

– министр– Татарстан Республикасы баш дәүләт урман инспекторы;

– министрның беренче урынбасары – баш урманчы – Татарстан Республикасы баш дәүләт урман инспекторы урынбасары;

– урман мөнәсәбәтләре өлкәсендәге мәсьәләләрне алып баручы структур бүлекчәләр башлыклары – Татарстан Республикасы өлкән дәүләт урман инспекторлары;

– урман мөнәсәбәтләре өлкәсендәге мәсьәләләрне алып баручы структур бүлекчәләр белгечләре – Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторлары.

2. Урманчылыкларда:

– җитәкчеләр – урманчылар – Татарстан Республикасы өлкән дәүләт урман инспекторлары;

– җитәкче урынбасарлары – Татарстан Республикасы өлкән дәүләт урман инспекторларыурынбасарлары;

– участок урманчылыкларының урман мөнәсәбәтләре өлкәсендәге мәсьәләләрне алып баручы белгечләре, урманчылар, участок мастерлары – Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторлары.

Федераль дәүләт урман күзәтчелеге (урманны саклау) һәм урманнарда янгынга каршы федераль дәүләт күзәтчелеге дәүләт хакимияте органнары тарафыннан үз вәкаләтләре кысаларында планлаштырылган тикшерүләр, шулай ук «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә планнан тыш тикшерүләр үткәрү юлы белән башкарыла.

Планнан тыш тикшерүләр түбәндәге максатларда үткәрелә:

– урманнар өлкәсендәге законнар бозуларны бетерү турында элек бирелгән күрсәтмәне үтәүне тикшерү өчен;

– урманнар өлкәсендә законнарны бозу турында дәүләт хакимияте органарыннан һәм жирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан һәм гражданнардан алынган мәгълүмат документлар һәм башка материаллар белән расланган очракта.

Оборона һәм иминлек органнары жирләрендә урнашкан урманчылыклар территориясендә федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урманны саклау) һәм урманнарда янгынга каршы федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда планлаштырылган һәм планнан тыш тикшерүләр оборона һәм иминлек өлкәсендә вәкаләтле федераль дәүләт хакимияте органнары белән килештерелә. Үткәрелә торган чаралар «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларнын һәм индивидуаль эшкуарларнын хокукларын яклау турында» федераль закон таләпләрен үтәп башкарыла.

Үзләренә карата федераль дәүләт урман күзәтчелеге (урманны саклау) һәм урманнарда янгынга каршы федераль дәүләт күзәтчелеге гамәлгә ашырыла торган юридик затлар һәм шөхси эшкуарлар Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторларының мондый тикшерү үткәрелә торган объектларга керүен тәэмин итәргә һәм аларны тикшерү өчен кирәкле документлар белән тәэмин итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторлары федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урманны саклау) һәм урманнарда янгынга каршы федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча үзләренә йөкләнгән функцияләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән рәвештә җаваплы булалар.

Федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урманны саклау) һәм урманнарда янгынга каршы федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторлары түбәндәгеләргә хокуклы:

а) урман законнарын бозуларны билгеләнгән тәртиптә туктатып калырга һәм бетерергә;

б) урман өлкәсендә законнарның үтәлешен тикшерергә;

в) тикшерү нәтиҗәләре буенча актлар төзергә һәм бу актларны, танышу өчен, урман кишәрлекләреннән файдалана торган юридик затларга, шөхси эшкуарларга җибәрергә;

г) тикшерүләр нәтиҗәсендә ачыкланган закон бозуларны бетерү турында үтәлүе мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирергә һәм билгеләнгән срокларда бу күрсәтмәләрнең үтәлешен тикшерергә;

д) билгеләнгән тәртиптә транспорт чараларын тикшерергә һәм, кирәк булганда, аларны токтарларга;

е) урманнардан файдалана торган, аларны саклау, яклау һәм торгызу белән шөгыльләнә торган затларга урман өлкәсендә законнар үтәлешен тикшерү нәтиҗәләре һәм ачыкланган хокук бозулар турында хәбәр итәргә;

ж) тикшерүләр нәтиҗәсендә ачыкланган хокук бозуларны бетерүне таләп итәргә;

з) федераль законнарда каралган башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

Татарстан Республикасында баш дәүләт урман инспекторы һәм аның урынбасарлары, югарыда саналган хокуклардан тыш, түбәндәгеләргә хокуклы:

а) судларга үз компетенцияләре чикләрендә дәгъва белдерергә;

б) тиешле анализлар, пробалар, тикшерүләр үткәрү һәм тикшерелә торган предмет буенча бәяләмәләр әзерләү өчен фәнни-тикшеренү, проект-тикшеренү оешмаларын һәм башка оешмаларны җәлеп итәргә.

Федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урманны саклау) һәм урманнарда янгынга каршы федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда дәүләт урман инспекторлары түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

а) урман өлкәсендә законнар бозуларны кисәтү, ачыклау һәм бетерү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы күләмдә үтәргә;

б) Россия Федерациясе законнарын үтәргә, юридик затларның һәм гражданнарның законлы мәнфәгатьләрен кайгыртырга;

в) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урманны саклау) һәм урманнарда янгынга каршы федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырырга;

г)федераль дәүләт урман күзәтчелеге (урманны саклау) һәм урманнарда янгынга каршы федераль дәүләт күзәтчелеге чараларын гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар вәкилләренә токтарлык ясамаска, тикшерү предметы буенча аңлатулар алып барырга;

д) федераль дәүләт урман күзәтчелеге (урманны саклау) һәм урманнарда янгынга каршы федераль дәүләт күзәтчелеге чараларын гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар вәкилләренә тикшерү предметына кагылышлы кирәкле мәгълүмат бирергә;

е) юридик затларның вазыйфаи затларын яисә шәхси эшкуарлар вәкилләрен федераль дәүләт урман күзәтчелеге (урманны саклау) һәм урманнарда янгынга каршы федераль дәүләт күзәтчелеге буенча үткәрелгән чараларның нәтиҗәләре белән таныштырырга;

ж) хокук бозулар өчен билгеләнә торган чараларны сайлаганда хокук бозуларның авырлыгын, аларның кеше гомере, сәламәтлеге өчен, әйләнә-тирә мохит һәм мөлкәт өчен куркынычлылык дәрәҗәсен истә тотарга, шулай ук юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезләнмәгән чикләүләрне рөхсәт итмәскә тиеш;

з) юридик затлар һәм гражданнар тарафыннан үз гамәлләренә шикаять белдерелгән очракта, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә хаклыгын исбатларга;

и) федераль законнарда каралган башка вазыйфаларны үтәргә.

Урманнар өлкәсендә законнар үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итү структурасы 2.4.3.1 нче рәсемдә бирелә.




2.4.3.1 нче рәсем. Урман турындагы законнарның үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итү структурасы

Агачны рөхсәтсез әзерләүләрне, аның законсыз әйләнешен ачыклау һәм булдырмау чаралары

Агач әзерләү, транспортлау, эшкәртү, сату һәм экспортлау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы УП-342 номерлы Указы белән Татарстан Республикасында агач материалларын законсыз әзерләүне, транспортлауны, эшкәртүне, сатуны һәм экспортлауны кисәтү һәм туктату мәсьәләләре ведомствоара комиссиясе төзелде.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 29 ноябрендәге ВЗ-П9-8105 номерлы, 2011 елның 24 февралендәге ВЗ-П9-1030 номерлы күрсәтмәләрен һәм Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы УП-342 номерлы Указын үтәү йөзеннән, федераль башкарма хакимият органнарының кызыксынган территориаль органнары белән берлектә, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «2012-2014 елларга әзерләү, транспортлау, эшкәртү, сату һәм экспортлаунықисәтү һәм булдырмау планы» эшләнде һәм расланды.

Эчке эшләр органнары белән ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында ел дәвамында «Чыршы», «Агач ташу» һәм башка шартлы исемнәр белән аталган оператив-профилактик чаралар һәм урман утыртмаларын законсыз кисүләрне кисәтүгә һәм булдырмауга юнәлдерелгән башка чаралар уздырыла.

Урманчылык белгечләре һәм Россия ЭЭМ территориаль бүлекләре хезмәткәрләре катнашында төзелгән мобиль патрульлек итү төркемнәре тарафыннан урман массивларында килешенгән маршрутлар буенча патрульлек итү гамәлгә ашырыла.

Законсыз киселгән, тартып алынган агач, Дәүләт мөлкәте белән идарә итү буенча федераль агентлыкның Татарстан Республикасында территориаль идарәсе һәм аның тикшерү органнары белән килешенеп, тикшерү чаралары тәмамланганчы һәм агач сатуга тапшырылганчы Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы «Урман» дәүләт бюджет учреждениеләренең җитештерү базаларында саклана.

Урманнар өлкәсендәге законнарны утыртмаларны законсыз кисү өлешендә бозу фактлары буенча материалларны дөрес һәм үз вакытында рәсмиләштерүне тәэмин итү максатыннан, Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторлары өчен Россия ЭЭМ территориаль бүлекләре һәм прокуратура органнары вәкилләре катнашында «Урманчылык» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре базасында семинар-киңәшмәләр үткәрелә.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында агач эшкәртү, транспортлау һәм әзерләү белән шөгыльләнә торган юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның реестры төзелде, Россия Федерациясе Җинаять кодексының 260 статьясы буенча гаепле затларны җинаять җаваплылыгына тарту буенча тикшерү органнарына тапшырылган эшләрнең мониторингы алып барыла, гаепле затларны җаваплылыкка тартуның тикшерү органнары тарафыннан җинаять эшләре кузгатылмаган нигезләре анализлана.

2011 елда түбәндәгеләр ачыкланды:

– урман законнарын бозуның 796 очрагы, зыян – 2982,5 мең сум, шул исәптән законсыз кисүләрнең 459 очрагы, зыян – 1746,93 мең сум;

– 1612,9 мең сум акча ихтыярый кире кайтарылды, шул исәптән 669 мең сум – законсыз кисүләр өчен;

– 41 эш тикшерү органнарына тапшырылды;

– 21 хокук бозучы җинаять җаваплылыгына тартылды;

– 1019,0 мең сум күләмендә административ штраф салынды.

2012 елда түбәндәгеләр ачыкланды:

– урман турындагы законнарны бозуның 945 очрагы, зыян – 2356,2 мең сум, шул исәптән законсыз кисүләрнең 451 очрагы, зыян – 1739,06 мең сум;

–1816,6 мең сум акча ихтыярый кире кайтарылды, шул исәптән 1342,6 мең сум – законсыз кисүләр өчен;

– 35 эш тикшерү органнарына тапшырылды;

– 19 хокук бозучы җинаять җаваплылыгына тартылды;

– 1714,8 мең сум күләмендә административ штраф салынды.

## Урман хуҗалыгында геомәгълүмат системалары

Мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән киң масштаблы файдалану, Татарстан Республикасында дәүләт идарәсе һәм муниципаль идарә системасының нәтиҗәлелеген арттыру, дәүләт хезмәтләреннән гражданнарның һәм оешмаларның файдалана алуы һәм аларның сыйфатлы булуы, шулай ук мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану нигезендә дәүләт хакимияте органнарының ачыклыгы юлы белән Татарстан Республикасы халкының тормыш сыйфатын яхшырту максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан 2008 елның 17 июлендә 513 номерлы «Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү һәм алардан файдалану (2008–2010 елларга «Электрон Татарстан») республика максатчан программасы турында» карары кабул ителде.

Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт хакимияте органнарының үзара нәтиҗәле эшчәнлеген оештыру кысаларында түбәндәгеләр төзелде:

– дәүләт учреждениеләрен бердәм челтәргә тоташтырырга мөмкинлек бирә торган интеграцияләнгән дәүләт телекоммуникацияләр системасы;

– электрон документ әйләнешенең ведомствоара системасы;

– Татарстан Республикасы Хөкүмәте порталы һәм республиканың дәүләт хакимияте органнары сайтлары;

– республика дәүләт хакимияте органнарының видеоконференция элемтәсе системасы.

Программада Татарстан Республикасын мәгълүматлаштыру юллары гамәлгә ашырыла, ул дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең сервис-ориентлашу моделен төзүгә юнәлдерелгән, мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын арттыру электрон үсешнең төп максаты булып тора.

### 2.4.4. Урманнарны нәтиҗәле үзләштерү өлкәсендә эшчәнлекнең башка юнәлешләре һәм чаралары

Татарстан Республикасында урманнардан файдалануның төп төрләреннән тыш эшчәнлекнең түбәндәге юнәлешләре башкарыла:

– жир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар күпләп таралган урыннарын табу;

– сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары, шулай ук гидротехник корылмалар һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм аларны эксплуатацияләү;

– электр тапшыру линияләрен, элемтә линияләрен, юлларны, торбаүткәргечләрне һәм башка линияле объектларны төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм файдалы казылмаларны табу процессында нефть, газ, комлыклар һәм балчык запаслары тикшерелә һәм ачыклана, шулай ук аларны чыгару чаралары оештырыла.

Ясалма су объектлары һәм гидротехник корылмалар төзелеше өчен урманнардан файдалану сулыклар (шул исәптән янгынга каршы һәм хуҗалык билгеләнешендәге), күперләр, портлар һәм башка корылмалар төзүдән гыйбарәт.

Линияле объектлар төзү өчен урман хуҗалыгы юллары, янгынга каршы юллар, гомуми файдалану юллары, торбаүткәргечләр, ЛЭП һәм элемтә линияләре төзелә.

Эшчәнлекнең югарыда санап кителгән төрләре өчен урман кишәрлекләре гражданнарга һәм юридик затларга 1 елдан 49 елга кадәр чорга файдалануга (арендага) бирелә. Урман утыртмаларын кисү, шулай ук урман инфраструктурасын булдыруга бәйле булмаган төзелеш, реконструкция һәм объектларны эксплутацияләү урманнарны үзләштерү проекты нигезендә эшләнергә тиеш.

Татарстан Республикасы территориясендә урман планы гамәлдә булган чорда эшчәнлекнең әлеге төрләре өчен урманнарны үзләштерүгә 2,0 мең га урман җирләрен бүлеп бирү планлаштырыла.

Республика территориясендә хәзерге вакытта урманнардан рекреация максатларында файдалану буенча актив эш алып барыла, шулай ук фәнни-тикшеренү һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану юнәлеше дә үзләштерелә башлады.

Фәнни-тикшеренү эшчәнлеге урманның экологик системасы турында яңа мәгълүматлар алуга, бу мәгълүматлардан гамәли максатларга ирешү һәм урманнардан файдалану, аларны яклау һәм торгызу өлкәсендә нинди дә булса мәсьәләне чишү өчен куллануга юнәлдерелгән эксперименталь яисә теоретик эшчәнлектән гыйбарәт.

Белем бирү эшчәнлегенә белем алучыларның урманнарны, табигатьнең башка компонентларын, кирәкле урман инфраструктурасы объектларын өйрәнү, алардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызу өлкәсендәге махсус белемнәрен һәм күнекмәләрен ныгыту өчен уку-тәҗрибә базалары (полигоннар, урман табигатен өйрәнү, урман таксациясе, урман утыртмаларын кисү, урманнарны торгызу, саклау,

яклау, үрчетү эшләре ысулларын үзләштерү өчен тәҗрибә мәйданчыклары) булдыру һәм алардан урман кишәрлекләрендә файдалану керә. Фәнни-тикшеренү һәм белем бирү эшчәнлеге өчен урманнардан файдалану урманчылыкның (урман-паркның) урман хуҗалыгы регламенты һәм урманнарны үзләштерү проекты нигезендә алып барыла.

Татарстан Республикасы территориясендә яшь буынга экологик белем һәм тәрбия бирү юнәлешендә шактый эшләр башкарыла. Экология-натуралистика эшенең инициаторы – Республика экология-биология үзәге (РЭБЦ). РЭБЦ эшчәнлегенең бер юнәлеше булып мәктәп укучыларының хезмәт берләшмәләре белән, шул исәптән мәктәп урманчылыклары белән хезмәттәшлек итү тора.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында 100гә якын мәктәп урманчылыгы бар. Алар нигездә урман хуҗалыгы (урман культураларын утырту һәм үстерү), табигатьне саклау (урманнарны янгыннардан саклау, дару үләннәре җыю, аларның таралу ареалын ачыклау); урман хуҗалыгы, урман экологиясе өлкәсендә уку-тикшеренү эшчәнлеге, экологик мониторинг; экологик агарту эшчәнлеге (урман хакында гыйлемнәрне ММЧ аша тарату, урман массивларында уку-укыту сукмаклары булдыру) белән шөгыльләнә. Мәктәп урманчылыкларының урман хуҗалыклары тормышында катнашуы аларның актив эшчәнлеге нәтиҗәсе булып тора, РЭБЦ яшь урманчылар белән шөгыльләнә торган педагоглар белән эшли, мәктәп урманчылыклары өчен даими рәвештә республика семинарлары оештыра.

Киләчәктә Татарстан Республикасы территориясендә урманнардан фәнни-тикшеренү һәм белем бирү максатларында файдалануны тагын да арттыру күздә тотыла.

## 2.5. Урманнарны саклау, торгызу һәм урман үрчетү эшчәнлегенең төп юнәлешләре һәм чаралары исемлеге

### 2.5.1. Урманнарны саклау буенча планлаштырыла торган чаралар

Россия Федерациясе Урман кодексы (51 ст.) нигезендә урманнар янгыннардан, пычранудан (шул исәптән радиоактив матдәләр белән) һәм башка төрле тискәре йогынтылардан сакланырга, шулай ук зарарлы организмнардан сакланырга тиеш. Урманнарны саклау буенча чаралар системасы эшләнгән, ул вазгыятьне тикшереп торырга һәм урманга тискәре йогынтыны бетерү һәм юкка чыгару буенча оператив чаралар күрергә, шул исәптән янгын куркынычын, урманнар авыруларын белеп торырга һәм урманнарга зыян салудан саклауны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында урманнарны саклау системасы эшли, ул урман янгыннарын үз вакытында күреп алырга һәм оператив рәвештә сүндерергә, башка төрле тискәре йогынтыларга, шул исәптән урманнарга зыян салуга каршы торырга мөмкинлек бирә. Урман турындагы законнар үзгәрүгә бәйле рәвештә бу системада тиешле модификацияләр булды, алар эшнең нәтиҗәлелегенә тискәре йогынты ясарга тиеш түгел.

Россия Федерациясе Урман кодексы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 30 июнендәге 417 номерлы карары белән расланган «Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре» нигезендә җаваплылык зоналары Татарстан

Республикасы министрлыклары, ведомстволары һәм оешмалары арасында катгый бүленгән.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы федераль милектәге урман җирләрендә урнашкан урманнарда янгынга каршы чаралар күрүне һәм урманнарны саклау эшен башкаруны оештыра.

ДКУ – урманчылыклар урманнарны саклау чараларының үтәлешен тикшереп тора һәм янгынга каршы пропаганда, янгын куркынычын мониторинглау белән шөгыльләнә.

«Түбән Кама» милли паркы, шәһәр эчендәге урманнары булган шәһәрләрнең муниципаль районнары администрацияләре, урман кишәрлекләрен арендага алучылар үзләре мөстәкыйль рәвештә урманнарны саклау чараларын үткәрәләр һәм үз территорияләрендә урман янгыннарын күреп алу һәм сүндерү эшләрен башкаралар.

Урман фондының арендага тапшырылмаган урманнарында Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы белән контракт нигезендә «Урман» дәүләт бюджет учреждениеләре саклау чаралары үткәрәләр, алар бу урманнарда янгынга каршы химия станцияләре көчләре белән, кирәк булганда, Урман янгыннарын сүндерү планы нигезендә өстәмә көчләрдән дә файдаланып, урман янгыннарын сүндерәләр. Киләчәктә урманнарны саклауның гамәлдәге системасын камилләштерү һәм түбәндәге юнәлештә чаралар оештыру планлаштырыла:

профилактика;

– чикләү;

– тискәре йогынтыны, шул исәптән урман янгыннары китергән зыянны бетерү буенча;

– урманнарны янгыннардан саклау буенча.

Урманнарны янгыннардан саклау чараларын үтәү максатларында, янгын куркынычы зур булган чор башланыр алдыннан әзерләнү эшләре үткәрелә, алар янгынга каршы кисәтү чаралары күләмен планлаштырудан башлана.

Янгынга каршы кисәтү чараларының урман планы гамәлдә булган чор өчен планлаштырыла торган күләмнәре 15 нче кушымтада бирелә.

Урманнарны янгыннардан саклау буенча уртак эшләрне оештыру, урман янгыннарына гаепле затларны һәм урман турындагы законнарны башкача бозучыларны оператив рәвештә табу өчен «Республиканың Урман хуҗалыгы министрлыгы, Россия Федерациясе Граждан оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Табигатьтән файдалану өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәте идарәсе арасында урман янгыннарын кисәтү, сүндерү, гаепле затларны ачыклау һәм Россия Федерациясе урманнарында янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозуларны булдырмау өлкәсендә үзара эшчәнлек турында килешү» төзелә.

Урман янгыннарын оператив сүндерү максатларында урман янгыннарын сүндерү планнары һәм Татарстан Республикасы территориясендә урман янгыннарын сүндерүнең җыелма планы эшләнә, алар буенча, кирәк булганда, өстәмә көчләр һәм чаралар җәлеп ителә. Урманнарны янгыннардан саклау буенча авиация ярдәмендә патрульлек итүгә конкурс нигезендә шартнамә төзелә. Янгынга

каршы химия станцияләренең махсус җайланмалары булу һәм аларның төзеклеге, янгын сүндерү командаларының тулы булуы, радиостанцияләрнең булуы һәм төзеклеге тикшерелә, урманнарны саклау зоналары ачыклана, авиация ярдәмендә патрульлек итү маршрутлары эшләнә.

Авиация ярдәмендә патрульлек итү урман янгыннарын күреп алу өчен генә планлаштырыла, чөнки гамәлдәге юллар челтәре янгын сүндерү командаларын барлык урман кишәрлекләренә кадәр җир транспортында алып барырга мөмкинлек бирә. Авиазона территориясе зур булмаганлыктан, янгынга каршы авиация командаларын тоту икътисадый яктан максатка ярашлы түгел. Янгын сүндерү өчен җайланмалар һәм янгын сүндерү командаларын илтү зарурлыгы булганда МИ-8 вертолетыннан файдаланырга мөмкин. Территорияне күзәтеп тору өчен республикада патрульлек итү маршрутлары эшләнде.

Территорияне урман янгыннарын күреп алу һәм сүндерү алымнары буенча бүлү, урманнарда янгын куркынычсызлыгы чаралары

Татарстан Республикасы территориясендә 3 нче дәрәҗәдәге табигый янгын куркынычлылыгы өстенлек итә.

Янгын чыгу куркынычы зур булган чорда урман янгыннарын үз вакытында күреп алу өченҗирдән һәм авиация ярдәмендә патрульлек итү оештырыла. Авиация ярдәмендә патрульлек итү Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2012 елның 30 ноябрендәге 601-төп номерлы боерыгы нигезендә 3 маршрут буенча үткәрелә:

1 нче маршрут 331 км озынлыкта, ул Казан – Әтнә – Балтач – Байлар Сабасы – Лаеш –Куралово – Казан торак пунктлары аша үтә;

2 нче маршрут 681 кмозынлыкта, Казан –Әтнә – Балтач – Мамадыш – Алабуга – Яңа Зәй– Алексеевск – Тәтеш – Апас – Лаеш – Питрәч – Казан торак пунктлары аша үтә;

3 нче маршрут 844 кмозынлыкта, ул Казан –Апас – Базарлы Матак – Аксубай – Әлмәт – Бөгелмә–Азнакай – Сарман – Минзәлә – Мамадыш – Арча – Казан торак пунктлары аша үтә.

Җирдән патрульлек итү янгын куркынычы зур булган урман кишәрлекләрендә алдан эшләнгән маршрут буенча транспорт чарасы ярдәмендә яисә җәяү үткәрелә.

Җирдән патрульлек итүнең гомуми озынлыгы 14495 км булган 317 маршруты эшләнгән.

Россия урман хуҗалыгының«Урман фонды җирләрен урманнарда янгын куркынычын мониторинглау алымнары һәм урманнарны саклау буенча авиация эшләрен башкару зоналары буенча бүлү турында» 2009 елның 9 июлендәге 290 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы боерыгы нигезендә җирдән мониторинглау зонасы 600.0 га, һавадан мониторинглау зонасы 1235800,0 га итеп бүленгән.

Урманнарда янгыннарга каршы профилактик эш урман янгыннары килеп чыгуны кисәтүгә, аларның таралуын чикләүгә һәм алар белән уңышлы көрәшүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын уздыруны күздә тота.

Транспорт чараларын һәм урман янгыннарын сүндерү чараларын тәртиптә тоту максатыннан, янгын сүндерү машиналарын, җиңел автомобильләр паркын, мотопомпаларны ел саен яңартып тору, җитми торган янгын сүндерү-химия станцияләрен, урманчылык контораларын төзергә кирәк. 2014 – 2018 елларда янгын сүндерү-химия станцияләре (7 бер., шул исәптән, 2 – III типтагы, 5 – II типтагы), урманчылык конторалары (2 бер.) төзү һәм янгын сүндерү машиналары (20 бер.), җиңел автомобильләр алу (30 бер.) планлаштырыла.

Урман планы гамәлдә булган чорда 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль закон белән расланган Янгын куркынычсызлыгы турында техник регламент нигезендә бакча, дача, йорт яны кишәрлекләрендәге хуҗалык һәм торак корылмаларыннан урман массивына кадәр кимендә 15 м янгынга каршы ара калдыру эшләре планлаштырыла. Урманнарны янгыннардан саклау буенча ел саен планлаштырыла торган чаралар 15 нче кушымтада бирелә.

Радиактив матдәләр белән пычрану шартларында
урманнарны саклау чаралары

Татарстан Республикасы территориясендә радиацион-экологик хәл, гомумән алганда, тотрыклы, гамма-фон дәрәҗәсе гамәлдәге санитария нормаларыннан артык түгел.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 19 апрелендәге 484-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган «2008 елга һәм 2015 елга кадәрге чорга атом-төш һәм радиация куркынычсызлыгын тәэмин итү» федераль максатчан программасы концепциясен гамәлгә ашыруга әзерләнү максатларында «В.Г. Хлопин исемендәге радий институты» НПО ФГУП белгечләре тарафыннан объектларны һәм территорияләрне дезактивацияләү һәм реабилитацияләү эшләренең кирәкле күләмен башлангыч бәяләү үткәрелде. Атом энергиясен куллану өлкәсендә эшчәнлек алып баручы республика оешмаларында (38 бер.) радиация куркынычсызлыгы нормалары һәм кагыйдәләре таләпләрен үтәү өчен кирәкле барлык җайланмалар да бар.

**2.5.2. Урманнарны саклауның планлаштырыла торган чаралары, моңа урманнарны урнашу районыннан чыгып саклау, урман патологиясен тикшерү, зарарлы организмнарны җәелдермәү һәм бетерү, санитария-чистарту чаралары керә**

Татарстан Республикасы территориясендә урман утыртмалары гөмбәчек авырулары, вируслы, бактериаль авырулар белән авырый, корткыч бөҗәкләрдән, уңай булмаган һава шартларыннан, янгыннардан зыян күрә.

Татарстан Республикасы урманнарында санитария иминлеген тәэмин итү максатларында, урманнарны урнашу районыннан чыгып саклау чаралары үткәрелде, алар урман патологиясе куркынычы аз, уртача һәм көчле булган зоналарны билгеләргә мөмкинлек бирде.

Урман фонды территориясенең урманнарны саклау районнары буенча бүленеше 2.5.3.1 нче рәсемдә бирелә.




2.5.3.1.рәс.Урманны саклау буенча

Урман патологиясе куркынычы яный торган зонаны билгеләү, урманнарның максатчан билгеләнешен, экологик һәм хуҗалык кыйммәтен исәпкә алып, аларның зарарлы организмнардан зыян күрү дәрәҗәсенә бәйле.

Урман патологиясе куркыныч яный торган һәр зона өчен урман патологиясе мониторингы үткәрүгә һәм урманнарны саклау чараларын гамәлгә ашыруга таләпләр билгеләнде, шулай ук урманнарны саклау чаралары планын эшләү өчен критерийлар ачыкланды (2.5.2.1нче таблица).

2.5.2.1 нчетаблица

**Урманчылыкларның урман патологиясе янаган зоналар буенча бүленеше**

| Көчле куркыныч яный торган зона | | Уртача дәрәҗәдәге куркыныч яный торган зона | | Аз куркыныч яный торган зона | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Әгерҗе | 9 | Болгар | 3 | Аксубай |
| 2 | Азнакай | 12 | Алабуга (Татарстан уч.урм. керми) | 4 | Әлки |
| 5 | Әлмәт | 14 | Зеленодольск | 6 | Арча |
| 7 | Баулы | 19 | Кызыл Йолдыз | 8 | Биләр |
| 10 | Бөгелмә | 20 | Лаеш | 12 | Алабуга (Татарстан уч.урм. керми) |
| 11 | Буа | 27 | Шәһәр яны | 13 | Зәй |
| 16 | Кайбыч | 30 | Чирмешән | 15 | Ары |
| 18 | Кама | | | 17 | Кәләй |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | (Чистай уч. урм. керми) | | | | |
| 21 | Лениногорск | | | 18 | Кама (Чистай уч.урм.) |
| 22 | Мамадыш | | | 25 | Нурлат |
| 23 | Минзәлә | | | 28 | Саба |
| 24 | Түбән Кама | | | | |
| 26 | Идел буе | | | | |
| 29 | Тәтеш | | | | |

Урманнарны саклау чараларының күләме һава торышы-климат шартларына, урман патологиясенә, урманнарның санитар торышына һәм башка тискәре факторларга бәйле рәвештә ел саен эшләнә.

Ылыслы агачлар күрше субъектлардан (Марий-Эл, Удмурт Республикасы, Киров өлкәсе) китерелә, агачларны эшкәртү пунктлары территорияләрендә карантин объектлары табылу (вак кара нарат мыеклачы һәм зур кара чыршы мыеклачы) шуның белән аңлатыла. Әзерләнә һәм эшкәртелә торган агач республика территориясендә файдаланыла, шуңа күрә бу корткычларның табылуы таралу куркынычы тудырмый. Урман патологиясенә элек үткәрелгән тикшерүләр вакытында бу бөҗәкләр очрамаган иде.

Бәян ителгәннәрдән һәм үткәрелгән тикшеренүләрдән чыгып карантин объектларын зарарсызландыруга һәм бетерүгә юнәлдерелгән чаралар әлегә планлаштырылмый.

2009 елга урманнарны саклау чараларының күләме 16 нчы кушымтада бирелә.

Санитария-чистарту чараларының планлаштырыла торган күләмнәре 2007 елда булган 2 давыл китергән зыяннарны исәпкә алып билгеләнде.

Урман патологиясе мониторингы (ЛПМ) – урман экосистемаларының санитар һәм урман патологиясе торышын тикшереп тору системасы, ул түбәндәгеләрне тәэмин итә:

– авыруларга каршы торучанлыгы бозылган, корткычлардан зарарланган, авыру күпләп таралган урыннары булган утыртмаларны үз вакытында ачыклауны;

– урман патологиясе вазгыятенә анализ үткәрүне;

- агачларның урман патологиясе торышын санитар фаразлауны, авыру тудыручы корткычлар һәм авыру күпләп таралган урыннары популяциясе үсешен фаразлауны;

- урманнарны саклауның нәтиҗәле чараларын планлаштыру һәм гамәлгә ашыру буенча карарлар кабул итүне.

Россия Федерациясе урманнарында урман патологиясе мониторингы үткәрү федераль башкарма хакимият органнарына йөкләнгән.

Урманны саклау буенча планлаштырыла торган чаралар күләме 16 нчы кушымтада бирелә.

### 2.5.3. Урманнарны торгызу буенча урман утырту материалын үстерү, урманнарны чистарту, шулай ук урман үрчетү гамәлләрен дә кертеп, планлаштырыла торган чаралар

Узган елларда урманнарны торгызу эшләре республика урманчылыклары территориясендә 3 алым ярдәмендә башкарылды: ясалма (урман культураларын утырту юлы белән), катнаш һәм урманнарның табигый артуына булышу юлы белән (киселгән мәйданнарның кыйммәтле токымлы агачлар, беренче чиратта чыршы һәм нарат белән каплануын тәэмин итә торган шартлар тудырып).

Киләчәктә культуралар булдыруның төп алымы урман утырту булырга тиеш (аеруча ябык тамыр системалы утырту материалларыннан файдаланып), ул үсентенең яхшырак үзләшүен һәм тизрәк үсүен тәэмин итә, бу үз чиратында культураларның тизрәк җайлашуына һәм яхшы биологик сыйфатларга ия булуына китерә.

Урман культуралары составындагы төп токымны билгеләү урман үсемлекләре үсә торган шартларны, культивацияләнә торган агач токымнарының биологик һәм товар үзлекләрен, урман утыртмасын үстерүнең максатларын истә тотып эшләнә.

Европа һәм себер карагае культураларын һәм башка интродуцентларны нигездә саклагыч урманнар үрчетелә торган урман фондында үстерергә киңәш ителә, алар өчен ком һәм җиңелчә балчык катнаш сәрин туфрак, карбонатлы токымнар (урман төрләренең төркеме – көртмәлекле һәм катнаш; урман үсемлекләре үсә торган шартларның тибы – $B_2$,$C_2$) үсә торган мәйданнар булу мөһим.

Урман типларының төп төркемнәрендә урман культураларын булдыру өчен түбәндәге төп токымнар тәкъдим ителә:

– лишайниклы, нарат җиләге һәм озын мүкленаратлыклар өчен – гади нарат;

– наратлыклар, мүк җиләге үскән чыршылыклар һәм катнаш чыршылыклар өчен – гади нарат һәм Европа чыршысы. Урман типларының бу төркемнәрендә нарат культурасы комлы, комсу, җиңелчә балчыклы туфракта $A_3$, $B_2$,$B_3$ урман шартларында, ә чыршы культуралары балчыклы туфракта $C_2$, $C_3$,$B_3$ урман шартларында үстерелә.

Хәзерге вакытта урман торгызу гамәлләре кисенделәрдә («б» һәм «в» категориясендәге мәйданнарда), яфраклы токым агачларының (усак, каен, юкә, өрәңге һ.б.) табигый артуы күзәтелә торган мәйданнарда алып барылуга бәйле рәвештә,составы ягыннан чиста нарат, чыршы, имән агачлары культураларын булдыру тәкъдим ителә. Төп токымнарның үсешен тизләтү һәм утыртмаларның судан саклагыч үзлекләрен арттыру өчен наратлыклар, катлаулы чыршылыклар тибындагы урман төркемнәрендә, «а» категорияле мәйданнарда һәм «б», «в» категорияле мәйданнарда туфракны тулысынча эшкәрткәндә, рәт арасы киңлеге 1,5 – 2,0 м булган «в» категорияле мәйданнарында катнаш нарат-чыршы, чыршы-юкә культуралары утырту тәкъдим ителә.

Тамыр губкасы күпләп таралган урыннарында катнаш нарат-каен яисә чыршы-каен культуралары утыртырга кирәк. Ылыслы агачлардан гына торган мәйданнарда янгын куркынычсызлыгын арттыру өчен утыртмалар арасына аерым рәтләр яисә полосалар итеп каен һәм яфраклы башка токым агачларын утыртырга тәкъдим ителә.

Культураларда яфраклы токымнар катнашмасының күләмен җайга салырга кирәк, бу эш, әлеге агачларның югары продуктив үсентеләр формалаштыруда

катнашуын тәэмин итеп, чистарту өчен кисүләр үткәрү юлы белән башкарылырга тиеш.

Табигый юл белән үсеп чыккан каен, юкә, өрәңге һәм башка кыйммәтле токымнар төп токым агачларын каплап китмәсә, чистарту өчен кисүләр вакытында бу яфраклы токымнар саклап калына, алар катнаш ылыслы-яфраклы утыртмалар барлыкка китерә.

Урман культураларын ябык тамыр системалы чәчкеннәр һәм үсентеләр утырту юлы белән булдырырга кирәк. Ылыслы токым культуралары өчен үсентеләр утырту чәчкеннәргә караганда нәтиҗәлерәк. Үсентеләр утырту урман культураларының тиз җайлашуын һәм интенсив үсүен тәэмин итә, бу урман утыртмаларының куелыгын җайга сала, агротехник чистартуларның санын киметергә мөмкинлек бирә.

Урман кисү җирләрендә ылыслы үсентеләрне саклап калуга игътибар бирелергә тиеш, чөнки әлеге чара токымнарның алмашуын булдырмаска, урманнарны торгызу өчен шактый акчаны янга калдырырга һәм үсентеләрне киләчәктә урманнарның нигезе буларак файдаланырга мөмкинлек бирә. Бу чара техник яктан өлгергән агач үстерү срокларын 20-30 елга киметә һәм урманның продуктивлылыгын арттыруның реаль резервы булып тора.

2018 елга кадәр урманнарны торгызу эшләренең күләме һәр урманчылык буенча билгеләнгән, бу эшләр урман үсемлекләре белән капланмаган, тоташ кисү мәйданнарында һәм кисенделәрдә, янган мәйданнарда урманнарның табигый үсеп чыгуы күз алдында тотылган җирләрне исәпкә алып башкарыла. Бу очракта кисенделәрдә, янган җирләрдә, сирәклекләрдә, аланнарда, урман үсемлекләре белән капланмаган башка җирләрдә урманнарны торгызу, ә элек урман үсмәгән җирләрдә урман үрчетү планлаштырыла.

Россия Федерациясе Урман кодексы нигезендә урманнарны торгызуны түбәндәгеләр тәэмин итәргә тиеш:

а) урман кишәрлекләрен агач әзерләү өчен арендага алган арендаторлар шул урман кишәрлекләрендә;

б) урманчылыклар барлык кишәрлекләрдә, моңа агач әзерләү өчен арендага тапшырылган кишәрлекләр керми.

Үсеп китү ихтималлыгы 25-85% булган урман культуралары янына яңаларын утыртып торырга (тулыландырырга) кирәк. Кишәрлек мәйданындагы корыган урман культуралары янына яңа үсентеләр аларның ничек җайлашуына карап утыртыла. Яңа үсентеләр белән тулыландыру, урман культураларының хәзерге торышын анализлаудан һәм сакланышыннан чыгып, мәйданның 50 процентында күздә тотыла.Тулыландыру өчен шундый ук агач токымнары файдаланыла. Тулыландыру өчен кулланыла торган утырту материалының яше бу мәйдандагы культура яшенә туры килергә тиеш.

Урман культураларының үсеп китүе һәм үсеше алга таба агротехник чараларга, аларның үз вакытында үткәрелүенә бәйле. Агротехник чаралар сирәкләндерү характерында булырга тиеш һәм вегитация чорының беренче яртысында, урман культураларын кирәкмәгән үсемлекләр каплап киткәнче башкарыла тиеш. Бу чараларның саны һәм кабатлануы үсеш шартларыннан, утырту материалының зурлыгыннан һәм үсү интенсивлыгыннан, үләннең куелыгыннан һәм

биеклегеннән тора. Комлы, комсу һәм балчыклы коры туфракта лишайниклы, көртмәлекле урман типлары (үләннәр каплап китү куркынычы булмаган җирләрдә) төркемнәрендә урман культураларын карау 4 ел дәвамында 3-4 тапкыр үткәрелергә тиеш. Катлаулы һәм кара җиләкле урман типлары төркемнәрендә урман культураларын утыртканнан соң беренче 4 елда агротехник чаралар 5-6 тапкыр үткәрелә. Мондый чараның саны һәм даимилеге һәр очракта реаль ихтыяждан чыгып башкарылырга тиеш.

Татарстан Республикасы территориясендә урманчылыклар буенча урманнарны торгызуның планлаштырылган чаралары 17, 18, 19 нчы кушымталарда бирелә.

Торгызу чыгымнарын киметү өчен урманның табигый юл белән үсү потенциалыннан мөмкин кадәр күбрәк файдаланырга, бу максатлар өчен оптималь булган кисү алымнарын һәм урманнарны торгызу чараларын сайларга кирәк. Бу чараларга түбәндәгеләр керә:

– сайлап кисүләр вакытында кыйммәтле токымнар ярдәмендә урманны даими рәвештә табигый яңарту;

– акрынлап кисүләр вакытында кыйммәтле токымнар утыртып, урманны акрынлап табигый яңарту;

– урманнарның табигый яңаруына булышлык күрсәтеп һәм урман кисүләр вакытында кыйммәтле токым үсентеләрен саклап,башлангыч табигый яңарту;

– тоташ кисүләр вакытында урманның табигый яңаруына булышлык күрсәтеп, кыйммәтле токымнарның киләчәктә табигый яңаруы;

– кыйммәтле токымнарны яңартуның башка ысуллары нәтиҗәле булмаганда урманнарны ясалма яңарту.

2014 – 2018 елларда ел саен 7669,7 га мәйданда яшь агачларны карау планлаштырыла.

Урманнарны чистарту максатыннан киселергә тиешле урман үсентеләрен билгеләү аларга ихтыяждан чыгып һәм агачлар капламының составы, ябалдашларының тоташуы, агачлар капламының тулылыгы һәм куелыгы, агач токымнарының буталу характеры, аларның биеклеге, мәйданда агачларның урнашуы һ.б билгеләр буенча билгеләнә.

Яшь агачларга хас билгеләр булып түбәндәгеләр тора: агач капламының составы, аның ябалдашларының тоташуы, мәйдандагы агач саныннан чыгып билгеләнә торган куелыгы, төп һәм икенчел токымнарның биеклеге чагыштырмасы; урта яшьләрдәге урман утыртмаларына хас билгеләр булып ябалдашларның тоташуы исәпкә алынган тулылык, агач капламының куелыгы һәм составы, төрле агач токымнары кушылу үзенчәлекләре тора.

Киләсе елларда питомник хуҗалыгын үстерү гамәлдәге урман питомникларыннан, урман питомниклары комплексларыннан нәтиҗәлерәк файдалану буенча алып барылырга тиеш. Урман питомниклары комплексларына питомниклар, урман орлыкчылыгы плантацияләре, урман орлыкчылыгы кишәрлекләре, имән чикләвеге киптерү җайланмалары, орлык саклау, утырту материаллары, ашламалар, химикатлар саклау складлары, техника саклау урыннары керә.

Урман хуҗалыгы предприятиеләренең утырту материалына ихтыяҗын тәэмин итү өчен республикада 55 питомник эшли, аларның гомуми мәйданы 448 га тәшкил итә.

Питомникларның 145,5 га мәйданыел саен планлаштырылган күләмдә ылыслы токымнарның утырту материалын үстерү өчен җитәрлек.

Утырту материалы үстерүнең еллык күләме, уртача алганда, түбәндәгечә:

– чәчкеннәр 30970 мең данә;

– үсентеләр 10973 мең данә.

2014 – 2018 елларга кадәр планлаштырыла торган чорга утырту материалынын күләме 269715 мең данә тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы күрсәтмәләре нигезендә питомниклар хуҗалык функцияләрен башкара торган «Урман» ТР ДБУ карамагында. Урман фәне таләпләренә туры килерлек дәрәҗәдә урманнарны яңарту кыйммәтле нәселдәнлек үзлекләренә һәм югары чәчүлек сыйфатларына ия булган урман токымнары орлыкларынын билгеле бер санын таләп итә, ул урман орлыкчылыгы тарафыннан тәэмин ителә.

Урман үсемлекләренең төрләре буенча орлыкларга хәзерге һәм киләчәктә таләп ителәчәк ихтыяҗ түбәндәгечә:

2.5.3.1 нче таблица

**Урман үсемлекләре төрләре буенча орлыкларга ихтыяж, кг**

| Токым | Еллар | | | | | | | | | | Гомуми күләм |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Нарат | 700 | 700 | 700 | 700 | 700 | 555 | 555 | 555 | 555 | 555 | 6275 |
| Чыршы | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 550 | 550 | 550 | 550 | 550 | 5250 |
| Карагай | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 185 | 185 | 185 | 185 | 185 | 1925 |
| Имән | 15000 | 15000 | 15000 | 15000 | 15000 | 13690 | 13690 | 13690 | 13690 | 13690 | 143450 |
| Юкә | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 185 | 185 | 185 | 185 | 185 | 1925 |
| Корычагач | 250 | 250 | 250 | 250 | 250 | 222 | 222 | 222 | 222 | 222 | 2360 |
| Каен | 2500 | 2500 | 2500 | 2500 | 2500 | 2220 | 2220 | 2220 | 2220 | 2220 | 23600 |
| Сары сәрви | 400 | 400 | 400 | 400 | 400 | 370 | 370 | 370 | 370 | 370 | 3850 |
| Миләш | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 185 | 185 | 185 | 185 | 185 | 1925 |
| Алмагач | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 45 | 45 | 45 | 45 | 45 | 475 |
| Слива | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 93 | 93 | 93 | 93 | 93 | 965 |
| Чия | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 93 | 93 | 93 | 93 | 93 | 965 |
| Вак гөләп | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 107 | 107 | 107 | 107 | 107 | 1535 |
| Барлыгы | 20400 | 20400 | 20400 | 20400 | 20400 | 18500 | 18500 | 18500 | 18500 | 18500 | 194500 |

Ылыслылар токымына керә торган агачларның орлык бирүе чорларга бүленгән булуы белән аерылып тора, мәсәлән, Татарстан Республикасында Европа чыршысы һәм гади нарат орлыгы 3 – 5 елга бер тапкыр өлгерә. Әлеге үзенчәлекне истә тотып, урман үсемлекләре орлыгын өлгергән елда запаста булганнарын

исәпләп һәм орлык булмаган елларда чәчү өчен таләп ителә торган күләмнән чыгып әзерләү планлаштырыла. Узган чорның орлык өлгергән елларын (2003, 2007 еллар) исәпкә алганда, урман планы гамәлдә булган чорда 2015, 2018 еллар бу яктан уңышлы булыр дип көтелә.

Урман орлыкчылыгын үстерү стратегиясе нигезендә урманнарны торгызу өчен районнарга яраклаштырылган югары сыйфатлы орлыклар белән гарантияле тәэмин итү өчен түбәндәгеләр планлаштырыла:

нәселдәнлек үзлекләре яхшыртылган орлыклар процентын орлык әзерләүнең гомуми күләмендә арттыра бару;

урманнарны торгызганда яхшыртылган, сортлы һәм нормаль урман үсемлекләре орлыкларын утырту.

Урман орлыкчылыгы объектларын булдыру, формалаштыру, карап тоту һәм алардан файдалану буенча планлаштырыла торган чаралар
(шул исәптән агротехник чистартулар һәм урманнарны чистарту өчен кисүләр үткәрү, кирәкле агачларны һәм утыртмаларны сайлап алу һәм аттестацияләү буенча, урман орлыкчылыгы объектларын саклауны һәм яклауны тәэмин итү буенча, урман үсемлекләре орлыкларын әзерләү, шул исәптән орлыклар запасын һәм нәселдәнлек үзлекләре яхшыртылган орлыкларны булдыру буенча чаралар)

2013 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында:

–1251,2 га даими урман орлыкчылыгы кишәрлекләре;

–48,9 га урман орлыкчылыгы плантацияләре;

–390,7 га плюслы утыртмалар;

– 508 данә плюслы агач бар.

Урман орлыкчылыгын үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру максатында Татарстанда урман орлыкчылыгы плантацияләре, даими урман орлыкчылыгы кишәрлекләре булдыру күздә тотыла.

Даими урман орлыкчылыгы кишәрлекләрен булдыру өчен урман эшләре үткәргән вакытта орлыктан үстерелгән яисә килеп чыгышы билгеле урман культураларының табигый утыртмалары үскән югары продуктив һәм югары сыйфатлы кишәрлекләрне сайлап алу планлаштырыла.

Беренче чираттагы ЛСП булдыру өчен урман эшләре вакытында җитештерүчәнлеге кимендә II-III бонитет классына, дренажлы яхшы туфракка ия, тигез рельефлы туңмый торган җирдә урнашкан, машиналар һәм механизмнар белән керү юллары тәртиптә булган урман фонды кишәрлеген сайлап алу планлаштырыла.

ЛСП булдыру өчен ОСТ 56-74-96 таләпләренә туры килә торган проект эшләргә кирәк.

Урман орлыкчылыгы объектларының максималь сакланышын тәэмин итү өчен урман планын гамәлгә ашыру барышында урман орлыкчылыгының гамәлдәге һәм яңа төзелә торган объектларына агротехник һәм урманчылык эше чараларын үз вакытында үткәрергә кирәк.

Плюслы агачларны карап тоту тирә-юньдә агач кәүсәсенең үсүенә һәм тармаклануына комачаулый торган тискәре факторларны бетерүдән гыйбарәт.

Сынау культураларында һәм географик культураларда санитар-чистарту чаралары үткәрергә кирәк.

Гамәлдәге һәм яңа төзелә торган орлыкчылык объектларында (ЛПС һәм ПЛСУ) әлеге объектларны булдыру һәм алардан файдалану срогы дәвамында чистарту, янгыннардан саклау, корткычлардан һәм авырулардан яклау буенча агротехник һәм профилактик чаралар үткәрергә кирәк.

Республикада урман орлыкчылыгы плантацияләре белән бергә урман орлыкчылыгының башка кыйммәтле объектлары да бар. Болар – сынау культуралары, географик культуралар, клоннар архивлары. Бу объектлар житештерү ягыннан гына түгел, фәнни яктан да кызыклы. Кызганычка каршы, соңгы елларда чыршының күп сынау культуралары кибә. Бу 2010 елгы корылык аркасында килеп чыккан вазгыять («Арча урманчылыгы» ТР ДКУ).

Татарстан Республикасы территориясендә урманчылыклар буенча урман орлыкчылыгы объектларын булдыру, формалаштыру, карап тоту һәм алардан файдалану күләмнәре 17 нче, 19 нчы кушымталарда бирелә.

Урман үсемлекләре орлыкларының иминият фондын булдыру өчен орлыклар әзерләү күләме

Татарстан Республикасында урман үсемлекләре орлыкларының иминият фонды юк.

Иминият фонды формалаштыру өчен орлыклар әзерләүнең планлаштырыла торган күләме урманчылыкларның аерым бер агач токымы орлыкларына еллык ихтыяжыннан чыгып, агачларның орлыгы өлгерү дәвамлылыгын истә тотып уртача билгеләнә (2.5.3.2 нче таблица).

2.5.3.2 нче таблица

**Иминият фонды орлыклары күләме**

| Чор | Барлыгы орлык, кг | шул исәптән, | |
|---|---|---|---|
| | | нарат | чыршы |
| 2008-2011 еллар | 2000 | 1200 | 800 |
| 2012-2015 еллар | 2000 | 1200 | 800 |
| 2016-2018 еллар | 2000 | 1200 | 800 |

Урман орлыкчылыгы объектларын саклауның һәм алардан файдалануның кирәкле режимын тәэмин итү чаралары, шул исәптән аларны аеруча саклана торган урман кишәрлекләренә кертү

Урман орлыкчылыгы объектлары норматив-методик документлар, Россия Федерациясендә урман орлыкчылыгы буенча күрсәтмәләр нигезендә рәсмиләштерелгән булырга һәм катгый сакланырга тиеш. Урман орлыкчылыгы объектларын саклау, шулай ук аларны формалаштыру, чистарту, карап тоту һәм алардан файдалану эшләрен сыйфатлы һәм үз вакытында үткәрү өчен дәүләт бюджет учреждениеләре – урманчылыклар җаваплы.

Урман эшләре үткәргән вакытта селекция-орлыкчылык, шулай ук урман хуҗалыгын алып баруның һәм урман фондыннан файдалануның кирәкле режимын тәэмин итә торган яклану категориясенә кертелмәгән плюслы агачлар булган таксация кишәрлекләре аеруча саклана торган кишәрлекләрдән бүлеп бирелергә тиеш, монда өлгергән, озак үскән утыртмаларны кисү, нарат чәере, икенчел урман ресурслары, агач соклары, техник чимал җыю һәм терлек көтү тыелырга тиеш.

Урман орлыкчылыгы буенча эшләрнең нәтиҗәлелеген арттыру, урман орлыкчылыгының даими базасын үстерү, нәселдәнлек үзлекләре яхшыртылган утырту материалын үстерү күләмнәрен һәм орлык әзерләүне арттыру максатларында түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

– урман орлыкчылыгының даими базасы объектларыннан орлыкларны ел саен һәм тулысынча җыюны оештыру;

– селекциянең куллану мөмкинлеге зур булган ысулларын: урман орлыкларын сортларга аеруны һәм чистартуны, утырту материалын сортларга бүлүне гамәлгә кертү;

– контрольне көчәйтү һәм селекция кыйммәте түбән булган утыртмалардан орлыклар җыярга рөхсәт итмәү;

– урман орлыкчылыгы базасы объектларының җитештерүчәнлеген һәм алардан файдалану срокларын арттыру максатларында гамәлдәге объектларны үз вакытында карап тоту.

## 2.6. Урман һәм урман эшкәртү инфраструктурасы үсеше күрсәткечләре

Урман инфраструктурасын һәм урман эшкәртү инфраструктурасын, урманнардан файдалануның төрле төрләре өчен үзләштерүне һәм перспективаларны исәпкә алып, планлаштырылган үстерү

Урман һәм урман эшкәртү инфраструктурасын үстерү турыдан-туры юллар челтәренең сыйфатына һәм торышына бәйле. Җитештерүнең начар техник тәэмин ителеше, төп капиталга инвестицияләрнең аз булуы белән бергә ел әйләнәсенә йөрерлек урман юлларының җитәрлек дәрәҗәдә булмавы да урман сәнәгате үсешен тоткарлый торган төп факторларның берсе булып тора. Урман хуҗалыгының һәм урман сәнәгатенең нормаль эшләве өчен 1000 га урманнарга 7 – 12 км юллар кирәк. Татарстан Республикасы урманчылыкларының күбесендә юлларның факттагы

озынлыгы таләпләргә туры килә, шулай да ел әйләнәсенә йөрү мөмкинлеге булган юлларга ихтыяҗ бар.

Урман кишәрлекләреннән икътисадый файда алуны, агач әзерләүнең рентабельле булуын ел әйләнәсенә йөрерлек урман юллары төзү юлы белән арттыру күздә тотыла торган урман транспорты инфраструктурасын үстерү, урманнардан файдалану күләмен шактый арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы предприятиеләрендә агач ташу өчен файдаланыла торган автомобиль юллары 2.6.1 нче таблицада күрсәтелде.

2.6.1 нче таблица

**Юллар озынлыгы**

| Т/с | Урманчылык | Автомобиль юллары озынлыгы, км | | | | 1000 гектар урман фондына юллар озынлыгы, км |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | каты өслекле | грунтлы | ел буе йөрерлек | |
| 1 | Әгерҗе | 275 | 2 | 273 | 27 | 6,0 |
| 2 | Азнакай | 144 | 6 | 138 | 21 | 3,2 |
| 3 | Аксубай | 218 | 1 | 217 | 9 | 7,4 |
| 4 | Әлки | 186 | - | 186 | 44 | 5,0 |
| 5 | Әлмәт | 148 | 6 | 142 | 21 | 3,0 |
| 6 | Арча | 237 | 1 | 236 | 14 | 7,4 |
| 7 | Баулы | 186 | 52 | 134 | 59 | 8,1 |
| 8 | Биләр | 324 | 3 | 322 | 186 | 6,4 |
| 9 | Болгар | 147 | 2 | 125 | 125 | 3,0 |
| 10 | Бөгелмә | 251 | 17 | 234 | 41 | 8,2 |
| 11 | Буа | 146 | 5 | 141 | 139 | 3,0 |
| 12 | Алабуга | 918 | 64 | 854 | 657 | 33,1 |
| 13 | Зәй | 327 | 12 | 315 | 76 | 5,0 |
| 14 | Зеленодольск | 216 | 15 | 201 | 41 | 8,2 |
| 15 | Ары | 131 | 13 | 118 | 10 | 7,7 |
| 16 | Кайбыч | 180 | - | 180 | 32 | 7,2 |
| 17 | Кәләй | 245 | 12 | 233 | - | 6,0 |
| 18 | Кама | 562 | 10 | 552 | 304 | 10,4 |
| 19 | Кызыл Йолдыз | 331 | 17 | 314 | 89 | 10,8 |
| 20 | Лаеш | 291 | 12 | 279 | 188 | 6,4 |

| Т/с | Урманчылык | Автомобиль юллары озынлыгы, км | | | | 1000 гектар урман фондына юллар озынлыгы, км |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | каты өслекле | грунтлы | ел буе йөрерлек | |
| 21 | Лениногорск | 357 | 14 | 343 | 30 | 6,8 |
| 22 | Мамадыш | 424 | 21 | 403 | 259 | 8,6 |
| 23 | Минзәлә | 343 | 5 | 338 | 67 | 4,8 |
| 24 | Түбән Кама | 367 | 15 | 352 | 139 | 8,0 |
| 25 | Нурлат | 803 | 17 | 786 | 91 | 9,1 |
| 26 | Идел буе | 144 | 6 | 138 | 3 | 5,0 |
| 27 | Шәһәр яны | 174 | 1 | 173 | 2 | 7,1 |
| 28 | Саба | 436 | 21 | 415 | 131 | 7,2 |
| 29 | Тәтеш | 187 | 2 | 185 | 45 | 4,8 |
| 30 | Чирмешән | 226 | 3 | 223 | 48 | 6,0 |
| Барлыгы | | 8924 | 355 | 8550 | 2898 | 6,9 |

–барлыгы – 8924 км;
– грунтлы – 8550 км;
–ел буе йөрерлек – 2898 км.

Урманчылыклар территорияләрендә урнашкан транспорт юлларына характеристика 1.2 бүлектә бирелде. Урман хуҗалыгы чараларын үз вакытында һәм сыйфатлы үткәрү һәм әзерләнгән агачны чыгару өчен өстәмә рәвештә грунтлы юллар төзү таләп ителә. Урманнардан файдаланучыларның үзләренә беркетелгән базалар территорияләрендә төзегән урман ташу буенча махсуслашкан юлларның кайберләре районнар әһәмиятендәге юллар базасында төзелгән, алар урманнардан агачны республика әһәмиятендәге автомобиль юлларына чыгару һәм эшкәртү өчен түбән складларга илтү максатларында файдаланыла. Санап үтелгән юллардан тыш агач чыгару өчен өлешчә авыл юллары һәм урман юллары да файдаланыла. Бу юллар гомуми файдалану юлларына килеп тоташа.

Юлларның күпчелеге урманчылыклар тарафыннан урман хуҗалыгы эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә файдаланыла һәм зур әһәмияткә ия. Барлык урманчылыкларда киңлеге 6 – 20 м булган үтеп йөрү юллары бар, алар янгынга каршы чара булып тора һәм чистарту өчен киселгән агачларны чыгару, урманнарны торгызу эшләре вакытында утырту материалларын ташу өчен хезмәт итә.

Урман планында гомуми озынлыгы 150 км булган төрле билгеләнештәге юллар төзү карала (төзү күләмнәре 2.6.2 нче таблицада бирелә).

2.6.2 нчетаблица

**Агач әзерләүнең сезонлы булуын киметү, техника кулллануны һәм урман хуҗалыгы эшләрен яхшырту өчен ел буе йөрерлек юллар төзү планы**

| Юл урнашкан урын | Юлның башы-ахыры (урнашуы) | Озынлыгы, км |
|---|---|---|
| Арча урманчылыгының Сорнар һәм Тукай уч.урманчылыклары | Ашытбаш – Иштуган | 50 |
| Кама урманчылыгынын Кама буе һәм Шомбыт уч. урманчылыклары | Мельничный Починок –Кама урман хуҗалыгы | 25 |
| Лаеш урманчылыгының Питрәч һәм Янтык уч. урманчылыклары | Питрәч – Державино | 25 |
| Кече һәм Олы Чирмешән елгалары арасындагы район | Юхмачи – Мамык | 45 |
| Шәһәр яны урманчылыгының Матюшино уч. урманчылыгы | 9кв., 29-30 кишәрлекләр, 14 кв, 32 киш., кв. 15, 23 киш., кв. 16, 30 киш. | 5 |
| БАРЛЫГЫ | | 150 |

Урман складлары урман эшкәртү инфраструктурасы объектлары булып тора. Алар йомры агачларны вакытлыча саклау һәм беренчел эшкәртү өчен, өлешчә эшкәртү һәм кулланучыларга продукция төяп җибәрү өчен каралган. Урман складлары технологик процесс буенча югары һәм түбән складларга бүленә.

Югары складлар урман кисенделәрендә, урман ташу юлына якын җиргә урнаштырыла, алар гадәттә урман ташу транспортыннан агачларны яисә юкә кайрыларын төяп җибәрү мәйданы буларак хезмәт итә, мондый складлар гадәттә 1-2 ай эшли.

Агач эшкәртү буенча барлык технологик операцияләр түбән складларда башкарыла, алар урман ташу юлларының соңгы пунктында оештырыла. Бу складларның гамәлдә булу срогы һәм җитештерүнең зур күләмдә булуы, складларда башкарыла торган җитештерү процессларын комплекслы механизацияләштерергә һәм автоматлаштырырга мөмкинлек бирә. Эшкә яраклы агач күләмен арттыру һәм йомры килеш агач ташуларның файдасызлыгын киметү өчен түбән урман складларында беренче эшкәртү белән бергә агач кисү цехлары да оештырыла һәм сыйфаты түбән булган агачларны һәм калдыкларны эшкәртү гамәлгә ашырыла.

Урман комплексын модернизацияләү өчен республикада урман инфраструктурасы һәм урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын төзү һәм реконструкцияләү күздә тотыла. Әлеге мәгълүмат 20 нче кушымтада бирелә.

### 2.7. Урманнарга антропоген, рекреакцион һәм техноген йөкләнешне киметүнең максатчан күрсәткечләре

#### 2.7.1. Урманнарның табигый мохитендә рекреация йөкләнешенең, пычратучы матдәләр концентрациясенең рөхсәт ителә торган чик күрсәткечләре

Рекреация сәламәтлекне һәм хезмәткә сәләтне торактан читтә – табигатьтә, турист буларак ял итү юлы белән торгызу ул. Ял итү урыннары буларак еш кына урман җирләре – урман читләре, аланнар, ачыклыклар, су буйлары, урман утыртмалары һәм башка кишәрлекләр сайлана. Шәһәрләргә һәм эре торак пунктларына якын урнашкан территорияләрдә ял итүчеләр аеруче күп. Кагыйдә буларак, ял итү өчен бер үк урыннар сайлана, бу үлән катлавының начараюына, агачларның һәм куакларның зарарлануына һәм юкка чыгуына, туфракның тапталуына, пычрануына китерә.

Яшел зоналарны һәм урман-паркларны проектлаганда һәм алардан файдаланганда утыртмаларның рекреацион сыйдырышлылыгы урман тибы төркемнәре буенча (2.7.1.1 нче таблица), өстенлекле токымның аерым бер яшьтәге агачларын истә тотып (2.7.1.2 нче таблица) һәм дигрессия нормалары һәм шкаласы нигезендә башкарыла.

2.7.1.1 нче таблица

